

# Казан утлары

9.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**1987**

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

М. ШАБАЕВ. **Ачыктан-ачык.** *Публицистик поэма* . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Г. КАШАПОВ. **Лачын кошка күкләр кадерле.** *Повесть.* . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Ф. БӘЙРӘМОВА. **Күл балыгы.** *Поэма-фантазия* 65

НУРИ АРСЛАНОВКА 75 ЯШЬ

Н. АРСЛАНОВ. **Тукайга.** *Шигырьләр* . . . . . 79

ЗӘЕТ МӘҖИТОВКА 60 ЯШЬ

З. МӘҖИТОВ. **Төрле еллардан.** *Шигырьләр* . . 85

НИКОЛАЙ БЕЛЯЕВКА 50 ЯШЬ

Н. БЕЛЯЕВ. **Рәхмәт сиңа, язмыш!** *Шигырьләр* 89

Ә. ГАФФАР. **Яшиселәр алда иде әле.** *Повесть* . . 92
Р. МИРХӘЙДӘРОВ. **Оренбур шәле.** *Хикәя* . . . 130

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. А. ОФИЦЕРОВ. **Иделнең текә ярында** *(Тәтеш районы)* . . . . . . . . . . . . . . . . 137

АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

Э. ШӘРИФУЛЛИНА. **Кабатланмас шәхес өчен** 140

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Ф. ЛАТЫЙПОВ. **«Дошман», «Демон» һәм башкалар** . . . . . . . . . . . . . . . 145

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. **Тарих һәм шагыйрь** . . . . 155

ВИБЛИОГРАФИЯ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Танышу дәвам итә** . . . . 163

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. **Ул кабызган утлар һаман янар** . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Б. ГЫЙЗЗӘТ. **Яңа сәнгать өчен көрәштә** . . . . 171
Р. ИШМОРАТ. **Дустым һәм остазымны сагынып** 177

*

**Бер сорауга — бер җавап** . . . . . . . . . 179

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

**З. МӨХӘММӘТҖАНОВА. Җәүдәт Фәйзи туган йорт** . . . 182
**Җ. МИҢНУЛЛИН. Оренбургның моңлы егете** 183

ЮБИЛЕЙЛАР

**Ф. ГАНИЕВА. Иөз яшьлекләр буыныннан Мәхмүт Галәү** . . . 184

«КАЗАН УТЛАРЫ» — 1988 ЕЛДА

**Гашыйк булу бәласе** . . . 187
**Безне кайда күпме укыйлар** . . . 188

**Культура тормышы көндәлеге** . . . 190
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Публицистическая поэма М. ШАБАЕВА. Повесть Г. КАШАПОВА «Сокол небом дорожит». Поэма-фантазия Ф. БАЙРАМОВОЙ «Озерная рыба». Повесть А. ГАФФАРА «Жизнь осталась впереди». Рассказ Р. МИРХАЙДАРОВА «Оренбургский пуховый платок». Стихи Н. АРСЛАНОВА, З. МАЗИТОВА, Н. БЕЛЯЕВА.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» — статья первого секретаря Тетюшского РК КПСС М. ОФИЦЕРОВА.
В рубрике «АЭС — литературный пост» — статья Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Наша мораль» — очерк Ф. ЛАТЫПОВА.
«Литературная критика» — статья Т. ГАЛИУЛЛИНА «История и поэт».
«Библиография»: рецензия Ф. ГАЛИМУЛЛИНА на книгу Г. Ахунова «Дочь Волги».
К 100-летию К. Тинчурина: статьи А. АХМАДУЛЛИНА, Б. ГИЗЗАТА, Р. ИШМУРАТА, интервью артистов театра — исполнителей ролей в пьесах К. Тинчурина.
«Памятники татарской культуры в Оренбурге». Дом, где родился Дж. Файзи.
В номере отмечается 100-летие М. Галяу.
На первой странице обложки — образцы татарского ювелирного искусства — подвески (чулпы).
На четвертой странице обложки — памятник Л. Н. Толстому в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 28.07.1987 ел. Басарга кул куелды 26.08.1987 ел. ПФ 14083. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 66849. Заказ М-294. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

**Марс Шабаев**

# АЧЫКТАН-АЧЫК

## ПУБЛИЦИСТИК ПОЭМА

*Умри, мой стих, умри, как рядовой...*

В. Маяковский.

«Шигыреңнең,— дип,— ник юк рифмасы?» —
сорама миннән, укучым, яме.
Лимиты чыккан,
фондлар киселгән,
запас рифмалар бетеп киткән чак —
рифмага кытлык,
рифма — дефицит!
Аннары әле рифма кырырга —
станогым да калтыр да кылтыр,
илленче еллар башыннан бирле
минем бит аны яңарткан юктыр.

Тулаем болай (вал белән ягъни)
шигырь планы үтәлә безнең.
Әмма шулай да шигырьгә кытлык,
шигырь — дефицит...
Чын шигырь, димен...
Бик сирәк туа,
көттереп туа,
җаныңны сыгып язганда гына —
сыйфат мөһере сугарлык шигырь.
Ә шигырь кирәк...
Аны да, җаным, өчәр ел алдан
планга сала бездә нәшрият.

Шигырьне, дөрес, ашап та булмый,
киеп тә булмый шигырьне аны.
Маяковский әйткән әйтүен:
коеп куйган бер шигъри юл өчен
сүзләр рудасын тонналап актар...
Ә нигә әле чиләнергә, ди?
Тезмәләп чыккач, ярамаганмы?

«Шаяртасыз сез! Бик күпертәсез...
Алай җиңелдән язмас чын шагыйрь...» —
дисең инде син, укучым, миңа.
Үзең диеп үк әйтмим дә болай

---

МАРС ШАБАЕВ (1933) — шагыйрь, «Яңа җыр», «Җикән камыш», «Онытма» һ. б. татар һәм рус телләрендә егермега якын шигырь китабы авторы. Ул ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.

(бәлки чынлап та үзең дә шундый?),
ә нигә әле синең иптәшең —
әйтик, бер Әхмүш,
эштер-өштердән деталь кыра да
эш хакы ала,
премия ала,
исе дә китми?
Димәк, синеңчә, ул да шаярта.
Бу «шаяртулар» ил җилкәсенә
нинди йөк булып төшә икән соң?

Ә син, укучым, кибетләргә кер:
күр әле — анда ни кадәр товар!
Аяк киеме — киштә сыгыла...
Костюм-чалбарлар — дивизиялек...
Пальто-туннарның бәясе кәттә,
сукыр тиенлек тормый үзләре.
Әле менә тик шушы көннәрдә
безнең Казанның бер фабрикасы
өч йөзме данә, биш йөзме данә
ирләр пальтосы тегеп чыгарган,
ә төймәләре — хатын-кызныкы!
(Төймә-каптырма дефицит заман!
Шуңа еш кына бер каптырмалы
шигырь языла, кемдер әйтмешли.)
Ә статистик отчетларда бит
бар да бик әйбәт, һәммәсе яхшы:
план үтәлгән,
бүләк алынган...
Ничәмә-ничә миллиард сумлык
чималның шулай җилгә очканын
статистика безгә күрсәтми!

Димәк, синеңчә, бу да «шаярту?»
Ник ул товардан йөз чөерәсең?
Шыпыртын гына сорап куясың:
«Импорт юкмы соң?..»
(Оялуыннан егылып төште
«Спартак» теккән аяк киеме!)
Ә беләсеңме, җан башына без
Америкадан бермә-бер артык
аяк киеме ел да тегәбез —
сыйфат кына юк...

Кибеттән чык та урамга күз сал,
халыкка күз сал: шәрә йөрмиләр.
Аякта-башта, эчтә дә өстә —
шыфырт та шыфырт —
импорт та импорт!
Исән-сау булсын «сорочий базар!»
(Бар әле ул, бар!)
Исән-сау булсын алыпсатарлар!
Чегәннәр генә диеп ялгышма.
Яшәсен «фирма!»
Ә кибетләрдә елый Казанның
«Ирләр өс киемнәре тегү
производство берләшмәсе»нең
(исеме хәтта шигырьгә сыймый)
карачкылар да баш тарта торган
«затлы» товары —
биркасындагы «сыйфат билгесе»
акаеп тора.
Бу — безнең фирма...
Әйт син, укучым, ачыктан-ачык:

син миңа үтмәс товар теккәндә,
нигә әле мин «тегәргә» тиеш,
«чигәргә» тиеш сәнгать әсәре —
ихлас чын шигырь?

Я, ярый, булды...
Шаяртуларны бер якка куйыйк.

Иҗат итмәкче идем мин менә
ил күләмендә тирән-фәлсәфи,
зур масштаблы эпик бер әсәр...
Һәм ул әсәрдә ачмакчы идем
бүгенге көнне:
үзгәртеп кору, тизләнеш чоры,
демократия, кеше факторы,
хаклык-гаделлек —
болар барысы якты буяулы
мисаллар белән сурәтләнергә тиешле иде.

Уй-хыялларың кәгазьдә шома,
ә тормышта ул башкача чыга...

Шул зур социаль мәсьәләләрнең
үзәгендәге геройларымның
социаль йөзен образлы итеп
төсмерли генә башлаган идем,
фикер чуалды, җырым өзелде...—
көндәлек тормыш мәшәкатьләре арага керде.

* * *

Улым өйләнде.
Квартир алды.
Барнаулда ул, Алтай ягында...
Квартирымы?
Гадәттәгечә...
Өр-яңабаштан ремонтлау кирәк.
Яңа фатирны беләсез инде...—
мәңгелек тема сатирикларга.
Яңа фатирга күчү башлана
гозер төшүдән сантехникларга,
нинчә әйтсәң дә, шул Әхмүшләргә.
Аннары — идән...
Аннары — түшәм...
Аннары — ишек...
Һәркайда тишек!

Яза бит малай:
«Вокзалда кебек яшәп ятабыз
как идәндә без... Әти, булыш, ә?!»

Кибетләрендә мебель юк икән...
Әйтерсең, монда тутырып куйган!
Хәзерге яшьләр түземсез халык:
аларга булсын тиз һәм сыйфатлы.
Ә үз эшендә тиз һәм сыйфатлы
эшлиме алар — анысы мәсьәлә!

Бала — газиз җан.
Булышмый булмый:
киттем кибеткә, кулда исемлек.
Янәсе менә барам да алам.
Алдың, пычагым!

Айлар буена Казанны айкап,
ничәмә-ничә кибет төбендә
«башлангыч белем» алдым мин башта.
Анда тәртип бер:
яки «төртәсең», яки көтәсең...
Мебельгә кытлык,
мебель — дефицит!

Кемнәр өчендер ипле вариант —
«төртәсең»неме беләсең килә?
Бардың кердең дә, тизрәк «төрттең» дә
җан теләгәнең алдың түгел ул.
Мин үзем менә һич «төртә» белмим,
тумыштан шундый кимчелекле мин,
кибетче теле белән әйткәндә,
мин бик «идейный».
Димәк, идеяң-иманың белән,
оят-намусың, вөҗданың белән
башка вариант сайларга кала —
«көтәсең» дигән шул вариантны
уртага салып тикшерсәк әгәр,
бу язманы да сузарга мөмкин
ахырызаман көненә кадәр...

Юк, ахырызаман көненә кадәр
Йөрмәдем болай йөрүен үзем,
улым йомышын үтәп чыгарга
җитте... тугыз ай!

«Бу — кичәге хәл.
Хәзер бит, шагыйрь,
яңадан-яңа әйбәт карарлар,
яңадан-яңа әйбәт законнар
гамәлгә керә...» — дисең инде син.

Керүен керә...
Грузчик Әхмүш әле бүген дә
кич, эш беткәндә, «төшереп» алгач
зарлана шунда үзара гына:
«Бүген мин берне «эшкәрттем» бары,
бозылып бара клиентлары...
Ә бит эш хакым — бер төкерерлек!
Көне буе син ат кук эшлә дә,
таралып төшкән шкаф шикелле,
сөякләреңне җыеп алмаслык
булып ватыл да — чумарасыз кал...
Шайтанымамы?!»
Әхмүшнең аның фәлсәфә шундый:
кереме хәләл, эшләп тапкан мал...

Ә син, укучым, үзгәреш дисең...
Бер селтәнүдә булса икән ул!
Кемнәргәдер бит үзгәреп тору
кирәк тә түгел: иманы-җаны,
намус-вөҗданы бербөтен, камил.
Ә кемнәрнедер үзгәртер өчен —
яңадан тудыр!
Шунсыз булмыйдыр...

Ярый, хуш, шуннан...
Инде мебельне кайтартыйк өйгә.

Кибеттә синнән Трансагентлык
бюросының фәрештә кызы
(ах, елмаюы!)

җиһазны санап, этажны санап,
километражны өчкә арттырып,
җиһаз сутканга (сүттеләр, ди, көт!),
җиһаз җыйганга (җыйдылар, ди, көт!),
керфеген сирпеп елмайганына
бер сумнан өстәп, акча каера
(күбрәк каерса — күбрәк сала ул
процентын да үз кесәсенә):
«Бар, кайт, абзыкай!
Безнең бөркетләр иртәгә илтер,
өеңә кертер, җыеп та бирер.»

«Иртәгә»не син өч көн көткәчтен:
«Эш нәрсәдә?» — дип, кибеткә килсәң —
арба ватылган, үгезе үлгән...
Имеш, фургонның фаралары юк,
«бишенче көпчәк» шартлаган яки,
Әхмүшнең дә бик башы авырта,
сиңа барганнар — юлда көрт булган,
кергә алмыйча кире киткәннәр,
яки бөтенләй синең мебельне
«төртә» белүче бераү сыптырган!
Ә фәрештәнең елмаюларын
җен ялаганмы?! —
килә чат та пат!
Булмасын инфаркт, валидолың кап...

«Ниһаять, килә көтелгән шатлык»... —
димә әле син, тукта, тыңлап тор:
инде мебельне Барнаулга бит
озатасы бар, шайтан алгыры!
Киттем мин хәзер контейнер юллап.
Анда да шул ук кибет «тәртибе»,
анда да шул ук Әхмүшләр икән!
Шарты һаман шул:
«төрт» кенә, абзый!
Әйткәнемчә, мин «төртә» белмимен...
«Дөньясы шундый аның абзыкай:
минем икмәккә синең маеңны
ягарга куша, Райкин әйтмешли.»
Якмадым майны икмәкләренә.
Сыер дуласа, аттан да яман
кыланмасам да,
берничә түрә ишеген шакып,
бер атна-ун көн ары да чабып,
бире дә чабып,
ике арада күп килəп сарып
йөри торгач, мин
озата алдым әйберләремне...

* * *

ене, укучым, бер генә кыйсса.
сөйләдем сиңа ачыктан-ачык.
Иң өстә яткан, иң күңелсезен,
шигъри томанга төрмичә генә.
Ялыктырдыммы? Эчпошыргычмы?
Ә бит көндәлек тормышыбызда
һәрвакыт безгә юлдаш-күләгә
җанны әрнеткеч ул күренешләр.

Эреле-ваклы түрәләрнең син
ишек төбендә күпме гомерең

кыскарттың икән, бер дә юк кына
йомышың юллап,
гаделлек эзләп?
Берәр ни-нәрсәң ватылган чакта
(телевизормы, суыткычмы ул,
яки гап-гади үтүк-фәләнме)
төзәттерергә күпме чиләндең
(я мастеры юк, я запчасть беткән,
я көе килми синең әйбернең)?
Нәрсәләреңне бозып кайтарды
яки югалтты, әйтик, «Химчистка»?
Үз гомереңдә күпмегә сине
алдады икән официантлар?..
Никадәр баналь, күпме чәйнәлгән,
таушалып беткән мисаллар болар!
Хәтта сөйләргә оят ул хакта,
бетерә генә алмыйбыз әмма...
Чөнки болар бит — нәкъ без үзебез!
Үзеңне үзең бетереп кара...
Докторлар әйтә (дөрес әйтәләр):
тискәре тойгы-эмоцияләр
китерә безне стрессларга.
Син яшәп кара аларсыз гына!
Бер-беребезгә үзебез үргән
гаделсезлекләр җәтмәсендә без
бөҗәкләр кебек тыпырчынабыз...

Әшәкелеккә кытлык юк аңа!
Ул бит һәркайда:
зур түрәләрдән-министрлардан
ишек төбендә йокымсыраган
вахтер-лифтерлар миенә кадәр
үтеп кергән ул вирус-микроблар.

Оялмыйбыз да, хурланмыйбыз да —
күр әле ничек шомартып-майлап
сөйли беләбез кирәк чагында
(Ул баналь түгел!
Ул таушалмаган!):
сыйфаты начар әйбер эшләнсә —
к о н д и ц и я с е килеп җитмәгән,
планнар әгәр үтәлмәс булса —
к о р р е к ц и я л ә п үтибез аны,
кычкырып торган ялган отчет юк —
бары тик беркадәр
а р т т ы р ы п я з у,
эш урынында әйбер урлашу — урлашу түгел,
к ы с т ы р ы п ч ы г у,
иң соңгы нокта,
«иң образлысы» —
намусны сату — ул
я ш и б е л у!

Гомер-гомердән, ата-бабадан
гамәлдә йөргән иң олуг хөкем,
иң кырыс хөкем иң гадел хөкем —
әхлак кануны бизмәннәрендә
үлчәнә торган халык хөкеме —
әхлакый хөкем бармы ул хәзер?
Оныттык бугай без аны тәмам.
Комсызлыкка ник статья юк?
Статья юк көнчелеккә дә,
куркаклыкка да юк статья...
Әшәкелекләр хөкем ителгән

элек-электән тик әхлак белән.
Әхлак нәрсә ул?
Җисемсез нәрсә:
ашап та булмый әхлакны аны,
киеп тә булмый аны — әхлакны.
(«Рәхмәттән, дибез, тун тегеп булмый...»)
Өс-башлар бөтен, тамак тук заман!
Нигә соң әле әхлакка кытлык,
әхлак — дефицит?
Тормыш куабыз... Әй җилдерәбез!
Җилдергән чакта кайсыдыр чатта
коелып кала, ахры, әхлак та
бик күбебезнең арбаларыннан...
Артка борылып карарга хәтта
вакытыбыз юк — әй җилдерәбез!

Иң изге-газиз төшенчәләрне
инде оныттык бугай дигәндә,
коеп бетердек бугай дигәндә —
Намус чаң сукты!
Илнең өстеннән күптән көтелгән
язгы җил исте —
Апрель җилләре.
Шуннан бирле ул туктамый исә,
себереп исә,
чистартып исә —
тизләнеш җиле,
үзгәреш җиле:
әхлагын күптән коеп калдырган
түрәләр оча урыннарыннан,
бик күпләр оча,
күп нәрсә оча...
(Очарга тиеш күп нәрсә кала,
Әхмүшләр кала,—
әлегә кала!)
Безнең ил-йорт зур.
Чүп-чар җитәрлек.
Байтактан бирле чистартылмаган.
Югартын искән җилләргә генә
ышанып ятмас өйдә чын хуҗа,
себерке тотып үзе дә чыгар.


Бәлкем, иң элек эшне үзеңнән —
«мин»еңнән башлау хәерлерәктер.
«Минме? Мин!» — диеп күкрәк сугулар,
вәгъдәләр-антлар, адарынулар,
юк, кирәкмәстер...
Кирәк арыну, кирәк чистарту,
кирәктер, бәлкем, вөҗдан мунчасы,
фин мунчалары-сауналар түгел,
ата-бабадан калган шифалы
гореф-гадәтләр мунчасы кирәк
пакьләнү өчен.
Я, кем ул анда чыраен сыта:
«Тагын негатив
(«тискәре» диммм!)...
Ник күрми шагыйрь казанышларны?
Һаман берьяклы казыну нигә?»
Ә казылмаган, тик казыласы
негативларың
тау да тау әле!
Ничәмә еллар чишелеш көткән
күп мәсьәләләр төйнәлеп беткән —
бер тартып кына чишеп кара, бар!

Уңышлар, димсез? Казанышлармы?
Бәхәссез алар.
Илнең куәтен бар дөнья белә.
Әмма онытмыйк: «ура!» да «ура!» —
шапырынулар, алкышлауларның
алсу күбеге астында бик еш
күмелеп кала «юасы бала».

Илдә җанлылык, илдә хәрәкәт,
гүя йокыдан уянды халык,
мәйданга чыкты кеше факторы —
кешенең аңын үзгәртү кирәк.
Рухи торгынлык, битарафлыклар
ныгытмасының таш маңгаена
публицистик бер йодрык булып
бәрсен бу шигырь ачыктан-ачык!
Ачыктан-ачык тәкърарлыйм бүген:
авыр өлгерә,— әмма өлгерә! —
безнең аңнарда рухи яңарыш —
Октябрьгә тиң революция.

*1986*

**Газиз Кашапов**

# ЛАЧЫН КОШКА КҮКЛӘР КАДЕРЛЕ

ПОВЕСТЬ

*18 нче укчы дивизия составындагы 97 нче полк командиры Барый Кадерматовның онытылмас батырлыгына багышлыйм.*

Автор.

## Пролог



иңгез гүли дә гүли...

Дымлы җил исә. Яз исләренә манчылган бу дымлы җил куе болытларны мин белмәгән якларга таба куа да куа.

Кояш, иртәнге якта гына бераз күренгән сыман булып алды да, каядыр еракка, салынкы-сүрән болытлар артына кереп яшеренде.

Ничәнче көн инде аңлашылмас сәер бер халәттә яшим мин. Эшем — эш, ашаганым аш түгел... Ул халәтне берничек тә аңлатып булмаган кебек, аңардан беркая качып котылу чарасы да юк, ахрысы. Серле, сихри, хыялый бер халәт ул, моңарчы кичерелмәгән халәт.

Бу якларга килгән көнне үк, кирәге чыга калса дип алынган, әллә кайчан язып тутырылган көндәлек дәфтәрем арасыннан каен яфрагы хәтле кәгазь кисәге очып төште.

Хәзер исә, кем әйтмешли, Кабан күле кадәрле зур өстәлемдә шушы саргая башлаган кисемтәдән башка бер әйбер дә юк.

Әлеге кәгазь кисәген кайчан кисеп алганымны хәтерләмим, әмма ни өчен икәнлеген аермачык аңлыйм: Татарстан уллары Бөек Ватан сугышы кырларында күрсәткән фидакарьлекнең сүзсез бер шаһите, килер буыннар хәтерендә онытылмыйча саклана торган Батырлыкның сыңар кыйпылчыгы, уртак Ватаныбыз каршындагы пакь йөзебезгә тап төшермәс көзге ул.

Бу Батырлыкның сәхифәләре халкым өчен мәгълүм түгел, минем күңел күземә дә бары тик хәзер генә, яу кырларында һәлак булган әтиләребез яшен байтакка узып киткәч кенә, Бөек Җиңүнең кырык еллы-

---

ГАЗИЗ КАШАПОВ *(1942)— прозаик, «Сәмум җиле», «Еллар тыныч үде», «Язмышыңа ышан» дигән китаплар авторы. Брежнев шәһәрендә яши.*

гын бәйрәм итеп уздырганнан соң гына ачылды, йөрәгемнең ерак тамырларына үтеп керде.

Гадәттәгечә, бу юлы да иҗат йортына ярты чемодан кулъязма, тәмамлыйсы эшләремне тутырып килгән идем... Ләкин... аларга, тотыну дип әйтмим, әйләнеп тә караганым юк...

Баш миенең иң сизгер өлешеннән давылланып, кайтаваз булып бер үк сүзләр актарылып чыга. Ул сүзләрнең чакырулы авазлары, тынлы оркестрның көчәя барган тавышлары сыман, колак төбемдә кабат-кабат яңгырый:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! Кудров мин булам!

Бу набат шулкадәр көчле, шулкадәр котылгысыз ки, мин ни кылырга, кая барырга, нәрсә эшләргә белмичә аптырыйм, чарасызлыктан интегәм. Әйтерсең, мин япа-ялгыз Смоленск урманнары арасына кереп адашканмын да чыгу юлын таба алмыйча йөрим. Шулай йөрим-йөрим дә, аптырагач, Хачлы авылына барып чыгам...

Анда исә мине тагын баягы:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез!!!— дигән үлемсез аваз көтеп тора.

Ниндидер могҗиза ярдәмендә яңадан Гәрәбә диңгез буена әйләнеп кайтам. Әлеге чакыруның яңгыравык авазларын акчарлак тавышлары арасында адаштырып калдырмакчы булам.

Кая инде ул!

Дөрес, бу юлы Гәрәбә диңгез тынычланып, басынкыланып калган, ләкин мин беләм: аның төпсез тирәнлегенә дә шушы ук чакыру авазлары сеңгән.

Мәңгелек дулкыннар гасырлар дәвамында юылган алтынсу комлыкка йөгерешеп менәләр дә, хәлсезләнгәч, көч тупларга ашкынып артка чигенәләр, яңадан үз иншләренә кушылалар һәм... ишетелер-ишетелмәс сулкылдап:

— Тимәгез!!!— дип эндәшәләр.

Мин, юеш комда ярылып яткан эзләр калдыра-калдыра, диңгез буенда саф һава сулап йөрүчеләрнең сәер карашларын ияртеп бар көчемә еллар каршына йөгерәм...

Хәзер миңа ерак еллар аша килгән чакыру авазы аермачык ишетелә. Ашкынулы хыялым ул вакыйгаларны җанлы сурәткә әйләндерә, чынбарлыкка кайта-кайта хәтер тасмасы сүтелә башлый.

Яз исләренә манчылган көрпә кар болытлары агыла да агыла.

Дымлы җил исә.

Җепшек кар ява да ява...

## Беренче кисәк

### I

Кайдадыр якында тагын бер мина шартлаганнан соң, әйләнә-тирә тынып калды.

Дөрес, тоташ шартлаулар тетрәндергән колагы һәм борын тишекләреннән кан саркып торган Кадермәтов моны ишетмәде, ләкин ниндидер эчке бер сиземләү аны сискәндереп җибәрде, селкенергә мәҗбүр итте. Ул, яңа гына судан чыккан ат шикелле калтыранып, өстендәге туфракны коеп төшерде...

Бераздан кан килү туктады, акрынлап җирдәге тавышларны аеру мөмкинлеге туды, әмма баш миенең гүләве басылмады. Шулай да Кадермәтов аермачык төшенде: атыш тынган, баягы мәхшәр басылган. Мина һәм снаряд чокырларыннан төтен һәм әчкелтем-сасы тротил исе аңкый.

Барый Кадермәтов үзенең яралымы-түгелме икәнлеге турында уйлап та карамады. Ул, туктаусыз сугыш эчендә байтактан чигенеп килүенә

карамастан, әлегә кадәр бер генә мәртәбә дә яраланмаган иде. Дөрес, аны инде фашист козгыннарыннан сибелгән бомба һәм эреле-ваклы снарядлар берничә мәртәбә җиргә күмде, траншеяларны таптап-изеп килүче танклар өстеннән узды, контузия мингерәүләтте, әмма бер генә адашкан ядрә дә, тары ярмасы хәтле кыйпылчык та хәзергәчә аның тәненә эләкмәде. Бу юлы да Кадерматов тән ярасы булу-булмауны сизмәде, тик колакларына гына төеп-төеп мамык тутырылган шикелле. Әнә шул хәл дөньяда ни барын ачык ишеттермичә колакның сизгерлеген томалап тора иде.

«Тагын,— дип уйлап алды Кадерматов ачынып,— тагын... инде ничәнче тапкыр чолганыш элмәгеннән чыгарга туры киләчәк... Мондый кыямәттән соң исән калучылар булса, билгеле?»

Соңгы уй Кадерматовны айнытып җибәрде, башындагы мингерәүләнү кимегәндәй булды. Һәм ул, куллары белән гәүдәсен җирдән күтәрә төшеп, эндәште:

— Ип...тәшләр... Исәннәр бармы?

Көек исе таралып өлгермәгән кырда кабер тынлыгы хөкем сөрә иде. Колаклардагы бер көчәя, бер кими барган шаулау-сызгырудан битәр берни ишетелмәде.

Кадерматов тагын, бу юлы тезләренә баскан килеш, әле бер, әле икенче якка борылып:

— Исәннәр... булса, тавыш бирегез!— дип кычкырды.

Тавыш-тын ишетелмәде.

Борын эчендә укмаша башлаган кан сулыш алырга ирек бирмичә тора иде, Кадерматов аны уң кулы белән кысып чыгарды. Шул көчәнүдән соң, ни хикмәттер, дөнья шау-шулары аермачык ишетелә башлады. Юкса әле генә бөтен тирә-юнь тынлыкка күмелгән кебек иде, баксаң — контузия мингерәүләндерүе шулай иткән икән. Еракта туплар шартлавы, авиабомбалар гөрселдәве дә ишетелеп куйды һәм Барыйның колак төбендә диярлек козгын карылдавы яңгырады. Бу хәл майорны чынбарлыкка тагын да тизрәк кайтарды. «Ах син, кабахәт...— диде ул, кипшенгән иреннәре белән генә пышылдап. Аннары бөтен ачуы һәм нәфрәтен туплап кычкырды:— Булмас, барыбызны да кырып бетерә алмассыз... Торырга... Кичекмәстән торырга кирәк, исән калучыларны эзләргә...»

Исән калучылар...

Күпме генә икән инде алар, Барый Кадерматов полкында сугышучылар?

Менә ничәнче көн инде, ил чигеннән бирле канлы бәрелешләрдән чыкмавына карамастан, сугышчанлыгын югалтмаган сирәк полкларның берсе теткәләнгән, ләкин тар-мар ителмәгән килеш көнчыгышка таба чигенергә мәҗбүр. Әйе-әйе, тар-мар ителмәгән... Бирелдәге бәрелешкә чаклы майор Кадерматов полкының нибары җитмешләп сугышчысы бар иде... Асылда ул әле һаман полк булып санала, шуңа тәнгәл сугышчан бурычлар ала, димәк, яши иде... Чөнки аны беректереп торучы Кызыл Байрак алар белән иде...

Байрак искә төшүгә, Кадерматовның бөтен тәне, аяк-куллары тартылып, сискәнеп куйды. «Кайда, кайда ул?»

Майор үз-үзенә «һек» дип көч өстәде, башта дүрт аякланды, аннары шул хәрәкәтен дәвам иттереп торып ук басты. Тиз буыннары хәлсезләктән калтырый, күз алларында кара болыт кайпылчыклары кебек таплар йөзә иде. Барый, хәлсез аякларын көч-хәлгә селкетеп, үзен ике адым атларга мәҗбүр итте, таплардан арынырга тырышып күзләрен ешеш йомгалап торды һәм каршысында гына төтенләп торган бомба чокырын күрде. Хәтер ачыла төшкәч, шушы чокырдан фашистларның соңгы атакасына каршы ут ачкан пулеметчы Мөхәммәтҗановны эзләргә ниятләнде. Майор бер адым уңгарак атлады, туктап хәл алгандай итте, яңадан кузгалды, сулгарак борылып басты һәм чокырның эченә күз төшерде. Баягы кара таплар таралганчы текәлеп-текәлеп карады.

Мөхәммәтҗановның пулеметыннан, кем әйтмешли, «мөгезе дә тоягы» гына калган иде...

Кадермәтов тезләнде, аннары куллары белән таяна-таяна чокыр читенә сузылып ятты да аска карады. Старшина Мөхәммәтҗанов әллә ничек җайсыз һәм гайре табигый килеш бөгәрләнеп, башын туфрак томалаган хәлдә хәрәкәтсез ята иде.

— Әмир... Әмирҗан, якташ,— диде полк командиры, чокырдагы иптәшенә таба үрелеп...

Старшина дәшмәде, селкенмәде, тереклек билгесен күрсәтмәде.

Кадермәтов чокыр читенә утырды да, куллары белән ян-ягына тотынып һәм аякларын саклык белән генә аска таба сузып, басар урын табарга тырышты. Тапты. Ниһаять, ике кулын берьюлы җибәреп, чокыр төбенә төшеп басты. Шуннан соң, бил каешыннан ике куллап тотып, Мөхәммәтҗановны үзенә таба тартты. Беравык хәл туплагач, кулларына — тезләре, аннары җилкәләре белән ярдәмләшә-ярдәмләшә, якташының җансыз авыр гәүдәсен өскә, чокыр читенә чыгарып салды. Аякларын чокыр эченә таба салындырып утырып торды, маңгаена бәреп-бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп алды һәм бөтен гәүдәсе белән борылып якташының йөзенә карады...

Сугыш кырында үлгәннәрне моңа кадәр дә күрмәде түгел, кызганычка каршы, бик күп, бик күп күрде Кадермәтов. Нindиләрен генә күрде әле! Әмма моннан нибары ике сәгать элек бер котелоктан ашап утырганда:

— Без әле, Барый абый, үзебезнекеләргә чыгу түгел, еракта, көнбатышта калган гарнизоныбызга да әйләнеп кайтырбыз. Фашист көчекләрен илдән дөбердәтеп куып чыгарырбыз,— дип полк командирын тынычландырырга тырышкан, чик буеннан бирле күзенең карасыннан да ныграк саклап килгән Байракны гимнастеркасы астына ураган якташы Мөхәммәтҗановны җансыз килеш күрү халәте Кадермәтовның йөрәген телеп узды. Ул, торатащка әйләнеп, Мөхәммәтҗановның өстенә караган килеш озак торды... Бу минутларда майорның акылы эшли, Мөхәммәтҗановның гәүдәсеннән Байракны сүтеп алырга кирәк икәнлеген искә төшереп-төшереп ала, ләкин ул ни хәрәкәт кылырга да белмичә, йөрәгенең сыкравына түзә алмыйча тавышсыз-тынсыз, өнсез калып елый иде.

Кадермәтов — Халхин-Голны кичкән, фин сугышында булып андагы Маннергейм ныгытмаларына һөҗүмгә барган, сугыш кырында һәлак булганнарны илнең көнбатыш чигеннән бирле адым саен диярлек күреп килгән кеше — бу юлы, бәлки сугыш башланганнан бирле, беренче тапкыр шулай чарасыз булып, аптырап, югалып калган иде...

Шулвакыт төтен, күңелне болгаткыч тротил һәм кан исләре белән бергә кушылып кергән әллә нинди бер көч Кадермәтовның үпкәләренә бозлы салкын сулыш тутырган кебек булды. Беравыктан ул сулыш, тын юлларын өшетә-өшетә, тамак төбенә таба күтәрелә башлады һәм, тавыш ярыларын тартылдырып, чыдап булмаслык әрнү тудырды. Аннары әлеге авырту, канлы төергә укмашкан килеш, Кадермәтовны укшыта-укшыта тышка ыргылды.

— Вәх... шилә-ә-әр!— диде Кадермәтов тамагын ярып чыккан канлы төерләрдән арынгач.— Вәхшиләр! Туктагыз әле... Җаныгызны кая куярга белмәссез... бел...мәс...сез!

Шул мәлдә ул берән-сәрән генә үз янына туплана башлаган сугышчыларын шәйләде. Мәскәү ягына таба узып киткән бомбардировщиклар гөрелтесен, снарядларның тонык шартлауларын — барысын-барысын берьюлы ишетә башлады...

Фашистларның котырынган һөҗүменә каршы торган җитмешләп сугышчының егермесе Кадермәтов янына килеп тупланган иде инде.

— Иптәш майор... Без... Мухаметзяновны...— диде беренче батальондагы взвод командиры Добротов, бераз иелә төшеп. Контузиядән

миңгерәүләнгәнгә күрә каты гына кычкырып сугышчыларга дәште:— Ал-ыгыз, иптәшләр.

Ике сугышчы, дәррәү кузгалып, Мөхәммәтҗановның җилкәсенә һәм аяк очына барып тотындылар.

— Туктагыз,— диде Кадермәтов аларга таба карамыйча, әмма ике кабатламый торган тавыш белән.— Туктагыз, иптәшләр... Анарда... Байрак... Байракны сүтеп алырга кирәк...

## 2

Фашистлар куйган капкынга кабат эләкмәс өчен алардан да хәйләкәррәк булырга, мәкерле чолганыштан чыгарга кирәк иде. Нишләмәк кирәк, Кадермәтовның беркайчан да чит йолдыз астында рәхәтләнеп яшәрмен дип өметләнгәне булмады, чөнки ул җирдәге юлларны кешенең бары тик үз йолдызы гына яктыртып барачагын белә иде. Хәзер дә соңгы ике көндәге яңа бәрелешләрдән соң полк кадәр полктан нибары дистәләп кеше калуга ачынса да, майор үз тирәсендәгеләрне көнчыгышка, фронт ягына, сирәк-мирәк кенә туплар гөрселдәве ишетелгән якка таба алып бара бирде. Кичә, төштән соңгы бәрелештән исән-имин котылып, урман эченнән ашыгып барганда, аларга тагын утызлап кеше килеп кушылды. Дөрес, алар төрлесе-төрле частьлардан булып бер-берсен рәтләп белмиләр, турысын әйткәндә, хәтта бер-берсе белән танышлар да түгел, кичәле-бүгенле генә очрашканнар иде. Әмма аларның барысын да изге бер нәрсә берләштерә — ул да булса, чолганыштан мөмкин кадәр тизрәк чыгып үзебезнекеләр сафына кушылу максаты.

Яңа кушылган сугышчылар, Кадермәтовның нindирәк командир икәнлеген белмәсәләр дә, майорның кичәге бәрелештә каушамавын, үз-үзенә нык ышаныч белән биргән боерыкларын ишеткәч, төркемнән аерылып калырга теләмәделәр.

— Иптәш майор, иптәш Кадермәтов,— диде әле генә разведкадан кайткан Добротов, полк командирын авыр уйлардан аерылырга мәҗбүр итеп.— Урман алдындагы авылда немецлар юк. Кичә булганнар. Ниндидер парашютчылар төркемен эзләгәннәр. Ләкин тавык урлаудан башка зыян-зарар китермәгәннәр.

Беренче карашка Добротов кирәгеннән артык гади, беркатлы, тирә-яктагы хәлләргә артык әһәмият бирмәгән авыл егете кебегрәк күренсә дә, чынлыкта исә ул, йөрәгенең ярсуын саклап, максатына ирешү юлында очраган кыенлыклар, бәла-казаларның күбрәге алда икәнлеген белгән килеш, үз дигәненә үҗәтләнеп баручылардан иде.

Кадермәтов, кече лейтенантның докладын тыңлаган арада, теге көнне Мөхәммәтҗановны күмгән чакта Добротов белән булган сөйләшүен искә төшерде.

— Иптәш Добротов,— диде ул чагында Кадермәтов аны читкәрәк алып китеп,— сез безнең полкның миннән башка бердәнбер офицеры. Мин, полк командиры буларак, кешеләр алдында һәрвакыт үз формамда булырга тиешмен. Теләсә генә нинди хәлдә дә... Алай-болай булган очракта да мин, өлкән командир, фашистларны үлеме-тереме килеш бик тиз кызыксындырырмын. Шуңа күрә мин сезгә өстегездәге киемнәрне рядовой сугышчы киеменә алыштырырга боерам...

Бу сүзләрдән Добротовның беркатлы йөзенә кызыллык йөгерде, сусыман яшькелт күзләрендә моңарчы күренмәгән усаллык чаткылары чагылып-чагылып алды, әмма ул тыелды, тирән сулыш алды һәм:

— Бик үк аңлашылмый, иптәш майор, нигә... нигә мин үземнең форманы алыштырырга тиеш? Миңа, әгәр дә мәгәр, моңарчы башларын куйган иптәшләрем язмышын уртаклашырга туры килә икән... бер дә үкенмим... Әгәр инде... ниндидер чиктән тыш вакыйга әсирлегенә эләксәм дә, язмыш сынавын мин үз җилкәм белән күтәрергә тиешмен,— диде Добротов, тәмам кыза башлап.

— Кызарга ашыкмагыз, кече лейтенант... Полкның намусын — Байракны, Мөхәммәтҗанов кебек, үзегезгә урарсыз... Аңладыгызмы? Кием алыштыруның сәбәбен мин үзебезнең полк сугышчыларына аңлатырмын... Яңа килеп кушылучылар моны белмәскә тиеш...

Кече лейтенантның кара көйгән йөзе яктырып китте, аңа тагын баягы гадилек, беркатлылыгы кайтты.

— Рәхмәт, иптәш майор, ышанычыгыз өчен. Үлсәм үләрмен...

Кадерматов аны бүлдерде:

— Монысын... ташла! Бу хакта сүз булмаска тиеш, кече лейтенант... Мин сезгә бу хакта уйламаска боерам... һәм... бәрелешләрдә башыгызны кирәк-кирәкмәс урынга тыкмаска, хәтта... саграк булырга, алдыгызны-артыгызны карарга... кирәк була икән, вакытында чигенеп, качып, яшеренеп өлгерергә боерам! Ситуациягә карап, билгеле.

Боерыкларга буйсынырга күнеккән кече лейтенант башта:

— Есть! — диде һәм шунда ук: — Ләкин... — дип тә ычкындырды.

— Никаких «ләкин»! Ишеттегезме?.. — Майорның бөтен кыяфәте ике сөйләргә җыенмавын күрсәтеп тора иде.

Добротовның разведкага барып кайтуы турында рапортын тыңлап бетерер-бетермәстән үк Кадерматов кече лейтенантны битәрләп ташлады:

— ...Бу хәл, иптәш Добротов, үз белдегегез белән йөрүегез, соңгы тапкыр булсын,— диде ул. Аннары бары тик кече лейтенантка ишетелерлек итеп өстәде: — Сезгә барыбызга караганда да җаваплырак бурыч йөкләнгән, иптәш Добротов... Онытырга хакыгыз юк...

## 3

Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кертелгәннән соң Иделнең урта агымындагы җирләр ике халыкның да уртак ватанына әверелде. Кадерматовның ерак бабаларыннан җуелмас мирас булып калган батырлык, яу кырында арыслandaй сугыша белү осталыгын заманында барлык патшалар да яхшы белгән. Шуңа күрә гасыр саен ничәшәр тапкыр Русиягә ябырылган культуралы басып алучы вәхшиләргә каршы аяусыз каты сугышларда Кадерматовны тудырган халыкның да күркәм сыйфатлары чыныга барган. Дөрес, уртак тарихның барлык борылышларын беркайчан да ачык китап итеп укып булмас булмавын. Ул еллар һәм гасырлар узган саен катлаулана барган. Ләкин бай талантлы, зирәк акыллы, уртак ил өчен җанын да кызганмаган, үз күңелендә бетмәс-төкәнмәс моң туплаган һәм хәзер татар дип аталган, чынлыкта болгар белән кыпчак тамырын берләштергән бу халык, бөек рус полководецлары белән берлектә тагын да ныгып, карлы Альп тауларын кичкән, Әдрән диңгез буена чыккан, Кытай чүлләрен үтеп, Тын океан ярларына барып җиткән, туган җирләрен сагынып җырлар иҗат иткән. Берлин һәм Парижларның таш түшәлгән урамнарыннан ике башлы бөркет сурәте төшерелгән байракларын күтәреп узган. Дошманнар, моны күреп, бу ике халыкның дуслык тамырын корыту өчен мәкерле хәйләләр корганнар. Авыр-авыр заманалар, кара болытлы төннәр һәм кояшсыз көннәр дә булмаган түгел, булгалаган. Ләкин уртак Ватан гөмбәзе астында яшәгән бу ике халык дуслыгы ул сынаулардан тагын да ныгыбрак яши биргән. Алар арасында дуслык җепләрен тагын да тыгызрак бәйләүче алдынгы кешеләр туа торган... Менә хәзер дә Гитлер илбасарларының танавын җимерәчәгенә бер тамчы да шиге юк иде Кадерматовның.

Кеше һәм командир буларак шушындый изге хисләр белән сугарылып үскән Кадерматов, тәвәккәл үҗәтлек күрсәтеп, үз тирәсенә тупланган күп төрле сугышчыларны фашистларның зур көчләре белән бәрелешүләрдән саклый-саклый, кечерәкләрендә аны юк итү мөмкинлеген ычкындырмыйча, көнчыгышка таба алып бара бирде.

Сугышның өч ае тулып узды.

Баштагы көннәрдәге аптырау бетте. «Ни булды? Нигә чигенәбез?» — дигән хаклы сораулар хәзер инде кабатланмый иде. Кадерматовны «Ни булганын ачыклап торыр вакыт түгел, хәзер бөтен көчне туплап, илнең азатлыгын саклап калырга кирәк»,— дигән фикер хәрәкәткә өнди иде.

Канлы сугышлар, тоташ чигенүләр, ара-тирә булган уңышлы һөҗүмнәр Барый Кадерматовка баштанаяк коралланган фашист гаскәрләренә каршы сугышып булганлыгын, хәтта аларны бик шәпләп кыйнарга да мөмкин икәнлеген төшендерде. Кадерматов кичәге бер привал вакытында сугышчыларына болай диде:

— Танклардан аерып алсаң, масаюдан башы миңгерәүләнгән фашист тәресе аптырый да кала, чөнки аның алдан ук фюрер сызып биргән план җебе өзелгән була. Менә шул чагында инде кичекмәстән аңа якынлашырга, штыкны муен тамырына батырып алыр вакыт җитә. Суворов нәрсә дигән, ягез әле, кем хәтерли?

Тиз генә җавап бирүче булмады, ул арада майор фикерен дәвам итте:

— Ярый, ярый... «Пуля — дура, штык — молодец!» — дигән Суворов. Чынлабрак карасак, фашист кабахәтләре бөтен Европа илләреннән талап җыйган заманча техникадан аерылсалар, безнең штыклар көченә чыдар әмәле калмавы ачыклана. Бу юлы да без аны... кһем...

Көзге кояш — аңа сугыш әллә бар, әллә юк — сүрән генә булса да җылыта. Сирәк болытлар арасыннан күгелҗем күк йөзе күренепкүренеп алгалый. Шундый минутларда урмандагы каеннар тагын да агарыбрак, тоташ акбүзгә төренгән сыманрак булып калалар. Яшеллеген югалтыр-югалтмас лепердәшкән яфраклар ачыклана төшә һәм озакламый үз хокукын алачак көз сулышын тойган кебек булалар. Хәер, кичә ике тапкыр теләр-теләмәс кенә яңгыр явып узгандай итте, әмма аяк астын пычратырга өлгермәде, шулай да тиздән көзге яңгырлар башланасын искәртеп китте.

Куе урман арасыннан озакламый аланлыкка, аннары ачык басу читенә килеп чыктылар. Алдан баручылар, текә ярга җиткәндәй, берьюлы туктап калдылар.

Майор ашыгыч адымнар белән алар янына ятлады. Килеп җитәргә ун-унбиш адым кала алдагыларның берсе онытылып:

— Иптәш командир, иптәш командир...— дип ярыйсы гына кычкырып куйды. Майор шул ук мизгелдә баш бармагын иреннәренә аркылы китерде, аннары: «Тс-с-с!»— дип ысылдады. Сугышчы, телен тешләп, шундук ике кулы белән авызын каплады.

— Ни булды, иптәшләр?

— Әнә!— Баягы сугышчы, күзләре белән ымлап, үзәнлек ягыннан килгән басу юлына күрсәтте.

Хәзер инде майор үзе дә күрә иде: аларга таба җигүле ат кушаклап чаптырып килә. Аның артыннан тар гына тузан тасмасы күтәрелә, ләкин ул җирдән әллә ни югары менми, көчен югалтып, юл читендә үскән әрсез үлән сабаклары өстенә төшеп куна иде.

— Әзерләнергә!— диде майор боерыкны теш арасыннан гына сыгып һәм бер үк вакытта кискен хәрәкәт ясап сул кулын җиргә таба изәде. «Ятыгыз!»— диюе иде бугай.

Арбадагылар урманга җитәргә утыз-кырык адым чамасы калгач кына хәрбиләрне күреп алдылар һәм, ни кылырга белмәгәнгә күрәдер инде, атларын туктатып-нитеп тормыйча, сикерешеп төшкән уңайга җиргә сузылышып яттылар.

Килүчеләрнең өчесе милиция формасындагы кешеләр икәнлеген күреп өлгергән Кадерматов:

— Соңга калдыгыз... Алдыгызга карабрак килергә кирәк иде. Бире килегез...— дип кычкырды һәм куаклар арасыннан чыгып басты.

Тегеләр, ышанырга яки ышанмаскамы дигәндәй аптырашып, яткан җирләреннән кинәшләшеп алдылар бугай. Ниһаять, уртадан берсе күтәрелде. Ул хатын-кыз иде.

Майор артына килеп җиткән Добротов:

— Хатын-кыз бит бу, иптәш командир,— дип раслап әйтте.

Хәер, моның шулай икәнлеген майор үзе дә бик яхшы күрә иде инде, алай-болай булмасын дип:

— Атмаска... Коралларны әзер тотарга... Урыннарыгызда калырга!— диде ул үзенең сугышчыларына.

Мөхәммәтҗановны күмгәннән соң старшина булып калган, командиры янәшәсендә йөрергә тырышучы башкорт Игебаев винтовкасын әзер тоткан килеш аз гына читтәнрәк атлады. Ләкин саклык чарасы кирәк булып чыкмады, әлеге хатын тулы тәртиптәге киемле өлкән командирны күрүгә (Кадерматовның сөйкемле сөяге ышандыра иде бугай), артка борылыбрак, сугышчыларга да ишетелерлек көчле тавыш белән әйтте:

— Үзебезнекеләр... Торыгыз...

Юл читендәге әрем һәм шайтан таяклары арасыннан өч милиционер күтәрелде.

— О-го, кораллары да бар,— дип куйды Добротов.— Шулай да хатын-кыз артына посарга яраталар бугай болар.

Майор әлеге хатынның алдына ук барып басты.

— Ягез. Сез кемнәр? Документларыгыз бармы?

— Док-к-умент? Нинди документ?— диде тегеләрнең берсе, өлкәнрәк яшьтәгесе.— Күрмисең... мени? Үзе-без-неке-еее-ләр...

— Болар куркуларыннан, иптәш майор, документларын да алырга онытканнар, ахрысы... Әллә ташлап кына калдырдыгызмы?

Майор аны бүлдерде:

— Туктап тор, Добротов... Минә документларыгызны карагач та белербез кемнәр икәнлегегезне,— диде Кадерматов икеләнергә урын калдырмыйча.— Минә мин үзем Кызыл Армия полкы командиры... Кудров булам,— дип өстәде.

Моңарчы да үз фамилиясен әйтергә теләмәгән, ялган сөйләргә өнәмәгән чакларда файдаланган ятышлы гына псевдоним иде бу.

— Ә мин, иптәш командир, шушы районның башкарма комитеты председателе урынбасары булам. Минә документым,— дип кулын күкрәкчәсе астына шудырды.— Болар исә... безнең милиция кешеләре... районда аларны беләләр, шуңа күрә... документларын яшереп калдырганнардыр... Мин аларны беләм, иптәш командир... Ручаюсь. Кайсы якка таба юл тотасыз дисәм... Тимофеева мин...

— Алай да, иптәш Тимофеева, хезмәттәге кешеләрнең документы юклык... Хәзер кешеләргә бик нык игътибарлы булырга кирәк... Бигрәк тә милиция киемендәгеләргә... Без очрашкаладык андыйлар белән...

— Әлбәттә, килешәм сезнең белән, иптәш Кудров. Без үзебез дә лазутчикларны күргәләдек... Нишләптер алар милиция киеменә киенергә яраталар, дөрестән дә...

— Халык ышанычыннан файдаланмакчылар,— дип майор әлеге ирләргә таба борылды.— Ә сез, иптәшләр... шуны белмисезме?

Милиционерлар дәшмәделәр.

— Без, иптәш Тимофеева, үзебезнекеләр янына ашыгабыз... Чираттагы чолганыштан,— диде майор.

Тимофеева башын чайкап куйды.

— Ай-яй, иптәш командир, ерак юлга чыккансыз... Җитә алырсызмы икән соң? Юлларда дип әйтүем немец... немец... немец тулы.

Кадерматов: «Боларның ышанычы бераз какшый башлаган булса кирәк»,— дип уйлап куйды, ләкин сиздерергә ашыкмады.

— Чыгарбыз... Чыгарга тиешбез. Аннары... беренче тапкыр гына түгел бит. Дөресме, иптәш Добротов?

Хатын үзенекендә тора бирде.

— Шулаен шулай да, иптәш командир, ләкин анда чыгып киткәнче сезнең бу сугышчыларыгызның күпмесе генә калыр?.. Житмәсә, алдыгызда тирән сулы киң елга бар... Тирә-якта сазлыклар. Әйләнеп чыгу мөмкин түгел. Ә күпердән... Ай-һай, чыгарырлармы икән соң?..

Майор йокысызлыктан, ару-талудан кызарынган күзләрен уып алды да Тимофеевага текәлебрәк карап алды. «Нәрсәдер әйтеп бетерми бу?» — дигән уй ярылып узды. Шуңадырмы, Тимофеева артык көттереп тормыйча, турыдан әйтергә уйлады һәм Кадермәтовның терсәгеннән тотып читкәрәк әйдәкләде. Добротов алар артыннан кузгалмакчы иде дә, килүчеләрнең як-якларына карангалап торуларыннан шикләнеп, калырга булды.

— Иптәш командир,— диде Тимофеева тавышын бөтенләй диярлек яшереп, сугышчыларга ишетелмәслек итеп, урман буендагы юлдан атлый-атлый.— Иптәш Сталинның чыгышында әйтелгәннәрне беләсездер инде... Безнең бу районда немецлар оккупациясе вакытында хәрәкәт итәргә тиешле бер төркем иптәшләр һич көтмәгәндә тар-мар ителде... Хәрәкәт итә башламас борын отрядыбыз юкка чыгарылды... Күрәсең, арага дошман ялчысы кергән булган... Хәзер инде аны ачыклавы да кыен... Әллә, мин әйтәм, сез... биредә генә каласызмы?

Тимофеева артык кыю, артык ышанып сөйли иде. «Күрәсең,— дип уйлады Кадермәтов,— иптәшләрен югалтудан чарасыз калган. Беренче очраган хәрби киемле кешегә ышанып сөйләргә мәҗбүр».

— Юууук... Ничек биредә?— дип вакытны бераз суздьı Кадермәтов.— Без бит, хөрмәтле иптәш Тимофеева, сезгә билгеле булсын, Кызыл Армия сугышчылары... Безнең бурычыбыз...

Тимофеева ярыйсы гына кыю хатын иде бугай, аптырап калмады, Кадермәтовнең терсәген кысыбрак тотып аны сүзеннән туктатты:

— Әйе, иптәш Кудров, әйе... Аңлыйм мин. Безнең бурычыбыз бер— фашистларга каршы көрәшү, аларны үз жиребездән куу... Иптәш Сталин әйткәнчә, фашистларның аяк астында җир янарга тиеш... Ашыкмагыз... Уйлап карагыз хәлегезне. Сугышлар белән бара-бара кешеләрне мәгънәсезгә... Ярый, ярый,— диде ул Кадермәтовның нәрсәдер әйтергә чамалавын сизеп.— Ярый, мәгънәлегә булсын ди... Аннан ни файда? Чыгуын чыгып житәрсез... Ничәү? Кыскасы, иптәш Кудров, партизаннар хәрәкәте ул...

Кадермәтовның партизаннар хәрәкәте турында ишеткәне бар, хәтта икенче тапкыр чолганыштан чыкканда алар белән очрашып, бер-берсенә ярдәм дә итештеләр, әмма хәрби кеше буларак, боерыксыз-нисез калуы... Тимофеева сүзләрендә дә дөреслек бар. Корал житәрлек, аны табуы хәзер кыен эш түгел. Кешеләрне дә тупларга мөмкин. Аптырап, үзебезнекеләр ягына чыга алмаудан гаҗиз булып йөрүчеләр дә аз түгел. Аларны оештырырга кирәк, әлбәттә. Югыйсә, вакыйгаларның агышына кушылып китүләре... Уйлап карарга кирәк моны...

— Ярый, иптәш Тимофеева, безгә барыбер ял итәргә вакыт... Бераз урман эченәрәк керербез дә ял итеп, булганы белән сыйланып алырбыз... Сезнең тәкъдимегез турында да уйлап карарбыз,— диде ул үзе дә көтмәгәндә ниндидер бер көчкә буйсынып.— Әйдәгез, сез дә ул кадәр ашыкмыйсыздыр, күренә ки...

## 4

Агачлар сирәгәя барып, ниһаять, бөтенләй вак, тәбәнәк куаклыкка әверелә башлады. Аяк астында әледән-әле чыбык-чабык сынуы ишетелде. Кадермәтов, бераз уйланып торганнан соң, Тимофеева күрсәткәнчә, урман куерган жиргә кадәр барды да юлга якынаерга кушты.

Башта өч сугышчы, аннары алар белән бергә Кадермәтов үзе дә юлны күзәтергә керештеләр.

Күпергә таба килгән һәм аның теге ягына чыгып югала барган фашист гаскәрләренең иге-чиге күренми иде.

«Караңгы төшкәч, бәлки, азаерлар, шул арада чыгып өлгермәбезме, каравыл артык зурдан булмаса»,— дип уйлап алды Кадерматов, юлга таба кузгалыр алдыннан Тимофеева белән булган сөйләшүне искә төшереп. «Иптәш Тимофеева,— диде майор,— Сез безгә елга аша чыгу юлын, күперне дим, күрсәтегез... Сынап карыйк... Ни әйтсәң дә без үзебезнең якка чыгарга тиешбез»...

Караңгы төшә башлау белән юлдагы хәрәкәт кимү генә түгел, киресенчә, бермә-бер арта башлады. Бигрәк тә техника күбәйде. «Посып ятканнар, кабахәтләр,— дип уйлады Кадерматов, эһ, рация булсамы? — дип нишләргә белмичә өзгәләнде майор.— Ике-өч самолет чакырып китерсәң. Күрмәгәннәрен күрсәтерләр иде. Юк бит, юк...»

Шулай да ниндидер чара кылырга, теге якка чыгу хәйләсен табарга кирәк иде. Моны, билгеле, Кадерматов уйлап табарга тиеш. Сугышчылар аңарга өмет белән карый. Моңарчы сынатмаган командир бу юлы да берәр әмәлен табар дип ышаналар. Командирның авыр уйларын белгән кебек, күзәтүдәге сугышчыларның берсе үз-үзенә сөйләнгән сыман:

— Иптәш командир, күрәсезме, иптәш командир,— дип эндәште һәм өстәп тә куйды:— Әллә узып беттеләр, әллә инде ара хасил булдымы?

Чынлап та, әлегәчә фашист колонналары өзлексез диярлек агылып торган юл буп-буш иде.

«Хәзер, хәзер үк талпыныш ясарга! Югыйсә кайчанга кадәр монда посып ята алырбыз, барыбер күрерләр таң ата башлагач»,— дигән кыю теләк Кадерматовны ирексездән алга таба этәрде. «Тиз генә юлга чыгарга... Сафка тезелергә дә шул килеш күпергә якынлашырга... Аны-моны сизсәләр?.. Ул чагында дошманга ябырылырга һәм ул аңына килгәләгәнче...»

Шушы карар белән Кадерматов урыныннан кузгалды, өч тапкыр рәттән үрдәк сыман бакылдап, куаклыкның куерак җирендә яшеренгән төп төркемне үз янына чакырды һәм алар килеп җитүгә:

— Алга, тизрәк, тизрәк юлга, иптәшләр!— дип боерды ул юлга таба атлый-атлый. Хәер, куаклар арасында хәрәкәтсезлектән интегеп яткан сугышчыларга ике мәртәбә әйтү кирәк түгел иде. Алар, күз ачып йомган арада, Кадерматов янына тупландылар.

Шул вакыт төркемдәгеләр арасында Кадерматов кичкырын килеп кушылучы милиционерларны һәм Тимофееваны күрде. Алар да башкалар кебек үк ашыга-ашыга атлыйлар иде.

— Сез... иптәш Тимофеева, калмыйсызмыни? Без күпергә... омтылыш ясап карамакчы булдык.

Тимофеева тирән сулыш ала-ала:

— Юк эш бу, иптәш командир... Сез биредәге хәлне тиешенчә бәяләп җиткермисез... Ярый инде, тәвәккәл таш яра, диләрме әле? Без дә сезнең белән теге якка чыгарга омтылып карыйбыз, командир... Анда чыгуын чыга алсак, үз юлыбыз белән китәрбез,— диде Тимофеева. Аның Кадерматов карары белән килешмәве сүзләреннән үк сизелеп тора иде. Ләкин хәзер бәхәсләшеп торыр вакыт түгел. Бер карар кабул ителдеме, дөресме-түгелме икәнен тикшерергә ара юк, аны ничек тә утәү ягын карарга кирәк.

— Бегом... Марш! Юлга,— дип боерды майор.— Алга таба хәбәр итегез: юлга чыгу белән өчәрләп колоннага тезеләбез... Уртадагылар күпергә... Әгәр немецлар эшне аңлап алса, кырыйдагылар як-яктагыларга ут ача... Добротов уртаның уртасына баса! Тизрәк! Тизрәк!..

Юл белән куаклык арасындагы йөз илле метр араны эһ дигәнче, бер тын белән йөгереп мендeләр. Эңгер-меңгернең куелыгыннан оста файдалану булып чыкты бу.

Әй син, Кеше туганым! Тәвәккәл, ашкын һәм күп очракта искиткеч ваемсыз беркатлылык күрсәтүче, очраклылык галиҗанәпләренә язмышын тапшыручы зат! Табигатьнең әллә нинди серләрен ачтың, күкләргә мендең, җир астына төштең һәм андагы байлыкларны алуга ирештең, төньяк һәм көньяк полюсларны иңләдең, химия, медицина һәм физика өлкәсендә хыял житмәс уңышларга ирештең, әмма син, Кеше туганым, гап-гади бер нәрсәне — үзеңнең соңгы минутларың, үләр мизгелләреңне сиземләү дәрәҗәсенә күтәрелә алмадың...

Юлга менеп, күпергә таба кырык-илле адым атларга өлгермәделәр... арт яктагы урманнан, әле генә сугышчылар атылышып чыккан куаклык янәшәсеннән дәһшәтле гөрелте ишетелә башлады.

«Танклар!»— дигән уй Кадермәтовнең миен яндырып узды. Ул хәзер инде нинди башсызлык эшләвен аңлап өлгергән иде, шуңадырмы, тәненең эсселе-суыклы калтырап алуын тойды.

— Бегом,— дип кычкырды ул болай да җан-фәрманга йөгереп баручы сугышчыларына канатлар куярдай булып:— Бег-ооо...

Шул ук мизгелдә, Кадермәтовның әмерен бүлдереп, күпер төбеннән бер-бер артлы өч ракета күк караңгылыгына таба атылды. Алар чыжылдавык сызгыру белән чөелә барып, утлары кабыныр-кабынмас борын ук инде күпер саклаучыларның:

— Ахтунг... Хальт... хальт!— дигән тавышлары яңгырады.

Тавышлар сүнәргә өлгермәде, кичке караңгылыкны ярып, Кадермәтов төркеменә таба ялтыравык эзләр сызылды. Ул очкыннарның беренчеләре сугышчылар өстеннән узганда фашист пулеметының саңгырау такылдавы да килеп җитте, аннары «шмайссер» лар тегү тегәргә кереште.

Кадермәтов эт оясына таяк тыгып алуларын аңлады гына түгел, һәлакәтчән чынбарлыкны бөтен күзәнәге белән тойды: бу тәвәккәллек — үлемгә баручылар тәвәккәллеге иде.

Көтелмәгән һөҗүм, аның кискенлеге үзенекен иткән — күпергә нибары илле-алтмыш адым гына калган иде. Ләкин шушы араны үтәсе бар! Аның өчен унбиш, күп булса егерме секунд кирәк... Әмма шушы арада сугышчыларның күпчелеген әлеге такылдавык пулеметлар озакламый танклар үтәчәк юлга түшәп салачак иде.

— Уңга... Юл артына!— диде Кадермәтов барлык көчен тамагына салып һәм кулындагы трофей автоматтан күпер төбенә, ялтыравык очкыннар күтәрелгән төшкә ут яудыра-яудыра, нинди дер төпсезлеккә очып төшә башлады.

Бәхеткә каршы, кече лейтенант ерак китеп өлгермәгән икән. Йөгерүеннән туктап, ул да командир янына таба чигенде:

— Мин монда, командир, борчылмагыз,— диде.— Ашыгыгыз...

Бу якка төшәсе булмаган икән...

## 5

Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер дигәндәй, юлдагы кыяматтән котылган сугышчылар мондагысына тагын да хәтәррәгенә килеп тераллеләр. Дамбадан тигезлеккә ташланып йөз илле адым китүгә, каршыдан, уңнан һәм сулдан яуган ут астына эләгеп, җиргә капланып ятарга мәҗбүр булдылар. Алар ирексездән яңа бер капкынга — елга яры белән дамба арасындагы болынлыкта яшеренеп яткан дошман өстенә бәрелә яздылар...

— Нишлибез, командир?!

«Нишлибез, командир?— дип эчтән генә кабатлады Барый Кадермәтов.— Нишлибез?..»

Чынлап та, нишләргә, дошман тозагына үз аякларың белән килеп кергәч, алдан-арттан, уңнан-сулдан кургаш яңгыры явып торган минутларда нинди чара табарга, сугышчыларны ничек итеп һәлакәттән коткару чарасын табарга соң?

Дошман ягыннан бер-берсенә таба кыеклап-кыеклап чөелгән ракета нурлары сүнгәләгәнче, Кадерматов тирә-якны карап-чамалап өлгерде.

Үләне котырып үскән болын аларны кочагына алды. Дөрес, хәзер ул чәчәкле печән болынына түгел, тапталган, аннан-моннан гына сөрелгән басуга күбрәк охшап тора. Ләкин, кем әйтмешли, һәр начарның бер яхшы ягы була, шушы тәртипсезлек, берсеннән-берсе авыррак машиналар һәм танклар салып узган эзләрдә сугышчыларның бәхете — күпмедер вакытка башларын яшерер урыннар бар иде.

Привалдагы дошман аларны оешкан көчкә санамый, тар-мар ителгәннән соң фронт ягына таба баручы фанатикларның таркау төркеме генә, дип уйлый булса кирәк.

— Урында калырга! Түгәрәк оборонага күчәбез!— дип кычкырды майор якындагыларга җаен туры китереп һәм шундук Добротовка борылып:— Уңга таба шуыш, лейтенант... Сугышчыларны мөмкин булганча дошман һөҗүмен каршыларга оештыр. Мин сулга таба китәм. Йөз метрдан артык бармассың...

Төнге караңгылыкны ярып, тагын ике ракета берьюлы өскә чөелде. Кадерматов, ракеталар чыжылдый башлауга, тапталган, ләкин әле үзләренең хуш исләрен югалтырга өлгермәгән үләннәргә башын куйды, ләкин шундук яңадан күтәрде һәм ике-өч адым шуышып киткән Добротовка:— Ә-ә-нә тегендә, артта, сынган агач янында очрашырбыз,— дип өстәде.— Игебаев, син Добротовтан бер адым да калмыйсың... Алга!...

Ул арада атыш гөрелтесе тынып калган иде. Ләкин Кадерматов моның вакытлыча гына икәнлеген, таң ата башлауга озакламый аның тагын да хәтәррәк булып яңгырасын, дошманның үзләрен юк итәргә тырышачагын сизә иде.

## 6

Түгәрәк оборонага күчү турында әлегә бердәнбер дөрес боерыкны бирде бирүен Кадерматов, ләкин аның күңелендә утлар кайный иде. Моңарчы да иң кискен минутларда көтелмәгән, ахырынача уйланылмаган карар кабул итәргә туры килмәде түгел анысы. Әмма сугышчыларны мондый тозакка кертеп бастыру... Әллә нәрсә булды Кадерматовка. Өч айдан артык туктаусыз сугышлардан чыкмыйча йөрү дәверендә мондый төшенкелеккә бирелгәне булды микән? Кадерматов — тәҗрибәле командир, ул яхшы белә: төшенкелек дигән нәрсә барлык бәлаказа һәм авырлыкларның да иң явызы. Явызларның явызы, чөнки күңелең бер төшенкелеккә бирелдеме, аңардан котылуы кыен, ай-һай, кыен! Кадерматов хәтерли: фин сугышы вакытында взвод командиры Иван Падун җитәкчелегендә төркемне дошман тылына разведкага җибәрергә туры килде. Фронт сызыгын исән-имин узуларын белгәнгә күрә, бирелгән заданиены да уңышлы гына башкарып кайтырлар дип өмтләнгән иде. Әмма...

Төркем кайтырга тиешле көнне иртәдән үк күз ачкысыз буран купты, җилекләрне туңдырып җил өрде. Ниһаять, көтә-көтә билгеләнгән сәгатьне җиткерделәр, тик разведчиклар гына күренмәде, дошман ягыннан ник бер тавыш әсәре ишетелсен...

Көттеләр, көттеләр, ләкин өметләнү бушка булды. Разведчиклар ул көнне дә, бер атна узгач та әйләнеп кайтмадылар. Кадерматовка рәхмәт әйтмәделәр, билгеле, ләкин аның сәләтле, тәҗрибәле командир икәнлеген белгән югарыдагы иптәшләр әллә ни бәйләнмәделәр.

Унөченче көн дигәндә төркемдәге иң оста разведчик, срогыннан тыш хезмәттәге сержант Володинның күрше дивизия каршына килеп җитә алганын хәбәр иттеләр. Кадерматов кичекмәстән шунда юнәлде.

...Буранлы төн кайту ягына чыккан төркемне юлдан яздырган, өстәвенә, әледән-әле дошманга юлыга барып, бәрелеш саен кеше югалткан-

нар һәм, ниһаять, Володин белән командир икәүдән-икәү генә калганнар. Житмәсә, бәрелешләрдән чигенә-чигенә фронт сызыгыннан ерагайганнар. «Менә шундый чакта,— дип сөйләде Кадерматовка сержант Володин,— иң куркынычы, уйга кертеп тә чыгармаганы башланды: взводный төшенкелеккә бирелде. Ни генә эшләп, ни генә сөйләп карамадым, файдасызга булды. Теге бичараның авызында: «Беттек, Володин»,— дигән ике генә сүз. Шушы төшенкелек бәласедер инде, бәрелешләрнең берсеннән чигенгәндә взводный аягындагы итеген кар эчендә батырып калдырды... Бер төн эчендә күзгә күренеп диярлек картайды, чәчләренә, ышанасызмы, юкмы, чал сукты. Күпме вакытлар кар өстендә яшәп тә булмаган хәл, взводныйның битләре, аннары куллары туңып әйбер тота алмаслык хәлгә килде, аягына ураган нәрсәләр дә ярдәм итмәде. Өч көн дигәндә мескенемнең җаны чыкты... Кичкырын аны тирән бер чокыр төбенә алып төшеп кар астына күмдем дә алга киттем. Тупланган мәгълүматларны кайтарырга кирәк иде».

Сержант сөйләгәннәрне хәтерләү Кадерматовны сискәндереп жибәрде, хәтта калтыранып куярга мәжбүр итте.

Майор, игътибарын тирә-яктагы хәлне ачыклау-аныклауга җигәргә тырышып, тавышларны тыңларга керешә. Еракта сирәк ухылдаулар, күпер янында сирәк-мирәк чөелгән ракета чыжылдавыннан башка әлегә һичбер нәрсә ишетелми сыман. Хәер, тагын да игътибар беләнрәк тыңласаң, сугышчыларның окопсыман чокыр казырга тырышуларын да чамалап була. Әһә!.. Димәк, Кадерматовның колакларын томалаган контузия зәхмәте бөтенләй беткән, ишетү сәләте кайткан дигән сүз. Димәк, Кадерматовның күзләре күрә, колаклары ишетә, баш мие ару гына эшләп тора. Димәк, бу үлем тозагыннан чыгу юлын да эзләп табарга мөмкин, бары тик төшенкелеккә генә урын калдырмаска, аны куарга, беренче нәүбәттә үзеңнән куарга, чөнки ул әшәке чирнең сугышчыларга да йогуы бар. «Юк,— диде ул үз-үзенә,— юк, болай ансат кына бирешмәячәкбез дошманга...»

Кадерматов бер-берсен белгән сугышчыларга иптәшләрен барларга кушты. Фашистлар, тынычланып торгандай булсалар да, ара-тирә котырынып ут ачалар, туктаусыз диярлек ракета чөяләр. Ләкин моңа карап кына юлдагы танклар хәрәкәте туктамый, алар фронт ягына таба узып китә торалар иде.

— Биш сугышчы һәм... бер милиционер юк, иптәш майор,— диде Добротов карлыккан тамак төбен чистартырга тырышып, учына йөткергәләп.

Кадерматов чираттагы ракета чөелеп килеп яктырган арада Тимофееваны күреп алды. «Ишеттеме?» Юк, ишетмәгән иде бугай. «Ярыйсы гына чая хатын бу, йөзендә ни аптыраш, ни курку галәмәте күренми»,— дип уйлап алды майор.

Үзе турында уйлаганны белгән диярсең, аның «Я, нишлибез, командир Кудров? Тозак капчыгының капчыгына эләктекме?»— дигәндәй шуышып килүе күренде.

Озакламый таң ата башлар һәм туар көн яктысында фашистлар күзенә уч төбендәге кебек күренеп торган сугышчыларга ни буласы аермачык иде.

Ул да түгел, фашистларның өзек-өзек кычкырып боерык бирүләре яңгырады. Алар күпергә омтылган совет сугышчыларына тын алырга ирек бирмичә, ничек тә өтәләп чыгармакчылар иде. Шуны раслагандай, фашистлар минометлардан ут ачты.

Баштагы тонык ухылдаудан соң кемнеңдер «Аһ»— дигән ыңгырашу авазы төнге салкынча һавага ыргылды.

— Кем ул анда? Синме, Добротов? Ни булды?— диде майор икенче залпны көтә-көтә.— Ни булды, Добротов?

— Да-аа... Кулны... кулны өзде, сволочь...— дип әллә ничә катлы итеп сүгенде Добротов.— Кууулны...

Кадерматов, үлән сабакларын аралый-аралый, Добротов янына килде.

— Кая, бир әле кулыңны,— диде ул һәм үрелеп Добротовның кулбашыннан тотты. Кул үз урынында, ләкин ул мунчала сыман салынып төшкән иде.

— Ничего, Добротов, без әле бу кул белән...— Кадерматов: «Полк байрагын тотып узарбыз»,— димәкче иде, тыелып калды.— Син әле бу кул белән, Добротов, дистәләгән фашистның муенын борып сындырырсың.— Ул шулай диде дә ике куллап кече лейтенантның кулын аска тартты һәм бер үк вакытта алга таба борды.

— Аһ, мать твою... Ух... Убил... фашист окаянный...

— Түз, кадерлем, түз!

Добротовның кулы элеккеге табигый хәленә кайткан иде инде.

Өченче залп ишетелмәде. Тагын тынлык урнашты.

## 7

«Ни булды, нигә туктадылар болар?— дип сагайды Кадерматов, кече лейтенантка ярдәм күрсәтеп, тегенең кулын урынына утырткач та.— Нигә туктадылар?»

Кадерматов кабат күпер ягына төбәлде... Нинди зур кичү бит. Безнекеләрнең аны шартлатмыйча фашистлар кулына калдыруы бер гаҗәп булса, безнең авиациянең шушы кичүне пыран-заран китерергә омтылмавы тагын да сәеррәк, дип уйлавын дәвам итте ул. Хет бер-ике самолет очып килсен дә чукындырып китсен иде фашистлар кулына төшкән күперне...

Ул уеннан бүленде, башына килгән яңа фикернең кыюлыгыннан сискәнеп куйгандай итте, күпер корылмаларын, аннан да битәр, дамбаның биеклеген сынап карады. Дамба әллә ни текә түгел, ләкин ут астында менәр өчен шактый биек, әмма ыргылышның кискен, көтмәгән чагында, бигрәк тә, бомбага тоту вакытында менмәслек дип тә булмый. Кадерматов аңлады: хәзер аларның бу тозактан котылу мөмкинлеге — күпергә һөҗүм итеп маңгайга маңгай чәкәшүдә, сугышчыларны югалтып елганың киң һәм тирән суына ташлануда түгел, ә менә шушы дамбага бер тын белән сикереп менү, гранаталар, штык һәм приклад белән дошманны миңгерәтүдән соң теге яктагы әрәмәлеккә кереп югалудан гыйбарәт иде. Ләкин бу максатка ирешү өчен ышанычлы ярдәм — безнең авиациянең дошман кулындагы күперне бомбага тота башлавы кирәк...

Кадерматов бу планның тулысынча диярлек очраклылыкка корылуын аңлый. Хәер, төптән уйлап караганда, Кадерматов башына килгән бу кыю фикер бөтенләй үк нигезсез түгел иде. Чөнки аларның һәлакәтен якынайтучы якты көн бер үк вакытта күпер тирәсенә тупланып өлгергән фашистларның да көлен күккә очырырга мөмкин. Чөнки күпер мөһим стратегик кичүне тәшкил итә.

Шулай булгач... туачак көннең Кадерматов сугышчыларына һәлакәт кенә түгел, ә бәлки тозактан котылу мөмкинлеген дә алып килүе ихтимал.

Бераздан Кадерматов иртәнге әнгер-меңгернең сыегая башлавын, дамба һәм күпер корылмаларының табигый яктылыктан ачыкланыбрак күренә башлавын чамалады.

Кадерматов һәм аның тирәсенә тупланган сугышчыларның бәхет дигән нәрсәләре әллә кайларда, күк гөмбәзенең иксез-чиксезлегендә генә йөрми икән әле... Туып килгән якты көн фашист хәшәрәтләренә ачык йөзен күрсәтергә ашыкмый кебек: әнә ул күпер корылмаларына, дамбага болындагы үләннәр арасына яшеренгән сугышчылар өстенә сөтсыман куе томан чыбылдыгын каплый башлады.

Дошман тозагыннан котылу чарасы белән мавыгып киткән Кадерматов фашистлар ягыннан нәрсәдер шытырдап алганын ишетте. Җир өстенә ябырылып төшкән куе томанның үзләренә өстәмә ярдәм икәнлеген аңлау куанычы арткарак чигенде. Беравыкка тынып торган нәрсә тагын шытырдарга кереште.

8

«Нәрсә булыр бу,— дип уйлап алды Кадерматов — тагын нинди этлек уйлап таптылар икән?»

Шытырдау тагын, бу юлы исә көчлерәк һәм озаграк кабатланды. Аның артыннан ук, Кадерматов һәм аның сугышчыларын сискәндереп, су буе киңлеген яңгыратып русча дәшкәннәре ишетелде.

— Кхы-ым-кым... А-а-нна Матвеевна... Командир Кудров... Болар... ни... сезгә чыгарга кушалар... Әгәр бирелмәсәләр, томан таралуга минометлардан куырып чыгарабыз диләр...

Кадерматовны гаҗәпләндереп, Тимофеева, көтмәгәндә, тозлап-борычлап сүгенде:

— Павлов бит бу, эт җан! Елан маен ялаган нәмәрсә,— дип төкереп тә куйды.— Бик тиз, бик тиз сындырганнар моны. Ни-и-чек сайрый! Эх, белгән булсам... Хәер, дуңгыздан, билгеле инде, бервакытта да кондыз ясап булмый.

Томан куелыгыннан тагын Павловның тавышы килде:

— Бирелегез... Алар сезгә берни дә эшләмиләр. Менә бит миңа тимәделәр... Томан беткәнче чыкмасагыз, минометлары әзер!

Кадерматов аның бер генә сүзенә ышанды: фашистлар, һичшиксез, томан таралуга аларны юк итәчәк иде.

— Иптәшләр... Минем арттан шуышыгыз. Дамба читенә якынаерга кирәк,— диде ул һәм беренче булып шуышырга кереште.— Тавышланмаска! Боерыкны чылбыр буенча кабатларга!— дип өстәде ул, бер-ике адым шуышкач.

Шулвакыт тагын көчәйткечнең шытырдавы ишетелде.

— Сугышчылар,— диде сатлык җанның карлыгып калган тавышы,— сугышчылар... Җиңелмәс немец армиясе командирлары әйтергә куштылар: яхшылык белән чыгып котылыгыз... Командирларыгызны тотып бәйләгез дә үзегез белән алып чыгыгыз... Сезгә берни булмас... Лагерьга озатырлар... Сугыш беткәнче рәхәтләнеп эшләп, туйганчы ашап ятырсыз,— диләр. Исән калырсыз... Уралга кадәр сузылачак Бөек Дәүләттә... тугрылык күрсәтсәгез, туган җирегездән җир бирерләр...

«Кара син бу эт җанны, ничек сайрый! Тыны да чыкмаган иде... Ул җирне фашист өере түгел, бөтен дөнья капкорсаклары берләшеп тә яулый алмады бит әле...»

Добротов кечәге мина шартлавыннан тәмам аңышкан, күзләренә нур иңгән, карашы ныгыган, элеккедәй яшь, көчле рухлыга әверелгән иде. Дамбага барып җитәрәк ул:

— Әллә, иптәш командир, өч-дүрт сугышчы белән разведка ясап карыйммы?— дип тәкъдим ясады. Кадерматовның да шул хакта баш ватып торганын белгәннәр диярсең, Тимофеева янәшәдә генә иде, ул да хуплап кушылды. Үзенең юеш һәм салкында шуышудан теше-тешкә тимичә калтыравына да карамастан, бирешергә исәбе юк иде аның.

— Әйе, әйе, тәвәккәлләп карыйк соң, командир...— диде ул.

Әле көчәеп, әле акрыная төшеп, күпергә таба дошман танклары узып тора иде.

«Томан булгач, яшеренмиләр... Кайдадыр фронтта кирәк булганга шулай ашыктырып кауллыйлар боларны. Эх-ма, рация булсамы?— дип ачынды Кадерматов.— Ике-өч кенә самолет чакыртыр идек. Күрсәтерләр иде күрмәгәннәрен бу килмешәкләргә»...

— Юк,— диде өзен кенә Кадерматов.— Юк!— Ул хәзер баягыдан да кыюрак план өлгертеп кила иде.— Юк, Добротов, разведка ясап тормыйча, кинәттән һөҗүм итәбез...

## 9

Кыюлардан үлем курка ди халык. Кадерматовның башында ялтырап ярылган яңа фикер әнә шуны тагын бер кат раслый иде. Фашистлар үзләренчә: «Тар-мар ителгән Кызыл Армиянең рухы сынган сугышчыларын тозакка каптырдык, озакламый алар кулларын күтәреп, мәрхәмәт сорап безнең алга чыгачак. Чыкмасалар инде без аларны бер селтәнү белән юк итәбез»,— дип тынычланган булгандыр, бәлки. Ләкин алар гап-гади бер нәрсәне: «Тар-мар ителгән» Кызыл Армия майоры Кадерматов һәм аның сугышчыларының фашистлардан мәрхәмәт сорау турында бөтенләй уе юклыгын исәпкә алмадылар. Томанга яшеренеп кенә кетмәгәндә юл дамбасына үрмәләгән сугышчыларны фашистлар иң соңгы минутка чаклы күрмәделәр. Үлем белән якага яка килеп тә, яшәүгә өметләрен югалтмаган сугышчыларның һөҗүме тиз һәм ярсулы булды.

Дамбадан баручы танклар колоннасының берсе узып китеп, икенчесе килеп җитмәгән бер мәлнең туры килүе Кадерматовка кыюлык өстәде. Ул гранатасының алкасын ычкындырды да, күкрәгенә иртәнге салкынча һаваны тутырып, кыска гына боерык бирде:

— Ут!!!

Бу боерыктан соң махсус билгеләнгән сугышчылар инде юл дамбасының яртысыннан артыгына күтәрелергә һәм гранаталарын дошманга ташларга тиеш иде.

Кулындагы гранатасын өскә таба бәрүгә, Кадерматов башын дамба итәгендәге вак ташларга куйды, аларның юеш салкынлыгын бөтенләй сизмәде дә, чөнки аның бар уе алга таба юнәлгән иде.

Дүрт секунд... Нибары дүрт секунд вакыт болай караганда бик аз, искиткеч аз ара, әмма яшәү белән үлем хакында бәхәс барган чакта бу мизгелләр дәвамында әллә никадәр эш башкарырга, уй уйларга, тормышының иң четерекле вакыйгаларын күз алдыннан уздырырга мөмкин.

Барый Кадерматов беркайчан да куркакларны акламады һәм анламады, чөнки ул үзе тумыштан ук тәвәккәл, кыю кеше иде. Ләкин аның күкрәгендә чуерташ түгел, ә йөрәк тибә. Күп мәртәбәләр үзенең дә ишеткәне, күзәткәне, кичергәне бар: курку дигән тойгыны бөтенләй белмәгән кеше була алмый. Курку ул — сөйли, көлә һәм уйлый белә торган җан иясе өчен табигый тойгы. Һәр яңа бәрелеш, яңа һөҗүм, гомумән, дошман белән йөзгә-йөз очрашып алдыннан маңгайга салкын тир бөртекләре бәреп-бәреп чыга. Дамба тирәсенә сыенып яткан сугышчыларга һәр грамм кешенең йөрәген тибүдән туктатырдай кургаш өермәсенә каршы гимнастеркадан битәр калканы булмаган хәлдә күтәрелүе кыен, бик кыен иде.

— Ал-гааа!!!

Дамба кикригенә күтәрелеп алга ыргылуга, күпер ягыннан һәм болында привалга туктаган фашист машиналарыннан пулеметлар ут яудырырга кереште. Сугышчылар арасыннан берәү кыска, ләкин гаять әрнүле «Аһ!» дигән аваз чыгарып җиргә ауды. Тыныч вакытта теләсә кемнең колагын торгызырдай итеп сүгенгән тавыш та ишетелде. Кадерматов миномет янындагы озын буйлы, мөгаен, үзеннән ике башка биегрәк таза гәүдәле немецның куркудан атылып чыгарга җиткән күзләрен, ыржайган тешләрен күрде. Ике ара шул хәтле якын иде ки, беренче мизгелдә Кадерматов әлеге фашистның йөзенә карап «Атаргамы-атмаскамы?» дигән кебегрәк икеләнеп калды. Бу мизгел шундый кыска — мизгелнең мизгеле генә иде, әмма шушы тоткарлык үзенекен итте. Кадерматов, автомат чакмасына басарга өлгерә алмыйча, килгән

шәпкә бөтен көченә фашистның корсагына барып бәрелде. Бәрелү үзе дә шундый көчле булып чыкты ки, бик сирәк кеше генә мондый бәрелештән соң аягында басып калыр иде. Майор үзе дә бәрелүдән резин туп шикелле артка чигенде. Чигенгән чакта ул аяк астында аунап яткан мина тартмасына абынды, тигезлеген саклап калырга тырышса да булдыра алмады, янтаеп җиргә ауды. Бу хәрәкәт аны баладән коткарды, куәт белән башына килеп төшәчәк куш йодрыкның җилкәсенә ышкылып китүенә генә сәбәп булды. Алай гына да түгел, үзенең куш йодрыгына ияреп, дәү фашист танавы белән Барый Кадерматовның аяк астына кадалып төште. Шул ук секундта майор автоматының түтәсен дошманның аркасына кундырды. Тик бу юлы да очраклылык кагыйдәсе үзенекен итте. Автомат түтәсе дошманның әйберләр тулы биштәренә туры килгән иде. Фашист, күрәсең, сугышларның төрлесен күргән, ачысын-төчесен татыган немец булып чыкты, ул танавы белән җиргә кадалса кадалды, тик бер үк вакытта кулы белән Кадерматовның итегеннән тотып үзенә тартырга өлгерде. Майор, киселгән агач кәүсәсе сыман, җиргә егылды. Егылып җитмәс борын ук янга таба тәгәрәп китмәкче иде, тик бу юлы инде очраклылык дигән нәрсә аңа каршы төште, дошман солдатын өлгеррәк итте. Имән бүрәнәдәй таза фашист, бөтен авырлыгын аңлашылмас көч белән җиңеп, Кадерматов өстенә ташланды. Бу авырлыктан майорның сөякләре шыгырдап куйды, күкрәге кысылып, тын алмаслык хәлгә килде. «Беттем»,— дигән иң соңгы бер мизгелдә ул кинәт фашист гәүдәсенең йомшарып, хәлсезләнеп калуын тойды, шуның артыннан ук:

— Сез исәнме, командир, яраланмадыгызмы?— дигән кайгыртучан сүзләрне ишетте.

Әйе, бар иде, бар иде Барый Кадерматов дигән затның бәхет дигән канатлы кошы. Югыйсә, иң явыз көчләр ябырылган минутларда ул кош аны үзенең канат-калканнары белән каплап килмәсә, ничек итеп өч ай буена тоташ сугыш эчендә йөргән тәненә бер ядрә янсә кыйпылчык эләкмәс тә, ничәмә-ничә тапкыр әҗәл хәтле әҗәл кулыннан ычкынып калыр иде соң ул?

— Рәхмәт, кадерлем...— диде ул, үзен үлемнән я булмаса хурлыклы әсирлектән коткарып алган сугышчыга карап. Вакытның һәр секунды кадерле чак булганга, ул аның бары тик кабарып торган мыегын гына абайлап өлгерде. Икенче күзе белән сугыш мәйданын күзәткән килеш, ә бәлки күреп тә түгел, күңеленең нинди дер сизгер җепләре белән тоептыр, һөҗүмнең нәтиҗәле икәнлеген аңлады.

— Коралланырга! Пулемет һәм патроннар алырга!— дип кычкыра иде аңардан биш-алты адым читтәрәк Добротов.— Коралларны калдырмаска!

Һөҗүм башланып, күп дигәндә дүрт-биш минут узуга карамастан, иртәнге әңгер-меңгер куелыгында сыегая төшкән томан яңа көн яктылыгында эреп таралырга җыена иде инде.

Ул арада Добротов, аның артыннан ук Игебаев та җилкәләренә фашист автоматларын аскан хәлдә Кадерматов янына килделәр.

— Мондагыларның эшен бетердек, дөмектердек, командир... Әллә, мин әйтәм, күпер төбендәгеләренә дә бер уңайдан бәрәбезме? Бәлки, чыгып китәрбез?— диде уңышлы һөҗүм белән рухланган кече лейтенант, төнге хәлләрне онытып.

Әмма бер тапкыр авызы пешкән Кадерматов хәзер инде һәрбер хәрәкәтен уйлап, бер генә дә түгел, җиде кат уйлап эшләячәк иде.

## 10

— Юк, Добротов, бәрмибез. Алга, тизрәк алга — юлның теге ягына! Туплану урыны — кичәге салам кибәннәре,— диде майор һәм кем-

нендер юл буйлап, нелә төшебрәк күпергә таба йөгергәнен күрде. Ул бар көченә:

— Тукта... тукта... Артка! — диде. Эмма йөгерүче үзенең нишләгәнен яхшы белә иде бугай, тагын да тырышыбрак алга ыргылды.

Кадерматов, ялгышмас өчен сул кулын терсәгеннән бөгә төшеп, уң кулындагы пистолетын беләзек турына куйды да җентекләп төбәгәннән соң курокка басты. Әлеге тетрәнү-кичерешләрдән соң аның кулы элеккечә үк нык түгел иде шикелле. Шулай да пуля барыр юлын тапты, теге бәндә җан-фәрманга йөгереп барган уңайга юл уртасына кадалып төште. Кызганычка каршы, аны карап торыр вакыт түгел, немецлар инде бу якка таба кузгала башлаганнар иде. Кадерматов бар белгәнен кушып сүгенде дә:

— Яраланып калучылар юкмы? Калдырмаска! Китәбез, — диде һәм дамбаның теге ягына, әлегә качып котылырдай иркенлеккә тәгәрәп төшә башлады.

Болын түмгәкләре арасындагы әсирлектә күшегеп ятканнан соң иркенлекне тоеп йөгерүләр бөтенләй башка иде. Фашистлар куып керткән тозактан инде котылуларын, икенче юлы мондый капкынга кермәскә, алдын-артын җиде кат карап керергә тырышачакларын беләләр, шуңа күрә икеләтә көч белән йөгерәләр алар.

— Без монда, иптәш командир, бире килегез, — дип каршы алды аны Добротов. — Мондарак...

— Тимофеева сезнең яндамы?

— Борчылмагыз, командир, без аны калдырмадык. Әйдәгез...

Шул вакыт сугышчылар иләмсез гүләү авазлары ишетеп, дәррәү югарыга, күпер ягына карадылар. Анда күперне һәм күпер төбендәге фашистларны дөмектерү максаты белән килгән совет самолетларының берсе яна-яна җиргә якынлашып килә иде. Сугышчылар бу самолеттан парашютчы аерылмасмы дип өметләнделәр. Арадан берәү хәтта: «Я, сикер инде, сикер!» — дип кычкырып та карады. Ләкин бу теләк кабул булмады, янып барган самолеттан берәү дә сикермәде һәм ул, шул килеш күперне узып, елга суына томырылды...

Тирә-якны гөрселдәтеп көчле шартлау яңгырады. Тагын бераздан шушы гөрселдәүнең ерак кайтавазлары әйләнеп кайттылар да, авыр ухылдашып, елга аръягына китеп югалдылар.

Уңышлы һөҗүм шатлыгына күләгә төште. Кадерматов та, бүтәннәр дә монда артык озак калырга ярамавын аңлыйлар иде. Шуңа күрә тиз-тиз генә барлау уздырдылар да күпер ягына тагын бер тапкыр карап тын тордылар. Арттан килүчеләр күренми-ишетелми иде.

— Кузгалырга! — дип боерды Кадерматов. Аннары, сугышчылар куаклыкка кереп киткәч: — Иптәш Тимофеева, — дип эндәште. — Мине көтегез әле... — Беравык сүзсез баргач, башын чайкап уфтанып алды һәм өстәде: — Тагын бер иптәшегезне... качмакчы иде, калдырырга туры килде.

— Колагын кисеп кенә ишәк чапкын булмый инде, иптәш командир, — диде беравык дәшмичә барганнан соң Тимофеева. — Икмәк эчендә дә кибәк очраштыргалый...

Аның хәлен аңлап була иде, билгеле.

Тавыш-тынсыз диярлек бардылар. Ара-тирә кыска боерык тавышлары гына ишетелгәләде. Добротов берничә сугышчыны алга дозор итеп җибәргән икән. Алардан әледән-әле хәбәр килеп торды. «Әйбәт егет булып чыкты кече лейтенант», — дип күңеленә беркетеп куйды Кадерматов.

Тоташтан дүрт сәгать чамасы барганнан соң:

— Туктарга! Ярты сәгатьлек привал, — дип белдерде командир. — Барлау уздырырга!

Ләкин... барлау уздыра алмадылар... Ял итәргә туктауга, коточкыч арыган сугышчылар җиргә ату белән саташулы йокыга талдылар.

Биредә атыш тавышлары, шартлау-гөрселдәүләр, ишетелми. Әйтерсең, андый нәрсәләр бөтенләй булмаган, әйтерсең, аларның сугышчан дусларын берничә грамм кургаш мәңгелек йокыга талдырмаган... Урман, андагы кош-корт, җәнлек-мазар да сугышчылар кебек үк, таң алдындагы авыр йокыда. Ләкин бу хәл сугышка хәтле булган кайгы-хәсрәтсез йокы түгел, киресенчә, тынычсыз, авыр, гадәттән тыш уяу йокы иде.

— Сез дә бераз йоклап алыр идегез, иптәш командир,— диде Кадерматовка янәшәдәге агачка аркасы белән сөялгән Петров.— Ятыгыз... Мин сакта торырмын. Ул-бу булса, уятырмын...

— Ә соң сез, Петров, йокламыйча түзәрсезме?

— Минме? Күпме кирәк, командир?

Петровның тавышы, вакытына күрә, хәтта бераз балаларча бераз катлырак ишетелде. Кадерматов, сизелер-сизелмәс, ирен читләре белән генә елмаеп куйды. Ләкин сугышчы аның елмаюын күрмәде, шуңа күрә сүзен дәвам итте:

— Минме, иптәш командир? Мин бит Уссури тайгасында гомер кичергән кеше, аучы! Ничәмә-ничә тапкыр юлбарыс белән алышкан аучы! Мин тагын теләсә күпме түзеп торам әле... Аннары, әнә, Игебаев белән алмашырмын...

— Ярый, ярый, Петров, ышанам мин сиңа. Рәхмәт сиңа, аучы кеше,— диде ул, ниһаять, сингә күчеп, якын итеп.

— Рәхмәткә иртә әле, иптәш командир,— диде Петров каушаган елмаю белән.— Җиңү хөрмәтенә булыр...— Һәм ул чолгауларын сүтәргә керешге.

— Бу хакта икеләнмәскә мөмкин, иптәш Петров. Без, нинди генә авырлыкларга тарысак та, җиңәчәкбез. Һичшиксез...

Петров тавыш-тынсыз диярлек чолгауларын сүтеп бетерде.

— Анысы шулаен шулай да, иптәш командир... Ләкин... ләкин ничек соң без шул хәлгә килеп җиттек?— диде ул, кинәт тавышын әкренәйтеп, пышылдауга күчеп диярлек.— Ничек соң безне фашист гаскәрләре таптап-туздырып, ил кинлекләренә сибелергә мәҗбүр итеп бара? Кайда соң безнең запас юлдагы бронепоездлар? Кайда? Инде бит биредә — Смоленск янында да туктата алмадык, мәлгуньне...

Бу сораулар Кадерматов аңында да сугышның беренче көннәрендә үк яралганнар иде. Ул вакытта дивизия командирына шундый сорау белән мөрәҗәгать итүдән дә курыкмады Кадерматов... Ә бит нибары бер ел элек кем уйлаган аны шулай булыр дип...

— Иптәш Петров, бу сорауларга җавапны сугыштан соң, һичшиксез, бирерләр. Хәзер, беләсең, вакыты түгел... Булган эш булган, аны тиз генә җайга салып җибәрүе бик үк җиңел түгелдер, күрәсең. Мин әлегә бернәрсәне төп-төгәл әйтә алам: сугыш... озакка сузылачак, дәһшәтен күз алдына китерүе дә кыен булачак. Без җырлаганча гына түгел... Ләкин, безнең халык әйткәнчә, «Бер төкерсә бер булыр, ил төкерсә күл булыр». Әлегә безнең ил көчен туплый гына, мин шуңа ышанам. Ни өчен фашистлар безне тозакка кертеп бастыргач та бирелергә теләмәдек? Ни өчен? Чөнки сугышчыларның иң зур күпчелеге белә һәм ышана: илсез ирнең, рәхмәтлем Петров, ирке дә юк аның...

Петров бу сүзләрне мыекларын җыера-җыера җентекләп тыңлады. Аннары салмак кына, бераз суза төшебрәк әйтеп куйды:

— Әйе, анысы бик дөрес, иптәш командир, илсез ир — күлсез балык ул, дип тә әйтәләр безнең Уссури якларында...

## II

Көзге кояш чыгып, бер кул яссуы кадәр күтәрелеп өлгергән иде инде. Кадерматов йокыдан уянып күзләрен ачты да берничә секунд арада үзенең кайда, ни эшләп ятуын исенә төшерде. Һәм, барысын да хәтерләп, шундук торып утырды. Өстендәге киеме ярыйсы гына кипшенгән,

кичәге кебек тәнне чиркандырып ябышып тормый иде инде.

— Без сине уятмыйчарак тордык, иптәш командир. Без инде кайбер нәрсәләрне эшләп тә өлгердек...

Шулвакыт майорның күзләре каршыдагы каен ботакларына төште. Ак каенның яфраклары инде саргайган, алтынсу төскә кергән. Димәк, көз җиткән дигән сүз.

— Әйтегез, кече лейтенант...

— Беренчедән, иптәш командир, барлауны бик җентекләп уздырдык: барыбыз — кырык җиде сугышчы. Безнең полктан ун кеше, бераү тозактан чыкканда, дамбадагы бәрелеш вакытында һәлак булган, төгәл күрүчеләр бар. Калганнары төрле частьлардан килеп кушылучылар. Алардан җиде кеше юк. Араларында бер старшина бар — гаять тәҗрибәле командир. Гамәлгә яраклы коралыбыз: бер станковый пулемет, өч кул пулеметы, унөч тартма патроны белән, унбиш автомат, утыз ике винтовка, йөз дә җиде гранатаның бишесе танкка каршы бәрә торганы. Иптәш Тимофееваны санамаганда һәркем коралланган...

— Минем коралым бар.— Анна Тимофеевна куртка кесәсеннән пистолетын алып күрсәтте.— Күрмәдегезмени?

Аның сүзләренең дөреслеген раслагандай, якындагы агач кәүсәсенә сыенган тукран тукылдарга керешге. Кадерматов шунда гына Анна Матвеевнага күңел күзе белән карады. Шушы минутта гына ул ир-ат буларак янында хатын-кыз заты барлыгын исенә төшерде. Хәтта: «Карале, ничектер бөтенләй игътибар итмәгәнмен. Бу бит әле миннән дә яшьрәк»,— дип уйлап алды.

Кадерматов янәшәсенә килеп баскан Тимофееваны терсәгеннән тотып читкәрәк алып китте.

— Сезнең соң, Анна Матвеевна, ни... элемтәгез бармы? Ничектер үзебезнекеләргә берәр төрле хәбәр бирәсе һәм берәр төрле күрсәтмә аласы иде бит.

Шушы ике көн арасындагы вакыйгалардан соң Тимофееваның дошман тылында безнекеләр тарафыннан калдырылган булуына шиге юк иде инде аның.

Тимофеева бер минут чамасы уйланып, дәшмичә баргач:

— Безнең, иптәш Кудров, партиянең район комитеты калдырган төп төркемебез тар-мар ителгәннән соң элемтәбез өзелде. Хәзер инде, кызганычка каршы, моның чын сәбәбе ачыкланды. Безне сугыш алдындагы дүрт-биш ел эчендә бик күпләргә ышанмаска күнектерделәр. Ләкин без, шуңа карамастан, сукыр булганбыз, күз алдында йөргән кабахәтләрне күрмичә, күп кенә ышанычлы кешеләребезне көрәшсез-нисез шундыйлар кулына биргәнбез. Бәхеткә каршы, сезгә тап булдым, югыйсә теге Зайцевлар мине фашистлар кулына тапшырган булырлар иде...

— Тынычланыгыз, Анна Матвеевна... тынычланыгыз. Алар, андый Зайцевлар, санаулы гына бит. Әнә безнең сугышчыларга карагыз. Берсе дә, фашистлар вәгъдәсенә ышанып, теге якка чыгарга уйламады бит.

— Дөрес әйтәсез, Кудров, дөрес... Мин үз күзләрем белән күрдем.

Тимофеева тагын беравык дәшмичә уйланып барды. Аннары, Кадерматовка борылып карап, сүзен дәвам итте:

— Турысын әйтим, Кудров, элемтә өзелде. Ләкин мин... берәр җаен табармын. Күршеләрне эзләп табармын... Аларның элемтәсе бар...

Тагын беравык саргайган яфраклар өстеннән, агачлар арасыннан атладылар.

— Ә безгә, иптәш Тимофеева, кайсы җирдәрәк урнашу мөмкин булыр икән? Үзебезне тәртипкә китереп, бераз тын алырга, тирә-якка күз салырга һәм фашистларны борчый башларга туры килер болай булгач...

— Менә... күптән шулай диләр аны, Кудров. Югыйсә...

Тимофеева, күрәсең, Кадерматовны: «Югыйсә үзегезне дә, мине дә алга өндәп, тозакка бастырып үтерә яздыгыз» дип, хатын-кызлар-

га хас рәвештә битәрләп алмакчы иде дә, сүзен башламас борын фикереннән кайтты.

— Беравыктан кузгалырбыз алайса... Безгә бүген кимендә утыз биш километр үтәсе һәм Чириковск тирәсенә барып, андагы куе урманга кереп урнашырга кирәк булыр... Юлда, берәр авылда туктап, тамак ягын кайгыртып алырбыз...

Иртә белән күнелләрне шатландырып чыккан кояшны озакламый салынкы болытлар каплады, аннары тымызык яңгыр сибәләргә керешге.

Кадерматов, сугышчылар артыннан атлаган килеш: «Мондый болытлы көн безгә кулайрак,— дип уйлый-уйлый барды.— Хәзер безгә, гомумән, аяз көннәр түгел, болытлы, яңгырлы, давыллы һәм караңгы көннәр һәм төннәр кирәк. Без шундый чакларда фашистларга күренмичә үз эшебезне эшләрбез. Һөҗүм итәрбез дә урманнарга китеп югалырбыз»...

## 12

Алар ярыйсы гына күтәренкелек тоеп озак атладылар. Тимофеева юлны яхшы белгәнгә күрә, баштагы ике-өч авылга кермичә, әйләнеп кенә уздылар.

Фашистлар булмаса да, аларның үзәкләргә үтеп беткән «рама»-энә карагының күреп алуы ихтимал иде.

Шулай да, кем әйтмешли, ачлык ул туган апаң түгел, үлем янавы ерагайгач, киеренке вакытта искә дә кереп чыкмаган ашау дигән нәрсә күкрәк астын бораулый башлады. Алдагы авыл күренгәч тә Кадерматов тәмам хәлдән тайган сугышчыларына туктарга кушты.

Алар әле генә урманнан чыгып, тирән ерганак үзәнлегенә яшеренә-яшеренә, ниндидер елганың биек ярына килеп бастылар. Авыл әллә ни зур түгел иде, урамнарында хәрәкәт әсәре күренмәде. Дөрес, табигать кочагындагы тынлыкны әллә нигә бер тапкыр сыер мөгерәве, эт өргәне бүлгәләп куйды. Саклык — беркайчан да комачаулый торган нәрсә түгел, тагын ярты сәгать чамасы күзәтеп тордылар. Нибары ике кешене күрделәр. Таякка таянган бер карт аксый-туксый урамның бире очындагы тәбәнәгрәк, каралты-курасыз йорттан чыкты да теге очтагы икенче бер йортка кереп югалды. Уң як рәттәге кырый йорттан башын-күзен урап яулык бәйләгән хатын чыгып елганың теге ягындагы ялгыз чишмәдән су алып китте.

Фашистлар күренми, аларның барлыгына ишарә ясаучы бер генә билге дә юк иде. Кадерматов разведка җибәрергә булды.

— Петров,— диде ул һәм кулын изәп сугышчыны янына чакырды.

— Тыңлыйм, иптәш командир...

— Ике сугышчы белән авылны урап барып, теге очыннан керегез... Саклык чараларын онытмагыз. Безне чакырырсыз.

Шулвакыт Тимофеева майорның иңбашына кагылды.

— Кирәкмәс, командир, сугышчыларны җибәрмәгез. Мин бу авылны яхшы беләм, андагылар да мине хәтерлиләрдер дип уйлыйм, шуның өчен дә үземнең генә керүем хәерлерәк булыр. Әнә тегендәрәк, чишмә турысында, елга аша салынган тар басма бар. Мин шуннан гына...

Кадерматов килеште, ләкин шулай да Тимофееваның ялгызын гына җибәрмәячәген белдереп:

— Петров, яшеренеп кенә ике сугышчы белән иптәш Тимофееваны озатып барырсың,— дип боерды.

«Әһ-ма, кызык та инде бу тормыш дигән нәрсә,— дип уйлады Кадерматов елганың биек ярыннан авыл урамнарын һәм анда таба китеп баручыларны карап яткан килеш.— Бер карасаң, әтәч булып кукәй сала, икенче баксаң, урле-кырлы сикертә, артыңнан килеп ач бүре сыман котларыңны ала...»

Көзге эленке-салынкы көннең аязыбрак торган сәгатендә, Тимофееваның шомлы билгесезлек эчендә боегып утырган авылга кереп, ашау-эчү турында белешүен көтеп ятарга мәҗбүр ителгән Кадермәтов үзенең «сугышка хәтле» тормышын искә төшереп алды. Күрәсең, кеше дигән катлаулы затның күңеле табигать тарафыннан шулай яратылган һәм ул теләсә нинди хәлләрдә дә үзенең үткән тормышына битараф булалмый, аны онытып, узганы белән бәйләнешне өзеп тора алмыйдыр.

...Мәхәббәтне мәңгелек сер ул дигәннәрен ишеткәне бар иде Кадермәтовның. Ләкин теге вакытта, Казандагы хәрби командирлар мәктәбендә «беренче мәхәббәттән» авызы пешкәнгә күрә, күзе төшәрдәй, йөрәген телгәләп яндырырдай хатын-кызлардан бик озак читләшеп йөрде. Хәер, кем белсен, бәлки гомерлек буйдак сыйфатында ил буйлап гарнизоннан гарнизонга күчеп йөргән-яшәгән дә булыр иде. Әмма 1934 елның көзендә үзе тап булган бер очрашу Барый атлы егетнең башын икенче бер озын чәчле кызга бәйләде дә куйды. Чишелмәслек итте шул бәйләүнең төенен.

Ташкентка командирларның бер айлык курсына җыйганнар иде аларны. Сүз курслар турында түгел, анысы бик тә файдалы булды анын. Яңа ел алдыннан гына укуны төгәлләделәр. Ташкент зур шәһәр, икмәкле шәһәр, күрер нәрсәләргә бай кала. Ләкин анда бер ай яшәгәннән соң, яңа ел көннәрендә дә калып торасы килмәде Кадермәтовның. Житмәсә ерак гарнизонда калган ротасыннан да күңелсез хәбәр килде: яшь бер сугышчыны чүлдә елан чагып үтергән. Шуны ишеткән командир зур каладагы хәрби кунакханә бүлмәсендә тыныч күңел белән яңа елны бәйрәм итеп ята аламы соң инде?

Кадермәтов вокзалга ашыкты. Исәбе — хәрби комендатура аша билет юнәтү иде. Ниндидер күзгә күренмәс җепләр аны кеше йөри торган юлдан түгел, вокзал алды мәйданы янындагы сукмактан атлатты. Ул сукмак исә аны бәләкәй бакчага алып керде һәм... эскәмиядә елап утыручы бер татар кызына юлыктырды. Күптән, бик күптәннән күргәне юк иде Барыйның чәч үрмәләренә чулпы таккан, балаитәкле күлмәк киеп, яулыгын арттан бәйләгән кан кардәшен. Ирексездән туктап калырга мәҗбүр булды. Ул арада әлеге кыз янына олы-олы гәүдәле ике үзбәк милиционеры да килеп басты. Аларның, кызга бирелгән сорауларыннан бигрәк, үзара гәпләшүләреннән аңлады Барый: адашып калган татар кызы иде бу.

Мәхәббәтне мәңгелек сер диләр диюен, ләкин аның кайчан, кай җирдә ярала башлаячагын кем төгәл генә белә дә, кем аны алдан әйтеп-кисәтеп куя ала? Аерылышыр өчен генә күпмедер вакыт кирәк, ә мәхәббәт яралсын өчен аңа ике йөрәкнең бер-берсенә күз сирпеп алуы, я булмаса көтмәгәндә, искәрмәстән әйтелгән сыңар бер сүз дә җитә, бик җитә... Әгәр дә мәгәр Ташкент вокзалы алдындагы бакчада басып торган Барыйдан: «Узып барган җиреңнән капыл гына туктарга, аннары ашыгып барып сүз кушарга нәрсә мәҗбүр итте соң?» — дип сорасаң, мөгаен ул төгәл генә аңлатып бирә алмас та иде. Ул чагында... ул чагында Барый тегеләр янына ук барып басты да:

— Ни булды сиңа, үскәнем? Ник елыйсың? Кыерсыттылармы әллә? — диде саф татарча. Аннары милиционерларга борылып, үзбәкчә: — Калдырыгыз безне, иптәшләр, мин үзем җайлармын, — дип өстәде. — Яле, яле, үскәнем-чибәрем, елама. Сөрт әле күзләреңне... Житкән кызга шулай елап утыру килешми бит инде, килешми...

Кыз, чынлап та, үз телендә шундый ягымлы итеп сөйләшә белүче, беренче минуттан ук ышаныч яулардай кеше табылу шатлыгыннан булса кирәк, үксүеннән туктап җиң очыннан кулъяулыгын тартып алды, күзләрен сөрткәләргә кереште.

— Менә... әллә кайчан шулай кирәк иде. Елап кеше куркытып утырганчы...

Барыйның бу сүзләре кызга мәзәгрәк тоелды булса кирәк, ул кулъяулыгын күзләреннән алмас борын ук көлеп җибәрде. «Болай булгач,— дип уйлап куйды Кадермәтов,— эшләр бөтенләй начар түгел, ахры...»

— Кем син, үскәнем? Каян килеп чыктың бу якларга? Кая барасың, кем белән барасың?— дип тезде ул сорауларын бер-бер артлы.

— Цистай йагыннааан,— дип суузды кызның көйле тавышы. Ул әле күтәрелеп карарга кыймый иде.— Цистайдан киләбееез...

— Чистайдааан?— диде Барый гаҗәпләнеп һәм кызга яраклашыбрак. Ул тирә-ягына күз салгалап алды.— Кем белән киләсез соң?

Кыз, Кадермәтовның сүзләреннән кызык табу өстенә, аның кемнедер эзләгәндәй итүен дә күргәч, көлеп үк җибәрде. Көлә башлагач, аның тавышы бигрәк тә көмешләнеп, челтерәп аккан чишмә суы кебек сафланып ишетелде. Елмаюлы йөзе тагын да сөйкемлерәккә әверелде. Кызарып-алланып пешкән чияне хәтерләткән иреннәре «теләсәң-теләмәсәң дә үп мине, үп, үп» дигәндәй үзләренә тартып тора башладылар.

— Кацтылааар... Адаштырып калдырдылар, цукынцыклар,— диде кыз, үз затына гына хас булганча, берничә мизгел арасында капмакаршы якка үзгәреп.— Үзләре Алма апаларга апбарабыз дип ышандырып цыктылар дааа...

— Йә, йә, елама инде, табылырлар. Ерак китмәгәннәрдер, нигә болай ук өзгәләнергә? Менә хәзер вокзалдан эзләп табарбыз...

— Табарбыыыыз...— диде кыз үртәлебрәк.— Ницек табарбыыыз? Алар бит киттеләәәәр. Пуезга утырып...

— Да? Шулайукмыни? Ничек алай киттеләр, сине калдырып киттеләр соң? Ачуландырдыңмыни?

— Юууук. Мин дә утырмакцы идем, дөбер-дөберегез кузгалды да китеп бардыыы...

Кыз тагын яулык тоткан кулын күзенә каплады.

— Туктале... Кая бара идегез соң?

— Бохарадагы Алма апаларга...

— Фамилиясен, адресларын беләсеңдер бит?

— Ул бит бүтән фамилиядә, безненцә түгел, үзбәкцә... Оныттым... Адрисларын белмим...

Кадермәтов мәгълүматларның сыеклыгыннан бермәлгә аптырап торды.

— Әйдә,— диде ул, кинәт башына килгән уйдан шатланып, кызның кулыннан эләктереп алды.— Әйдә...

Кыз болай әллә ни гәүдәле булып күренмәсә дә тиз генә бирешмәде, кулын көч белән тартып алды.

— Җибәр, цукынцык, карале... Кайа барабыз?

Кыз кулының кайнарлыгы, Барыйның бармактагы нерв җепселләре аша үтеп, кан юллары буйлап йөрәккә таба йөгерә-йөгерә бара иде инде.

— Бо-ха-рага!.. Мин дә шул якка барам. Кертеп чыгармын. Табарбыз Алма апаңны,— диде Барый икеләнергә урын калдырмыйча, буйсындыручан тавыш белән.— Әйдә дим мин сиңа! Поездның китеп баруы ихтимал. Нәрсә терәлдең? Монда торырга вакытым юк минем.

Кадермәтовның боеручан тавышы җиңдеме, әллә аңардагы ышаныч тәэсир иттеме, нәрсә булса да булгандыр, кыз бүтән ләм-мим сүз дәшмичә урыныннан торып басты.

Кыздагы буй-сын, тулган айны көнләштерерлек алсу бит алмалары, ул кара кашлар астындагы шомырт күзләрнең мөлдерәмә тутырып караулары!!

Ниһаять, аңына килде Кадермәтов.

— Әйдә, әйдә, киттек,— диде ул ирексездән кулын сузып, кызны, качмасын тагы дигәндәй тотып, алга әйдәде.— Исемең ничек соң синең? Фамилияңне әйтсәң дә ярый, сораулары мөмкин. Ни диярмен?

— Ни... Ниса диләр хәзер...

— Һе, кызык, ә элек ничек диләр иде?

— Элекме? Гөлниса... Кадерматова.

Барый атлаган җиреннән капыл туктады, кыз үзе дә сизмәстән күкрәге белән аның кулбашына килеп төртелде.

— Аллакаем... Нишлисееең?

— Ничек, ничек диден фамилияңне?

— Ницек тә ницек... Кадерматова инде... Алма апа да элек шулай иде, хәзергесен белмим...

— Сеңелем бу минем... Кунакка килгән... Юлда кәгазьләрен югалткан... Ачык авыз,— диде Кадерматов комендантка үзенең юл кәгазьләрен сузып, күзен дә йоммыйча карап.— Ике билет... Бохарага хәтле...

Кадерматовның документларын карагач, комендант: «Нигә Бохарага гына? Сезгә күп арырак, Кушканың үзенә үк кирәк бит»,— димәкче иде дә, ятышлы киемнәр кигән сылуга карап алгач: «Да-а-а!» дан башканы тапмады, кассалар ягына таба чыгып китте.

Бохара — бик борынгы кала, калаларның каласы, ләкин Казан яки Мәскәү түгел. Анда Алма апаны гынамы, энә югалтсаң табып китерергә әзер торучылар бар. Кадерматов, үзе әйтмешли, Хозыр Ильяс кодрәте белән юлында пәйда булган Нисаны җитәкләгән килеш әнә шундый белдекләләрнең берсенә, шунда яшәүче бер татар агаена юлыкты. Алай гынамы, ул «Бер үзбәк мулласының хатынының сеңелесе юлда югалып адашып калган»,— дигән хәбәрне дә ишеткән кеше булып чыкты.

Алма апа да, үзбәк җизни — мулла әкә дә Кадерматов белән Ниса килеп кергәнне күргәч, хәйран булып, телләрен шартлатып куйдылар.

— Алма апа, җизни,— диде тегеләрне тагын да аптыратыбрак Кадерматов...

Хәрби киемле кешедән — бер, югалган сеңелләрен җитәкләп тотуыннан — ике, «Алма апа, җизни» дип өзелепләр әйтүеннән өчләтә каушаган «туганнар» телгә килгәләгәнче, ул тагын өстәп куйды:

— Безгә хәер-фатихагызны бирегез, яме? Ниса... Гөлниса минем хатыным булсын, ярыймы?

— Кит аннан, цукынцыклааар,— диде Алма апалары үзбәк җизнидән дә җәһәтрәк аңына килеп.— Тузга язмаганны...— Аннары кычкырып елап ук җибәрде:— Никахсызмы?..

— Вай-вай-вай...— дип сузды үзбәк җизни шушы сүзне теленнән төшерә алмыйча.— Гәпләшү кирәк... Калым кирәк...

Ни булса да булды, ничек итсәләр иттеләр, Ниса үзе дә өздерепъ:

— Карышмагыз инде, Алма апа, күктән төшкән бәхетем шушы цибәр егеттер... Мин үземне аңа тапшырдым инде...— дип торгач, килешми булдыра алмадылар.

Ләкин Кадерматовны да сындырдылар, күңел өчен генә, картлар килешсен өчен генә дия-дия, кеше күзеннән яшереп, кунак-фәлән чакырмыйча гына никах укытырга күндерделәр...

— Иптәш командир, теге хатын чакыра безне,— диде Кадерматовтан өч-дүрт адым чамасы читтәрәк авылны күзәтеп ятучы Игебаев.— Авылга чакыра, фашистлар юк ди.

Озакламый әле генә сугышчылар яшеренеп торган яр битенә, елга үзәнлегенә, әлеге авылның кыл суккандай туры урамнарына һәм андагы йортлар өстенә караңгы төште.

## Икенче кисәк

### 1

Көзнең иң соңгы көннәре, якынлашып килүче кыш белән тартышырга чамалап караса да, ниһаять, чигенергә мәҗбүр булды. Әле кайчан гына берән-сәрән очкалаган ак күбәләкләр, хәзер инде салкын җил-

ләргә кушылып, өер-өер тупланып авыл урамнары, басулар һәм үзәннәрне тутырып бөтерелә ләр, агач ботакларына сарылып аларга сихри серлелек өстиләр иде.

Кадерматов сугышчылары, күпер янындагы хәллардән котылганнан соң, олы юллардан читтәге урманнарга сыенып-сыенып утырган авылларда ял итеп, көч тупларга урнашканга да ике атнадан артык вакыт узды.

Фашистлар белән бәрелешүне үзләре эзләмәгәнгәме, бәлки саклык чаралары да ярдәм иткәндер, ара-тирә булгалаган ике-өч атышудан битәр куркыныч очрашулар булмады.

Кадерматов аңлый: вакыт уза тора, Кызыл Армия анда дистәләгән башлы аждаһа белән бергә-бер алышкан чакта, хәрәкәтсез яту, ерак тылда калу җинаятькә тиң иде.

Дөрес, вакытны бушка уздырмады Кадерматов. Сугышчыларны, коралларны тәртипкә китерүдән тыш, фронт ягына таба өчәр кешелек ике төркем җибәрде ул. Аларның максаты бер: үзебезнекеләр янына барып житү. Кадерматов полкының хәлен аңлату, мөмкин булса, ике арада элемтә урнаштыру, дошман тылында мөстәкыйль хәрәкәт итәргә рөхсәт сорау иде.

Кызганычка каршы, беренче төркем Хачлыдан егерме километр чамасы киткәч, Чириковск янында полицайлар белән маңгайга маңгай бәрелешеп, көчләр тигез булмау сәбәпле, һәлак булган. Бу хакта Кадерматов берничә чыганактан ишетте. Бәлешергә баручылар да һәлак булучыларның үз иптәшләре икәнлегенә ышандыргыч дәлил — бәрелеш урыныннан сугышчылар яшергән документларны табып кайттылар.

Икенче төркемнең андый-мондый бәрелешләргә очравы турында ләммим бер хәбәр дә ишетелмәде. Ләкин аларның фронт сызыгына барып житүләре шулай ук шөбһәле иде. Шулай да Кадерматов аларга багланган өметен тәмам өзмәде. «Бәлки, кем белсен, аларның юлы уңар? — дип уйлады ул.— Ялан-ялан җиңелү дә чигенү генә димәгән бит инде. Хәер, фашистлар куып керткән тозактан, аннары аларның эзәрлекләвеннән чагыштырмача җиңел котылу безнең бәләкәй генә җиңүебез инде ул...»

Барыбер Кадерматовның күңеле тыныч түгел, башындагы уйлар өереннән аның чигәләре чатнап ярылырга житә. Әмма ләкин әлегә тынычланырдай эш күренми, дошманга каршы көрәшкә әзерләнүдән башка конкрет һөҗүмнәр оештырылмый. Һәр нәрсәнең үз чираты, үз сәгате бар диләр, күрәсең, хактыр бу.

Болай ярамый, сугышчыларны авыл йортларына яшереп яткыруның зарары көчле булачак. Тик яту аларның рухына зыян китерер, төшенкелеккә юл ачар. Кыен көннәрдә япа-ялгыз калудан да начар нәрсә юк. «Ил алдында үлем дә җиңелрәк»,— диләр халыкта. Бергәлек сукса, берәгәйле суга. Әгәр дә мәгәр сугышчыларның рухын төшерүгә юл куйса, моның өчен иң беренче чиратта җавапны Кадерматов — полк командиры бирергә тиеш. Аның гамьсез сүлпәнлегенә ни диярләр?

Кадерматовның бу уйларында беркадәр чынлык булса да, хакыйкатькә туры килеп үк бетми торган арттыру бар иде. Чөнки дошманга каршы көрәшне туктату, сугышчыларның рухын төшерү кебек куркыныч уйлар аңардан ерак йөри. Хәлбуки, ул, аның таянычы булган Добротов, Петров, Игебаев һәм күптән түгел генә килеп кушылган чик сакчысы-старшина хәрәкәтсез ятмыйлар, килер көрәшләргә әзерләнү, көч туплау, баш-күз алу, тирә-юньдәге хәлне ачыклау белән мәшгуль иделәр.

Көннәрдән бер көнне Кадерматов яшеренгән йорт хуҗасы Серафим дәдәйнең хатыны Василиса түти күрше авылдагы сеңелесе янынннан ах та вах килеп кайтып керде һәм күргән-ишеткән яңалыкларын сөйләргә кереште.

Серафим дәдәй, карт булса да, эшсез утыра торганнардан түгел, тирә-күршеләренең аяк киемнәрен ямарга һәвәс кеше. Хәзер дә шуның

белән мавыгып утыра. Кадерматов исә кухня ягында хәлennән килгәнчә ярдәмләшә, күбрәк вакытын уйланып, планнар корып утыра иде. Василиса түтинең сүзләрен баштарак игътибар бирмичә тыңлады, ләкин «аэродром, аэроплан» сүзләрен ишеткәч тә колакларын торгызыбрак тыңларга керешге. Алай гына да түгел, аралыкка чыгып ук басты.

Василиса түти: «Беләм инде, беләм синең бирелеп тыңлаганыңны... Синең өчен сөйлим ләбаса»,— дигәндәй аның ягына карангалап алды да картына төбәп дәвам итте:— Вәт шул, ышансаң — ышан, карт, ышанмасаң — ышанма. Бездән нибары егерме ике чакрым җирдә, каһәр суккан немец аэродром кора башлаган...

— Кит аннан... Алдашырлар,— диде Серафим дәдәй. Мондый хәбәргә бик ук ышанып бетми иде ул. Чөнки алар тирәсендә моңарчы андый нәрсәнең булганы юк иде.

— Кем... алдаша? Минме?— диде карчык.— Әгәр дә мәгәр менә бу аякларымның сызлавы булмасамы, мин сине хәзер ук алып китәр идем күрсәтергә... Үз күзләрем күрмәсә бер хәл. Ярый алайса... иртәгә алып барырмын әгәр ышанмасаң...

Кадерматов аңлады: Василиса түти бер дә юкка күрше авылларга чыгып йөрми, нияте — вакытлыча яшеренеп ятарга мәҗбүр булган Кадерматовны көрәшкә өндәү, аңа ни эшләргә кирәклеген ишарәләп күрсәтү иде.

Самавырны яңартып, Василиса түти кайдандыр юнәтеп кайткан такта чәй эчеп, иртә белән үк мич төбенә тәгәрәтелгән бәрәңге ашыйашый сөйләшүне дәвам иттерделәр.

Кадерматов ирексездән (биредәгеләр өчен дә Кудров иде ул) әле тәрәзәгә, әле ишеккә карангалап утырды, тынычлыгын югалтты. Ниһаять, урыныннан торып, киемен ала башлады. Серафим дәдәй аны кулын ишарәләп туктатты.

— Кудров, сиңа ярамый, әле бит караңгы да төшмәгән. Кая барырга? Кемне, Добротовыгызны чакырыргамы?

Бу зиһенле карт Кадерматовның нишләргә җыенганын аңлап алган иде. Тирә-күршеләргә, күрше хуторга таратылган сугышчыларның кайберләрен аның кушуы буенча ул инде берничә тапкыр эзләп алып килгәләгән иде. Ялчы полицайлар өч-дүрт мәртәбә авылга килеп күренгәләсәләр дә, әлегә хәтле зыян-зарар күрсәтмәделәр. Бары тик: «партизаннарга, десантчыларга ярдәм итүчеләрне, чолганыштан чыгучы кызылармеецларны яшереп ятучыларны, хәбәр итмәсәләр, беренче агачка асарбыз»,— дип янап, староста кую белән канәгатьләнделәр. Шул көннән соң Кадерматов сугышчыларына: «Кеше күзенә күренмәскә»,— дип боерган иде.

— Әйе, Серафим дәдәй, Добротов кирәк. Тагын, әгәр иренмәсәң, мыеклы сугышчыбыз Петровны да табалмассыңмы?

Серафим дәдәй:

— Һе, нишләп мин иреним? Нишләп мин аны тапмыйм?— дия-дия клеенкадан теккән алъяпкычын салып калдырды да, кирәк-яракларын җыеп куйгач, урамга чыгып югалды.

Василиса түти, ул чыгып киткәч тә кухня ягында озак кына савытсаба шалтыратып йөрде, аннары, сөйләшәсе килгәнгә түзә алмый башлагач, Кадерматов ягына чыгып басты.

— Беләм инде, беләм мин аны,— дип башлады ул бу юлы сүзен.— Теге сугышта да шулай йөри-йөри теңкәмә тиде. Кушсалар, башы ярылганны да белми йөгерә тизрәк... Бервакытны, Борис күгәрченкәем, мин сиңа әйтим, тегермәнче Кузьма белән ул чактагы немецларның пушкасын урлап су төбенә яшерделәр алар,— диде Василиса түти пышылдауга күчеп.— Ни хәтле генә эзләсәләр дә, җир йоткан шикелле булды, тегермән ишегалдыннан юкка чыккан пушкаларын таба алмадылар... Һе-һе... Кая инде ул? Шуның хәтле зур әйбер, тегермән ташыннан очкан он тузаны диярсең, юк булды да куйды. Этләр апкилеп эзләгән бул-

дылар тагы... Чуртум да табалмый аны, су төбендәге нәрсәне... Минме? Картлач мине белмидер дип йөргән булды. Бер ачуымны чыгаргач әйттем үзенә. Тыны бетте... Син... син ди, саескан ди, каян беләсең аны ди. Соң, дим, ничек белмисең аны... Тегерменче Кузьма белән пышын-пышын сөйләшүегезне ишетеп, артыгыздан чыгып, кем каравылда торды соң дим. Шулай шул...

— Әй, молодец та инде үзең Василиса түти...

— Молодецын молодец та бит... тик миңа ул нәмәрсәкәй эшсез ята... Мин әйтәм, Борис күгәрченкәем, шул нәмәстәкәйне алып, чистартып аэродромнарыңа дөмбердәтсәң, ә?..

— Соң хәзер анда микән соң ул, Василиса түти? Аны ул чагында ук алганнардыр ләбаса...

— Алдылар ди... Су төбеннәнме? Серафимушкамы? Урманга тайдылар алар... Ятадыр әле шунда... Аннары инде, күгәрченкәем, ул пушка кайгысы булдымыни бездә? Баштарак тегеләй дә болай, җир бирелгән шатлыктан нишләргә белмәдек, акылдан язар дәрәҗәгә җиттек. Аннары инде колхоз дигәннәре чыкты... Смоленск боярының мондагы усальбасыннан алган аты да... ярый иде... Тик миңа аның колыны, яп-яшь колынын да иртәп илтте, картлач, колхозга... Гомер буена мал күрмәгән кеше мал кадерен белә димени инде... Ә теге нәрсә хәзер дә шунда, күгәрченкәем, тик син аны алдыр, солдатың күп, төзәттер дә туздырт әле шул а-аэродромнарын...

Кадерматовны бу хикәя ярыйсы гына кызыксындырды. «Чынлап та,— дип уйлады ул,— биредәге көрәшне шушы аэродромга һөҗүмнән башларга кирәк. Безнең коралыбыз җитәрлек...»

— Һе, һе, беләм мин сезне... Сез, мужиклар, барыгыз да бер чыбыктан сөрелгәнсез... Сезгә сугыш та сугыш кына булсын. Уйнарга булсын сезгә... Сез барыгыз да дөньяны тар санайсыз... Шуңа чыгарып кына торасыз сез сугыш дигән убырлыны...

— Алай түгел инде, Василиса түти, безнең совет иле...

— Һе, ничә тапкыр сугыштыгыз инде?

— Соң бит үзләре керәләр, Василиса түти, без чакырып китерәбезме әллә?

— Ә сез кертмәслек итегез, нигә кертәсез? Мин белгәннән бирле торган буабыз куәтле яңгырдан соң ерылды. Барып та караган юк... Кавыз алдында җир бик тирән иде, анда су бетмәгәндер. Күренсә... әнә кулак Захарийның милициядә оялаган еланы... хәзер полицай булып исәнәеп йөри ди. Әллә кайчан немецларга илткән булыр иде.

Кадерматов «Кулак Захарийның милициядә оялаган улы»ның үзе күпер төбендә атып та тидерә алмаган Зайцев икәнлеген белми иде, әлбәттә...

— Аэродром төзү турында, Василиса түти, хатыннардан гына белдеңме, әллә үзең дә эшләгәннәрен күрдеңме?— дип сорады Кудров, әлеге хәбәрне ачыклый төшәргә теләп.

— Мин сиңа, Борис күгәрченкәем, уйнап сөйләр яшьтән чыккан,— Василиса түти үпкәләп савыт-сабаларын шалтыратып куйды.

— Ярый инде, Василиса түти, гафу ит...

— Шулай диген... Юкса... Солдатларың күп дип тормам...

«Ну, бу Василиса түтинең белмәгәне бер генә дә юк.»

— Күп дип инде, Василиса түти...

— Беләм, беләм мин... Кемнәрдә икәнлеген санап күрсәтимме? Бөтен кеше белә, авылдагылар дип әйтүем... Тик сез болай озак ятсагыз... кулак Захарий эте...

— Бик озак ятмабыз, Василиса түти, аз гына хәл алыйк дидек.

— Кысанланганнан әйтмим, тик... безнең улыбыз да синең Карга Степан хатынындагы сугышчың кебек берәр җирдә шулай йортка кергән булса... Кайчан килер безгә азатлык? Куып чыгара алмассыз мәлгуньнәрне...

«Әгәр дә мәгәр солдатның йортка керүе чын булса,— дип уйланды Кадерматов,— бернинди киртәгә дә сыймый торган нәрсә бу. Беренчедән рөхсәт сорау юк, димәк, ул үзенең кем икәнлеген оныткан яки дисциплинаны санга сукмаган. Икенчедән, ул үзе шикелле үк сугышта йөри торган сугышчы семьясын боза... Авылда яшәү яхшыга китермәс дип уйлаган идем аны... Юк, кичекмәстән урманга күчәргә, анда ышанычлы база булдырырга кирәк... Ә Тимофеева китте дә югалды...»

Берничә көн элек Кадерматов күрше районда хәрәкәт итәргә тиешле партизаннар белән элемтә урнаштыру, әгәр җае чыкса, алар аркылы фронт белән бәйләнешкә керү мөмкинлеген эзләп киткән Тимофееваның тизрәк әйләнеп кайтуын көткәнлеген төшенде. Баштарак ул бу теләген үзенә үзе бары тик элемтә урнаштыру кирәклеге, көрәшкә омтылыш белән аңлатырга тырышты. Чынлап та, әгәр Тимофеева күрше райондагы партизаннарны эзләп тапса... Хәер, аларның да тар-мар ителгән булуы мөмкин, ә без монда арка җылытып ятсак, дип шөбһәләнде Кадерматов. «Хәзергә хәтле без бары тик үзебезне тәртипкә китерү мәшәкатен күрдек. Дөрес, бу эш тә бик кирәк, аннан башка дошманга оешкан төстә каршылык күрсәтеп булмаячак, ләкин аны озаккарак суздык бугай. Безне бер нәрсә генә аклый: мондагы шартларны үзләштермичә, баш-күз булдырмыйча әллә ни кыра алмаган булыр идек». Көннәр үткән саен Кадерматов үзенең Тимофеева язмышы өчен ныграк борчыла башлавын сизде. Теге чакны, күпергә җитәрәк урман читендә очрашкач та, ул аның хатын-кыз икәнлегенә игътибар итмәде диярлек. Фашистлар куып керткән тозактан чыккач кына Кадерматовның күңел күзенә чалынды. Һәм шул минуттан соң әледән-әле Тимофеевага кайчандыр үзенең Нисасына карагандай каравын сизде. Кем белсен, бәлки, уңышсыз кичүдән соң ул — Кадерматов кебек тәҗрибәле командир — фронт ягына таба баруның башка, әйләнечрәк сукмакларын тапкан, тапмыйча калмаган булыр иде. Ләкин ул фашист тылында калып көрәшергә, кешеләрне фронтка бару юлында харап итеп бетермәскә карар кылды. Билгеле, монда беренче нәүбәттә, Сталинның дошман тылында партизаннар сугышын ачу турындагы сүзләре тәэсир итте, әмма ләкин авыр юлларның берсендә очраган Тимофеева дигән хатынның йогынтысы да юк түгел иде кебек...

## 2

Серафим дәдәйнең кайтып ишегалдына керүе, дөресрәге, аның тамак кырганы, йөткергәләгәне ишетелде. Димәк, ялгызы гына түгел иде ул. Кем белән булыр икән? Безнекеләр карт белән бергә килмәскә икәнлеген яхшы беләләр...

Кадерматов тиз генә барып тәрәзәдән читкәрәк басты да ишегалдына күз төшерде. Караңгы төшеп үк бетмәгән, ләкин эңгер-меңгер ярыйсы гына куерган иде инде. Берәү дә күренми... Кадерматов тиз-тиз атлап кухня ягына, мич артына керде дә идән астына төште. Василиса түти аның артыннан ябылган такта өстенә сулы чиләкләрен күчерде.

Әмма Кадерматов юкка гына борчылган булып чыкты. Карт ишектән кереп, идәннәрне шыгырдата-шыгырдата бер-ике адым атлауга әйтте:

— Каяле син, Кудров? Чык монда, үзебезнең кеше. Чык...

Ул да түгел, Тимофееваның салкын тиюдән карлыга төшкән тавышы ишетелде:

— Анда сезнең район тулы партизаннар, әллә нихәтле фашистны юк итеп, аларга көн күрсәтмиләр, дип сөйлиләр тагы. Алар, әнә, идән астыннан колакларын да күрсәтмичә тын алырга куркып яталар икән...

Шулай да Кадерматов сизде: Тимофееваның тавышы, салкын тиюдән арынып бетмәгән булса да, теге вакыттагы кебек аптыраулы түгел, ныклы һәм ышанычлы иде. Кадерматов моны яхшыга юрады.

— Исәнмесез, исәнмесез, иптәш Тимофеева,— диде ул кухня ягын-

нан чыгышлый ук, шатлыгын яшермичә.— Югыйсә, борчыла башлаган идек.

— Ничего, иптәш Кудров,— диде Тимофеева «Кудров» сүзенә басым ясый төшеп.— Дөрес, сезнең белән уздырган теге төн мина кыйммәткә төште. Урында ук ятарга туры килде. Әмма күп яңалык ачтым... Анда бит Кудров фамилияле полк командиры мәгълүм түгел, иптәш Кадирметов...

Бу инде шатлык өстенә шатлык иде! Димәк...

— Шатланырга бигүк ашыкмагыз, иптәш Кудров. Без, турысын әйткәндә, командованиегә үк барып житеп, аның белән элемтәгә керә алмадык хәзергә. Ләкин... мин булган жирдә бер генерал бар иде. Ул ... нче укчы дивизия командиры. Чолганыштан чыгышы. Аның разведчиклары үзебезнекеләргә чыгып житеп, кире әйләнеп килгәннәр. Хәер, менә сезгә аңардан пакет...

Кадерматов, елмайган килеш, Тимофеева кулыннан хатны алды. «Иптәш Кадирметов,— дип укып китте ул мич алдындагы учак яктысына елышып. Мин дивизия командиры Николаев булам. Соңгы чолганыштан чыгып килгәндә яралангач та иптәшләр мине монда калдырып киткәннәр иде. Үзебезнекеләр яныннан жибәрелгән кешеләр килеп житте. Бүген төнлә мине алырга самолет килергә тиеш.

Сез, иптәш Кад-ов, безнең дивизия тар-мар ителде дип уйламыйсыз, беләм. Дөрес, без тар-мар ителдек, чигенергә мәжбүр булдык. Моны сугышчылардан яшермәгез. Чөнки без фашистларның тимер армадасына винтовка һәм пулеметлар, күп очракта штык белән генә каршы торырга азапландык. Шуңа күрә дә безне таптап узды алар...

Сез, ипт. Т. сөйләвенә караганда, шактый гына тетрәнүләр кичергәннән соң, ул жирләрдә калып, үзебезнекеләр килгәнче көрәшергә уйлыйсыз икән. Мин моны хуплыйм. Партиянең һәм совет хөкүмәтенең бу хакта махсус карары булды. Ләкин сез ... нче дивизиянең сугышчан берәмлеге икәнлегегезне истән чыгармассыз дип ышанам. Мин кайту белән сезнең инициативагыз турында үзебезнең командованиегә житкерермен. Сез шушы тирәләрдән ерак китмәскә тырышыгыз. Корал жибәрүне, тагын бер кат әйтәм, бик ныгытып сорармын...

Жиңү көнендә күрешергә язсын, Кад-ов!

Сәлам белән ген. м-р Николаев.»

Николаевның ни әйтергә теләве яхшы аңлашыла. Кадерматов хатны тагын бер кат күздән кичерде. Ул үзенә-үзе сөйләнеп:

— Безнең хакта командованиегә мәгълүм булыр дип уйларга тулы ышаныч бар,— диде.

Ул арада ишек ачылды һәм:

— Иптәш Кудров, без килеп життек,— дия-дия чакырылган иптәшләр килеп керде.

Кадерматов хатны яшереп олы якка чыһуга, әйткәнне көтмичә үк, Серафим дәдәй үзенең күпне күргән бүреген кия-кия:

— Әйдә, старуха, чыгып ишегалды тирәсендә булашыйкмы соң әллә?— дип Василиса түтигә эндәште. Теге көттермичә генә:

— Тукта инде, бу хәтле мәгънәсез булырсың икән, картлач,— дип сукрана-сукрана кулларын алъяпкычына сөртте.— Аннушка, күгәрченкәем, чуенда бәрәңге пешеп чыга, карарсың, аннары өстәлгә куярсың,— дип өстәде дә, карты артыннан юнәлде.

Тәрәзәләрне бик яхшылап томалап лампаны кабызгач, та Кадерматов тирә-яктагыларга сынап карый-карый сүз башлады.

— Добротов, иптәш Петров,— диде ул дүрткә бөкләнгән кәгазьне күкрәк кесәсеннән чыгарып әйләндерә-әйләндерә.— Менә бу безнең дивизия командирының күрсәтмәсе. Без биредә, үзебезнең гаскәрләр килгәнчегә хәтле, махсус задание белән калдырылган булып саналачакбыз. Димәк, безнең полк яшәячәк дигән сүз бу. Моны онытмаска тиешбез. Шушы көннәрдә актив көрәшкә, сугышчан бурычыбызны үтәргә кере-

шербез. Бу хакта соңрак конкрет сөйләшербез... Кешеләр ни хәлдә, иптәш Добротов? Без моны соңгы вакытта исебездән чыгардык. Шуңа күрә сез, иптәш Добротов, штаб начальнигы буларак, моны тәэмин итәргә тиеш буласыз. Байракны Игебаевка тапшырырсыз. Ул ышанычлы егет. Хачлы авылының төньягындагы Чикләвек урманы алдында туплану вакыты, иптәш Добротов, иртәгә — 21.00.

Тимофеева бу чыгышны игътибар белән тыңлады, бүлдермәде. Шул ук вакытта ул үзе алып кайтып биргән кечкенә кәгазьнең, нибары бер бит ярым язуның Кадерматовка никадәр көч һәм ышаныч өстәвен күрде. «Менә бит,— дип уйлады ул көрсенеп,— үзенең ялгыз түгеллеген аңлау кешегә нинди мөһим. Болай булса, без фашистларга тынычлык бирмәячәкбез».

Ул арада инде Кадерматов конкрет эшкә күчкән иде.

— Миндәге мәгълүматларга караганда, иптәшләр,— диде ул тирәсендәгеләргә күзләрен кысыбрак карый-карый. Бездән нибары егерме километр ераклыкта фашистлар аэродром төзү эшенә керешкәннәр. Без беренче зур операцияне шуннан башларбыз дип уйлыйм. Алар хәзергә әле бездән берәгәйле һөҗүмне көтмиләрдер. Шуннан остарак файдаланырга кирәк булыр. Корал һәм тәҗрибә җитмәүне дә каплар бу...

— Шулайдыр, командир, ләкин моны, төпле разведка ясамыйча башкарып булмаячак...

— Дөрес, иптәш Добротов... Мин әйтергә җыена идем: Сез, штаб начальнигы буларак, шуның белән шөгыльләнерсез. Сезгә конкрет ярдәмче хәзергә Петров һәм старшинаны да үзегезнең янга алырсыз. Разведкада аннан да кулайрак кешене тапмабыз.

Тимофеева да сүзгә кушылды:

— Иптәш Кудров, минемчә, биредә калган яшьләрне, бигрәк тә комсомолларны да эшкә тартырга кирәк.

— Бик дөрес. Бу хакта да әйбәтләп уйлашырбыз. Минем менә, иптәш Тимофеева, мондый фикер бар: иптәш Добротовны, ишеттегез инде, үзебезнең штаб начальнигы иттек. Сез каршы түгелдер бит?

— Мин каршы түгел, сезгә, хәрбиләргә, бу яхшырак мәгълүмдер.

— Анысы шулай... Ә менә сез, иптәш Тимофеева, безгә күктән төшкән әзер комиссар инде. Сез әнә шул вазифаларны үз өстегезгә алырсыз. Кичекмәстән. Хәер, без моны урманда җыелгач та рәсми төстә игълан итәрбез.

Тимофеева нидер әйтмәкче иде, ләкин Кадерматов аңа ирек бирмәде, елмаеп карады да сүзен дәвам итеп китте... Шулвакыт ишек ачылды, анда Василиса түти күренде.

— Үзем ишегалдында йөрим йөрүен, әмма син, күгәрченкәем,— Тимофеевага карады.— Нигә пешкән бәрәңгене алып өстәлгә куймыйсың? Бөтен ишегалды хуш ис белән тулды бит инде, ә син сизмисең... Ә?— диде ул, җавап та көтмәстән кәче якка кереп китте.

Кадерматов, Тимофеева, Добротов һәм Петров берьюлы көлешеп куйдылар...

## 3

Башкалар чыгып киткәннән соң да байтак кына сөйләшеп утырдылар. Ниһаять, лампадагы ут «пет-пет» сикергәләде дә кечерәя барып бөтенләй сүнде. Йокларга урнашудан башка чара калмады. Кадерматов, гадәтенчә, сәндерәгә үк менеп кунаклады.

Тимофеева нык характерлы кешегә охшый болай. Бүген ул аңа әледән-әле күз төшергәләп утырды. Ихтыярлы булуы өстенә, Василиса түти әйтмешли, Аннушка ир-ат күзе төшәрдәй чибәр дә иде әле.

Кадерматов ирексездән йодрыкларын баш астына салды һәм күзләрен йомды.

...Эһ, Ниса, Гөлнисакай...

Бохарадагы Алма апа һәм үзбәк җизни белән саубуллашып, Барый хезмәт иткән гарнизонга хәвеф-хәтәрсез кайтып җиттеләр. Ул вакытта Кадерматовның җыйнак кына бер бүлмәле куышы бар иде инде. Кадерматовның өйләнеп килүен белгәч тә, башка командирларның хатыннары шул ук кичне табадыр, кашыктыр тотып керделәр. Полк командиры хатыны Дина Сергеевна алты кешелек чәшке-чәйнек күтәргән иде.

Барый белән Ниса килүчеләрне ачык йөз белән каршы алдылар, икесе ике телдә рәхмәтләр яудыра-яудыра озатып калдылар. Әмма дөнья гаме, тормыш мәшәкатьләреннән өстен иде алар. Икесе дә һич көтмәгәндә дөрләп кабынган, бер-берсенә күз сирпеп караган саен йөрәкләрен өтеп-өтеп ала торган кайнар мәхәббәт ләззәтен тоялар иде.

Яшь хатын Барыйның куышын тиз арада җылы ояга әверелдерде дә куйды. Китсә, елмаеп-үбеп озатып калды, кайтса, берсеннән-берсе тәмлерәк аш-су белән каршы ала торган булды.

Мәхәббәтнең кайнарлыгыннан, тормышының көйләнеп китүеннән, яраткан хезмәтенең үз дигәнчә баруыннан Барый бетмәс-төкәнмәс бәхет дәрьясында итеп сизде үзен.

Шундый көннәрнең берсендә алар, икәүләшеп, табигать кочагына, таулар биләмәсенә чыктылар. Һәр тарафта бу якларга гына хас җылылык белән хакимлек итә торган иртә яз иде. Тау ташлары арасындагы кулъяулык тикле җирдә аллы-гөлле тюльпаннар чәчәк аткан тылсымлы чак иде. Барый шушы чәчәкләрнең аерата матурларын, үзләренә тартып тора торганнарыннан зур бәйләм туплады да Нисаның тигез рәтләргә салып артка тараган толым-толым чәчләре арасына кыстырып куйды.

Бу минутларда Барый үзенең Нисасын әкиятләрдәге иң акыллы, иң гүзәл, иң тугрылыклы һәм иң гадел патша кызларыннан да артыграк итеп күрде.

Нисаның исә йөзе ачылганнан ачылды, нурланганнан нурлана барды. Аның шомырт күзләрендә әллә ничә гомергә җитәрлек сөю чаткылары биеште. Сәйлән төймәдәй ак тешләре арасыннан ул әледән-әле: «Барый җаным, әгәр дә мәгәр дөньяда син барлыкны белмичә яшәсәм, нинди бәхетсез булыр идем»,— дигән сүзләр сибелешеп чыгалар да кургаш ядрәләре булып ир-егетнең йөрәгенә барып кадалалар. Ләкин шунысы гаҗәп: алар бер бөртек тә авырттырмыйлар, киресенчә, сөю утында чыныга барган йөрәккә тормыш дәртен торган саен күбрәк өстиләр иде.

Аннары Барый тау-ташлар арасында кеше аяк басмаган чинар агачлары, төрле куаклар, таныш булмаган чәчәкләр, үләннәр үсеп утырган гүзәл бер үзәнлеккә алып барды.

Көньякның җылы һәм шәфкатьле кояшы тирә-яктагы агачларга, чәчәкләргә, кыяның кызган ташларына, алар арасында мыжылдаган бөҗәкләргә дә нурларын бертигез сибә иде... Ә күк йөзе, күк йөзе шундый зәңгәр, шундый иркен һәм шундый биек иде ки, андагы сирәк-мирәк болытларга сикереп менәсе дә, аларга утырып, ерак-еракларга, кеше күзенә күренмәгән тылсымлы галәм чиксезлегенә туктаусыз карыйсы, алсу хыялларга биреләсе килә иде.

Барый белән Ниса, фани дөнья тылсымына бирелеп, яшел үлән арасына күмелделәр...

Аннары, икесе дә иксез-чиксез күк йөзенә карап ләззәти рәхәтлек эчендә йөзгәндә, Ниса Барыйның уң кулын йомшак кына тотып алып күтәрде дә үзенең тыгыз тәненә куйды.

— Сизәсеңме, Барый җаным?.. Тибә бит...— диде Ниса, иреннәрен сизелер-сизелмәс кыймылдатып.

Барый тынсыз калды. Аңа ияреп, яшел үзәнлектәге барлык җан ияләре дә сайрау-чыркылдаудан туктады. Бары тик күк гөмбәзенең өске катындагы болыт кисәкләре генә Нисаның иреннәреннән төшкән пышылдауны ишетмәделәр, каядыр чиксезлеккә таба агыла бирделәр. Сизде Барый, «мин монда» дигән шикелле уч төбенә тибеп куйган җан иясенең барлыгын сизде. Һәм бөтен гүзәллек-тынлыкны сискәндереп:

— Ни-сааааaa! Мин сине яратам!— дип сузып-сузып кычкырып җибәрде, шундук урыныннан сикереп торды да, бөгелә төшеп, яшел хәтфә келәм өстендә күзләрен йомып бәхетенең зурлыгыннан оеп яткан Нисаны көчле кулларына алды, үзәнлек буйлап ары барды, бире таба килде... Салмак кына җиргә тезләнде. Нисаны кулларында тоткан килеш үзе белән аны да нык тотеп чалкан ятты. Аның иреннәре Нисаның алсуланган кайнар иреннәрен эзләп тапты...

— Ай-вай-вай! Карагыз әле бу имансызларны, карагызчы, мөселманнар!— дигән гөбердек тавыш Барый белән Нисаның икесен дә бозлы суга салгандай куырып алды. Барый күз иярмәс тизлек белән, ләкин сак булырга тырышып, Нисаны янәшәсенә әйләндереп салды да сикереп торып басты. Һәм... үзенә таба сузылган кәкре кылычлар бөҗрасында калганлыкларын күрде.

— Ай-вай-вай!— диде баягы гөбердек тавыш.

Шик юк, бу тар-мар ителгәннән соң да агулы еланнар кебек тау-таш арасында качып яшәүче басмачылар калдыгының башлыгы иде. Кадермәтовның басмачылар белән беренче тапкыр очрашуы түгел иде. Әмма кулга корал тоткан килеш кара-каршы килеп бәрелешү бер, ә инде көтмәгәндә, коралсыз-нисез хәлдә, җитмәсә сөйгәнең белән бергә алар кулына эләгү бөтенләй икенче нәрсә...

Барый күз кырые белән генә тирә-юньне күзәтеп чыкты. Кызганычка каршы, якын тирәдә кешеләр күренми иде. Шул ук вакытта ул басмачыларның баштанаяк кораллы булуларын һәм коралларының безнеке түгеллеген дә чамалады, атлар, җиһазлар, киемнәренең чиста һәм таза булуына карап билгеләде: болар яңа гына чикне үтеп ил эченә кереп баручылар иде. Барый тынычлана төште. Бәхеткә күрә, ул хәрби киемнән түгел иде. Бу кешеләр башлап хатын-кыз белән сөйләшә башламаячаклар, әлбәттә. Димәк без укытучылар дияргә мөмкин. Шуны сизгән кебек, басмачылар башлыгы:

— Вай-вай-вай, оятсыз адәм, син кем буласың?— дип бераз алгарак чыкты һәм кулындагы кылыч очын Барыйның уң як кулбашына куеп, ияк астына терәде. Аның салкынлыгы ияк астын өтеп алды, ләкин Барый кымшанмады. Басмачылар башлыгының телен яхшы аңлый, иркен сөйләшә иде ул; шулай да аны ватып-сындырып, дөресрәге Ниса аңларлык итебрәк җавап бирде.

— Әссәламегалайкем,— диде ул башта тагын бер кат салкын канлылык күрсәтеп.— Хатыным белән мин, без — мөгаллимнәр. Таудагы ташлар, үсемлекләр белән танышабыз. Сабыйларны укытырга кирәк бит. Ә сезне кемнәр дип белергә боерасыз, хөрмәтлем?— Барый сүзнең болай башлануына сөенеп куйды, чөнки Ниса аның басмачылар башлыгына биргән җавабын ишетеп-аңлап алды.

— Вай, син нугай баласы буласыңмы?

— Без Казан иленнән, хөрмәтлем,— диде Барый дәрәҗә сакларга тырышып.— Мөгаллимнәр...

— Ялганлый,— диде башлык артындагы чалмалы берәү.— Мөгаллим? Мөгаен, коммунисттыр әле? Рөхсәт ит, Бәк, бу мөгаллимәне үзебезнең пәһлеваннар белән тикшереп карарга... Безне дә шулай, бу шакалны яраткан кебек ярата алыр микән?..

Барый басмачылардан рәхим-шәфкать көтеп булмасын белә иде. Сүз җайлы гына башлангач та бәлки үтеп китәрләр дип өметләнгән иде. Шакал дип авыз чайкаучының кабахәтлеген башына китереп тә карамаган иде.

— Бәк!— диде ул.— Аңла, без — мөгаллимнәр... Синең кан кардәшләреңнең балаларына сабак эстәүчеләр. Син бу бәндә кебек надан адәм түгелсеңдер... Юл куйма моңа...

Шулай дигән чакта ул уңгарак атлады. Уе — бәкнең кылычыннан арыну. Нисага якынаю иде. Ләкин шул ук мизгелдә артына ук килеп баскан ике басмачы аның кулларын каерып тоттылар... Барый кискен тар-

тылып җиргә чүгәләде, борыла төшеп арттагыларның берсенә типте һәм... аяк астына килеп тигән чукмардан тешләрен шыгырдатып җиргә чалкан әйләнеп төште дә аңын җуйды.

Нисаның ачы тавыш белән: «Барыыый!»— дип кычкыруыннан шул ук мизгелдә диярлек күзләрен ачты. Әмма талпынырга өлгерә алмады, үз эшләрен яхшы белгән басмачылар аның аяк-кулларына ураган каеш бауны искиткеч көч белән тарттылар, башмак очы белән янтыгына типкәләргә керештеләр. Барый тагын аңын җуя башлаганда колак төбендә диярлек Нисаның йөрәк өзгеч тавышы яңгырады. Һәм шундук өзелеп калды.

Барый, авыртудан түгел, көчсезлектән ни кылырга белмичә, телен аркылы тешләде...

4

Аннан бирле инде ничәмә ел узды. Барый Кадерматов үзен коткарган чик сакчылары белән бергә шул басмачыларны дөмектерүдә катнашты, Халхин-Гол бәрелешләрендә, фин сугышында, ниһаять, фашист яуларына каршы көрәштә нинди генә җәфаларны башыннан кичермәде, әмма еракдагы тау-ташлар арасындагы шул хәерсез көн исенә төшкәндә сыкранмыйча түзә алмый. Күзләреннән яшь чыкмаса да, аның бөтен җаны-тәне сулкылдап-сулкылдап елый башлый иде.

Хәзер дә шундый халәт иде булса кирәк, чөнки төр яктан Тимофеева һәм ишек катындагы сәкедән Серафим дәдәй икесе берьюлы диярлек сорадылар:

— Ни булды, Кудров?

— Нигә елыйсың, Кудров?

Кадерматов алар тавышына сискәнеп китте, йөрәгенең котырынып тибүен басарга тырыша-тырыша сәндерәдән мич башына, аннан аралыкка төште һәм кухнядагы су кисмәгеннән чүмеч тотырып алды да эчтәргә кереште.

Тимофеева, Серафим дәдәй һәм Василиса түти дә кухня ягына керделәр.

— Ни булды, Борис, күгәрченкәем?

Барый әллә Василиса түтинең соравыннан, әллә күңеленең әрнүен киметергә тырышуданмы, ә бәлки күңел савыты мөлдерәмә тулган булгандыр — мич алдындагы баягы эскәмиягә утырды да, учак төбендәге күмерне кыскыч белән алып тәмәке кабызды һәм... әле генә хәтерендә яңарып җанын телгәләгән вакыйганы сөйләргә кереште.

Аның сөйләгәнен Тимофеева аралык ягыннан мич кирпечләренә сөялгән килеш, ә Серафим дәдәй белән Василиса түти кухня сәкесе читенә утырып тыңладылар.

Кадерматов тавышын артык күтәрмичә, көл арасындагы көйрәпялтырашып яткан күмерләрдән күзен алмыйча, кабызган тәмәкесен суырырга да онытып сөйләде...

Фашист яулары астында калып сыкранган җирнең караңгылыкка төренгән бер йортында язмыш очраштырган өч кеше бу төнне бүтәнчә йокларга ятмадылар, таң беленгәнче сөйләшеп утырдылар да утырдылар.

Төнге хәлләрдән бераз тынычланып, яңадан элеккеге рухи тынычлыгын кайтаруга ирешкән Кадерматов, иртәнге аштан соң урманга китәргә әзерләнеп йөргәндә, җаен туры китереп Серафим дәдәйгә эндәште.

— Күптән сорармын дип йөри идем әле, Серафим дәдәй,— дип ерактан алдырып башлады ул.— Беркөнне төшемдә күрдем, мин теге сугыш вакытында да бу тирәләрдә генә яшәгәнмен, имеш. Алай гынамы, тегермәнче Кузьма дәдәйнең өендә яшим, имеш. Син, Серафим дәдәй, тегермәнче Кузьма янына килдең. Бер пот чамасы бөртек тарттырырга килгәнсең, имеш. Вәйт, немецларның, имеш, бер пушкалары тегермән

почмагыннан күренер-күренмәс тора. Син, имеш, ни... йомыш белән чыккач та шуны күреп алдың...

Серафим дәдәй, «ни сөйли бу?» дигәндәй кечерәеп калган зәңгәр күзләрен мелт-мелт иттергәләп утырды да, сүзнең төбенә төшенеп житүгә, кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Ну, хитрый син, Кудров... таныш бер татар бар иде минем беренче герман сугышында, шундый синең кебек хитрый, ну батыр кеше иде.. Ну саесканын да әйтер идем... Ну саескан да соң син, старуха, ничә еллык нәрсәне онытмаган бит, ә? Күрәләтә үзенең картына нинди яла яга бит, ну саескан,— дия-дия көлүен дәвам итте...

Василиса түти исә кухнясыннан боларның сөйләшүен ишетеп торган икән. Ул аннан чыкмыйча гына:

— Нинди яла булсын? Үз күзләрем белән күргән нәрсәне,— диде.— Гомер буе миннән яшереп эшләргә маташтың эшләреңне, картлач. Әмма бер генә эшеңне дә белмичә калмадым...

— Калмадың? Һе-һе-һе! — Серафим дәдәйнең күзләрендә хәйләкәр чаткылар уйнап алды.

— Немец пушкасын тегермәнче Кузьма белән суга бәреп төшергәнегезне дә, аның артыннан унлап тартма снаряд томырганыгызны да күреп калдым... Ник дәшмисең? Ну вот, авызың ябылдымы, картлач...

Серафим дәдәй бу юлы да рәхәтләнеп кеткелдәде.

— Ну белдең... Ну балда...— диде ул кәефе килүдән арына алмыйча.— Соң бит аны күргәчтен үк барып әйтәләр... Йокы капчыгы син, старуха, вот кем син, мин сиңа әйтим... Аннары өч көннән соң без, партизаннар белән килеп, әйе, әйе, немецлар киткән төнне үк ул пушканы... Син кече малайны тапкач, йоклап яткан төнне пушканы Чикләвек урманына алып киттек... Тик ул бернәрсәмә дә ярамады, беренчедән снарядларын яшермәгәнбез, икенчедән, аның замок диган нәрсәсен ватканбыз... Тапмадык.

Бу юлы инде Кадермәтов тә рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

«Нинди кызыклы кешеләр, бер-берсен кабатламыйча, ләкин берберсен тулыландырып яши бу гади кешеләр,— дип сокланып куйды ул.— Әгәр дә мәгәр, кайчандыр басмачыларга очрамасак, Ниса бәгырем, без дә шулай яшәгән булыр идек...»

## 5

Кадермәтов сугышчылары туплана торган урман Чикләвек урманы дип аталса да, анда катнаш урманның төрле агачлары үсә һәм ул әледән-әле зур-зур басулар, урләр-үзәннәр белән аралаша. Ул басулар арасындагы ерганакларның вак куакларга, арада чикләвек куакларына да күмелеп утырганнары күп. Бик кирәк чагында дошман күзеннән азмы-күпме яшеренеп тору өчен мөмкинлекләр бар иде.

Кадермәтов белән Тимофеева, бергә килеп, билгеләнгән урыннан өч-дүрт йөз метр чамасы читтәрәк туктадылар.

Үч иткәндәй, иртәдән бирле кар явып тора, жир өсте агарып бара иде инде. Шулай да биредә, урман арасына килеп кергәч, сулыш алуы иркенәйде, җилнең җилекләргә үтүе бетте, күңел тынычланды. Ни әйтсәң дә, урманда, авылдагы өйләрдә яшеренеп ятуга караганда, ышанычлырак иде.

Озакламый сугышчылар җыела башлады. Алар, берән-сәрән килсәләр дә, урманга кергәч үзара сөйләшкәннәре еракка ук ишетелә. Агачлар арасында тавыш ныграк яңгырый иде. Димәк, дип уйлады Кадермәтов, иң беренче чара — саклык һәм уяулыкны бер генә минутка да истән чыгармау булырга тиеш. Сугышчыларны бу хакта аерым кисәтергә кирәк булыр...

Шушы уйлар белән сугышчылар ягына таба кырык-илле адым атларга өлгермәделәр, каршыга килүчеләрнең ярыйсы гына тозлап-борыч-

лап сөйләшүләре ишетелде. Кадерматов таныды: Добротов тузына иде.

— Ни булды, Добротов, кемне шулай эттән алып эткә саласың? — диде Кудров ара якынайя төшкәч, агач артына чыгып.— Сез бер дә яшеренергә уйламыйсыз. Тегендә дә шау-гөр киләләр.

— Исәнмесез... Күп яшеренеп йөрдек инде, иптәш Кудров, без үзебезнең урманда хәзер... Шауламыйча да булмый, иптәш майор...— диде Добротов. Аның гадәти сабырлыгын нәрсәдер бозган, кайнарлаткан иде.— Җылы җиргә оялап та өлгергән, оятсыз... Сугышчы Кравчукны әйтәм... Үзе кебек үк сугышчы хатынына чынлап торып йортка кергән. «Үзегез сугышыгыз, китте миннән»,— дип авыз тутырып сөйләп торган була... Алып килдек әнә...

— Аның әлегә Кызыл Армия сугышчысы икәнлеген исенә төшердегезме соң? Нәрсә дип җавап бирә?

— Күрһәттек, күрһәттек, иптәш майор! — Шулай дия-дия вак бәрелешләрнең берсендә җиңел яраланган Игебаев калкып чыкты.— Әсәен дә, атаен да күрһәттек...

— Игебаев? Ничек, тәртипме, якташкай? — дип, шатлыгыннан кочаклап алды аны Кадерматов.— Бу сугышчы, Анна Матвеевна, минем якташым була...

Армиядә хезмәт иткән кешеләрнең, тирә-як өлкәләрдән килүчеләргә якынлык хисләре күрсәтеп, «якташ» диешеп йөрүләрен, Татарстан һәм Башкорстан егетләренең үз ягыннан килгән туганнарын очраткан кебек шатланышуларын күп тапкырлар күргән иде Кадерматов.

— Җыелышып беттеләрме, Добротов? Ничә кеше?

— Алтмыш тугыз сугышчы, иптәш командир!

— Соң, килмиләр дисең, без бит кырыклап сугышчы гына идек түгелме?

— Монда, иптәш командир, чолганыштан чыгып, безгә хәтле һәм аннан да берән-сәрән килеп тупланган сугышчылар байтак икән. Алар безнекеләр урманга җыелганны белгәч...

Кадерматов кашларын җыерды, нәрсәдер әйтергә җыенды.

— Бер яктан, сугышчыларның күбәюе шатлыклы күренеш булса да, икенче яктан, иптәш Добротов, безгә бик сак булырга, уяулыкны онытмаска кирәк киләчәктә,— диде майорның ни өчен кашлары җыерылганны аңлап өлгергән Тимофеева.— Син, Добротов, ул кешеләр өчен җавап бирә аласыңмы? Ышанасыңмы аларга. Араларында дошманга сатылган җаннар юкмы? Күрдегез бит, безнең районда алдан әзерләп калдырылган отряд та нәкъ шундый сәбәпләр аркасында тармар ителде...

— Без аларны алдагы беренче бәрелешләрдә үк сынарбыз сынавын, иптәш Тимофеева,— диде, ниһаять, Кадерматов.— Аннары син, Добротов, сөйләшкәнчә, старшинага аларны күздән югалтмаска куш... Аның күзләре андыйларны тиз танырга тиеш. Әйдәгез, киттек, көтәләрдер...

Төрлесе төрле формадан киенгән сугышчылар төркеме урман аланына җыйналган иде.

— Бу нинди толпа? — диде Кадерматов.— Бу нинди тәртипсезләр төркеме?..

— Безнең сугышчылар болар...

Добротовның җавап сүзләрен Кадерматов ишетмәмешкә салышты.

Добротов эшнең асылын сизеп алган иде инде, командирны узып, алга чыкты да барысына да тезелергә фәрман бирде... Аннары Добротов бөтен шартын китереп рапорт бирде.

— Иптәш сугышчылар,— дип башлады Кадерматов.— Мин... нче полк командиры майор Кудров булам. Сезнең кебек үк чолганышта калып, үзебезнекеләр янына барып җитә алмаган сугышчы. Без бирегә азмы-күпме хәл алып өлгердек. Хәзер инде безгә үзебезнең изге бурычыбызны — фашист илбасарларына каршы көрәшне — дәвам итәргә вакыт. Болай да ялыбыз озакка сузылды. Фронтта һәр сугышчы, һәр

винтовка санаулы, искиткеч авыр бер вакытта безнең тылдагы толлар артына качып ятарга хакыбыз юк. Дөрес хәбәр булса, кайберәүләр, сугышны «бетердек»кә санап, йортка керергә дә өлгергәннәр...

Сафтагылар арасында көлешкән авазлар ишетелде.

Кадерматов аларның туктаганнарын көтеп алды һәм:

— Күрәм, кайберәүләрнең кәефенә хуш килде бу хәбәр,— дип дәвам итеп китте.— Юк! Без хатын-кызлар юбкасы астына качып калырга теләүчеләрне нишләтәсен белербез. Хәзер сугыш вакыты икәнлеген истән чыгармагыз... Без — барыбыз да хәрби хезмәттәге сугышчылар. Аңлыйсыздыр, үзебезнең вазифаларны үти башларга тиешбез. Бер генә кеше дә командирларының рөхсәтеннән башка берничә минутка да аерылып китә алмый. Мин югарыдагы командованиедән шундый приказ алдым. Хәрби уставны барыбыз да яхшы беләбез...

Кадерматов тынып торган арада сафтагыларның үзара сөйләшеп алганы ишетелде. Уртаданрак берәү: «Во дает»,— дип ычкындырды. «Әйе, бу килеш, кешеләрне әйбәтләп тикшерми-араламый торып, аэродромга һөҗүм итеп булмаячак. Сугышчыларны, коралларны барларга, тәртипкә китерергә кирәк»,— дип уйлап алды Кадерматов.

— Кем дә кем минем сүзләр белән килешми икән, хәзер үк сафтан чыгыгыз. Андыйларның алдыннан арты яхшы. Хәзер үк китсеннәр. Соңыннан бу мөмкинлек булмас — рөхсәтсез китүчеләрне дезертир дип санарбыз.

— Нишләрбез соң без, иптәш майор? — дип сорады баягы «Во дает» дигән тавыш.— Немецлар бит әнә Мәскәүне алган диләр... Шулай булгач, сугышу нигә кирәк?

Кадерматов бу сугышчыга каты ук бәрелмәкче иде. Иң соңгы мизгелдә: «Аның ни гаебе бар? Ул билгесезлектә ич»,— дип уйлап өлгерде һәм үз-үзен тыярга тырышып:

— Ялган бу! Фашистлар Мәскәүне, үз колакларын күрмәгән кебек...— дип әйтә башлаган иде, Тимофеева түзмәде, алгарак чыгып басты һәм командирның сүзләрен куәтләде:

— Әйе, чеп-чи ялган бу, иптәшләр! — Тимофеева күкрәген тутырып тирән сулыш алды да дәвам итте:— Дөрес, фронттагы хәлләр гаять авыр хәзергә. Фашистлар өере Москвага ыргыла. Кулыбызда булган коралдан файдаланып, булмаганын дошманның үзеннән тартып алып, куркусызлык, салкын канлылык һәм чыдамлык күрсәтеп, фашистларга бер генә тыныч көн һәм төн дә күрсәтмәү — безнең изге бурычыбыз иптәшләр. Үлемгә — үлем, канга — кан!

Кадерматов ялкынланып кулларын бутый-бутый сөйләгән Тимофеевага карап сокланып куйды. «Коеп куйган комиссар бит»,— дип уйлап алды ул һәм бу хатынның үз күңеленә туктаусыз якыная баруын тойды.

— Дошман безнең җиребездә моңарчы булган барлык вәхшиләрдән дә уздыра, коточкыч җинаятьләр кыла,— дип дәвам итә иде Тимофеева.— Шәһәрләр һәм авылларыбызны яндыру гына аз аңарга, аз. Ул бер гаепсез кешеләрне коллыкка куа, меңәрләп-меңәрләп җиргә күмә, хатын-кызларны, аналарны һәм балаларны кызганмый... Сез моны үз күзләрегез белән күрдегез...

Без, иптәшләр, кулыбызда корал булган исән-имин сугышчылар, әнә шулай харап ителгән яралылар, мәсхәрәләнгән хатын-кызларыбыз, пычрак итекләр, канга манчылган танк гусеницалары белән таптатылган иген кырларыбыз һәм чәчәкле болыннарыбыз өчен үч алмабызмыни соң?

Мин, бу районлагы совет власте вәкиле һәм яңа оешкан партизаннар отрядының комиссары буларак, сезгә шуны аермачык әйтәм: фашистлар беркайчан да Москвага кермәделәр һәм кермәячәкләр. Әйе, Ватаныбыз ут эчендә, башкалабыз капкасы төбендә аяусыз каты сугышлар бара. Ләкин Москва безнеке һәм иптәш Сталин Кремльдә!

Тимофеева сөйләп бетерүгә сугышчылар дәррәү шаулашырга кереш-

теләр. Аннары сафтагыларны ерып озын шинельле, петлициларына дүрт өчпочмак кадаган берәү чыкты.

— Иптәш командир, һәм комиссар Тимофеева,— диде ул озак еллар буе күнегелгән командирларча тавыш белән.— Мин погранзастава старшинасы Никифоренко булам. Сугышны 22 июнь таңында көнбатыш чик буенда каршы алдым... Дошманның мәкерле һәи вәхшиләрнең вәхшие икәнлеген әнә шуннан бирле күреп киләм. Мондагы сугышчылар да аның кабахәтлекләрен бер генә күрмәделәр. Без әзер, иптәш командир һәм иптәш комиссар, бүген үк дошманның бугазына ябышырга, аны кайда күрсәк шунда тукмарга әзер без...

Кадермәтов киң җилкәле, салмак, ләкин нык адымлы, көнбатыш чик буеннан монда кадәр килеп житкән һәм өстендәге формасын яшермәгән бу старшинаның киләчәктә менә дигән партизаннар разведкасы начальнигы буласына шикләнми иде инде.

— Сугышчылар,— диде Кадермәтов,— сугышчы иптәшләр! Дөрес әйтә Тимофеева, башкалабыз Мәскәү тирәсендә аяусыз сугышлар бара, ләкин мондагы бәрелешләр дә аяусыз булачак. Әмма дошман нинди генә көчләр тупламасын, ул җиңеләчәк. Безнең халыкның куәтен сындырырлык көч дөньяда юк. Җиңү, һичшиксез, безнең якта булыр... Канга — кан, үлемгә — үлем!.. Дошманның аяк астында җир янарга, күк йөзендәге болытлар аның өстенә ишелеп төшәргә тиеш...

Ул сөйләп бетергәндә сугышчылар сафы бер тирәгә тагын да тыгыз тупланып баскан иделәр.

— Иптәш Добротов,— диде, мондый бердәмлеккә күңеле тулып, йөрәге еш-еш тибә башлаган Кадермәтов,— сугышчыларны урман каравылчысы йортына таба алып барыгыз. Килеп житүгә кече командирларны җыярсыз. Никифоренко, хәзер үк минем янга!

## 6

Кешеләрне өйрәнү, аларның һәркайсысы белән аерым-аерым сөйләшеп чыгу, кече командирлар сайлап алу, төрле группалар туплауга ике-өч көн вакыт китте. Боларның барысы белән дә Кадермәтов, Добротов, Тимофеева шөгыльләнделәр. Шул ук вакытта урман каравылчысы йортыннан биш километр арырак, юлсыз һәм әлегәчә кеше кулы тимичә сакланган аулак урында төп база булдыру эше көнен дә, төнен дә туктамады. Андагы эшләр: торак землянкалар, азык-төлек һәм санчасть өчен аерым җиһазландырылган урыннар булдыруны Кадермәтов тайгада аучы булган Петров житәкчелегендәге егерме ике кешелек төркемгә тапшырды. Аэродромга һөҗүм иткәннән соң отряд шунда кайтырга тиеш иде.

Аэродромга бару юлларын, андагы көчләрне ачыклау старшина Никифоренко сайлап тәкъдим иткән биш кешелек группага йөкләнде. Ул төркем инде беренче тапкыр өч көнлек разведкага барып та кайтты.

— Килмешәкләр үзләрен чиктән тыш иркен тоталар, иптәш майор,— дип сөйләде Никифоренко үзенең күзәтүләренә йомгак ясап.— Фронт сызыгыннан еракта икәнлекләрен беләләр һәм бары тик һава һөҗүменнән генә шикләнәләр. Безнең әллә нигә бер узган бомбардировщиклар тавышы ишетелә башлауга, бөтен эшне туктатып, әсирләрне шундагы чокырларга яшерәләр. Каравыл бинасын, рота урнашкан, авыллардан китереп салынган йортларны һәм әсирләр сараен гына саклыйлар. Каравыл яхшы коралланган, барысында да автоматлар, өч кул пулеметы һәм бер станковый, шуның өстенә бер миномет расчеты да бар. Әмма һөҗүм булырын башларына да китермиләр шикелле. Рөхсәт итсәгез, командир, мин аларны егерме-утыз кеше белән туздырып кайта алам...

Кадермәтов, фашистларның шулай иркен кылануына ачуы килгән Никифоренконың омтылышын аңласа да, дошманның ротасы гына түгел, аннан зуррак көчләре дә кирәк чакта бик тиз арада сугышка әзер-

ләнеп өлгерәсен белә иде. Егерме биш-утыз партизанга каршы алар бик җиңел генә каршы тора алачаклар. Шуңа күрә, элек тә тәҗрибә туплаган, күпер төбендәге саксызлыктан соң бигрәк тә авызы пешкән командир разведчикларның икеләтә-өчләтә сак һәм уяу булырга тиешлекләрен нык кисәтте.

— Бу беренче һөҗүм аерата нык хәзерләнелгән булырга тиеш, иптәш Никифоренко,— диде ул старшинаны аерым алып.— Без, беренче операцияне уңышлы уздырсак, үзебезне генә түгел, немец оккупациясе астында калган халыкның да ышанычын ныгытачакбыз. Шуңа күрә, һөҗүм уңышлы чыксын, бер генә фашист та исән котыла алмасын өчен дошман ротасының һәрбер постын, ничек урнашу тәртибен бик тә төгәл белү кирәк безгә...

— Моның өчен бит, иптәш майор, алар янына үтеп керәсе иде. Анда булырга кирәк...— диде старшина һәм бераз уйлап торганнан соң өстәп куйды: — Әгәр теләсәгез, мин аларга үзем теләп «әсир» төшәм дә бөтенесен ачыклыйм...

Кадермәтов бу юлы Никифоренконың малайлык күрсәтүенә бик нык дулады:

— Син нәрсә, старшина, нинди авантюрага бармакчы буласың? Ярый, кердең — эләктең ди... Аннары ничек чыгасың һәм разведка мәгълүматларын ничек тапшырасыңны уйладыңмы?.. Соңгы тапкыр булсын мондый башсызлыгың... Югыйсә разведкага синнән башка кеше табарбыз...

Никифоренко кашларын җыерып торды, аннары Кадермәтовка таба кара күзләрен чаткыландырып карап алды.

— Сезгә рәхәт, иптәш майор... Сезнең гаиләгез һәм туганнарыгыз фронт сызыгыннан еракта дыр. Алар немец вәхшилекләрен бөтенләй күрмиләрдер... Ә беләсезме? Чолганышлардан чигенеп килгәндә мин үзебезнең авыл аша үттем... Ә анда... беләсегез килсә, нибары өч-дүрт йорт исән калган. Башкалары урынында кара күмер дә көл генә. Ә минем әни карчык белән этине фашистлар снаряды күккә очырган...

Майор башта старшинаны бик нык сүгеп ташларга уйлаган иде, әмма теге үзенең авылы һәм әти-әнисе турында әйткәч, тыелып калды. Шулай да беравык тын торганнан соң:

— Бу сүзләрең дә соңгы тапкыр булсын, Никифоренко, ишетәсеңме, соңгы тапкыр булсын... Сиңа да, миңа да җитәрлек эләкте, дустым ил дошманнарыннан... Ә син беләсеңме, минем хатынны, бөтен дөньяда бердәнбер кешемне — әти-әнием, туганнарым һәм сеңлемә тиң булган бердәнбер кешене басмачылар нишләтте??

Старшина бераз кайтып төшкән иде инде, ул башын иеп тыңлады да:

— Гафу итегез, иптәш майор, бүтән кабатланмас бу йомшаклык,— дип китәргә рөхсәт сорады.

— Ял итегез, старшина, яңа разведкага әзерләнегез!

Чынлап та, дошман турында төгәл мәгълүматлар кирәк иде. Димәк, дип уйлады Кадермәтов, теләсәң теләмәсәң дә, дошман ягыннан «тел» алу кирәк.

Тимофеева, Добротов һәм Никифоренко белән киңәшкәннән соң, аэродром тирәсеннән андагы барлык серне белә торган немец солдатын кулга төшерергә карар иттеләр. Бу эш, билгеле ки, Никифоренко төркеменә тапшырылды.

Бер көнлек махсус әзерлектән соң разведчиклар юлга кузгалдылар. Кадермәтов белән Тимофеева аларны каравылчы йортыннан алып урман читенә хәтле озатып бардылар.

Көн эленке-салынкы, кургашсыман авыр болытлар җир өстенә ятар-ятмас булып төньяктан көньякка таба актарылалар иде.

— Ничек уйлыйсың, Кадермәтов,— диде Тимофеева, разведчиклар

төркеме кыр казлары шикелле тезелешеп күздән югалгач та.— Без сугышта җиңеп чыгарбыз, бу хакта шигем юк минем, әмма мондый михнәтле сугыштан соң да безнең ил һаман шулай җир шарында берүзе генә капиталистлар дөньясына каршы торырмы? Алар бит яңа бер Гитлерны тудырачаклар һәм ул тагын, белеп торам, безгә таба карап өрә башлаячак...

— Хөрмәтлем, Анна Матвеевна,— диде Кадерматов,— Анна Матвеевна... Мин сезнең соравыгызны аңлыйм... Дөресрәге, сүзләрегезнең аерым-аерым мәгънәләрен аңлыйм... Тик, кичерегез, төгәл генә җавап бирә алмыйм. Без бит әнә Гражданнар сугышыннан соң да озакламый бөтендөнья революциясе җиңәчәк дип уйлый идек... Әмма бер нәрсәне төгәл беләм, ышанам һәм шуңа күрә кабатлап әйтә алам: бу сугышта безне җиңеп чыгардай көч юк. Без әле үзебезнең күкрәкне киереп житкермәдек. Безнең әле көчләребез чын-чынлап тупланмаган... Нигә шулай?.. Аңысы инде полк командиры каланчасыннан гына күренә торган нәрсә түгел...— Ул, туктап торган җирләреннән, кузгалып, урманның кырыена ук чыгып, байтак кына күзәтеп торды. Разведчиклар күптән инде күренмиләр иде. Урман тирәсендә, аңа алып килә торган юлда да хәрәкәт юк. Хәер, аның күренгән җире дә биш-алты йөз адымнан узмый иде...— Әйдәгез, кайтабыз, Анна... Матвеевна,— диде ул һәм үзе дә сизмәстән беренче тапкыр Тимофееваның беләгеннән тотып алды. Ә Тимофеева исә, шулай ук искәрмәстән, хатын-кызга хас гадәт белән терсәген гәүдәсенәрәк кысты... Кысты һәм шунда ук кире җибәрде, ләкин Кадерматов шул арада да аның тән җылысын тойгандай булды, үзеннән-үзе дулкынлана башлады...

Алар шул килеш урман куелыгына илтә торган, бары тик атлылар гына йөргән, урыны-урыны белән баш очында агач ботаклары кайтарылып төшкән юлдан алга — урман каравылчысы яшәгән йортка таба атладылар.

Урман эчендә җил юк, әмма агач башларының вакыт-вакыт бөгелеп куюларыннан аның ачыклыкта ярыйсы гына көчле искәнлеге беленә иде. Яфраклар инде коелып беткән диярлек, бары тик каен агачларындагы саргылт, усаклардагы алсу-кызгылт яфраклар гына юлчыларны күзәтеп, ара-тирә лепердәшеп калалар. Кайсыберләре исә Кадерматов белән Тимофееваның өстенә төшәләр дә, аларны сыйпап-иркәләп алгач, тагын каядыр китәргә омтылгандай итәләр, ләкин хәзер инде алар яңадан иректә очуга ирешә алмыйлар, җиргә төшеп капланалар иде.

### 7

Старшина Никифоренко җитәкләгән разведчиклар төркеме аэродром төзелә торган җирдән бер километр ярым чамасы ераклыктагы ерганак ышыгыннан юлны күзәтә башлады.

Ләкин... ни хәтле генә колак салып тыңласалар да, төзелә торган аэродром белән район үзәген тоташтырган юлда тавыш-фәлән ишетелмәде, хәрәкәт эсәре күренмәде.

Шулай итеп, көтә-көтә төн уртасын җиткерделәр, аннары таң атканны көтә башладылар, әмма тормыш, әйтерсең, бу якларда бөтенләйгә сүнгән иде.

Старшина Никифоренко берничә тапкыр инде: «Әллә соң аэродромга якынлашыйк та, яхшылап күзәткәннән соң бер часовойны сугып миңгерәтикме?» — дип уйлап алды. Ләкин шундук майорның: «Аэродромга якын бармаска, анда тавыш чыгармаска, «тел»не юлдан алырга, эзне яхшы яшерергә!» — дип катлы-катлы кисәтүен исенә төшереп, йодрыгы белән җиргә сугып-сугып куйды.

«Нишләргә? Нишләргә соң? Немецны, безгә тел кирәк, юлга чык, дип чыгарып булмый бит,— дип баш ватты ул.— Әллә соң райүзәккә

якынлашырга да патруль солдатларына ябырылырга һәм берсен урларгамы?—дип шундук бу фикереннән дә кире кайтты.—Аларның аэродромдагы тәртипне яхшы белмәүләре көн кебек ачык».

Ниһаять, беркайчан да үтмәс кебек озын тоелган төн үтте, ялындырып кына булса да таң атты. Кичәге түбән болытлар каядыр югарыга китеп беткәннәр, ләкин барыбер кояшны томалап агылалар иде әле.

Бераз тамак ялгарга, яшереп кенә булса да, тәмәке тартып алырга кирәк иде. Ләкин аларның өметләре өлешчә генә акланды. Бар булган сохариларын кимереп бетергәч тә, арадан берәү:

— Старшина, минәйтәм, эт тә юк бу юлда, әллә бишебезгә берне төреп алыйкмы? — дип сүз башлап карамакчы иде, тик сүзен төгәлләргә өлгерә алмады, старшинаның усал йөзен һәм бала башы хәтле йодрыгын күреп, телен тешләде.

Аэродром ягындагы үрдән район үзәгенә таба бишекле мотоцикл атылып килеп чыкты.

«Элемтәче бу яки берәр офицер сәләмәсе булырга тиеш,— дип карар итте фашистны уенда булса да кимсетергә тырышып.— Озак әйләнмәс бу... Алырга кирәк моны, ничек кенә булса да, алырга!»

Әмма көпә-көндез такыр юлга ничек чыгарга да, ничек итеп тавышсыз гына кулга төшерергә соң аны?

Разведчиклар, старшинаның йөзенә карап ук, аңладылар; моны кулдан ычкындырмаячак иде ул!

Старшина исә бу вакытта берсеннән-берсе кыюрак, берсеннән-берсе хыялыйрак планнар кора иде. «Ерганак чокыры аша салынган күперсыман нәрсәне шайтаныма очырырга, граната белән шартлатырга!» Ләкин: «Ул шартлауны ишетмәсләр дисеңмени? Аннары немец шыр тиле түгел, ул шартлатылган күперне күреп алачак. Юк! Болай булмый!»— дигән акыллырак уй баштагысын кире какты. «Алайса нишләргә соң?»— дип тешләнде старшина. «Уйла, уйла һәм тап хәйләсен,— диде тагын бер уй аңа.— Син чик сакчысы, чекист... Шуңа да ярамагач...» дип үртәште. Бусы инде старшинаның мин-минлегенә суга торганы иде.

Ул арада мотоциклчы ерганак аша салынган күперне чыкты да район үзәге ягына таба элдертте. Немецлар икәү — йөртүче һәм бишектә утырган биек фуражкалы, күн курткалы берәү иде. «Мөгаен, аэродром төзетүчеләрдәндер,— дип нәтиҗә ясады старшина.— Ул безгә кирәк нәрсәләрне, һичшиксез, белергә тиеш».

Шулвакыт старшина разведчикларына карап-карап торды да: «Кулъяулыкларыгыз бармы?.. Чыгарыгыз булса»... дип боерды.

Әгәр дә мәгәр старшиналары бу минутта: «Юлга ташланабыз, аягүрә басып һөҗүм итәбез!»— дигән тузга язмаган боерык бирсә дә, сугышчылар бу хәтле аптырап, гаҗәпләнеп калмаслар иде.

— Нәрсә катып калдыгыз, егетләр? — диде старшина.— Ычкынып китте бу дисезме әллә? — Үзенең баш бармагын уң як чигәсе тирәсендә боргалап алды.— Юк, ычкынмадым әле. Ягез, кемдә бар андый нәрсә?

Разведчиклар берәм-берәм кесәләрен актара башладылар.

Кырым татары Алядинов кулында күренгән кара бәрхет кулъяулыкны старшина тартып диярлек алды, тезләренә куеп диагональгә бөкләде, дүрт бармак киңлегендәге тасма ясады. Шуннан соң гына Алядиновның җиңенә бәйләп куйды.

— Менә син, Алядинов, полицай булырсың? — диде старшина икеләнергә урын калдырмыйча.— Син мине, чолганышта калып урманда качып йөрүче Кызыл Армия командирын тотып, райүзәккә алып барасың...

Алядинов әле аңына килмәгән иде, калган разведчиклар, эшнең мәгънәсен төшенеп, көлешә башладылар.

Разведчикларның берсе юлны күзәтергә калды. Старшина үзе, Алядинов һәм тагын ике сугышчы, ерганак буйлап, күпергә таба төшеп киттеләр.

Мотоцикл күренде. Моңарчы һәр секунд диярлек аның килүен көтеп торган Никифоренко белән Алядинов, бер-берсенә карашып, чыгаргамы-юкмы дигәндәй, икеләнеп алдылар. Ләкин старшина шул ук секундта:

— Ал-га! Каушамаска, Шамил! — дип әмер итте, үзе башлап юлга үрмәләде. Ул инде өстен-башын пычратып яланбаш калган, шинелен күпер астында калдырган, ерткалап бетергән, әмма петлицаларындагы өчпочмаклы билгеләре калдырылган гимнастеркадан иде...

— Безнең белән тигезләнгәч тә туктамасалар, син водительгә штыкны кадыйсың, мин бишектәгесенә ташланам...— дип пышылдады тагын бер кат старшина.

Ләкин алар уйлаганча җиңел генә килеп чыкмады...

Мотоцикл старшина белән Алядиновка дүрт-биш адым җитмичә туктап калды. Рульдә утыручысының автоматы аркасында булса да, бишектәге курткалы унтер-офицерның (хәзер күренә ки, ул авиатор икән), алдында кул пулеметы җайлап куелган иде.

— Хальт! — дип кычкырды унтер-офицер.— Хальт!

Старшина туктап калды. Алядинов винтовкасының штыгы аның калак сөягенә төртелеп, авырттырып алды.

— Пош-ооол... Нигә туктадың, сволооочь? — дип чеп-чи сүгенеп ике адым артка чигенде «полицай», исереккә сабышып. — Пош-шоол...

— Хальт!

Бу юлы унтер-офицер пулеметын юлдагыларга төбәде.— Komm hier![1]

Алядинов шунда гына мотоциклны һәм немец унтер-офицерын күргән сыман булып читкәрәк чыкты, винтовкасын күз иярмәс тизлек белән янбызына кысты һәм өч адым алга атлады, «әсиргә» күрсәтеп: «Воот... пленный... командир... Ком-мен-да-тура!» — диде. Янәсе, бу командирны комендатурага алып бырышы аның.

Унтер, үзенә куркыныч янамаганны күргәч, батыраеп китте. Чөнки аңа, авиациядә хезмәт итүчегә кызылларны сирәк күрергә туры килә иде. Шуңа күрә дә ул, авызы пешмәгән булгандыр инде, перчаткалы бармагы белән старшинага күрсәтеп тагын бер кат:

— Komm hier! — диде.— Сюда...

«Полицай» ул арада унтердан бер адымга арткарак атлады, винтовкасын сул кулына күчерде, ә «әсир» унтерның алдына ук килеп басты. Ләкин соңгы адымын баскан чагында аягы таеп киткән сыман итте, янтаеп, егыла башлады, ләкин бер генә секундка да унтерны күзеннән югалтмады. «Пистолетын аламы-юкмы?»— дип чамалады ул. Бәхеткә каршы, бу унтерның кызылармеецлар белән дә, партизаннар белән дә очрашканы булмаган ахры. Үзенең аяк астына егылып барган старшинага карап: «Ха-ха-ха»,— дип көлеп җибәрде һәм... Шул ук мизгелдә старшина аны, ике аягыннан да кочып тоткан килеш, кинәттән үзенә таба тартты... Старшинаның егылганын карарга дип аяк очына күтәрелгән солдатның кабырга арасына Алядиновның штыгы кадалган иде инде...

Разведчиклар мотоциклны күпер астына ничек житте шулай кертеп, ләкин аны күренмәслек итеп яшергәннән соң, еракта каралып торган урманга таба атладылар...

## 8

Ниһаять, аларның барлык табышларын уртаклашканнан соң, Кадерматов, алар белән бергә барып, юлны һәм аэродром урнашкан басуны, төзелештә эшләүче әсирләр яши торган сарайны, аның янындагы каравыл ротасы солдатлары һәм киләчәктә очучылар яшәргә тиешле, авыллардан сөтеп бирегә китереп корыла торган йортларны ерактан булса да карап,

[1] Komm hier — ко мне!

һөҗүмнең юнәлешләрен билгеләп — кыскасы, рекогносцировка ясап кайттылар.

Әмма...

Хәзерлек тәгәлләнде, иртәгә тәвәккәллибез диП торганда, Никифоренко тагын яңа хәбәр алып кайтты. Булачак аэродромга фашистлар зур-зур цистерналар китереп, аларны чокырларга күмдереп куйганнар да ягулык ташырга керешкәннәр иде.

«Димәк,— дип уйлады майор, булгач-булгач, берәгәйлерәк булсын, ягулыкны күбрәк ташысыннар, аның ялкыны, еракларга күренеп торсын.»

Тимофеева да бу фикерне хуплады, бик шәп тәрбия чарасы булыр, кешеләрне көрәшкә чакыру булыр диде.

Ниһаять, барлык эшләрне дә тәгәлләделәр. Кадермәтов сугышчыларның барысын да урман каравылчысы йорты алдына тезәргә кушты. Сугышчылар бу юлы беркөнгечә өелешеп түгел, командирлары кушканча саф-саф булып килделәр.

— Иптәшләр! — дип эндәште сугышчылар сафына карап дулкынланган Кадермәтов.— Без әлегә хәтле әзерлек эшләре белән мәшгуль булдык. Бүген без беренче заданиегә чыгабыз. Аны, урынга барып җиткәч, отделение командирлары сезгә җиткерерләр. Ләкин аңа кадәр...

Болдырда басып торган Кадермәтов артына борылып ишеккә йодрыгы белән суккалады. Ишек ачылып китте һәм... аннан Байрак, чып-чын сугышчан Кызыл Байрак күренде. Ул иртәнге кояш нурларында аерата ялкынлана сыман иде.

Байракны күрүгә сугышчылар, берьюлы җитдиләнеп киттеләр. Эленке-салынкы басып торуның әсәре дә калмады, барысы да, командасызнисез, «смирно» бастылар.

Сугышчыларның бердәм карашы Кызыл Байракка төбәлде.

Добротов, Игебаев һәм Петров, байракны йөртүчеләр, тантаналы адымнар белән сафның уртасына килеп туктадылар.

Башта Кадермәтов, аның артыннан Тимофеева болдырдан төшеп Байрак янәшәсенә бастылар. Шуннан соң гына майор башлаган сүзен дәвам итте:

— ...Иптәш сугышчылар, бу безнең ... нче полкка тапшырылган сугышчан Кызыл Байрак. Сезгә билгеле булганча, хәрби частьнең Байрагы — ул сугышчы намусының, батырлыгы һәм данының символы. Ул безгә, һәрбер сугышчыга үзебезнең иң изге бурычыбыз — Совет иленә тугрылык, туган җирнең һәр карыш җирен каныбыз һәм гомеребезне дә кызганмыйча явыз дошманнардан сакларга тиеш икәнлегебезне искә төшереп тора.

Мин беләм: хәрби хезмәткә килгәч, сезнең барыгыз да хәрби ант тоткан кешеләр. Сынауларның иң-иң зурысы җитте. Хәзер без биредә, дошман тылында, мөстәкыйль хәрәкәт итә торган сугышчан берәмлекне тәшкил итәбез. Беренче җитди операциягә чыгар алдыннан шушы Кызыл Байрак алдында антыбызны кабатларга бурычлыбыз.

Шулай дигәч, майор Байрак алдына тезләнеп басты, сугышчылар да, байрак йөртүчеләрдән башкалар, шуны ук эшләделәр.

— ...Аяусыз һәм канлы сугышка керер алдыннан Туган ил азатлыгы өчен немец-фашист илбасарларын тар-мар иткәнчегә хәтле батырларча сугышырга, канымны һәм җанымны кызганмаска, сугышчан дусларымны, теләсә нинди җәзаларга тарган очракта да, сатмаска Ватаным һәм совет халкы алдында тантаналы төстә ант итәм...

Тугрылыкка антның бу сүзләре Кызыл Байрак булып талпына, ә аннары урман агачлары арасыннан ашкына-ашкына һавага сибелә һәм бераздан, тагын да бердәмрәк булып, төгәл бер яңгырашка әверелеп, мәйдан өстенә кайта иде.

Кадермәтов, аягүрә баскач та, күкрәген тутырып сулыш алды һәм каядыр еракка, агач башлары өстендә күренгән һава киңлегенә карады.

Добротов белән Кадерматов юлны бик яхшы беләләр иде инде, шуңа күрә тоткарлык булмады диярлек. Дөрес, берничә урында, урман бетеп, басулар башланган җирдә, озак-озак күзәтеп торырга, андыймондый хәрәкәт күренмәвенә тәмам ышангач кына хәрәкәт итә башларга туры килде.

«Кышкы көннең озынлыгы — яшь килennең тәүге төне инде ул»,— дип уйлады Кадерматов, эңгер-меңгер төшәр алдыннан сирәк каенлыкка туктарга боерганнан соң. Бу каенлык янышнан, ике япьле сәнәк сыман булып, ерганаклар башлана һәм шуның бер тармагы фашистларның күчмә постлары очраша торган аэродром юлын кисеп үтә иде.

— Привал... Тәмәке тартмаска, кычкырып сөйләшмәскә, каенлыктан чыгып күренмәскә! — диде Кадерматов отделение командирларына.

Теге көнне майор шушы каенлык читеннән бинокльдән карап яткан иде. Ләкин хәзерге эңгер-меңгердә юл үзе дә, аэродром янындагы корылмалар да юньләп күренми иде.

— Кадерматов,— диде ауган агач өстенә барып утыргач та Тимофеева.— Менә без синең белән ничә көн инде бергә сөйләшеп йөрибез. Әмма безнең сөйләшүләр ниндидер кырыслыкка уралган. Ир белән хатын сөйләшүе дә түгел. Безнең телдә каян корал табарга, ничек үзебезнекеләр белән элемтәгә керергә, сугышчыларга ризык табып китерергә һәм тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр. Ә бит уйлап карасаң, без, Кадерматов, сугышка хәтле тормышыбызның кадерен белмәдек... Сине белмим, хәрби кеше булгач, һәрвакыт мөһим эшләр белән кайнашкансың, бәлки... Ә мин...

Кадерматов Тимофеева үзенең сүзен дәвам итәр дип байтак кына көтеп торды. Әмма ул нишләптер ашыкмады. Кулындагы таягы белән яңа яуган карны актара башлады.

— Ничек инде, Анна Матвеевна, син, мәсәлән, хатын-кыз булуыңа карамастан, зур урынга куелгансың. Партия эшендә булгансың. Райбашкарма председателе урынбасары булу — бик зур дәрәҗәгә ирешү турында сөйли,— диде Кадерматов, аңгәмәне өзмәскә тырышып.

— Эх, Кадерматов... Беләсеңме?... Безнең халыкның беркатлылыгын... Эш дибез... Урын дибез... Ә үзебез кешеләрнең кадерен белмибез...

— Мин, нишләптер, Анна Матвеевна, аңлап бетермим әле сине...

— Шул, шул, командир, син дә... Менә мин, беләсең килсә, Кадерматов... үземнең ирем белән нибары өч ел ярым гына яшәп калдым...

Кадерматов ни әйтергә дә белмәде. Гадәттә, соңгы елларда бу хакта кычкырып сөйләшмәскәрәк тырышалар иде.

— Ничек алай, Анна Матвеевна? Хәбәре дә юкмы? Гаебе?..

— Юк шул,— диде Тимофеева һәм, урыныннан торып, сугышчылар ягына карап торды.— Син, Кадерматов, гафу ит мине, әллә ниләр телгә килә... Шулай да... Мин үземнең йомшаклыгымны, иремнең гаебе юклыкны белгән өстенә, аңардан ваз кичүемне кичерә алмыйм... Ярый... Бу хакта хәзергә сөйләшергә кирәкмәстер. Әллә ничек... күңел әллә нишли... Ярый, онытыйк. Соңыннан... исән-сау кайтсак...

— Нинди сүз инде бу, Анна Матвеевна, ни сөйлисең?..

— Шулай, Кадерматов, вөҗдан дигән нәрсә тынгылык бирми икән ул.

Кичке алты тулган иде.

Майор отделение командирларын чакырып алды һәм бурычны аңлатырга кереште.

Тагын ярты сәгатьтән кузгалдылар.

Күчмә постны юк итәргә тиешле төркем юлга якынлашканда гына, уч иткәндәй, ялтырап ай калыкты. Ул болытлар арасыннан җирдәге хәлләрне күзәтергә керешкән кебек. Анда-санда гына йолдызлар да

жемелдәп күренгәли. Шулай да беренче заданиегә баручыларның бәхете юк түгел икән. Алар ерганак аша салынган күпергә чаклы калган илле-алтмыш метр араны ничек узарга дип уйланып торган арада, каядыр ашыккан самолетлар гүләве аермачык ишетелә башлады.

Кадермәтов, теге вакыттагы сабакны исенә төшереп, бу хәлдән тагын бер кат файдаланырга булды: бердәм рәвештә шуышырга әмер бирде. Җиде-сигез минут үттеме-юкмы, сугышчылар күпер төбенә килеп җиттеләр...

Озакламый Добротов җитәкчелегендәге төп төркем дә Кадермәтов янына килеп тупланды.

Майор тагын беравык көтәргә карар итте. Каршы яктан килүче төркемнең юлы озынрак иде. «Урыннарына килеп җитсеннәр,— дип уйлады ул,— әзерлекне ашыкмыйча тәгалләсеннәр...»

Командир як-ягына карангалап алды һәм үзләренең гаять олы ялгыш җибәрүләрен аңлады. Чөнки сугышчылар барысы да диярлек кар өстендә кара тап булып ачык күренәләр иде.

Ләкин, кем әйтмешли, үткән эшкә салават...

Петров белән ике разведчикның каравыл ротасы яшәгән бинага таба киткәненә ун минут чамасы үткәч тә, Кадермәтов җиңелчә генә сызгырып куйды һәм, җирдән күтәрелә төшеп, бүреген алга таба селтәде. Үзе юл читеннән бөгелә төшебрәк алга ыргылды.

Сугышчыларның да бердәм кузгалганын аркасы белән тоеп барды ул. Ниһаять, каравыл бинасының уты күренә башлагач, майор кар өстенә ятып шуышырга тотынды.

Нибары кырык-илле адым җирне шуышып узарга кирәк иде.

Әмма Кадермәтовка ул ара искиткеч ерак сыман тоелды. Халхин-Голда, фин сугышында, аннан соң да инде ничәмә-ничә тапкыр дошман уты астында менә шулай шуышырга туры килгәләде аңа . Ул чакларда Кадермәтов болай ук дулкынланмады шикелле. Чөнки ул анда сугышчыларының һичшиксез үзе артыннан барачакларына ышана иде...

Аякларын алмаштырган арада, ул артка борылып карады. Ләкин аның борчылуы урынсыз иде: сугышчылар инде һөҗүм дәртенә кергәннәр, аларның һәркайсы тизрәк максатка ирешергә ашкына иде.

Шулвакыт алдан:

— Тизрәк! Алга, иптәшләр! — дигән чакыру ишетелде.

Сугышчылар бердәм күтәрелделәр, фашистларның каравыл бинасына ташландылар. Шул ук мизгелдә диярлек фашистларның ягулык тутырган цистерналары ягыннан көчле шартлау тавышы күтәрелде.

Аңа тәрәзә пыялаларын ватып кергән гранатаның тоныкшартлавы кушылды. Ул да түгел, берьюлы ике пулемет ажгырып ут сиптерә башлады, аларга автоматларның өзек-өзек тыкылдавы килеп ялганды.

Бинадан чыгарга омтылып караучы фашистлар, һөҗүм итүчеләрнең ярсу утыннан сөрлегешеп, җирне түши башлады.

Кадермәтов Тимофееваның:

— Иптәшләр, әсирләр... әсирләр сараена! — дип кычкыруын ишеткән кебек булды. Әсирләр сараена барырга тиешле отделениенең төп төркемнән аерылып китүен күз кырые белән генә чамалап өлгерде.

Майор, тәрәзәдән сикерүчеләрне автоматыннан кистерә-кистерә, уйлап алды: «Чая хатын булып чыкты бу Тимофеева, лачын шикелле алга ташланды. Шулай да икенче тапкыр мондый бәрелешләргә кертмәскә кирәк булыр аны»,— дип күңеленә беркетте.

Шушы мизгелдә Тимофееваның ихтыярсыздан артка каерылып, канатлары сынган кош шикелле җиргә егылганын күрергә вакыты булса иде Кадермәтовның...

Ләкин тәрәзәдән олы гәүдәле фашистның сикереп төшүен, автоматының атмый башлавын күреп: «Ни булды?» дип уйлый иде ул. Автоматында патроннарның бетүен аңлады. Фашист инде атарга кулын күтәрә, аның пистолетының кара салкынлыгы аермачык тоела иде. Менә-

менә... Әмма фашист атарга өлгерә алмады, кемдер (тагын Петров бит бу!) арттан килеп аны бик тиз миңгерәүләтте...

— Рәхмәт, Петров,— дип кычкырды Кадерматов, автоматына яңа магазин куя-куя, бәрелеш кайнарлыгы сүнмәгән урынга йөгерде.

Биш минут үттеме, юкмы, фашистларны кырып салдылар.

Кадерматов:

— Коралсызларга монда калырга, бөтен трофейны тупларга, калганнар — минем арттан! — дип кычкырды. Бу турыда алдан ук сөйләшенгәнгә күрә, аны шундук аңладылар.

Цистерналар тирәсендәге ялкын күк гөмбәзенә хәтле күтәрелгән иде. Хәзер инде бөтен тирә-як көндезгедәй әллә ничә чакрымга яктырып күренә.

Әсирләр сараена җитәргә биш-алты адым калгач арадан берәү Кадерматовка:

— Иптәш командир, иптәш командир... Тимофееваны...— диде. Анары, командирның туктап борылуын күреп:— Үтерделәр...— дип тә өстәде.

Майор — һәрнәрсәне бик тиз аңлап алып, тиешле чараны күрергә өйрәнгән кеше — сугышчы авызыннан чыккан сүзләрнең мәгънәсен аңлый алмыйча тораташтай басып торды.

— Бул...мас, бул...мас,— диде Кадерматов, ниһаять, тамак төбеннән чыккан, кинәттән карлыгып киткән тавыш белән. Ләкин аның бу тавышы үзенә дә ишетелми һәм аңлашылмый иде.— Бул...мас...

Дүрт сугышчы Тимофееваның гәүдәсен плащ-палаткага салган килеш күтәреп киләләр иде. Кадерматов янына җиткәч туктап калдылар.

— У-ухxx! — дип тешләрен шыгырдатып алды майор.— Кабахәтләр, җавап бирерсез моның өчен!

Кара төтен белән ялкын кушылган шәүләләр кар өстендә качышлы уйныйлар иде... Кадерматов ике арадагы берничә адымны тәнендә булган барлык көчен җыеп бергә туплаганнан соң гына атлый алды.

— Ан-на... Матвеевна, бу ничек болай булды соң? Нигә сакланмадың?

Кадерматов салмак хәрәкәтләр белән Тимофеева пальтосының төймәләрен ычкындырырга кереште. Аннары колагын аның күкрәгенә куеп йөрәк тибешен тыңлап карады, әмма берни дә ишетмәде. Шул чагында гына ул Тимофеева өстендәге аксыл джемперның алсу төскә манчылганын күрде, кесәсендәге кулъяулыгын алып, кан саркып торган ярага каплады. Аның бармаклары Тимофееваның күкрәгеннән саркуын дәвам иткән канның җылысын тойдылар. Алай гына да түгел, шушы җылы аның үзендәге кан тамырлары буйлап йөрәгенә таба йөгергәндәй булды. Майор сул кулы белән Тимофееваның маңгаена төшеп торган чәчләрен артка сыпырды.

Кадерматовның шул хәрәкәтенә җавап биргән сыман, Тимофееваның күз кабаклары селкенеп куйды.

Сугышчыларның берсе шуны күреп:

— Исән бит! Комиссар исән әле, иптәш командир! — дип кычкырып ук җибәрде.— Тизрәк ярдәм күрсәтергә кирәк... Яраларын бәйләргә кирәк, командир. Каравыл йортында фашистларның аптечкалары булмый калмас...

«Эһ-ма,— дип уйлады майор,— врач юк инде, ичмасам, бер фельдшер кисәге булсын иде». Һәм шунда ук өстендәге шинелен салып җиргә җәйде дә сугышчыларына:

— Куегыз! — диде.— Әсирләр янына йөгерегез, берегез. Бәлки алар арасында хәрби врач бардыр?

Ул арада старшина төркеме дә килеп җитте.

— Иптәш командир,— диде ул, килеп җитмәс борын ук.— Задание үтәлде. Райүзәк юлын арканлап, засадага барыйкмы әллә? Ярдәм килмәгәе...

Никифоренко, җирдә яткан яралының Тимофеева икәнлеген күреп, сүзсез калды.

Сугышчы дөрес чамалаган икән: каравыл бинасыннан шәхси медицина пакетлары табып китерде. Кадермәтов шундук аны теш- ләре белән ертты да Тимофееваның канлы джемперын икегә аерып ташлады һәм йөрәк турысыннан өстәрәк, кулбашы төбендә күгел- җемләнебрәк торган ике нокта күрде. Кан шулардан саркый иде.

Анна Матвеевна, Кадермәтовның колагына гына пышылдагандай, ишетелер-ишетелмәс итеп:

— Хуу-ушш... Кадер-мә-тов,— диде.— Хуш... Булдырдык бит...

— Сөйләшмә, Анна... Сөйләшмә...

Тимофеева көрсенеп куйгандай итте, аннары елмайган килеш күз- ләрен йомды. Ләкин бу — күзләрнең мәңгелеккә йомылулары түгел иде әле...

Трофейларны җыеп бетергәч тә, унлап немецның райүзәк ягына таба качып котылуын әйттеләр. «Бусы, билгеле, бик үк әйбәт түгел... Качырмаска иде аларны, дөмектерергә иде бөтенесен дә»,— дип уйлады майор. Тик эш узган, тегеләрне куып тотарлык түгел иде инде.

Әлеге бәрелештә Тимофеева һәм тагын дүрт сугышчы яраланган иде. Беренче операция өчен зур югалту иде бу, чөнки Тимофеева белән тагын ике сугышчының яралары гаять куркыныч һәм кичекмәстән дәвалауны сорый иде.

— Никифоренко, син хәзер үк Тимофееваны Хачлыга, Серафим дәдәйгә алып китәрсең... Бәлки ул күрше районнардагы партизаннарга озату җаен табар? Шул ук вакытта берәр врач-фәлән юкмы, беле- шерсең,— дип боерды Кадермәтов.— Сугышчыларны авылга илтергә ярамас... Булдыра алганча үзебез дәвалагандай итәрбез. Бәлки, врач табарбыз әле...

## 10

Һөҗүмнән соң өч көн үтте.

Баштагы көнне Кадермәтов «фашистлар эзәрлекләп килмәгәе» дип урман юлларына көчле дозор-маяклар җибәрде. Әмма кар, ява башлап, сугышчыларның эзләрен каплап киткәнгәме, әллә нинди дә булса бүтән сәбәптәнме, фашистларның зур көчләре урман тирәләрендә күренмәде. Дөрес, тирә-як авыллардан: «Десантчыларны күрмәдегезме? Авылга кермәделәрме?» дип, полицайларның артларына ут капкан шикелле иснә- неп йөрүләрен хәбәр иттеләр.

Майор, немецларның аэродромдагы көчләрен туздырып кайтырга чык- канда ук, үзләре уйлап җиткермәгән бер нәрсәне хәл итәргә тиеш булды.

Һөҗүм вакытында аэродром төзелешендә эшләүче әсирләрне кот- карачаклары мәгълүм иде. Аларны яңа базага алып кайтырга туры киләчәк иде. Ләкин теге мескеннәрне күргәч тә моны эшләргә яра- мавын аңладылар. Бер-берсеннән киемнәренең начарлыгы белән генә аерылып торган йөз дә тугыз әсирнең җитмешләбе генә үз аягында йөреп урманга таба атлый ала иде. Ачлык, каторжаннарча эшләтү, әсирлеккә эләгүнең хурлыгыннан нишләргә белмәгән бу бичараларның байтагысы эч китү кебек йогышлы авырудан интегә булып чыкты. Шуның өстәвенә, егермеләп кеше әле сугышларда алган яралары төзәлмичә чилә- нүдән бимазалана иде. Тагын да тирәнрәк уйлап карaганда, Кадер- мәтов, алар арасында сатлык җаннарның булу ихтималын да чама- лады. Кем белсен, бәлки әсирләр арасындагы командирлар һәм комму- нистларны аралап алыр өчен махсус кертелгән «әсирләр»нең дә булуы бик мөмкин. Ә аларны тикшермичә-нитмичә генә партизаннар базасына алып кайтсаң...

Шулай итеп, әсирләр өчен, яңа базадан арырак, тагын бер лагерь оештыру кирәк булып чыкты. Яңарак кына мөстәкыйль хәрәкәт итә башлаган отрядның үз кешеләрен тукландырырлык та азык-төлек запасы юк иде, тагын йөз дә тугыз кеше өстәлгәч, бу мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кирәк иде. Шул максат белән аэродромнан бөтенләй икенче яктагы ерак авылларга өч төркем җибәрелде. Алар иң беренче нәүбәттә, немецлар обозын табып, засада оештырырга, алар халыктан талап алган ризыкны кулга төшерергә тиеш иде. Тик ачлыктан шешенеп беткән әсирләрдә ул төркемнәрнең уңышлы засадалардан кайтканын көтәрлек көч калмаган иде инде. Шуңа күрә, тагын бер бәләкәйрәк төркем туплап, якын-тирә авылларга җибәрергә дә туры килде.

Бары тик дүртенче көнне генә Кадерматовның мәшәкатьләре бераз кимеде. Тимофееваның хәлен белешәсе иде, ул Хачлыга барып кайту уе белән җилкенде. Ләкин хәл итәлергә тиешле мәсьәләләрнең күплеге, аларның барысына да командир кирәклеге аны бу адымнан тотып, тоткарлап килде. Аннары фашистларның авылларга ябырылуы да бик ихтимал иде.

Ниһаять, урман каравылчысы йорты янында калдырылган пост-«маяк»тан өч полицай килеп, урман каравылчысыннан «десантчылар» турында сорашуларын җиткерделәр. Бу хәбәр турында уртак фикер туплап өлгермәделәр, Хачлыга Тимофееваның хәлен белергә җибәрелгән Никифоренко әйләнеп кайтты. Ул да авылга биш-алты полицайның килеп төшүен, аларның колхоз идарәсенә урнашып алуларын сөйләде.

Майор старшина алып кайткан хәбәрләрне бүлдермичә тыңлады, әмма аның күңеле икенчене — Тимофееваның хәле турындагы сүзләрне көтте... «Нишләде, аңына килдеме-юкмы икән,— дип түземсезләнеп уйлады.— Күрше район отрядына озату чарасын күрмәдеме икән Серафим дәдәй? Моны хәзер разведчикларга тапшыруы кыен һәм икеләтә куркыныч. Бөтен өмет Серафим дәдәйдә генә инде...»

Ниһаять, түзмәде, сорады Кадерматов:

— Комиссарның хәле ничек, старшина? Нигә ул хакта әйтмичә сузып торасың? Уңайгамы? Берәр төрле ярдәм күрсәтә алганнармы?

Никифоренко, гомумән, әйтәсе сүзен җиде кат уйлаганнан соң гына әйтә, ләкин бер әйткәнен икенче кабат сорарга урын калдырмый, аңлаешлы итеп әйтә белә иде. Бу юлы да ашыкмады ул. Кесәсеннән тәмәке тулы янчыгын чыгарды (майор белде: Серафим дәдәй бүләге иде бу...), икенчесеннән пөхтә итеп бөкләнгән газета кисәге алды һәм шуннан соң гына:

— Терегез, иптәш командир, янган йөрәкләрне бастыра торганы,— диде. Үзе, күптән өйрәнелгән гадәтенчә, көяз «каз аягын» төрде, теленең очы белән чылатып ябыштырды һәм көйрәтеп җибәргәч кенә: — Икеөч тапкыр һушына килгән, командир,— дип өстәп китте.— Минем алда да бераз сөйләшеп алды... Яралары җиңелдән түгел, ләкин ике пуля да үтәли чыккан, димәк, операция-мазар кирәкмәстер... «Бөтен тәне утка салгандай яна, температурасы көчле, кайтканда салкын тидермәдегезме икән»,— диде Василиса түти... Ул карчыкның үз дарулары, әллә нинди үләннәре бар аның, доктордан бер дә ким түгел...— Старшина тәмәкесен тирән итеп ике-өч тапкыр рәттән суырды да тагын өстәп куйды: — «Кадерматов исәнме? Аны күрәсем килә»,— дип сорады Тимофеева.

Болай да җай көтеп йөргән, ләкин ихтыяр көче белән үз омтылышын басып торган Кадерматовка старшинаның соңгы сүзләре җитә калды. Ул урыныннан торып штаб землянкасындагы дүрт-биш адымлык араны үлчәп килде һәм:

— Барырга кирәк, барырга...— дип күңелендәге кычкырып әйтте.— Сез ничек уйлыйсыз, егетләр? Син, Добротов?

Кече лейтенантка һөҗүмнән соң да эш җитәрлек иде, шунлыктан аңа йокларга туры килмәде диярлек. Ул кызарынган күзләрен майорга таба күтәрде. Аның карашында: «Бармаска кирәк, командир, полицай-

лар бер дә юкка гына килмәгәннәрдер».— дигән сүзләр булса да, Кадерматов белән Тимофееваның көннән-көн нығый барган үзенчәлекле мөнәсәбәтен, аларның көнләп түгел, сәгатьләп бер-берсенә якынаюларын үзләреннән күбрәк күреп торганга, бөтенләй икенче сүзләрне әйтте:

— Турысын әйткәндә, командир, бармыйча тору да бик ярар иде... Ләкин, нишләмәк кирәк, яралы кешенең теләге изге... Минемчә, Никифоренко командирны озата барса...

Кадерматов моңа шундук каршы төште.

— Юк! Никифоренко районүзәк гарнизонын күздән ычкындырмаска тиеш. Төп-төгәл разведмәгълүматлардан башка без дөм сукыр калачакбыз. Аннары... аннары, немецларга яңа көчләр килгәләгәнче, андагы гарнизонны да кайнар табада куырып алырга кирәк булыр. Никифоренко, шушы операциягә кирәкле мәгълүматларны тупларга тиеш син. Бу — боерык сиңа! — дип икеләнергә урын калдырмады майор.— Ә мине Игебаев белән берәр сугышчы озата барырлар...

Шулай да, Добротовның командирны җибәрәсе килми иде, күрәсең, ул килешеп үк бетмәвен белдерде:

— Иптәш командир... Әгәр дә мәгәр Тимофееваның хәле кискенләшсә, хәбәр итәрбез. Василиса түтинең үләннәре теләсә нинди врачны алмаштыралар ди бит әнә...

— Юк инде Добротов,— дип кырт кисте Кадерматов.— Мин, аңлыйсыңмы, мин Анна Матвеевнаны утка керттем... Аннары, ул бит бөтәннәрне түгел, мине чакыра... Үзең әйтәсең бит, яралының теләге...— Ул тагын беравык дәшмичә арлы-бирле йөренде. Ниһаять, үзенең икеләнүләрен бөтенләй җинде.— Син биредә каласың, Добротов. Син, штаб начальнигы буларак, бөтен элемтә җепләрен кулыңда тотарга тиеш. Син — минем урынга каласың...— Аннары, тагын бер әйләнеп килде дә:— Дөнья хәлен белеп булмый, Добротов... Ни генә булмасын, син полк Байрагын сакларга, үзебезнекеләр килгәнче сакларга бурычлысың...

## 11

Айсыз, ләкин аяз төн иде. Аяк астында яңа яуган кар сизелерсизелмәс кенә кыштырдый. Урмандагы агач ботаклары, экияти дөньяны хәтерләтеп, кар мендәрчекләрен күтәреп утыралар. Һәркайда тынлык. Хәтта башка төннәрдә тегендә-монда авыр улашып узган самолетлар тавышы да ишетелми. Әйтерсең, тирә-юньдә дошман басып алган, туздырылган, яндырылган авыллар һәм шәһәрләр, гаепсез атылган кеше гәүдәләре белән тулган чокырлар, үзләрен генә җирдә яшәргә хаклы дип масаючы фашист хәшәрәтләре — берсе дә, берсе дә юк. Әйтерсең, һәммә җирдә менә шундый тынычлык хөкем сөрә бүген...

Кадерматовның аяк астыннан диярлек, чикләвек куаклары арасыннан, урман тавыгы пырхылдап чыкты да, куркуыннан нишләргә белмичә, сикерә-оча агачлар арасына кереп югалды.

Майор моны яхшыга, бары тик яхшыга гына юрады.

Эх, Анна, Анна... Ничек болай булды соң әле бу? Көтмәгәндә генә очрадың да, сугыш вакыты дип тормыйча, Нисадан соң күңелдә укмашкан төерне санаулы көннәр эчендә таратып та ташладың... Кадерматов тагын алсу шәүләләр биешкән кичне, плащ-палаткада яткан Аннаны һәм аның канга баткан күкрәкләрен күз алдына китерде, тетрәнеп куйды. Исән калырсыңмы соң син, Анна? Сиңа бит әле утыз яшь тә тулмаган... Синең бит әле сөяр һәм сөелер чагың гына... Күрәсең, Кадерматов дигән затның язмышы, хатын-кызлардан бәхете, чынлап та, шундыйрактыр инде... Нисадан соң инде ул, берәүне дә ярата алмам дип, гомерлек буйдак булырга әзерләнгән иде. Ләкин вакыт дигән нәрсә аның кайгысын үз тегермәненә салып әйләндереп чыгарды... Тимофеева дигән хатын белән очраштырды. Ләкин... Кадерметов үзенең хисләрен-

тойгыларын аңларга өлгермәде, Тимофеевага әйтү турында сүз дә юк, аның кайгы һәм хәсрәт, үч һәм нәфрәт арасында шушы хисләрен уяткан йөрәгендә фашист хәшәрәте тагын бер яра ачты...

Кадермәтов, гомерен хәрби хезмәткә багышлаган кеше, дошманнан ничек үч алырга тиешлеген яхшы белә иде...

— Иптәш командир,— диде алданрак атлаган сугышчыларның берсе. Кадермәтов аны таныды. Игебаев иде бу.— Хәчлы авылына алып төшә торган уйсулык башына җиттек. Нишлибез?

— Шулаймы? — диде тиз килеп җитүләренә гаҗәпләнгән Кадермәтов һәм тирә-ягына игътибар беләнрәк карады.— Минемчә, Игебаев, озакламый таң беленә башларга тиеш. Шуңа хәтле барыбыз бергә төшсәк тә була...

— Юк, иптәш командир. Кем әйтмешли, сакланганны ходай саклармын дигән...

— Ярый алайса, Игебаев, ходай хәтле ходай белән бәхәсләшеп торыр вакыт түгел хәзер... Авылга төшегез, күз-колак булыгыз. Шикшөбһә булмаса, минем арттан берегез бакчалар очына килсен. Анда таба мин беравыктан төшә башлармын. Ярыймы?

— Ярый, иптәш командир...

Сугышчылар китеп унбиш-егерме минуттан соң кузгалды Кадермәтов үзенең билгесез сукмагына...

Әй, бу адәм затының тормыштагы юлларының билгесезлеге, һавалардагы йолдызларны санарга, җир асты тирәнлегенә яшеренгән байлыкларны эзләп табарга зиһене житкән кеше дигән акыл иясенең сукырлыгы... Син бит җир шары дигән планетада миллион, кем белсен, миллиард еллар яшисеңдер... Әмма син бүгенгәчә үз язмышыңның кайсы урынга барып төртеләсен һәм кайсы төшнең кайсы минутында соңгы сулышыңны аласыңны мыскалның мыскалы кадәр генә дә чамалый алмыйсың...

Кадермәтов Хәчлы авылы бакчаларына барып җитә язуын сизмичә дә калды. Каршысында беренче каралтылар сураеп күренә башлагач кына туктап авылны күзәтергә, Игебаевтан хәбәр көтәргә кереште ул.

Төн инде таң ягына авышты. Тагын кар явар, бәлки, бураннар кубар, аннары чатлама салкыннар башланыр. Шул бураннардан һәм салкыннардан файдаланып калырга, фашистларның берәр азык-төлек складына, яки обозына һөҗүм оештырырга кирәк булыр дип күңеленә беркетте Кадермәтов. Ә разведчик нигәдер күренми әле, байтак вакыт үтте бугай...

Ул шулай уйлап бетерергә өлгермәде, бакчадагы куаклар янынннан бер кара шәүлә аерылды. Кирәге чыга калса дип, Кадермәтов автоматының затворын тартып куйды, бармагын саклагычка салды.

Игебаевның өзек-өзек сызгырып тавыш биргәне ишетелде. Бу аның «юл ачык» дигән сүзе иде.

— Нихәлләрсез, Серафим дәдәй, Василиса түти,— диде Кадермәтов.— Авырмыйсызмы?

Урынсызрак сорау иде бу, ләкин авыздан бер очып чыккан «чыпчык»ны кире кертеп булмый инде аны.

— Әйдә, Кудров, уз,— диде Серафим дәдәй. Аның тавышында ниндидер үпкә сизелеп тора иде.— Без авырмыйбыз да бит...

— Анна... Матвеевна кайда соң?

— Ул үз урынында ята. Ләкин нинди хәлдә ята? Ничек соң, Кудров, шундый саксызлык күрсәттегез? Ир-ат барыр җиргә хатын-кызны җибәрдегез? А-а-ахх! — Серафим дәдәй кухня ягына күрсәтте.— Анда... сине көтә... Саташудан арына алмый, температурасы көчле. Йокыга китте бугай әле... Шулай таң алдыннан гына бераз онытылып тора. Уятмыйча торыйк әле...

Кадермәтов дәшмәде, ни әйтергә дә кыймады.

— Дөрес, аңлыйм инде мин, Аннушканың дилбегәсе үзе белән иде... Алай да...— диде карт кинәт йомшара төшеп.— Син бөтенләй нитмә... Аннушка аңына килгән саен: «Райүзәктәге җәмәгать мунчасы янында пенсиядәге врач Дедов яши,— ди, шуны алып килсәгез иде»,— ди. Бүген шунда барырмын дип тора идем әле... Бу көннәрдә олау белән юлга чыгып кына булмый...

Кадермәтов болай да үзен ничә көн буена битәрли, Тимофееваны саклый алмауда бары тик үзен гаепли иде. Серафим дәдәй сүзләреннән соң тагын да аптырый төште.

— Ярар инде, ярар, Кудров, нишләмәк кирәк... Сугыш бит ул уен түгел...— диде Серафим дәдәй, Василиса түтинең мышкылдавын ишетеп.— Син, старуха, туктале, не каркай анда.

Василиса түти кухня ягыннан чыкты да:

— Ходайныкын кем белгән аныкын... Саклый алмагансыз, дип кешенең җанын телгәләп утырасың, картлач...— диде ул, Серафим дәдәйгә ачуланып.— Күрмисеңмени аның нинди хәлдә икәнлеген. Күзең чыккан мыни соң синең... Э-э-эхх! — Аннары командирга төбәлде: — Әллә соң, күгәрченкәем, берәр кружка салып биримме үзеңә? Кәефең ачылыбрак китәр иде...

Серафим дәдәй моңа бик нык гаҗәпләнеп карады. Байтактан бирле карчыгының андый сүзне телгә алганы юк иде. Ничә тапкыр сорап карады, «юк»тан башканы ишетмәде.

— Әйдәле, әйдә, китер, старуха. Сорап торган буласың тагын...— дияргә өлгермәде, урам ягында ату тавышы ишетелде, аннары бер этнең җан ачысы белән чинавы яңгырады.

## 12

Кадермәтов мәче җитезлеге белән ишеккә таба атылды. Ләкин Серафим дәдәйнең:

— Кая барасың, Кудров, оныттыңмы? Төш идән астындагы урынына,— дигәнен ишетеп, кухня ягына ашыкты. Андагы сәкедә Тимофеева ята иде. Өйдәге ыгы-зыгыдан булса кирәк, ул уянып китте.

Тышта инде яктырган диярлек, ләкин кухня тәрәзәсе томаланганга күрә, биредә эңгер-меңгер иде әле. Тимофеева майорның янәшәдә икәнлеген күңеле белән тоепмы, әллә сулышыннан таныпмы:

— Кадермәтов, ка-а-дерлем, син мондамы әллә? — диде.

Аның тавышы хәлсез, әмма барыбер аэродромдагы кебек үк өметсез түгел иде.

— Әйе, Анна... Мин бу,— диде Кадермәтов, идән асты капкачын ачык калдырган килеш, Тимофеева янына ук килеп, аның юрган өстендә яткан кулын тотты. Кайнар, нинди кайнар иде бу кул...

Идән асты капкачын яхшылап ябарга дип кергән Василиса түти озак сөйләшергә ирек бирмәде:

— Төш, төш тизрәк, Борис,— диде ул кабаланып.— Керәләр, ходаем, үзең сакла...

Кадермәтов, теге вакытта ук күнегелгән гадәтенчә, тавыш-тынсыз гына идән астына төшеп югалды.

«Серафим дәдәйнең үткенлеген әйтер идем,— дип уйлап куйды ул махсус куелган бүкәнгә утыра-утыра.— Түр ягындагыдан бөтенләй аерым идән асты бүлмәсе уйлап тапкан, ничек әйбәт итеп эшләгән бит. Безнең землянкалардан бер дә ким түгел»...

Өстә кемнәрнеңдер ишектән кергәне ишетелде, ул да түгел, Кадермәтовка таныш тавыш гөрелдәде.

— Сездә чит кешеләр юкмы, картлач? — диде тавыш Серафим дәдәйгә тупас итеп.— Бәхетең... Югыйсә, сине беләм мин... Партизанлыкка һәвәс кеше син, картлач... Тагын бер сәгатьтән карчыгың белән... майданга бар. Кара аны! Качып котылырмын димә. Җыен би-ик күңелле

булачак... Бәлки үзеңне староста итәрбез әле анда...— дип тагын бер кат җикеренде ул.

«Зайцев, валлаһи, күпер төбендә немецларга качкан Зайцев бит бу! — Кадермәтовның зирәк хәтере өстә җикеренүче тавышның хуҗасын эзләп тапты.— Күрәсең, дөмектерә алмаганмын...»

Шартлап ишек ябылды һәм тагын беравыктан өйдә тынлык урнашты. Аннары кухия ягына күчереп куелган чиләк тоткасы чылтырады.

— Мондагы полицайларның өлкәне... Теге елда ук сөрелгән кулак Захарий эте бу... Этнең дә котыра башлаганы. Кудров. Нindидер җыенга чакыра. Немецларның зур начальнигы, райүзәк коменданты килә ди. Син, давай, Кудров, идән астына шыл без киткәч,— диде Серафим дәдәй. Ул тагын нәрсәдер өстәмәкче иде, Василиса түти:

— Фашистлар... Күбәү... Авылны урыйлар,— диде тынына кабып.

Бу юлы майорның беренче теләге — ишегалдына, аннары печәнлектә яшеренгән Игебаев белән сугышчыны алып бакчага һәм уйсулык буйлап урманга качу иде. Ләкин Василиса түтинең: «Авылны урыйлар» дигәнен ишеткәч, соңга калуын, тышта инде яктырып җиткәнен төшенеп алды.

— Әйдә, старуха, җыенга,— диде Серафим дәдәй.— Бу эт баласының тагын килеп керүе бар. Кузгала башлыйк. Немецлар да күрер безнең чыкканны... Ә син, Кудров, давай, идән астына кач...

— Ә Анна...— диде Кадермәтов.— Аннаны үзен генә калдырабызмы?

— Нигә үзе генә, син каласың. Без кайткалаганчы... Керә башласалар, идән астына алып төшәрсең...

Әйтүе кыен, әмма ниндидер бер көч Кадермәтовны халык җыенына, мәйданга тарта иде. Бәлки, бу партизан отряды командирына әверелгән хәрби кешенең бүген-иртәгә аяусыз бәрелештә очрашырга тиешле дошманнарына якыннан карау, аларны танып калу теләге булгандыр. Бәлки, кем белсен, дошманның мәкерлелеген аңлап бетермәү... ничек булса да булгандыр, әмма Кадермәтов кинәт:

— Юк! Мин дә барам җыенга, Серафим дәдәй. Мине белмиләр бит алар... Ә авыл кешеләренә ышанычым зур минем, сатмаслар...

— Што син, Кудров, што син... Ни сөйлисең син? — диде Серафим дәдәй аның бу сүзләреннән аптырап, тунының җиңен таба алмыйча селтәнә-селтәнә.— Мин сиңа барысын да түкми-чәчми җиткерермен. Авыл кешеләре сатмас, ә теге Захарий эте...

— Юк, Серафим дәдәй, ул мине танымас... Күздән бирле әнә нинди сакал-мыек басты мине. Өс-башым да синекеннән аерылмый... Иске тун астыннан күренми...

Серафим дәдәй карчыгын көтеп торган арада Кадермәтов тышка чыкты. Аның башында: «Игебаев белән сугышчыны кисәтеп куйсаң ярар иде яравын»,— дигән уй кисәге ялтырап калды. Ләкин, урамнан үтеп баручы күрше-күлән картларын күреп, тиз-тиз генә капкадан чыкты да алар төркеменә кушылып мәйданга таба атлады.

— Ах, Кудров, ах башсыз... Яхшыга түгел бу... Бармаска иде,— дип сөйләнде Серафим дәдәй, печәнлеккә кереп сугышчыларны кисәткәннән соң. Әмма эшлисе, эш эшләнгән иде инде, шуна күрә ул да, Василиса түтине култыклап, җыен буласы урынга юнәлде.

Урамга чыгуга аңлады: чынлап та, хәерле көн түгел иде бу...

## 13

Халык җыелып бетте. Әле кайчан гына яшьләрнең шат тавышлары, уен-җырлары, гармун тавышлары күңелләрне җилкендереп торган клуб болдырына озын тунлы бер кеше һәм немец офицеры чыктылар да йөк машинасы әрҗәсенә күтәрелделәр.

Мәйдандагы сәер шау-шу берьюлы тынып калды. Әйтерсең, әле генә

биредә ыгы-зыгы хөкем сөрмәде, әйтерсең, балаларның елашулары ишетелмәде...

Офицер нәрсәдер әйтте, сүзләрен тагын бер кабатлады да туктап калды. Кулың биленләге кобурасына куйган килеш, халык өстенә югарыдан карап, «Менә мин сезнең яңа хуҗагыз булам»,— дигән сыман тота иде ул үзен.

Кадермәтов аның «ахтунг», «совет», «десант», «командир» дигән сүзләрен аңлап алды.

Халык, «тагын ни әйтер бу?» дигәндәй, шомлы тынлыкта торды.

Офицер тагын нәрсәдер кычкырды һәм Кадермәтов үз өстенә тау ишелеп төшкәнне күреп торган кеше шикелле куырылып куйды. Чөнки аның колаклары немец офицеры авызыннан чыккан сүзләр арасыннан «Ку-удруфф!» дигән авазларны аерып алды.

Ул арада офицер янында басып торган тунлы беркадәр алгарак чыкты һәм, тамагын кыргалап, халык өстенә кычкырырга керешге.

Кадермәтов, аны, тамагын кырып, беренче сүзен әйткәндә генә таныды: күпер төбендәге ыгы-зыгыдан файдаланып, немецлар ягына качкан Зайцев иде бу. «Эх,— дип тешләрен кысып уйлады Кадермәтов — бүтән вакыт булса кулым калтырамаган булыр иде. Ул чагында...»

— Офицер әфәнде сездән сорый,— диде сатлык җан, тамагын киереп.— Безгә билгеле булганча, ди ул, сезнең авылда совет десанты яшеренеп яткан. Димәк, сез аның кайда икәнлеген белергә тиешсез ди. Сез офицер әфәндегә һәм аның батыр солдатларына шул Кудров бандасы яшеренгән урынны күрсәтергә тиешсез. Әгәр күрсәтмәсәгез...— Сатлык җанның тыны бетте. Ул каушавыннанмы, әллә хезмәт күрсәтергә артык тырышуданмы, сулыш алырга да оныта иде бугай.— Немец солдатлары башта ирләрне, аннары хатын-кызларны, бәләкәй көчекләрегезгә хәтле атып үтерәчәкләр. Авылны яндырып, көлен күкләргә очырабыз ди. Мин әйттем... Хәзер офицер әфәнде сәгатенә карый һәм биш минутны саный башлый... Белүчеләр, яки күрсәтергә теләүчеләр алга чыгып басарга тиешләр...

Кадермәтов фашистлардан рәхим-шәфкать көтеп булмаганны яхшы белә. Ул аларның вәхшилекләрен аз күрмәде. Әмма ул күргән вәхшилекләр әлегә хәтле күбрәк хәрбиләргә, сугышучыларга гына кагыла иде. Хәзер исә фашистлар бер гаепсез кешеләрне җәзаларга җыеналар.

Нигә, нигә бу шулай килеп чыкты соң?

Нигә бу кешеләр фашистларның хурлауларына, гаепсез җәзалауларына дучар ителергә тиеш соң?

Нишләргә?

Әгәр дә мәгәр, аның аркасында кемнәрнедер вәхшиләрчә үтерәләр икән, алар артына яшеренеп калган Кадермәтов, гомер буена халык сакчысы булып кулында корал йөрткән, шул халыкны сакларга ант иткән кеше — ничек, нинди күзләр белән бу кешеләрнең йөзенә карар соң?

Кадермәтов белә, ышана: халык аны сатмас...

Теге сатлык җан да аны танымас... Мондагы ыгы-зыгыдан файдаланып, качып котылып та булыр иде, бәлки. Хәер, фашистлар шушы мәйданда ук ата башламаслар... Җыясы була бит... Читкәрәк, авыл кырыендагы ерганак читенә чыгарырлар яки әле бүгенгә биклән тә торырлар...

Кадермәтовның — Кызыл Армия командирының, коммунист кешенең гаепсезләр артына качып, аларны берәм-берәм атып үтергәннәрен карап торып үзенең җанын сакларга тырышырга хакы бармы?

Аның гомере мондагыларныкыннан кадерлерәкмени?

Алар бит әнә, үзләренең юклы-барлы ризыкларын да чолганыштан

чыгучылар белән бүлештеләр, туганнарын саклагандай яшереп яшәттеләр... Нигә, нәрсә хакына соңгы ризыкларын бүлештеләр соң алар?

Шул вакыт Кадерматовның күз алдына үлем белән көрәшеп ятучы Анна Тимофеева килеп басты. Бу шулкадәр көтелмәгән бер мизгелдә булды ки, Кадерматов, ирексездән иреннәрен кыймылдатып, ләкин берәүгә дә ишеттермичә генә күңеле белән сөйләшә иде: «Анна, сөйкемлем, әллә соң син минем күңелдә үзең кузгаткан хисләрне тоеп, аларны ишетергә теләп чакырдыңмы? Ә бәлки син үзең дә Хачлы авылының карт-корыларын, эби-карчыкларын, тол хатыннарын һәм әле мәхәббәт дигән татлы хисләрне татып карарга да өлгермәгән кыз-кыркын һәм яшь-җилкенчәкне яклашырга килгәнсең? Ә бәлки син өстенлек сөреме белән сугарылган, тарихка кереп калырга ашкынучы фашистларның йөзенә төкерергә уйлыйсыңдыр? Юк! Юк, сөйкемлем, монысын инде аның мин эшләргә тиеш... Хәзер минем чират. Бу юлы инде мин сине утка кертмәячәкмен! Бер гаепсез халыкны фашистлардан харап иттерсәм, мин бу җирдәге кешеләр күзенә, агачларга, хәзерге мизгелдә салмак кына битләремә төшүче энҗе бөртегедәй карларга ничек карармын, ничек яшәрмен соң мин? Илбасарлар тарихка керсәләр дә, яхшы сүз белән түгел, бары тик нәфрәткә төренгән килеш кенә керәчәкләр. Вәхшиләр булып, илләрне яндыручы-туздыручы булып керәчәкләр. Алар, иртәме-соңмы, халыкларның күз яшенә тончыгачаклар. Ә син, Анна, сөйкемлем, савык, яме. Мин сине, син сыенып ята торган җылы өйне яндырырга ирек бирмәм. Сине үз балаларыдай тәрбияләүчеләрне аттырмам... Ә сине, Анна, беләсеңме, сөйкемлем, яратып өлгергән идем бит инде мин... Тик ул сүзләремне син инде әллә ишетерсең, әллә юк...

Ату тавышы Кадерматовне чынбарлыкка кайтарды! Ни булды?

Аның бу соравы, теләнә килсә дә, авызыннан чыгарга өлгерми калды, халык арасыннан Василиса түтинең: «Серафим... Серафимушкаааа!» — дигән ачынышлы елавы атылып чыкты да мәйдандагылар өстенә күкләр күкрәве булып ябырылды.

Кадерматовка шулай тоелды. Дөрес, ул инде бу шартлаудан баягы кебек сискәнмәде, куырылып та куймады. Ул инде күкрәгенә мылтык терәсәләр дә курыкмаска, калтырамаска бөтен рухы белән әзер иде.

«Чык, Барый, нишләп торасың? Гаепсез кешеләрнең канын түктермә. Атла, алга таба атла... Төкер шушы фашист хәшәрәтләренең бәбәгенә, — диде Кадерматовка эчке бер тавыш. — Беләм, лачын кошка һава кадерле, әлбәттә. Аның биекләргә күтәреләсе, ерак-еракларга очасы, шушы биеклектән дошманның өстенә ябырылып төшәсе килә. Ләкин инде ул моны эшли алмый икән, ул чагында... ул чагында аның иксез-чиксез һаваларны айкап яшәгән җаны тоткынлык һәм көчсезлеккә түзми, ул шушы биеклектән кыялар кочагына ташлана. Син соң, Барый, күкләр кадерен белгән лачын кошка тиң түгелмени?»...

Кадерматов күкрәген тутырып салкын саф һава сулады һәм, үзен урап торган кешеләрне ике якка аралый төшеп, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! Кудров — мин булам!

Мәйдан, бердәм аһ итеп көрсенде...

Бу көрсенү Кадерматовка яңа көч бирде, аның йөрәге тагын да ныграк, ышанычлырак тибәргә кереште.

«Гаделлек хакына, халкымның азатлыгы хакына!» — диде Кадерматов һәм тагын бер тапкыр салкын һаваны күкрәгенә тутырып:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! Кудров — мин булам! — диде.

Төркемдәгеләр, Кадерматовка юл биреп, карлыгач канатлары сыман кыл урталай аерылдылар.

Шул ук минутта Кадерматовка дип ачылган бушлыкка җирдәге сугышка, кешеләрнең үлеменә битараф җаннар — чыпчыклар өере пырхылдап килеп керде. Алар артыннан ук, җитез истребитель шикелле, канатларын җилпемичә диярлек лачын кош атылып төште. Чыпчыклар,

Кадерматовның яланбашына һәм иңсәләренә тия язып, кешеләр арасына кереп югалдылар. Ә лачын кош исә өскә, күк йөзенә таба ыргылды...

Ирек сөюче бу җан иясе Кадерматовны да үзе белән әйдәп китте шикелле.

Баштагы сискәнүдән халык арасында ачыла төшкән сукмак акрынлап кысыла, ябыла башлады...

Ләкин... ябылырга өлгермәде, арага фашист автоматчылары килеп керде.

Кадерматов-Кудров салмак, нык адымнар белән аларга таба берничә адым ясады.

Ул өскә таба ыргыла барган лачын кошка күз төшерергә, аның белән саубуллашырга, туган якларына сәлам әйтергә өлгерде.

## Эпилог

Гәрәбә диңгез төне буена шаулады, котырынды.

Ул әле хәзер дә басылырга уйламый.

Бүлмәдә, балкон ишеге ачык булуга да карамастан, тын алу авырайды. Нишләптер, күз алдында кара таплар йөзеп-йөзеп йөрергә керештеләр. Чигәләрне тимер кыскычлар китереп кысты.

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! Кудров — мин булам!

Йодрык кадәрле йөрәк, миңа билгеле булмаган кануннарга буйсынып, күкрәкне бәреп чыгардай булып тибәргә, ирек дауларга керешге.

Мин ишекле-түрле атлаган җиремнән тиз генә өс-башыма киендем дә, озын коридордагы йомшак келәмнән барып, лифт төймәсенә бастым. Шул ук минутта колак төбемдә шартлау тавышы ишетелде.

Бөтен тәнем белән сискәнеп артка чигенә башладым...

Бер... ике... өч... адым.

Ләкин мине баягы көч яңадан үзенә буйсындырып алды, алга, тонык ут янган лифт тартмасына таба атларга мәҗбүр итте.

Ул тартма миңа Хачлы авылы мәйданындагы дар агачы сыман куркыныч иде.

Уйларым ишекләрнең теге ягында киселеп калды.

Йөрәк убылып-убылып алды. Ул ярсый, үч һәм нәфрәт белән тибенә. Колак төбемдә һаман бер үк сүзләр яңгырый:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! Кудров — мин булам!

Бу яңгыраш шул кадәр көчле, шул хәтле котылгысыз ки, мин нишләргә белмичә чарасызлыктан интегәм. Әйтерсең, Смоленск сугышлары вакытында урманнарда япа-ялгыз адашып, тәннәре туфракка әверелгән этиләрне эзләп йөрим-йөрим дә, аннары Хачлы авылына барып чыгам. Ә анда... Авыл уртасына куелган Туганнар һәйкәле янындагы Кызыл Байрак җилфердәвенә кушылып:

— Гаепсез кешеләргә тимәгез! — дигән чакырулы мәңгелек аваз яңгырый.

Гәрәбә диңгезенең тау-тау дулкыннары ак күбеккә баткан алмачуар чабышкы ат сыман ярсыйлар. Әйтерсең, аларга да еллар авазы сеңгән:

— Кешеләргә тимәгез!

Ярсыган дулкыннар, нишләргә белмичә, илаһи көч белән мең еллар буена куылган-тыгызланган комлыкны йөгерешеп узалар да, үзләренә киртә булып күтәрелгән ярның мәгърур күкрәгенә бәрелеп, яңадан табигый иркенлеккә ташланалар.

Мин ышанам: алар бу җирдән яңа көч алып, ераклардан килгән чакыру авазларын үзләренә сеңдереп дөнья океанына барып җиткәч, тагын бер тапкыр әйтәчәкләр:

— Ти-мә-геееез!!!

Ә диңгез гүли дә гүли...

*1985 ел. Дубулты.*

## Фәүзия Бәйрәмова

# КҮЛ БАЛЫГЫ

**ПОЭМА-ФАНТАЗИЯ**

Мин үземнең бу күлгә ничек килеп эләгүемне хәтерләмим. Язгы ташу сулары мине бирегә китереп аткан идеме, әллә җәйсән яңгыр тамчылары белән аралашып, күктән индемме — белмим. Мин әле башта үземнең балык икәнемне дә белмәдем. Мин башта а л а р н ы ң барысы кебек идем. Салкын күл төбенә төшеп ятулар, үлән арасыннан уйнаклап йөзеп узулар миңа бик ошый иде. Башкалар да минем белән бер, шөгыльләребез, хәрәкәтләребез дә барыбызныкы бертөслерәк иде. Ләкин әле мин аларның да кем икәнлекләрен белми идем.

Балык сүзе миңа югарыдан, су өстеннән килде. Юк, ул сүз дә түгел, аваз да түгел — ул сурәт, минем һәм башкаларның сурәте иде. Көн саен бер үк вакытта минем аңымда шул сурәт — мыжлап торган балыклар сурәте пәйда булды, һәм без, дәррәү атылып, бер тирәгәрәк җыела идек. Сурәттән тыш, су төбенә тонык кына дулкыннар да иңә. Бу безне шулай ашатырга җыеп алалар, берниндн хәвеф-куркытусыз безгә яхшылык эшлиләр иде.

Мин дә моны башта яхшылык эшләү дип аңлый идем. Ләкин су өстеннән, буталып, минем аңыма башка сурәтләр дә иңә башлады. Без, күл балыклары, бөтенебез зур ятьмәдә икәнбез. Безгә охшамаган ниндидер затлар безне зур чаннарга тутыралар. Без бәргәләнәбез, сикерәбез, чәбәләнәбез дә... тынабыз. Ут. Ялкын. Тәнне кисеп үткән авырту.

Хәтеремдә шушы сурәтләрне күргәч, мин а л а р биргән ризыкларны ашамас булдым. Котым очып, күл төбенә төшеп яттым. Башка балыклар, гөжләп, вак дулкыннар килгән якка йөзеп үттеләр. Мин башымны тизрәк үләннәр арасына яшердем. Су өстеннән тагын шул сурәтләрнең иңүеннән курыктым.

Ләкин бу юлы башка сурәтләр — мин бөтенләй күрмәгән, белмәгән сурәтләр иңде. Мин еректан үзебезнең күлне күрдем. Җир өстендә үсә торган үләннәрне, күктәге кояшны күрдем. Бу минем өчен искиткеч тын, искиткеч шомлы дөнья иде. Анда күктәге һәм судагы кебек зәңгәр төс түгел, анда күбрәк соры һәм яшел төс иде. Агачлар арасыннан кинәт... балык та түгел, мин кем икәнен белми торган, ләкин шулкадәр гүзәл бер зат йөгереп килеп чыкты. Менә ул күл буена йөгереп килә дә шундый ук бер затның күкрәгенә каплана. Шул сурәт су өстендә чайкалып тора, шул сурәт су төбенә төшә, шул сурәт минем аңыма үтеп керә дә, мин, үләннәр арасында кала алмый, кинәт авыраеп калган гәүдәмне

---

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА *(1950) — прозаик. 1986 елда Татарстан китап нәшриятында «Болын» дигән китабы басылып чыкты. Казанда яши.*

күлнең икенче читенә атам. Күл суы кинәт эсселәнеп китә, мин бер ярдан икенчесенә бәреләм, саташып. үзем кебек үк балыкларга килеп орынам да юеш салкынлыктан чирканып, тагын күл төбенә атылам.

Ул төнне бөтен балыклар әллә нинди тынгысызлык белән алгысындылар. Күл суы тоташ бер дулкын булып тирбәлеп торды-торды да таң алдыннан бөтен балыклар парлашып беттеләр. Алар, салмак кына йөзеп, бер-берсенә якынлаштылар, сыенган хәлдә, янәшә йөзеп бардылар, җирдәге парлы сурәт су астында кабатланды, меңгә тапкырланды, яшәде... парлап... янәшә...

Минем янга беркем дә килмәде. Балыклар күтүләре белән мине әйләнеп үттеләр, аулаграк урын сайладылар, мин якынлаша башласам, парларына сыенып, башка урынга күчеп киттеләр.

Башта гаҗәпләнсәм дә, аларның якын килмәвенә сөендем генә. Бу салкын, гамьсез балыклардан мин үзем дә читләшә, бизә башлаган идем инде. Аларның йөзүләре, су төбендә яши алулары минем кебек булса да, аларны миннән нидер аера, читләштерә иде. Соңыннан мин анысына да җавап таптым. Алар мин күргән сурәтләрне күрмиләр, алар уйлый да, курка да, тетрәнә дә белмиләр иде. Билгеләнгән вакытта ургылып ашарга баралар, көннең бер вакытында, үләнгә башларын төртеп, ял итеп алалар, аннан бер максатсыз йөзәләр дә йөзәләр, йөзәләр дә йөзәләр.

Мине тыелгысыз рәвештә су өстенә, әнә шул агачлы, чәчәкле, кояшлы җир өстенә, сәер затлар йөри торган җир өстенә тарта! Ут булып кызган тәнемне су өстенә ыргытам. Бер мизгелдә караңгы күкне, андагы якты нокталарны күреп алам. Минем инде аларны кайдадыр күргәнем бар кебек. Хәтеремне телгәләп, кинәт аңымда яшен яшьни. Күктәге якты нокталар бер якынаялар, бер ерагаялар, кинәт зураеп, зәңгәрләнеп, тоташ бер күлгә әйләнәләр. Юк, ул күл дә түгел, ул тоташ зәңгәр томан, шунда минем кебек үк балыклар йөзә. Ләкин алар мин күреп өйрәнгән күл балыкларына охшамаганнар. Йөзләре нәкъ теге җир өстендәге затларныкы кебек, әле алардан да гүзәлрәк, нәфисрәк. Ап-ак куллары да бар. Әнә мине дә үзләре янына чакыралар, йөзеп киләләр дә томан дәрьясына сарылалар, йөзләрендә моңсулык, борчу. Аннан зәңгәр томан кинәт юкка чыга, хәтеремне телеп, тагын яшен яшьни, җил-давыл куба, һәм мин, аңымны җуеп, караңгы бушлыктан түбәнгә атылам.

Аннан менә шушы күл...

Мин үземне башта күл балыгы дип белгән идем...

Хәтеремдә күкләр сурәте яңарган көннән мин үземнең ялгызлыгымны, чарасызлыгымны, фаҗигамне аңлап, күл төбенә капландым. Минем кузгаласым да, элеккеге кебек үләннәр арасында йөзәсем дә килмәде. Янәшәмдә йөзеп йөргән балыклар да миңа бөтенләй чит булып күренә башладылар. Күктәшләрем очканда, үземнең шул балыклар арасында йөзеп йөрүемә гарьләнү, түбәнсенү тагын ләмгә капландырды, тагы кимсендерде. Кем мин?! Балыкмы, кешеме, әллә зәңгәр күктән адашып килеп эләккән бер җан иясеме? Минем тиңдәшләрем әнә анда — зәңгәр томан илендә бит, ә нигә мин һаман бу ясалма күлнең ләменә капланып ятам? Очыйм дисәм — канатларым юк, йөрим дисәм — җир өстендә яши алмыйм, ә җаным, ә уйларым нәкъ аларныкы кебек бит, нәкъ аларныкы кебек...

Бәлки шул ләм, балчык, үлән арасыннан мин инде күтәрелә дә алмаган булыр идем — су өстендә тагын а н ы ң сурәте пәйда булды. Ул бүген ялгыз иде, агачлар арасыннан йөгереп чыккан гүзәл зат күренмәде. Сурәтләр дә өзек-өзек, бик буталчык, ләкин минем халәтемә бик якын... Чакыру, көтү, ыңгырашу, ялвару, көтү... Бу моң, теләк су төбенә дә төшеп җитә, мин ләмнән йөземне күтәрәм дә әкрен генә чакыру килгән якка йөзеп китәм. Кем ул? Күл балыгымы, зәңгәр томан иле балыгымы, кем ул? Ник минем җанымны шулай чакыра, борчый соң ул? Нигә аның уйлары минем уйларга охшаган, нинди теләк, нинди өзгәләнү бу?!

Күлнең читенә үк йөзеп киләм. Әнә ул, башын иеп, суга карап утыра. Аның йөзе күл балыкларына да, зәңгәр томан иле балыкларына да охшамаган. Бик сәер зат. Ләкин су төбеннән мине күтәреп торгыза алган зат. Менә син нинди икәнсең... Йөзендә әллә нинди илаһи нур бар. Юк! Бу бит — сагыш. Бу — авыру...

Кинәт ул йөзен минем якка борды! Зиһенемә кинәт сурәтләр дөньясы кереп тулды. Ике арада һаман теге көнне аның күкрәгенә килеп капланган гүзәл зат тирбәнә. Алар һаман бер-берләрен иркәлиләр, берберләренә сыеналар. Шул чагында зиһенемне коточкыч ачыш телеп үтте. Мин бит яр буенда утырган бу сәер затның уйларын күрәм! Алар кисәк-кисәк булып минем аңыма күчәләр! Ә бәлки ул да минем уйларымны күрә аладыр?! Бәлки ул, шуларны күреп, башын бу якка боргандыр? Юк. Уйларымның сурәтендә мин юк. Һаман теге гүзәл зат, һаман йөгерә, һаман аңа сыена... Ә мине күрсә? Куркуымнан тизрәк күл төбенә атылам. Беренче тапкыр үземнең рәвешем өчен оялам. Мин бит аның өчен балык... Балык... Күл балыгы.

Ә ул к е ш е дип атала икән. Алар барысы да кешеләр дип аталалар икән. Алар күл буена күбрәк җыелганда, сурәтләр дөньясы да бутала, мин ул сурәтләрнең кайсына карарга белмим. Җир өстендәге тормыш та бик сәер икән. Бераз гына күл балыклары тормышына да охшаган. Алар да, безнең кебек, вакыты җиткәч, җыелышып ашыйлар, без йөзәбез, ә алар һаман каядыр ашыгалар, йөгерәләр. Уйларындагы сурәтләрдә алар гел парлы, алар балыклардан җүләррәк, хислерәк, бәхетлерәк ахры. Кайвакытта шундый шашкын сурәтләр белән күл төбе тула, шуларны күрә алуым минем өчен оят та, яшерен бер ләззәт тә. Шушы кадәр көч, наз, матурлык кайдан килгән кешегә?! Югарыдагы күренешләрдән, кешеләрнең шулай парлаша алу бәхетеннән соң, үзе дә шушы халәтне көтеп сулкылдаган тәнем салкын балыкларга килеп бәрелә. Алар тизрәк читкә йөзеп китәләр. Аңымны җуярдай булып, күл буйлап әйләнә башлыйм. Су астыннан, су өстеннән ш у л к е ш е н е ң сурәтен эзлим. Ул минем җаныма, халәтемә якын. Ул — шашкын уйлары белән беренче тапкыр минем балык җанымны уята алган адәми зат. Мин инде аның сурәтен, уйларын таныйм. Ул хәзер күл буенда юк. Башкалар, башка сурәтләр бар, ә ул — юк.

Кешеләр бер-берләренең уйларын күрә беләләрме икән? Юктыр, күрмиләрдер алар. Ул кеше дә минем уйларымны күрмидер. Мин бит аны шулкадәр ялварып чакырам күл буена! Мин бит бу күлдә бер ялгызым. Бу балыклар бит миңа барысы да чит, ят! Аларның бит әнә барысының да парлары бар! Балык булсалар да — парлары бар! Мин бит алар арасында акылымнан шашам! Минем шушы уйларымны, күл төбендәге ләмдә бәргәләнгән сурәтемне күрмиме икәнни җир кешесе!? Ул бит кеше! Балык кына түгел! Минем ыңгырашуым, бәргәләнүем балык булып балыкларны сискәндерә! Ул бит кеше!.. Бу бит минем җирдә беренче язым! Ялгыз язым. Мин бит — Табигать...

Күл өсте тагын караңгылана. Җирдә ул төн дип атала икән. Җир кешеләре төннәрен акылларыннан шашалар икән. Ә балыклар йоклый. Мин йоклый да алмыйм. Мин балык та түгел, кеше дә түгел! Мин уйлый беләм, аларның уйларын күрә беләм, тик араларында яши алмыйм. Кем соң мин? Нигә бу күл төбендә соң мин?

Кинәт күл суы тибрәнеп китә. Тагын, тагын, тагын тибрәнә һәм аңыма дулкын-дулкын сурәтләр иңә башлый. Җир кешесенең сурәте бит бу! Янәшәсендә — теге гүзәл зат. Алар бит җир өстендә йөгереп йөрмиләр, алар нәкъ менә безнең кебек — күл балыклары кебек — йөзәләр! Сурәтләре гел янәшә. Әнә талгын гына йөзеп киләләр дә бер-берләренә сарылалар. Аннан тагын янәшә йөзеп китәләр. Минем хыялымда, уйларымда ничә тапкыр кабатланган, көткән, чакырган сурәт. Уйларым белән, сулышым белән, җаным белән күл буена тартып китергән җир кешесе! Янәшәсендә — җир кызы. Балык түгел, җир кызы. Аның уй-

ларын да күрә белмәгән, дөньяда зәңгәр томаннар иле барлыгын да белмәгән, күл төбендә адашкан җан иясе бәргәләнгәнен дә сизмәгән җир кызы! Ничек ярлы һәм кызганыч, ләкин нинди бәхетле җир кызы!

Мин инде аны күралмыйм. Мин инде аның сурәтеннән кая качарга белмим. Тәннәре тагын килеп кушылган мизгелдә, күл төбеннән аерылам да җанымдагы бөтен әрнү-ярсуларым белән су өстенә атылам. Күр, дөньяда мин дә бар! Табигать тарафыннан гарип итеп яратылган, ярым балык кыяфәтле, кеше җанлы кызганыч зат та бар! Кулларымны сузып, очып китәргә җыенгандай, бер мәл һавада талпынып торам да, сулышым буылып, тагын күл төбенә китәм. Анда да тын ала алмагач, кабат күкләргә атылам. Мин инде аларны күрмим, мин бары тик үземне чакырып, ымсындырып җемелдәгән зәңгәр йолдызларны күрәм. Ал мине, зәңгәр күгем, үзеңә, калдырма бу күл төбендә! Йөзем буйлап әллә күл суы, әллә яшем ага. Соңгы кат җир белән күк арасында талпыным да, суны ярып, күл төбенә төшәм. Тәнемне нидер сызып үтә. Үз артымнан кызыл дулкын калдырып, камышлар арасына кереп качам. Су өстеннән килгән сурәтләрне күрмәс өчен, йөзем белән салкын ләмгә капланам. Мин яткан урын кызарып, болганчыкланып бераз тора да, бөтен сурәтләр берьюлы юкка чыгып, мин караңгы бушлыкка төшеп китәм...

Мин тәнемне яралаганмын икән. Минем каным кызыл икән. Кешеләрнең дә каннары кызыл була икән. Әллә мин дә кешеме икән? Алайса нигә мин су өстендә яши алмыйм соң? Тыным бетеп, тизрәк су төбенә китәргә ашыгам?! Кешеләр кебек теләгәнемне аңлата да белмим. Алар бит, уйлаудан тыш сөйләшә дә беләләр икән. Нидер аңлаталар, хәрәкәтләнәләр. Миннән ниндидер ыңгырашкан, сулыш алган авазлар гына бәреп чыга.

Кинәт мин каршымда үземнең сурәтемне күрәм. Ләкин бит бу минем мена хәзер су төбендә яткан вакытым түгел, бу минем теге көнне җир белән күк арасында бәргәләнгән вакытым. Мин, гаҗәпләнеп, куркып, үз-үземә карап торам. Юк, мин кешегә охшамаганмын. Курыкынган зур яшькелт күзләр, ялварулы караш... Күкрәгемә төшеп торган көмеш чәчләр... һәм бөтенләй чит тән... Таш булып каткан җансыз бер тән. Күккә таба сузылган ап-ак куллар. һәм... балык койрыгы. Я, күгем! Я, таңрем! Шушы кыяфәтем белән җир егете турында уйлыйм түгелме соң мин?!

Ә минем сурәтем? Минем сурәтем кире үземә әйләнеп кайткач, димәк, минем турыда да кемдер уйлый бит инде! Минем турыда уйлыйлар? Минем бит дөньяда барлыгымны да белмиләр. Мин бит күл төбендә яшим. Мине беркемнең күргәне юк.

Шулчак куркуымнан су өстенә атылып чыга яздым. Ничек күрмәсеннәр ди! Теге көнне бит алар да монда иде! Мин шашып-шашып күккә сикергәндә, җир кешеләре турында бөтенләй онытканмын. Ул да бит бирегә иде! Димәк, ул мине күргән, коточкыч кыяфәтем аны куркыткан. Мин балыклардан читләшкән, качкан кебек, ул да мине күреп чирканган. Әле ярый уйларымны күрмәгән, әле ярый уйларымдагы сурәттә аңа сыенуымны, тартылуымны, ялваруымны сизмәгән. Әле ярый кешеләр уйларны күрә белмиләр!

Димәк, ул өстә. Үзе генә түгел, ахрысы. Сурәтләр бик буталчык. Аның уйлары гына дөрес — мин нәкъ менә үзем кебек. Ә башкалар мине бөтенләй башкача күз алдына китерәләр. Мин коточкыч кыяфәтле, елан койрыклы, күзләремнән, авызымнан ут чәчелә. Үзем кешеләрне ашар, йотар өчен әзерләнеп торам. Мин түгел бит бу! Кешеләр, мин мондый түгел бит! Сез ялгыш уйлыйсыз, мин андый түгел, түгел!!!

Су төбендә сурәтләр куера. Алар күлне әйләнеп йөриләр ахры, сурәтләр дә урыннарыннан күчә, бер якыная, бер ерагая. Мин урынымнан кыймылдарга да куркам. Хәзер кешеләр дөньяда барлыгымны белгәч, нигәдер шомланып, хәвефләнеп калдым. Сурәт-уйлар да куркыныч:

әнә алар мине тимер ятьмәгә урап, күл төбеннән тартып чыгаралар. Бөтен күл буе кешеләр белән тулган. Ул да шунда. Гаҗәпләнеп миңа карый. Мин, тыным бетеп, бәргәләнә башлыйм. Мине тизрәк сулы чынга салалар. Мин кире күлгә сикермәкче булам. Кешеләр, куркып, чан янынннан читкә сибеләләр. Ул, килеп, минем чаннан яртылаш асылынып төшкән гәүдәмне тотып ала. Ниндидер бер кыргый көч белән мине янадан чанга ыргыта...

Мин күл төбеннән баш калкытмас булдым. Кешеләр күл буенда йөрделәр, йөрделәр дә таралыштылар. Алар егет белән кызның сүзләренә ышанмадылар. Уй-сурәтләр бәхәсләштеләр, буталыштылар да, күл буенда ул берүзе калды. Ул мине үзе күргән иде. Хәтеренә минем сурәт мәңгегә салып куелган иде.

Ничә төн инде ул күл буеннан китми. Аның исбат итәсе килә. Кешеләр бит аның янынннан көлеп киттеләр. Ул мине аларга үз куллары белән тотып бирергә тиеш. Аның уенда бары шул гына. Ул бит мине үз күзләре белән күрде.

Су төбендә тагын бер сурәт пәйда булды. Аның янәшәсендәге кыз. Ул да бит мине күргән иде. Ләкин аның уенда сурәтем тоныкк, мин балык кебек кенә, сәер зур бер балык, күл балыгы.

Ул егетне күл буеннан китәргә үгетли. Бу күл буен, аның балыкларын каргый. Ул егетне рәнҗетә, ахры, аның уй-сурәтләре караңгы, болганчык. Кыз, теге төндәге кебек, аның иңнәренә сарыла — ә ике араларында — я, күгем,— минем сурәт! Аның уенда һаман мин бит! Тотып бирү нияте белән булса да, юк итү нияте белән булса да — мин! Ул минем барлыкка ышана, ул мине күрә, ул мине уйлый. Кыз аннан читкә тайпыла. Ул егетне нәрсәгәдер гаепли. Бу — миңа таныш булмаган халәт, миңа таныш булмаган сурәт. Ул егетне җүләрлектә, акылдан язуда гаепли! Минем сурәтне аяк астына салып таптый, тилкәләп йөртә, тураклый. Аннан, ярсып, агачлар арасына кереп югала.

Ә ул яр буенда утырып кала. Бик арыган, ахры, уй-сурәтләре дә тоныкк, хәлсез генә сулкылдый. Ул мине көтә. Ул миңа ялвара. Ул мине чакыра. Аңа үзенең хаклыгын, җүләр түгеллеген исбатларга кирәк. Мине корбан итеп булса да...

Уйларынннан иңгән бу чакыру, ялваруга түзә алмыйм, күл төбеннән әкрен генә кузгалам да су өстенә таба күтәрелә башлыйм. Мин аңа еракстан гына күренермен. Ул бит минем дөньяда барлыгыма ышана. Ул бит мине көтә...

Менә мин күл өстендә. Җирдә төн. Күгемнән аем төшеп килә. Ул монда хәтле төшеп җитмәс шул инде. Су өстендә салкынрак икән. Мин салкыннан бик куркам. Салкында мин уйлый да, башкаларның уйларын да күрә алмыйм. Нәкъ балык кебек булам да калам.

Мин күлнең нәкъ уртасында. Ул мине күрми. Мин дә аның кайда утырганын уйлары килгән юнәлештән генә чамалыйм. Әнә ул, башын иеп, яр буенда утыра. Уй-сурәтләрендә һаман мин сулкылдыйм.

Мин акрын гына аңа таба йөзеп китәм. Янына ук барып җитәргә куркам, бераз калгач, башымны судан чыгарып, аңа карап тора башлыйм. Озын көмеш чәчләрем су өстенә җәелә, мин, кулларым белән аларны як-якка җибәреп, әкрен генә бер урында тибрәлеп торам.

Әллә дулкын тавышын ишетте, әллә кулларымның хәрәкәте игътибарын үзенә тартты — егет кинәт мин чайкалган якка борылып карады. Мин дә качмадым, мин аның уйларында шундук үземне күреп алдым — ул мине таныган иде, ул минем күренүемә сөенгән иде, ул гаҗәпләнеп, куркып та калган иде.

Менә ул акрын гына аягына баса, як-ягына карап ала. Төн уртасы. Тирә-якта беркем дә юк. Уйларында ул әле күл буеннан читкә йөгерә, кешеләрне җыеп килә, кулларын селки-селки нидер аңлата, әле киемнәрен салып ташлап, күлгә сикерә. Аның уйларынннан куркып, читкәрәк

йөзеп китәм. Минем сискәнгәнне сизеп, ул да хәрәкәткә килә. Уйлары белән дә, куллары белән дә ул миңа китмәскә ялвара, ул минем юкка чыгуымнан курка, су төбенә китеп, күздән югалуымнан курка.

Минем үземнең дә китәсем килми. Минем җир кешесенә аның уйларын аңлавымны, үземнең күл балыгы түгел, бирегә очраклы гына килеп эләккән зат икәнемне белдерәсем килә. Уйларымда зәңгәр томаннар илен сурәтлим, шунда очып-йөзеп йөрүче күктәшләремне искә төшерәм — егет шуларны күреп, бәлки нидер аңлар, берәр чара күрер дип өметләнәм. Ләкин егетнең уйларында җавап күренми — минем уйларым аңа бөтенләй барып җитми ахры — җир кешесенең хәрәкәтләрендә дә, уйларында да үзгәреш юк.

Инде минем уйларымны күрми икән, аның уйларын күрә алуымны ничек тә аңлатырга кирәк. Һәм мин аның уй юнәлешендә, шуларга җавап рәвешендә хәрәкәт итә башлыйм. Ул минем ярга якынрак килүемне тели — мин койрыгым, кулларым белән салмак кына хәрәкәт ясыйм да ярга якыная башлыйм. Аның уйларында курку, гаҗәпләнү. Мин инде аны бик якыннан күрәм, ай нуры нәкъ безнең турыга төшкән. Тагын тирә-юнемдә суның эсселәнеп китүен, үземдә кинәт һаваларга атыласы килү теләге уянуын сизәм. Егетнең йөзе һаман якыная. Ул инде курыкмый, тетрәнеп, гаҗәпләнеп миңа карап тора. Уйларында минем сурәтем дә зурая, бөтен аңын тутыра, аннан зиһенендә ялварулы зур яшел күзләрем генә торып кала. Ул бу карашны күтәрә алмый, ул минем бу кадәр якынлыктан гаҗиз булып, куллары белән йөзен каплый. Мин аның уйларын да күрмим, уйларында — буталчыклык, уйларында минем күзләрем...

Мин су өстендә әкрен генә тибрәнеп куйгач, ул сискәнеп башын күтәрә. Мин бөтен җаным, тәнем, уйларым белән аны үз яныма — суга чакырам. Бер ашыгып эчкәрәк йөзеп китәм, бер салмак кына чайкалып, аның аяк очларына хәтле киләм. Мин инде аннан курыкмыйм, мин инде аның уйларында үземнең ялварулы күзләремне күрәм, аның миңа орынып карыйсы килүен сизәм, көтәм-көтәм... Балыклыгымны да онытып, мин җир кешесенең тәнемә кагылуын, иркәләвен көтәм...

Мин төн буе яр белән ике арада бәргәләндем. Ләкин ул урыныннан кузгалмады, суга ташланмады, җир кызын назлаган кебек, үзен көтеп тилмергән тәнемә кагылмады. Ләкин күзләремнең эзәрлекләвеннән дә кача алмады. Су өстендә дә, агач араларында да, төнге күктә дә — минем күзләр, минем түгелергә торган яшькелт күзләрем иде.

Мин көндез су өстенә чыгарга курыктым. Яр буенда ул ялгызы түгел иде, уй-сурәтләрен күреп, мин яр буена тагын кешеләр җыелганын аңладым. Алар егеттән минем турыда сорашалар иде ахры — уйларында сурәтем гел төрле кыяфәткә кереп, гел су өстендә тибрәнеп торды. Кинәт мин куркып, котым чыгып ләмгә ныграк сыендым. Егетнең уйларында мин моңа кадәр белмәгән сәер кешеләрнең рәсемнәре чагылып китте. Алар башларына ниндидер түгәрәк әйберләр кигәннәр, аркаларына да нидер асканнар. Алар су астында балыклар кебек яши алалар икән! Егетнең уйларында менә аларның берсе суга күмелә, менә мин яткан урынны эзләп таба, көмеш чәчләремнән эләктереп ала да мине су өстенә алып ташлый!

Бу сурәттән мин аңымны җуя яздым. Егет мине төнлә якыннан күрде. Ул минем күл төбендә ятканымны бик яхшы белә. Аның хәзер бер хәрәкәте җитә — бу сәер кешеләр, мине тотып алырга дип, күл төбенә ташланачаклар. Икенче айлы төн булмаячак, мин тәнемдә аның тәнен тоймаячакмын, тойсам да, инде су өстенә чыккач, инде тынсыз кыяфәттә. Күзләремнең дә җаны булмас, алар инде аның хәтерендә мөлдерәп тормаслар.

Нигә ул минем уйларымны күрми икән? Нигә кешеләр уйларны күрә белмиләр икән?! Аларда бит минем ялваруым, сагышым, куркуым, теләкләрем, минем җаным. Мин алар кебек сөйләшә белмим, мин уй-

лыйм гына, мин яшим генә, саташа-саташа, сагына-сагына күлегез төбендә яшим мин, кешеләр! Балык булып! Минем балык булырга да хакым юкмыни соң? Нигә кирәк мин сезгә? Нигә куркыныч уйларыгыз белән һаман аулыйсыз сез мине?

Ләкин... минем янга беркем дә төшми. Күл төбенә ябышып, бөтен зиһенемне өскә, кешеләр җыелып торган якка юнәлтәм. Я, күрегез! Ул кешеләргә... минем юклыгымны исбат итә! Юк! Күл төбендә беркем дә юк! Аждаһа да, җен дә, оча торган, кеше кыяфәтле балык та юк! Мин гади бер балык кына, зур балык, мөгаен, берничә ел күл төбендә ятып, шактый зур үскән балык. Бары шул гына.

Ул кешеләргә шулай дип ышандырырга тырыша. Беренче тапкыр аның уйларының ике катлылануын сизәм. Өстә, беренче катлауда — мин — күл балыгы, гадәти бер балык. Ә уенын аскырак, ераграк катлавында — минем зур яшькелт күзләрем, ап-ак тәнемә чорналган озын көмеш чәчләрем, үзенә таба сузылган кулларым...

Әле кайчан гына ул кешеләргә күл төбендә оча торган балык барлыгын сөйләгән иде. Аларга исбат итә алмыйча, көлкегә калып, яр буенда берүзе утырып калган иде. Аңа минем кабат күренүем кирәк иде. Инде минем барлыгымны, балык кына түгел икәнлегемне якыннан күргәч, ул минем юклыгымны исбат итә. Уйларында күзләрем генә мөлдермөлдер...

Кинәт яр буенда бер уй, бер сурәт калмады. Минем юклыгыма ышанып, барысы да киттеме икәнни? Ә ул? Яр буенда аның уй-сурәте дә юк бит! Куркыныч барлыгын да онытып, бер сулышта, күл өстенә килеп чыгам. Әнә алар, кешеләр: ашыга-ашыга каядыр китеп баралар. Ул да шулар арасында. Бу якка борылып та карамый. Ераклаша, ераклаша... Тыным бетә, якты көн кара төнгә әйләнә. Мин берни әйтә алмыйм! Мин берни аңлата алмыйм! Мин, җир өстенә чыгып, аның артыннан да йөгерә алмыйм. Аңымны җуеп, тагын бушлыкка төшеп китәм...

Күпме гомер шулай ятканымны хәтерләмим, аңыма кинәт өстән ниндидер яктылык иңде. Аннан шул яктылыкта мин үземнең күзләремне, тәнемне, үземне күрдем. Мин бит шушы кыяфәттә бары тик аның уйларында гына яшим! Димәк, ул бирелә! Шул яктылыкка тотынып, су өстенә күтәреләм. Әллә нинди җилле, давыллы төн. Күл өстендә зур-зур дулкыннар чабыша. Шул дулкыннар белән аралашып, мин аның аяк очларына килеп егылам, аннан кире китеп, ялварулы хәрәкәтләрем, карашым белән аны да үз яныма чакырам. Миңа синең янәшә булуың гына кирәк, җир кешесе! Миңа синең тәнемә кагылуың гына кирәк. Мин бит синең янына чыга алмыйм. Ничек ялварганымны, көткәнемне сизмисеңмени соң син, кеше? Кеше...

Ыңгырашып, тагы аяк очына барып ятам. Тәнем инде яртылаш судан чыккан. Шуышып менәргә теләгәндәй, кулларым күл ярына сузылып яткан. Тәнемнең бу ягы инде үлеп бара. Яңа дулкын китереп бәргәндә генә җан кереп, мин башымны күтәреп карый алам. Ул тезләнгән дә, нишләргә белмичә, миңа карап тора. Чәчләре җилдә тузгыган, йөзе, минем тәнем кебек, агарып калган. Менә ул әкрен генә кулын күтәрә, минем чуалган чәчләремне аралый, бармаклары белән йөземә кагылып үтә. Кинәт көчле авыртудан бөтен тәнем тартышып куя. Аның бармаклары минем тәнемне пешерә, яндыра, бу коточкыч авырту минем теләкләремнән көчлерәк, бу авырту мине, селтәнеп, кире су өстенә тотып ата, мин яңа башлаган йөземне тизрәк дулкыннар арасына яшерәм... Йөземдә аның бармаклары пешереп үткән эзләр кала...

Авыртуым бераз басылгач, яңадан су өстенә чыгам, инде якын килмичә, ерактан гына аны күзәтәм. Ул, әсәрләнеп, су өстенә карап тора. Уйларында — минем яр буенда яткан кыяфәтем, сискәнеп, куырылып, кире суга сикерүем, юкка чыгуым... Мине күргәч, ул әкрен генә суга керә башлый. Әле кайчан гына, шушы мизгелне бирүен сорап, мин күкләргә ялынган идем бит. Хәзер куркам. Йөземдәге янган урыннар һаман

авырттырып сулкылдый, суга кумелгэч кенэ бераз жинел булып китэ.

Ул һаман миңа таба якыная. Җаным аның тизрәк килеп кагылуын, мине саташтырып, күкләргә ыргыткан бу халәтемнән арындыруын көтә. Тәнем аның орынуыннан туачак авыртуны тоеп, куырылып килә. Битемдәге янган урыннар тагын әрни башлый. Димәк, минем тәнемә кеше кагыла алмый. Кеше кагылудан минем тәнем янып бетәргә мөмкин. Ә ул әнә һаман якынлаша. Күпме көткәнем, тилмергәнем, теләгәнем... Янып бетүдән куркып, хәзер тагын күл төбенә китимме? Анда кемгә кирәк соң минем бу тәнем? Шунда, күл ләменә капланып, юкка чыгар, черер өченме? Күгемә кире кайту юк, җирдә мин яши алмыйм, хәтта күл төбенә дә мин кирәк түгел! Димәк, янып бетү кала. Димәк, шушы бер яну, бер мизгел өчен мин күкләрдән җиргә иңгәнмен, күл балыгына әйләнгәнмен, җир кешесенә тыелгысыз теләк белән саташканмын; инде ул да мине күреп, җирен ташлап, минем арттан суга кергәч — тагын күл төбенә китәргәме?

Ул һаман миңа якыная. Мин күзләремне йомам да башымны дулкыннар өстенә салам. Кил, кагыл, ал мине, җир кешесе! Мин шушы бер мизгел өчен янып бетәргә дә риза... Синең белән... Бары синең белән...

Безнең арада бары бер дулкын. Шул дулкынның бер икебез ике ягында. Бер хәрәкәт һәм... минем көмеш чәчләремә чорналып, дулкын булып, күл уртасына таба йөзеп китәбез. Кулларының тәнемә орынуын сизәм, ләкин авырту да, яну да юк, баш әйләнерлек якынлык, хәлсезлек, тартылу... Утка ташлагандай, аның тәненә сарылам, авыртудан түгел, аның якынлыгыннан аңымны җуям, ләкин гәүдәм күл төбенә китми, аның кулларында әкрен генә чайкалам да чайкалам... чайкалам да чайкалам...

Күзләремне ачам. Аның күзләрендә икебезне дә күрәм. Чәчләрем, су өстенә таралып, безнең икебезне дә каплап киткән. Уйларында да, хәрәкәтләре белән дә ул аларны аралап, минем тәнемне иркәли, сыена, үзенә тарта. Бер тән булып, без бер дулкыннан икенчесенә атылабыз. Җирне, күкне, суны — бөтен табигатьне гаҗәпләндереп, яшәешнең кыргый бер мизгеленә кайтабыз, җирне, суны, күкне сискәндереп, кеше белән балык... якынаябыз...

Таң атканда, хәлдән таеп, ул минем кулларымда йокыга китә. Иреннәреннән, чәчләреннән, кулларыннан үбә-үбә, мин аны акрын гына яр буена таба алып китәм. Аны ярның сөзәгрәк, чирәмлерәк урынына китереп салам да, тыным бетеп, кулларым белән шуыша-шуыша, тизрәк кире күлгә сикерәм. Күл төбенә төшеп җиткәнче берничә тапкыр аңымны җуям, салкын ләмгә йөзем тигәч кенә айнып, кисәк кенә сулкылдап сызлый башлаган тәнемә, кулларыма карыйм. Аларда янып-янып кергән кара тапларны күреп, күл төбенә ныграк сыенам. Янган икән, барыбер янган икән. Тик аңа карата теләгем-хисем көчлерәк булган, янганны, авыртуны да сизмичә, һаман аңа тартылганмын, аңа сыенганмын. Янаяна, аныкы булганмын... Аныкы...

Моңа кадәр бер максатсыз, бер мәгънәсез күл төбе тормышым икегә аерылды. Берсе — озын, борчулы кирәкмәс якты көн, икенчесе — безне яшерә һәм аңлый торган, хәвефле ләззәте белән безнең тәннәрне берләштергән, икебезне дә акылдан яздырган кыска төн. Көндезләрен кайчагында аның уй-сурәте югалып тора. Мин аның күл буеннан каядыр киткәнлеген аңлыйм, моның белән килешәсем килми, ләкин мин күл өстенә чыга да, аны туктата да алмыйм. Ул бит барыбер минем уйларымны күрми! Мин — өнсез гәүдә, өнсез гәүдә! Балык! Туктата да, аңлата да алмыйм. Көндезләрен бигрәк тә куркыныч. Күл буен ят уй-сурәтләр каплап китә. Нәрсә турында гына уйламый икән бу кешеләр! Аларның уйларыннан миңа куркыныч була башлый. Үзем өчен генә түгел. Алар өчен дә. Ничек кенә түбәнсетмиләр, җәберләмиләр алар уйларында бер-берләрен! Бәлки алар тормышта болай рәхимсез дә түгелләрдер. Уйлары шулай кара булса да, бер-берләренә елмаеп та йөри алалар-

дыр. Алай булганда, бигрәк тә авырдыр бу кешеләргә. Гел ике тормыш белән яшәргә! Гел ялганлап яшәргә!

Кадерле кешеләрен искә төшергәндә генә аларның уйлары яктырып, чистарып китә. Хәтерләре буйлап кечкенә кешеләр — балалар йөгерә. Бу — яки аларның балачаклары, яки инде үзләренең балалары. Балалар турындагы уйларда нииндидер хәвеф-шом да сизелеп тора. Аларны гел әллә нинди бәлаләр, куркынычлар сагалый килә — уй-сурәтләр кискенләшә, олы кешеләр, кулларын җәеп, балаларына ярдәмгә ташланалар. Балалар турындагы уйлар борчулы да, мәрхәмәтле дә.

Кешеләрнең сөйгән ярлары турындагы уйлары да бик кадерле. Яратышу — бар табигатьтәге кебек — кошлар, җәнлекләр, балыклардагы кебек. Юк, яратышуны, назлауны, теләкне кешеләр уйлап тапмаган, ул аларга гына хас теләк түгел, табигатьтә әле ул көчлерәк тә, чистарак һәм бөегрәк тә. Кеше табигатьтән уйлый һәм сөйләшә белүе белән генә өстен. Ә уйларында күбрәк түбәнлек, шик, мәрхәмәтсезлек. Мин ул уйлардан куркам, алар өчен оялам, ләкин берни эшли, үзгәртә алмыйм. Мине балык итеп яратканы өчен табигатькә рәнҗим, бердәнбер чарам — кешеләрдән качу, качу, качу...

Ул да кеше. Ул да кешеләр арасында йөри. Аның уйларында кайвакытта мин бөтенләй белмәгән, күрмәгән, каныма сеңмәгән күренешләр чагылып үтә. Хәтерендә дөрләп шәһәрләр, йортлар яна. Җир өстеннән күтәрелергә азапланган гәүдәләр аша атлар сикерешеп үтә. Ат тоягы арасында мин аны, аның үземә таба сузылган кулларын күрәм. Аннан барысы да төтен, тузан, ялкын белән каплана. Хәтерендә кап-караңгы мизгелләр. Аннан зур су өсте, дәрья. Шул дәрьяда бишеге-ние белән йөзеп барган сабый. Дөрләп янган су буйлары. Сабый йөзендә дә аның йөз чалымнарын сизәм. Ә дәрьяның очы-кырые юк. Хәтерендә тагын кара таплар. Юл. Бер-берләренә бәйләнгән кешеләр. Аяк атларлык та хәлләре юк. Артларыннан ялкын куа килә, афәт куа килә. Кешеләр арасында ул да бар. Хәтерендә тагын кара таплар. Буыннар алышына. Кан кала. Хәтер кала. Кеше кала. Алар үзләре бу мизгелләрен күрәләрме икән? Уйлагач, күрәләрдер. Тик моны бер саташу гына дип уйлыйлардыр. Шушы зур бәла-каза, афәтләрдән исән калган кешеләр бүген ул кадәр вагая, түбәнәя алмаслар иде. Үзләренең бөеклекләрен, мәһабәтлекләрен аңлап, бөтен вак, кара уйларын селтәп атырлар иде. Бер-берләренә карата да, табигатькә карата да киң күңелле, мәрхәмәтлерәк булырлар иде...

Су төбендә кинәт таныш бер сурәт күреп, бөтен тәнем калтырап куйды. Бу бит теге кыз, агач араларыннан йөгереп чыгып җир кешесенә сарылган гүзәл кыз! Аның белән дулкыннар өстендә янәшә йөзгән кыз! Ул минем барлыгымны исбат итә башлагач, беренче булып аннан көлгән кыз! Мине дә балык кына дип исбат итәргә тырышкан, миндә тән дә, җан да күрмәгән җир кызы! Нигә килгән ул биргә? Нигә инде көн буе тилмереп көткән төнем җиткәндә генә, ул үзенең уй-сурәтләре белән мине шомландыра, ярсыта?! Кемне көтә ул монда?

Бөтен зиһенемне җыеп, аның уй-сурәтләре артыннан өлгерергә тырышам. Хәтерендә һаман аңа сарышкан мизгеле, аның мине иркәләгән куллары, мине яндыра-яндыра үпкән иреннәре, инде минеке булган тәне! Җир кызы?! Хәтереңнең дә хакы юк аларга кагылырга!.. Син бит инде киткән идең, аны миңа калдырып киткән идең! Сиңа бит әнә алар күпме — җир кешеләре. Мин сиңа ялварып, аякларыңа егылып, күгемсуларым белән үтенеп сорыйм — калдыр аны миңа! Җир кызы!

Уйларының агышы үзгәрми. Җир өстенә төбәлгән ялварулы уйларым, кабул булмыйча, кире үземә кайта. Кызның уйлары белән буталып, саташып, бәрелешеп, бары бер генә сурәт — аның сурәте генә торып кала. Төнем! Кодрәтле төнем! Без сиңа бүген өчәү кирәбез. Мин — балык, өнсез балык, көчсезлеккә дучар ителгән балык, күл балыгы — кешеләргә каршы нәрсә эшли алырмын соң? Төнем!..

Жанымның мөлдерәп тулуыннан төн уртасы житкәнен сизәм. Ул инде бирелә. Жир кызы да күл буеннан китми. Уй-сурәтләрендә алар янәшә утыралар, ләкин араларында минем яшькелт күзләрем. Шом белән, ялвару белән тулган күзләрем... Минем бердәнбер өнем, авазым, яклаучыларым...

Өстерәлеп кенә су өстенә күтәреләм. Бүтән төннәрдәге ашкыну, шатлыкны бүген ниндидер хәвеф басып тора, кешеләр бер-берләренә кылган явызлыкларын, түбәнлекләрен бүген минем белән дә кабатларлар кебек. Куркам. Аннан да куркам. Ул бит миннән берни яшерә алмаячак. Беренче тапкыр уйларны күрә алуыма үкенәм: ышанырга, өметләнергә урын калмый бит! Уйлар бернигә буйсынмыйлар, ялганлый алмыйлар.

Алар һаман янәшә утыралар. Кыз аның җилкәсенә башын салган. Үзе һаман нигәдер көлә, су өстенә таш, балчык ата. Йөзе елмайса да, хәрәкәтләре борчулы, тынычсыз. Ә уйлары? Бөтен зиһенемне аңа гына юнәлтәм. Нинди сурәт соң кызның уйларында? Әнә ул озын ак күлмәк кигән, башында — ак чәчәкләр. Янәшәсендә — ул. Кулларында чәчәкләр. Яннарында кешеләр. Менә ул аның иреннәреннән үбә, аннан кулларына күтәрә дә ниндидер йортка алып кереп китә. Сурәтләр алышына. Төсләр бутала. Менә алар икесе генә. Ак күлмәге дә, чәчәкләре дә юк. Бары ике тән генә...

Юк!.. Тик бу сурәт кенә түгел, тик бу сурәт кенә түгел!.. Дөньяда бит әле мин дә бар, мин бит аларның барысын да күреп торам, ничек түзәрмен мин бу уй-сурәтләргә?! Тәнемдә бит әле аның кулларыннан янган эзләр саклана, ул назлар һаман җанымда, аңымда яңара. Мин дә бит тере җан, уйларыгызны гына булса да күрсәтмәгез миңа!

Син дә, син дә яшер... Мин бит синнән куркам. Үзем көтәм, үзем куркам... Синең өчен куркам. Сиңа бит миннән дә авыррак хәзер. Янәшәңдә — җир кызы, уйларыңда — күл балыгы. Син бит минем турында беркемгә сөйли дә, аңлата да алмаячаксың. Сине җүләрлектә, кыргыйлыкта, тагы әллә нәрсәләрдә гаепләячәкләр. Син миңа да ярдәм итә алмаячаксың. Могҗиза булмаячак! Бу бит җир, кешеләр җире! Мин барыбер балык булып калачакмын, бары тик суда гына синеке була алачакмын, уйларыңда гына назлармын, газапларммын...

Әнә сез, әкрен генә күтәреләсез дә, суга керә башлыйсыз. Минем дөньяма, минем күңелемә, минем җаныма. Тәнем мине тыңламый, дулкын белән гел син йөзгән якка тартыла. Бер генә кагылып үтәсем, бер генә сыенасым, тагы бер генә тапкыр дөрләп янасым килә. Суда гына булса да! Җирдә бит син болай да кешеләрнеке, нигә алар суда да синең тәнеңә, җаныңа хуҗа соң?

Әнә бит, уйларыңда — минем күзләрем, кулларым, тәнем. Уйларыңда син аларга сарыласың, көмеш чәчләремә ураласың, дулкын булып, миңа кушыласың, миңа...

Бөтен дөньямны, җиремне-күгемне, кешеләрне, уйларны онытып, дулкын ярып, синең янга атылам. Мине күргәч, син сискәнеп китәсең. Уйларың да бутала, аларга, нигәдер, җир кызы килеп керә. Син аңа нидер аңлатасың, акланасың. Зиһенемне өшетеп, яңа төшенчә килеп керә — син миннән оялась. Уйларыңны яшереп өлгерә алмадың...

Син бүген миңа кагылырга куркасың. Мине күрмәгәнгә салынып, дулкыннарга чалкан ятасың. Менә янәшәңә ул йөзеп килә. Чәчләре белән йөзеңне, тәнеңне каплап ала, сез, бер дулкын, бер тән булып, миннән ераккарак, күлнең эченәрәк йөзеп китәсез. Әле акылымны җуеп, сезнең арттан ташланмакчы, арагызга кереп, дөньяда мин дә барлыкны исегезгә төшермәкче булам. Әле, гәүдәмне яр буена атып, син үтәсе юлга, синең аяк эзләреңә орынмакчы булам. Әле, кабат күкләргә ашып, арагызга яшен ташы булып атылырга телим. Уйларымда барысын да эшлим, уйларымда мин сиңа ялварам да, рәнҗим дә, каргыйм да, тилмерәм, чакырам, көтәм, куам, качам — янам!.. Табигать! Мәңгелек

ләгънәтләр сиңа — мине балык итеп яратуың өчен! Балык итеп яратып та, җан биргәнең өчен! Кая куйыйм мин хәзер ул җанны, инде кешегә орынып караган җанны, тәнне?! Кая?!

Ләм... Тагы ләм... Тагы күл төбе...

А-а-а-а-а-ы-ы-ы-а-а-а...

Ул күл буена башка килмәде. Мин һәр төнне су өстенә күтәрелдем, һәр төнне ул утыра торган яр буена килдем. Мин хәзер инде кемнеңдер күрүеннән курыкмый идем. Мин хәзер кешеләрне үзем көтә башладым. Күзләрем белән булса да сорар идем. Аның турында. Күзләрем белән ялварыр идем мин кешеләрдән. Бер генә хәрәкәт, бер генә үй. Тик аның турында гына булсын. Аңа ни булганын гына әйтсеннәр... Аның турында гына... Исәнлеген генә хәбәр итсеннәр.

Кешеләр төркемен мин ерактан ук күрдем. Башта миңа аларның уйлары килеп җитте. Мин, газапланып, ул уйларны аралый-аралый, аны эзләдем. Җир өстендәге сурәтләр минем зиһенемә томырылып керделәр, барысын күмделәр, аның сурәте, аның турындагы уй гына һаман юк иде. Уйлар арасыннан мин кинәт җир кызының сурәтен күреп алдым! Ул озын ак күлмәктән, кулында чәчәк бәйләме иде. Минем бит инде мондый сурәтне кайдадыр күргәнем бар! Кызның үз уйларында! Ә хәзер ул инде башкалар уена күчкән. Димәк, ул инде уй гына түгел, ул тормышта булган, кешеләр үзләре күреп, зиһеннәренә сеңеп калган күренеш.

Ак күлмәкле кыз сурәте белән күл төбе тула. Димәк, өстәгеләр барысы да хәзер шул турыда уйлыйлар, шул хакта сөйләшәләр. Ә нигә кыз сурәте һаман ялгыз соң? Янәшәсендә кем булырга тиеш соң аның? Шул сурәтне күрмәс өчен, тизрәк йөземне кулларым белән каплыйм. Ул сурәтне күрмәс борын ук күңелем нәрсәдер сизә, шомлана. Күл төбе бер мизгелгә болганчыкланып, актарылып тора да, әкрен генә аңыма аның сурәте иңә. Тик нигә башы иелгән, карашы да янәшәсендәге кызда түгел, бушлыкта, билгесезлектә соң аның? Ә аларны чорнап алган кешеләр нидер аңлаталар, көләләр, нигәдер шатланалар, ашыйлар, эчәләр, бер-берләренә сарылалар. Аннан, аягүрә басып, егет белән кыздан нидер таләп итә башлыйлар. Җир егете җир кызын кочаклап ала да... иреннәреннән үбә. Аннары көлә-көлә аларны икенче бүлмәгә озаталар. Күл буендагы кешеләрнең дә уйлары башкага күчә, сирәк-мирәк кенә егет белән кызның сурәте чагылып үтсә дә, мин инде ул уйларны тота алмыйм. Зиһенем кинәт хәлсезләнә, уйлый да, уйларны күрә алу сәләтен дә югалта. Таш кебек, күл төбенә төшеп ятам. Һәм берни хәтерләмим...

Мин ничә ел шушылай яттым икән? Әллә көнме? Әллә мизгел генәме? Җанда көенеч тә, сөенеч тә юк. Авыр, салкын бушлык. Бер сурәт юк. Бер уй юк. Күзем күргәнне генә уйлый алам. Әнә, салмак кына йөзеп йөрүче балыкларны күрәм. Алар инде яз көнендәге кебек шаян, ярсып-уйнаклап торган балыклар түгел. Авырайганнар, симергәннәр, йөзеп барган уңайга гел йокыга китәрләр кебек. Араларында нәни балыклар да бик күп. Гел кеше балалары кебек — ашыгып йөзәләр, арып туктыйлар да, нидәндер сискәнеп, берәр үлән төбенә посалар, аннан, онытылып, тагы өскә атылалар. Гамьсез кеше балалары кебек...

Кеше?.. Җанымны нидер авырттырып, тырнап узды. Кеше... Нәрсәнедер искә төшерә алмыйм, нидер тонык кына зиһенне шакый, җан авыртып, каршы тора. Болар барысы да кеше исеме белән бәйләнгән... Хәтергә төшерә алмыйча, бу халәтемә борчылмыйча әкрен генә икенче ягыма әйләнеп ятам. Суүсемнәр, чайкалып, тәнемә сарыла. Шуларның өнсез назына буйсынып, күзләремне йомам. Дөньяларын онытып йөзгән вак балыклар тынычлыгымны боза. Алар, йөзеп килгән уңайга минем тәнемә бәреләләр дә, тагы ялтырашып китеп баралар. Аларның шулай гамьсез шаяра алулары мине кинәт ярсыта, кыргыйландыра — рәхимсез бер көч белән алар артыннан ташланам. Мәгънәсез вак балык-

лар минем корбаныма әйләнәләр. Бөтен күл төбен дер селкетеп, мин аларны әзәрлеклим, аулыйм, юк итәм. Эре балыклар да, сискәнеп, миннән читкә сикерәләр. Аларның качулары, куркулары мине бөтенләй ярсыта — нәфрәтле бер ләззәт белән аларның юеш, көпшәк тәннәренә тешләремне батырам. Каршы тора да белмиләр, көрәшә дә белмиләр! Балыклар! Күл балыклары! Мескеннәр!!! Куралмыйм мин сезне! Балык булганыгыз өчен... Көчсез булганыгыз өчен... Куралмыйм!

Бушап, тынычланып, авыраеп, тагы күл төбенә төшеп ятам. Бөек бер тынычлык. Дәһшәтле бер тынычлык. Хәтерем — кан кебек кызыл таплар. Шулар арасында изерим. Инде күл төбеннән дә ары төшәр урын юк. Ә мин һаман төшәм, төшәм...

Зиһенем кинәт мең ел алга сикерә! Ул минем гәүдәмне дә өскә сөйри. Гәүдәм минеке түгел, ул миңа буйсынмый, һаман югары күтәрелә. Тукта! Бу сәер күтәрелештә мин бит ялгыз гына түгел, минем янымда әнә күпме күл балыклары бәргәләнә. Аңгыраюдан, куркудан күзләре акаеп чыккан, койрыклары белән үз-үзләренә, бер-берләренә бәрәләр, бу кысанлыктан котылып, иркенәеп йөзеп китмәкче булалар. Ләкин урын кысылганнан-кысыла бара, без берберебезне изә-сыта, котылгысыз тизлектә югарыга очабыз. Шушы лайлалы тәннәр арасында инде бетәм, инде аңымны җуям дигәндә, зиһенемне телеп хәтеремдә кинәт яшен яшьни, җил-давыл куз-гала, зәңгәр томаннар иле күренеп китә. Җир өстеннән килгән уй-сурәтләр кинәт аңыма иңә башлый. Без бит ятьмәдә! Безне бит хәзер кешеләр җир өстенә чыгаралар! Балык бит җир өстендә яши алмый!

Аңсыз, юеш тәннәрне кулларым белән аралап, ятьмә читенә килеп ябышам. Бу мәхшәргә килеп эләккән вак балыклар ятьмә тишекләреннән кире иреккә атылалар, эре балыклар аннан сыймый, алар аркылы килеп, тишекләрне томалыйлар, шушы хәлләре белән килешәләр.

Кулларым белән ятьмәне тарткалый, йолыккалый башлыйм. Үрелгән җеп кисеп кереп, уч төпләрем канап чыга. Кулларым белән өзә алмагач, ятьмәгә тешләрем белән ябышам. Кешеләрнең уй-сурәтләре һаман якыная, аларда — ятьмә тулы балык, күл балыгы. Яр буенда сулы чаннар, машиналар көтеп тора. Тагы бер мизгел... Һәм, теге вакытта мин кыргыйланып вак балыкларны йоткан кебек, кешеләр дә мине... Юк!!! Ярсып елый-елый ятьмә җебен өзгәләргә тотынам. Һәм, инде су өстенә чыгабыз гына дигәндә, ятьмәне ертып, кире суга сикерәм. Минем арттан берничә балык сикереп өлгерә, һәм ятьмә, кешеләрнең көчле куллары белән, яр өстенә алып ташлана.

Ул көнне иртәдән алып балык ауладылар. Күл төбен челтәр ятьмәләр каплап алды. Мин бөтен көчем, зиһенем, өлгерлегемне җигеп, шул ятьмәләр белән көрәштем. Күлнең кайсы гына почмагына качсам да, алар мине куа киләләр иде. Күл суы болганчыкланды, инде ятьмәләрне күреп булмас хәлгә килде, кая барып бәрелергә белмәгән балыклар бөтенләй аңгырайдылар, ятьмәләргә үзләре йөзеп керә башладылар. Мин, тырнакларымны ләмгә батырып, күл төбенә сеңдем. Кат-кат ташланган ятьмәләр өстемнән шуып-шуып, тәнемә, аркама, чәчләремә кагылып үтте. Аның саен йөземне ләмгә ныграк яшердем. Бу ләм, бу күл төбе минем өчен хәзер бердәнбер котылу чарасы иде.

Кичкә таба күл төбе тынычланып, бушап калды. Суы бераз тонгач, мин бу бушлыкның серенә төшендем — күлдә инде эре ак балыклар калмаган иде. Өркешкән вак балыклар гына күренгәләп китәләр, алар да тәмам миңгерәүләнгәннәр, әсәрләнеп калганнар. Бушлыктан, ялгызлыктан акылдан шашкан көннәремдә аларны рәхимсез рәвештә аулавым исемә төште. Оятымнан, үкенүемнән күңелем болганып, тыным бетеп, аларны күрмәс өчен тизрәк су өстенә менеп киттем. Инде менеп җитәм дигәндә, бәгыремне телгәләп, каршыма таныш сурәт килеп басты. Мине уяткан да, үтергән дә, акылымнан, хәтеремнән яздырган, мине кеше

дә, балык та итеп күргән... Җир егете иде ул!!! Хәтеремдәге назлар тоныкк кына янарышып куйдылар, акылым — аска, җаным өскә тартты. Ике арага, үтәлмәс бер стена булып, аның уй-сурәтләре яттылар. Әнә ул балык тулы чаннар янында йөри. Кулындагы таяк белән актарып, алар арасыннан нидер эзли, табалмагач, икенче чанга күчә, тагы актара, тагы эзли. Ул үзе генә түгел. Янәшәсендәге кешеләр аңардан күләләр, читләшәләр. Ул берни аңлатмый, беркемгә карамый. Һаман эзли дә эзли. Инде күл балыкларын аулауга кадәр барып җиткән тоныкк аңым тагы ачыргаланып, сызланып, җанланып уйлый башлый. Я, күгем! Ул бит мине эзли! Әнә бит уйларында — минем яшел күзләрем, үзенә сарылган тәнем, кулларым. Һәм дулкын, дулкын... Аннан... Сулы чан, инде үлә башлаган балыклар. Ул мине шулар арасыннан эзли. Балык өчен ятьмәне котылгысыз нәрсә дип уйлый. Минем балык кына түгел икәнемне, аңым да, хәтерем дә, җаным да бар икәнен һаман аңламадымы икәнни соң ул?!

Ул һаман берни дәшми. Чаннарны карап бетерә дә, элек үзе утыра торган, аның утырганын күреп, мин аяк очларына йөзеп килә торган урынга килеп баса. Карашы — күлнең уртасында, карашы — дулкын аша миңа текәлгән. Кайдан белә ул минем нәкъ шушы урында ятканны? Әллә ул да уйларны күрә башладымы икән? Балыкка әйләнсә, суга, минем дөньяга килсә — мин аңа элеккечә сыена, назлана алыр идемме икән? Ике арага, кулларын сузып, җир кызы кереп баса. Өстендә — ап-ак күлмәк, карашында — наз, чакыру, тантана. Теге төнне, миннән оялып, куркып, янына килгәч тә, күрмәмешкә салышып, шул җир кызы белән йөзеп китүең исемә төшә! Хәтер! Менә нәрсә каршы төшә бүген синең уйларыңа! Балык хәтере. Кешеләр тиз оныталар, алардагы хис, теләк горурлыктан көчлерәк. Ә мин — балык, мескен бер күл балыгы — бүген сине кичерә алмыйм! Ишетәсеңме, җир кешесе?! Кичерә алмыйм мин синең хыянәтеңне!!! Мине уятып та, күл төбендә шулай ялгыз калдырып китүеңне, минем өчен оялуыңны, миндә бары тик балык кына күрүеңне... кичерә алмыйм...

Авыр гына борылып, кире күл төбенә төшеп китәм. Башын игән сурәте арттан ияреп килә. Ялвара, чакыра, көтә... Күл өстендә бары тик бер генә тапкыр күренүемне, исәнлегемне, дөньяда барлыгымны белергә тели. Ә мин — юк бит инде. Шашып дулкыннарга сикергән балык юк, ярга чыгып, аякларыңа сарылган балык юк, бөтен табигатьне таң калдырып, куркытып, кеше белән кушылган балык... юк. Тән генә сөйрәлеп йөри бары күл төбендә, вак балыкларны куркытып...

Соңгы вакытта уйларым да авырая, салмаклана. Һәм миңа нигәдер салкын, салкын. Вак балыклар да бу көннәрдә тынып калдылар, йокылы-уяулы гына йөзеп йөриләр яки бөтенләй туктап калып, тын гына, оеп кына бер урында торалар. Минем дә тәнем авырая, ләкин мин йоклый алмыйм. Бөтен тәнем суыктан дерелди, кулларым күшегеп, кызарып чыктылар. Салкынрак булган саен мин уйлый белү сәләтемне югалтам. Үземне китереп кыскан бу салкынлыктан котыла алмый чарасызланып, су өстенә атылам. Башым белән ялтырап торган әйбергә килеп бәреләм, ул җиңел генә ватыла, уала. Һәм мин аңлап алам — елга өстен боз каплап киткән икән ич!

Бозны ватып, мин су өстенә килеп чыгам. Ләкин мин күл буен танымыйм! Куркып, гаҗәпләнеп, тирә-ягыма карыйм. Агачларда бер яфрак калмаган, әллә нинди шыксыз, караңгы кыяфәт белән күл өстенә карап торалар. Җир өсте кара-соры пычрак белән капланган. Мин яшәгән күл буемы соң бу?! Кая андагы ямь, кая андагы җылылык, серлелек? Кая аның кешеләре? Кая аларның тормыш белән кайнап торган уйлары? Мин шушы җансыз, салкын күл төбендә, инде авыр йокыга китеп барган күл төбендә, бер ялгызым калдыммы икәнни?! Кешеләр, алыгыз мине үзегез белән, балык булырга да риза, ятьмәгезгә дә керәм, тик мине бу салкында, бу караңгы күл төбендә генә калдырмагыз!

Беркем юк. Кулларым белән мине кысып китергән бозга таянам, ул тагы җимерелә, ватылып төшә. Аның салкынлыгыннан кулларым, тәнем ойый башлый. Чәчләрем боз кырыена ябышып ката. Аңымны югалтып, бер батып, бер калкып торам да, күзләремне йомып, тагы суга авам. Ләкин күл төбендә дә, нәкъ җир өстендәге кебек, миңа тын җитми! Төшеп җитмәс борын, мин буыла башлыйм, тәнемдәге соңгы көчемне җыеп, кабат су өстенә атылам. Башым белән тагы бозга килеп бәреләм. Инде соңгы тапкыр аңымны җуеп, инде үз дөньяма — мәңге салкынлык булмый торган зәңгәр томаннар иленә китеп барганда — үзем шул хәтле тилмереп көткән, чакырган җир кешеләренең сурәтләрен күреп алам. Боз аша мин аларның уйларын тонык кына күрәм, ләкин инде ул бозны ватып чыгарлык хәлем юк. Кешеләр нигәдер күл буена таба йөгерәләр, нindидер кискен хәрәкәтләр ясыйлар. Ул да алар арасында бит! Ул алардан алдарак йөгерә, чәчләре җилдә тузгыган, күлмәкчән, яланаяк. Көлә-көлә, елый-елый бирегә таба йөгерә. Миңа килә бит ул, минем яныма йөгерә! Миңа авыр, бик авыр икәнен белеп йөгерә! Нигә тотасыз сез аны, кешеләр?! Нигә кулларын каерып бәйлисез сез аның?! Нигә ышанмыйсыз сез аңа? Ул бит сезгә минем турыда сөйли, күл балыгы турында, шул күл балыгының җир кешесен ярата алуы турында! Без бит барыбыз да табигать балалары. Җибәрегез аны минем янга?!

Кешеләр мине ишетмиләр, күрмиләр. Аны, кулларыннан каерып бәйлиләр дә, өсте ябулы машинага таба алып китәләр. Ул минем якка каерылып нидер кычкыра, чакыра, бәргәләнә.

Мең гасырлык зиһенемне, көчемне, ярсуымны җыеп, гәүдәм белән салкын бозга китереп бәрәм. Боз кыйпылчыклары тәнемне кисеп, ертып керәләр. Шул килеп бәрелгән уңайга ярсып күккә сикерәм, ап-ак тәнем буйлап боз өстенә каным ага, зиһенем томалана. Бер мизгелдә тораташ кебек катып калган кешеләрне күреп өлгерәм. Алар, котлары чыгып, минем якка карап торалар. Кулларымны җәеп, гәүдәм белән боз өстенә килеп төшәм. Тыным бетеп, буыла-буыла боз өстеннән кешеләргә таба шуыша башлыйм. Боз өсте кып-кызыл кан булып кала. Минем үзләренә таба шуышканны күргәч, кешеләр бөтенләй куркып калалар. Ә ул көлә дә көлә. Акылыннан шашып, башын кара җиргә бәрә-бәрә көлә...

Кешеләр башта аны машинага кертеп ябалар. Аннары, артларына борылып карарга да куркып, күл буеннан китеп баралар.

Җаным күккә тарта. Боз өстенә чалкан ятам да, карашым белән күккә китәм. Кара болытлар арасыннан зәңгәр томаннар илен, мәңге җылылык илен, хыял илен эзлим. Шунда әллә йөзеп, әллә очып йөргән күктәшләремне күрергә тырышам. Әнә бит алар, ап-ак канатларын җилпеп, минем янга төшеп килаләр. Никадәр күп алар! Ап-аклар, җиңелләр, чисталар! Тик нигә болай салкын соң алар? Бәлки мин үзем шулай салкындыр, җылылыкны да сизмимдер инде? Менә алар минем чәчләремә, керфекләремә куналар, күктәге дөнья — икенче дөнья турында миңа нидер сөйлиләр, юаталар. Миңа шундый тыныч, рәхәт, җылы булып китә. Бу салкын җирдән, кешеләрдән, гомеремә хуҗа булып торган күл төбеннән һаман ераклашам, китәм. Кешеләргә дә рәнҗемим. Алар инде табигатьтән, кыргый чакларыннан күптән аерылганнар. Телсез табигатьнең үзләренә мөлдерәп, шәфкать көтеп караганын да аңламыйлар. Җирдә һәр тереклек иясенең җаны бар, ә кешеләрнең?.. Кем соң табигать ялгышы — гарип булып туып та, уйлый, ярата белгән күл балыгымы, әллә кеше булып туып та, җанында табигатькә, үзе кебек тереклек ияләренә карата мәрхәмәт хисе калмаган адәм баласымы? Кем?..

Биредә узган гомердән бер генә сурәт кала — Ул. Мин аңа кайту өчен китәм. Язларында — тамчы булып, җәйләрендә — дулкын булып, төннәренә, төшләренә наз булып кайтырмын әле мин аның... Җирдәге бердәнбер кешенең... зираты агачына чык булып кайтырмын. Барыбер кайтырмын...

## *Нури Арслановка 75 яшь*



*Күренекле татар совет шагыйре, тәрҗемәче, Бөек Ватан сугышы ветераны, әдәбиятыбыз аксакалы Нури Арсланов исеме журналыбыз укучыларына яхшы таныш. Шагыйрьнең күпсанлы шигырь һәм тәрҗемә китаплары илебезнең төрле җирләрендә сөелеп укыла; шулай ук ул үзенең җырлары белән дә замандашыбыз йөрәгенә юл тапкан шагыйрь. Н. Арсланов — Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

*Бу санда тәкъдим ителә торган яңа шигырьләре шагыйрьнең 75 еллыгы уңае белән укучыларыбызга матур бүләк булыр дип ышанабыз.*

# Нури Арсланов

## Тукайга

Һәр ташында Казан урамының,
Бөек шагыйрь, синең эзең бар.
Күңелләрдә яши миллион моңың:
Эзең генә түгел, үзең бар!

Пушкин белән беравыздан, Тукай,
Син Парнаска безне дәшәсең.
Җырга дисәң туган телебез бай,
Бай тел яши, син дә яшәрсең!

Һәр яз саен изге туфрагыңда
Гөлләр чәчәк ата бер диган!
Синең арттан Такташ, Туфаның да
«И туган тел, матур тел!» диган.

Шул тел белән без азатлык дәртен —
Даһи Ленин уен аңладык!
Шул тел белән татар шигъриятен
Җиңүләргә, яуга кауладык.

Атладың син бергә илең белән,
И мөкатдәс сазың чыңлавы!
Җәлилләрең барды синең белән,
Бетмәде көч, кылыч сынмады!

*1986.*

## Өч фәрештә килде каршыма

Кәнәфидә утыра идем калгып,
Өч фәрештә килде каршыма;
Күз алларым кинәт китте балкып,
Сәлам биреп тора барсы да.

— Сәлам! — дидем,— ишек какмый гына
Кергәнсез бит, ярый, әйдәгез,
Я, сөйләгез, эш нәрсәдә тора,
Кайсыгызның нинди хәйләгез?

Газазилнең йомышы иллә кызык,
Кинәт җилән җиле эченнән
Ул күрсәтә шешә муенын сузып:
— Унбиш исәбеннән эчертәм.

Дидем: — Тәңре дөрес бизгән синнән,
Күк капусын дөрес бикләгән.
Эчим дисәм, кибет бәясеннән
Алып куйган ширбәт бетмәгән.

Юкка борчып кабат килеп йөрмә!
Я, Газраил, синдә ни йомыш?
Ә Газраил әйтә: — Тиңли күрмә
Шайтан белән, миндә бик зур эш.

Хезмәт иттең, ял да итеп кара,
Язмаган гел исән калырга:
Хафаланма, гәүдәң үзеңә кала,
Килдем фәкать мин җан алырга.

— Рәхмәт инде, кайгыртуың күренә...
Тик җан алма, ал син гәүдәмне:
Җан һәрвакыт йолдызларга үрелә,
Ә тән сөйри аска бәндәне...

Менә шунда Җибрил телгә килде:
— Дөрес түгел, шагыйрь, фикерең,
Бераз уйлап сөйләү кирәк иде...
Ә мин менә илһам китердем!

Син үз итсәң, мине, дус дип танып,
Тыңлама шул ике азгынны:
Исеңдә тот, телен белсәң, халык
Кабул итә ТУЗГА ЯЗГАНны.

Җаның белән ашсаң да син күккә,
Тәнең белән җирдән аерылма:
Яшим дисәң колак сал син күпкә,
Мәрхәмәт юк илдән аерымга!

Кәнәфидән сикереп тордым. Хәйран!
Рухым мәҗнүн минем тагын да!
Газраилләр инде чыгып тайган,
Җибрил генә калган янымда.

*1986.*

## Очрашу сагышы

Без очраштык кинәт, көтмәгәндә,—
Каушап калдым сине күргәчтен:
Син төшендең, ахры, минем хәлгә,
Үзең туктап миңа эндәштең.

Бүгенгедәй җанлы минем алда:
— Сезне беләм,— дидең,— күптәннән.
Бу көчлерәк тәэсир итте аңга
Кинәт яшен сугып үткәннән.

Икеләндем башта, күзләреңдә
Ләкин күргәч җылы бер караш,
Мин исердем тавышың, сүзләреңә,
Әсирлегем тәмам булды фаш...

Гашыйк булу шулдыр бер күрүдән!
Без әверелдек якын дусларга:
Гыйш вә гашрәт урын бирде түрдән,
Мин буйсындым син ни кушсаң да.

Хатирәле Казан урамнары,
Казан суы буе, таш коймa...
Кайда сез, әй, бәхет томаннары,
Күңел һаман сезгә ашкына.

Нәрсә була инде, рәхәт чагым,
Тик бер генә кайтсаң ичмасам,—
Син дә, бәгърем, шат елмаеп тагын
Элеккедәй кинәт очрасаң?!.

1985.

## Өмет уты

Сөйделәр, сөйдем,
Йолдызлар чөйдем...
И күңелләрнең
Бәхетле чагы!
Шәбендә атның
Бәйгеләр чаптым,
Инде басылды
Тояклар чаңы.

Төштем толпардан,
Кышкы кич... Кардан
Алга юл ярып
Барам далада.
Тынлык-иптәшем...
Кыраулы чәчем
Иңнәргә төшеп
Тузгый, тарала.

Ат килә арттан.
Арбап еракτан
Төтенле бер өй
Күренә анә:
Ут алган көйгә,
Шул җылы өйдә
Көтәләр диеп
Җан өметләнә.

Атка ак ябма;
Үзең түр якка,
Сый да хөрмәткә
Рәхим итсәң.
Я гаҗәп өмет!
Язмыштан килеп,
Җикне бәхетле
Итәр икәнсең!

Ни кирәк артык! —
Уйларга батып
Бетә арулар,
Онытыла кышлар;
Яктыра аңнар,—
Истә узганнар...
Уяна җанда
Татлы сагышлар!..

1984.

## Мөгаллим

*...Ләкин җитмеш ике ел көн-төн уйлап,*
*Хәзер белдем бер әйбер белмәвемне.*
Гомәр Хәйям

Кеше акылы сыйдыралмаган белем —
Китапларда яткан хәзинә.
Ала алсаң шуннан бер бөртеген
Ал, бәхетле кеше, аз димә.

Тирән, чиксез бит ул белем эше,
Мәгънәсе зур хикмәт сүзенең:
Никадәр күп белгән саен кеше
Аз белгәнен белә үзенең.

Күп мәктәпләр тәмам кылып була,
Тик белемне тәмам кылмак юк!
Белгән кеше: «Белим!» дип омтыла,
Ә белмәгән: «Беләм!» белән тук.

Китапларга кереп кеше аңы
Китаплардан кайта акылга:
Җиһандагы базарлардан аны
Сатып алып булмый алтынга.

Бар байлыгым китап томнарында,
Күз нурларым шунда түгәм мин.
Гаҗәпләнмә укып туймавыма,—
Мин гел шәкерт, китап — мөгаллим!

1985.

## Син үзең

Бер офыкта ал таң ата, берсендә кызыл шәфәкъ:
Әңгер ята — кояш бата, ул кызыл якуттай нәкъ.
Янам шәфәкъ белән бергә, балкыйм алсу таңнарда!
Мондый халәт була икән диләр, сирәк җаннарда.

Син дә мине шуңа күрә ярата-сөясеңдер,
Бердәнберем, әллә кемем, гел терем диясеңдер:
Миңа җан өргән — терелткән, «әллә кем» иткән дә син,
Рухымны изге юлларга җитәкләп илткән дә син.

Шәфәгымне ал таңнарга тоташтырганым да син,
Вөҗүдем, аңыма иман урнаштырганым да син,
Шигърият дип диванага сабыштырган да үзең,
Толпарымны бәйгеләрдә ярыштырган да үзең.

Таң булып күңлем күзен камаштырган да син генә,
Дөньямны җәннәт итеп саташтырган да син генә.

1985.

## Күкерткенәм

Күксел ялкын синдә, күкерткенәм,
Күзләреңнән киләдер ул төс,
Кагылу белән кабынасыңны беләм,
Һәрни әйтсәң — сүзең бик дөрес.

Син «ә» дисәң, «я» дип кенә торам,
Каршы килгән белән мәгънә юк.
Табынмасам да, гел сәҗдә кылам,
Минем өчен синнән әгъля юк!

Җитен төсле сары чәчләрең күк
Саргайтмассың әле алай да,
Тиңләмәссең әле бөтенләй үк
Йомыш үти торган малайга.

Бозга тартым күксел күзләреңдә
Җылы да бар төсле, наз да бар.
Булдырасың, теләсәң, үзгәрергә:
Кыш артыннан чөнки яз да бар!

1986.

## Ишетә микән

*Сибгат Хәким истәлегенә*

Җыелганбыз Тукай михрабына
Шагыйрьләрнең әллә ничәве.
Шигырь сөючеләр килгән монда,
Сибгат алып бара кичәне.

Шыпырт кына шунда миңа кордаш
Елмайды да мыек астыннан:
— Сөю җырың бу кичәгә бик хас,
Укы әле,— диде,— Арслан.

Укы әле теге «Кызлар»ыңны,
Бер күңелләр китсен ачылып,
Тыңласыннар әле сызлавыңны
Гүзәлләргә табынып, баш орып.

Сөю моңың чын йөрәктән чыга,
Күренә рухан күккә ашканың!
Синең көчле гыйшкың чынлыгына
Инде мин дә ышана башладым,—

Диде шагыйрь... Ә мин нәрсә әйтим?
Мәхәббәттән анык туймавым!
Ишетә микән әле дә Сибгат Хәким
Лирам хәят җыры уйнавын?!.

1986.

## Арыну юк

Тыңлисез гамьсез бәндәгә,
Күп минем кайгыларым.
Юк минем келәч хәлдә дә
Кайгыдан аерылганым...

Хәсрәтләр агу булса да,
Йот үзең, дим, сиздермә:
Җаным борчуга тулса да,
Рәхәт булсын дим, сезгә.

Без бит хәят диган туйда,
Бозылмасын тантана.
Язмыш уйный,— син дә уйна,—
Хәсрәт ул бер таркала.

Өзгәләнсәң, аһ орсаң да,
Сыгылма сагышлардан:
Хикмәт нясе булсаң да,
Арыну юк ялгышлардан...

1985.

## Сызлану

Боегып йөргән чагым,—
Гөлчәчәкләр төсле сулып,
Коелып йөргән чагым...

Тыелып йөргән чагым,—
Гашрәтне куеп, акылга
Сыенып йөргән чагым.

Томанда тирә-ягым,
Тирән сагыш дәрьясында
Коенып йөргән чагым...

Ниләр котөмдер тагын?!.
Әй, кайларда син — ваемсыз
Уйнаган-көлгән чагым?..

1985.

6*

## *Диңгез тубыктанмы?*

Төркинең кече, олысы
Үрчегән Көнчыгыштан:
Ашинасы[1] да Дулусы[2]...
«Барсы да бер чыбыктан».

Уртак тел, йолалар... Ятмы
Без куманга, кумыкка?
Саф кыпчакмы, я «мулат»мы? —
«Безгә диңгез тубыктан».

Диңгез тубыктан дибез дә,
Уйламый әйтсәң ансат:
Ансат югалырбыз без дә
Нәселсез-нисез калсак.

Ил-Йортыннан аерылган —
Башкаларга килмешәк.
«Биренделәр»[3] дә бит булган...
Нәселсез булмый яшәп!

Тарихың диңгезләрен кич,
Төш тирәнгә, төпләргә:
Башкалардан ким түгел һич,
Ирлегең тиң купләргә!

*1985.*

## Эскиз

Диңгез томан сулап ята,—
Жылыга!
Сусылулар курай тарта —
Жырына.

Оеп тора тирә-яклар,
Тын алмый.
Бу чак ауга акчарлаклар
Чыгалмый.

Тылсымлы моң күк томанда
Тирбәлә.
Кинәт әкрен генә таңнан
Жил бәрә.

Кояш поскан кереп пәрдә
Артына,
Ул оялчак микән әллә?
Тартына.

Чыгар әле, түзмәс, томан
Таркалыр.
Балкышына бөтен җиһан
Таң калыр!

Шулай туа икән бу як
Иртәсе.
Уян, кеше, шат табигать
Иркәсе!

*1985.*

## Артист

Артист уйный дип әйттермәс идем,
Тыяр идем, килсә хәлемнән:
Сабак алып ул рухыннан илнең,
Сабак бирә тормыш фәненнән.

Язучылар үзенең язуын белә,
Алалсаң син укып ал ләззәт.
Артист, сөйләп, язмага җан өрә
Һәм күрсәтеп бирә сурәтләп.

Юк, уйнамый артист, янып яши
Каһарманнар булып сәхнәдә:
Аның йөзе бер якты, бер яшьле,
Ул... бер — хәким үзе, бер — садә...

*1985.*

---

[1] Ашина — Алтай төркиләре шәҗәрәсе.
[2] Дулу — Болгар шәҗәрәсе.
[3] Бирренделәр—Берендеи— башка кабиләләр кысрыклавы аркасында рус князьләренә бирелеп, утраклыкка күчкән төрки кабиләләр төркеме. Соңыннан Алтын Урда гаскәрләренә кушылып китә.



*Шагыйрь һәм әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Зәет Мәҗитовка 60 яшь тулды.*

*Зәет Мәҗитов шигырьләре 1948 елдан башлап республика көндәлек матбугатында басыла башлый. 1953 елда исә беренче китабы — «Таңгы җыр» дөнья күрә. Хәзер ул — дистәгә якын шигырь һәм поэмалар китабы авторы; алар арасында «Ярсу Ык» исемле шигъри повесть (1966), «Һәйкәл янында» (1949), «Кияү каршылаганда» (1967) кебек поэмалар бар. Әдипнең сайланма шигъри әсәрләре 1977 елда дөнья күргән «Рәхмәт яусын» исемле күләмле китабында тупланган.*

*З. Мәҗитовның күренекле татар совет шагыйре Ф. Кәримнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә багышланган монографиясе (1963), Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясенә багышланган «Сугышчан поэзия» (1975) кебек хезмәте, бүгенге поэзия процессына караган күзәтүләре, төрле жанрларга, әдәбият мәсьәләләренә багышланган күп санлы мәкаләләре дә укучыларга яхшы таныш. Ул «Әдәбият теориясе» китабы басмаларын әзерләүдә актив катнашты, аның авторларыннан берсе булды, Ф. Кәримнең әдәби мирасын барлау һәм җыеп бастыру эшенә күп көч салды. Бүгенге көндә ул «Хәзерге татар поэзиясе» дигән хезмәт яза...*

*Тынгысыз каләмдәшебезне олы юбилее белән котлап, без бу санда укучыларыбыз игътибарына З. Мәҗитовның бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Зәет Мәҗитов

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Чикләвек

Сап-сары, сап-сары,
Чын алтын төсендә.
Төсендә ни хикмәт?
Хикмәте — төшендә.

...Кәефне кыра тик
Корт булса эчендә.

*1960*

### Балыкчы фәлсәфәсе

Бармак чаклы балык тотар өчен дә кармак кирәк,
Кармак алып, су буена бармак кирәк!

*1981*

## Чуртан һәм сазан

Кечкенә бер Чуртан
Әйткән: «Йотам!»
Дәп-дәү бер Сазанның
Коты чыккан.

*1965*

❁

Әле көньяктан исә җил,
Әле төньяктан өрә.
Я ягымлы елмая ул,
Я салкыннар китерә.

Без барабыз. Безнең гадәт —
Юлны үзгәртеш түгел!
Җил җаена әйләнергә —
Без җил күрсәткеч түгел.

*1971*

❁

Юкка, юкка сары яфракларны
Сибәлисең минем тирәли...
Йөрәгемдә узыша яз атлары,
Сыкрап йөрмә әле, көз-әби!

*1964*

❁

Мин бит синең дустың диеп, еш киләсең,
Я бер йомыш, я бер ашыгыч эш белән син.

Дуслык хакы — зур хак, алам, карышмыйм мин.
Дустым өчен бер эштән дә ялыкмыйм мин.

Ә бер чакны минем сиңа йомыш төшә,
Бер ярдәмсез үти алмас зур эш — өстә.

Ярдәм сорап сиңа килдем — ишетәмсең?
Хәерче дип, артка чиктең ишектән син!..

*1970*

❁

Без еш кына, бел, дус, хәйран ирне
Уйламастан вәйран итәбез:
Әүвәл, мактап, тәмам тилертәбез,
Ә «тилергәч» — аннан өркәбез.

*1972*

❁

Болытлар артында болыт бар,
Офыклар артында офык бар.
Карама караңгы болытка,
Җит үз таңың аткан офыкка!

*1979*

Бөртекләп җыела бөртекләр,
Бөртекләрдән туа көшелләр,
Күптән белгән моны кешеләр,
Белмәгән тик минем ишеләр.

*1980*

## Тәкәбберлек

Үзенчә һәркем дә зур, һәркем эре.
Мин,— ихтимал, әле иң тәкәббере.

Көтү-көтү кандала талаганда,
Яткан кебек кашынмыйча һаман да

Бирмимен сер, сиздерми йөри бирәм,
«Бар»ымны «юк» дисә дә якын-тирәм.

Сөйли бирәү шыр ялган минем хакта,
Мин — су капкан. Бирмим аны уйлап та.

Минем алга керә нахал чиратка,
Кычкырмыймын. Вакланулар ят ир-атка.

Шулай йөрим, чөнки мин — зур, мин — эре,
Мин — дөньяның горуры, тәкәббере.

Эрелекне минем, димен, күрерләр,
Кызганыч тик... әрәм үтә гомерләр..

*1982*

❁

«Бөркет мин!» дисең. Бул, ярый!
Күңелеңә ләкин беркет:
Бөркет, җаный, бүре аулый,
Бөртек чүпләми бөркет.

*1983*

❁

Очраштык без гомер язында —
Язгы чирәм кебек чагында.
Белмәдек без язның үтәрен,
Таптап үттек яшьлек чирәмен.

Очраштырды язмыш тагын да
Көзге камыл кебек чагында.
Беләбез дә гомер үткәнен —
Табып булмый яшьлек эзләрен.

*1983*

# Сискәнү

Болын. Сахра. Яшел келәмендә
Ятам тыңлап Җирнең сулышын.
Әллә нинди сәер халәт миндә —
Бернәрсә дә килми уйлыйсым.

Әнә, пешеп килгән эре җиләк
Кояш белән нидер сөйләшә.
Чыпчык күзе утыра нидер көйләп,
Ике ак ромашка серләшә.

Күк чикерткә — болын сорнайчысы
Әй чиртә соң кылын, әй чиртә!
Көмеш кылган — аның тыңлаучысы,
Башын иеп тынган бер читтә.

Тукта! Кинәт ник сискәнде кылган?
Чикерткә ник читкә сикерде?
Нәрсә булды? Кинәт баш астымнан
Җир бер сәер тетрәү китерде.

Әллә, күкрәп, урман артларыннан
Давылланып, яңгыр киләме?
— Оеп ятма, уян, уян, уян! —
Дип, Җир миңа аваз бирәме?

Ниндидер ток үтте күкрәгемнән,
Җаным купты кинәт сискәнеп:
«Болыннарың, чәчәкләрең белән
Киттең мәллә, Җирем, тетрәнеп?

Югалтмасмы ритмын синең йөрәк?» —
Шул уй, шул гамь зиһнем каплады.
Әллә Җирнең, әллә минем йөрәк
Ярсып-ярсып тибә башлады.

Табип эзләп ашыгып киенгәндәй
Сикереп тордым болын-келәмнән.
— Тиз йөр! Тиз йөр! Тиз! — дип теләгәндәй
Озатып калды гөлләр, чирәмнәр.

*1981*

❋

Телсез йөрде гомергә,
Хәзер баеган сергә,—
Бик тели сөйләшергә.
Тик шунсы гына яман —
Бер якыны калмаган,
Сөйләшә алмый агаң.

*1983*

# *Николай Беляевка 50 яшь*



*Николай Беляевны укучыларыбыз Казанда яшәүче рус шагыйре һәм тәрҗемәче буларак яхшы беләләр. Ул үз буынының матур эшләре, аларның рухи дөньясы аша заман проблемаларын калку тасвирлаган лирик шигырьләр язу белән бергә, татар шигърияттен рус теленә уңышлы тәрҗемә итүчеләрнең берсе буларак танылды. Дәрдмәнд шигырьләре, Һади Такташның юлбашчыбызга багышланган «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы, Сибгат Хәкимнең шигырь һәм поэмалары, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис һәм башка шагыйрьләрнең күп әсәрләре рус һәм бөтенсоюз укучысына Николай Беляев тәрҗемәләре аша иреште.*

*Шагыйрь һәм тәрҗемәче Николай Беляев 1937 елның 23 сентябрендә Ярославль шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. 1955 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының геология факультетында белем ала. Университетта уку елларында геологик экспедицияләр һәм студент отрядлары составында чирәм җирләрдә, Урал, Себер якларында була, тормыш белән якыннан таныша. Университетны тәмамлагач, Татнефтегеофизика трестында геолог, фәнни институтта инженер-конструктор, Казан телестудиясендә кинооператор ассистенты, геология фәнни-тикшерену институтында гыйльми язмалар редакторы һәм 1968—1969 елларда «Комсомолец Татарии» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1973—1975 елларда Н. Беляев Мәскәүдәге М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Хәзер ул — профессиональ язучы.*

*Николай Беляевның шигырьләре матбугатта илленче еллар азагында күренә башлый. 1967 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Голоса расстояний» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Бүген инде ул — дистәгә якын китап авторы. Аерым әсәрләре Красноярск, Иркутск һәм башка шәһәрләрдә чыккан җыентыкларда һәм альманахларда дөнья күрде. СССР Язучылар союзы әгъзасы.*

*Шагыйрьне илле яше белән котлап, бу санда аның төрле елларда язылган шигырьләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

## Николай Беляев

# РӘХМӘТ СИҢА, ЯЗМЫШ!

●

Бу тормышны җырга салабыз дип
без уйладык микән ул чакта.
Шигырь утын кабызыйк дип әллә
Себердә без яктык учакларо.

Пошиларның бездән курыкмыйча
артыбыздан калмый йөрүе,
мүк җиләге, симез гөмбәләре
рифма өчен генә түгелдер.

Кешелләрдә ашлык янмасын дип,
уттай кызышуы колларның,
«Бер-ике-өч, алдык!» — дигән сүзләр
ритм өчен генә булмады.

Черки безләвеннән чеңләп торган
тайга сукмагыннан узганда
шигъри тема эзләү дигән максат
булды микән безнең уйларда?

Юк, дусларым, шагыйрь булам диеп
махсус өйрәнмәдем тормышны.
Яшәдем мин янып,
һәм янулар
матур җыр язарга булышты.

●

Эшләре белән кешеләр
җаныма эз салгандыр:
киң далада сызып уздык
беренче буразнаны.

Юк, эзләп бармадык анда
«озын сум»нар төргәген,
без алтын бөртекләр чәчеп,
үзебезне эзләдек.

Белергә теләдек шулай
эштә тамган тир тәмен,
егетлек һәм намус көчен,
җир тәмен һәм җыр тәмен...

Рәхмәт, язмыш, өлеш бирдең
миңа шундый сәфәрдән,—
йолып калдың — гомер буе
йокымсырап яшәүдән.

## Атлантлар

Болак янындагы бу урында
булган элек Печән базары.
Хәзер монда бакча. Бакчада өч
Атлант тора тотып Җир шарын.

Күгәрченнәр килеп куна җиргә,—
Атлантларга алар ышана:
Кулларыннан төшермәсләр Җирне,
күтәрүе авыр булса да.

...Без — малайлар — шунда уйный идек,
кинәт шартлау — Болак ярында!
Колак янибызда җил сызгырып,
күккә очты бензоколонка!

Әмма ләкин дәһшәткә үч итеп,
яшь агачлар калды... Җир калды:
Өч баһадир саклап калды ахры
безнең өчен ул чак аларны...

Әтиемнең шаяртуы истә:
«Ялга җыена икән атлант»,— дип,—
Алыштырыр кеше бәлки синдер?! —
Бер атлантның урыны вакант»,— дип...

## Сонет

Күп нәрсәнең сере ачылды инде
галәмнәрдән Җиргә баккан заманда.
Тик «җан» дигән мәҗүси бер сүз генә
сәясәткә серен чишми һаман да.

Җан — мәңгелек, ул — кешенең канында,
бирешми һич тормыш суккан-какканга,
рухыңны ул балкыта йолдыз булып,
иреннәрне иреннәр уятканда.

«Җан нәрсә?» — дип сорасак без, сәясәт
әйтер бәлки: — Ул — мәңгелек сәяхәт...
Белмим, ни соң яндырып рух чырагын
өзгәләнә, моңсулана, сагына?
Кул урнында пар канатлар тоямын
ашыкканда җан сөйгәнем янына...

## Сөембикә легендасы

(«КАЗАН ДӘФТӘРЕ»НӘН)

Төне авыр була Казан ханшасының,
ул төшендә күрә Мәскәү патшасының
шәһре Казанны камавын як-ягыннан...
Әнә күкне алсулата зур янгыннар!
Гаскәренең ялт-йолт килә сөңгеләре!
Котылырга бәлки соң түгелдер әле.
Сөембикә менә биек манарага,
«Выж-выж!» итеп уклар оча колак янда.
Ходавәндә! Чорнап алган елга ярын
ак чатырлар... Гаскәр, гаскәр... янгын, янгын...
Аһ! Коелыр микәнни соң тагын каннар?
Каршылыклардан кыела нигә җаннар?!
Ялваруның файдасы юк,
диннәр — көчсез.
Көчсез булсаң, «гөнаһларың» булыр чиксез.
Кол итәргә уйлаганнар безне, имеш,
ләкин юкка! Алалмаслар тере килеш...
Манараның түбәсендә Сөембикә
дога кыла соңгы тапкыр багып күккә,
аннан үзен таш шикелле түбән ата!

...һәм уяна.
Куркуыннан тиргә бата.

Халык хәтере көчле икән үлемнән дә...
Шул төш әле кай ара кергән телләргә?! —
Әйләнгән ул канатлы бер легендага:
ханлык түгел, халык канат куйган аңа.
Шуннан бирле, дәверләрне кичә-кичә,
киләчәккә бара Хыял-Сөембикә...

**Шамил МАННАПОВ** тәрҗемәләре.

## Әхәт Гаффар

# ЯШИСЕЛӘР АЛДА ИДЕ ӘЛЕ

ПОВЕСТЬ

*Авылдашым Кәримулла Гатиятуллин истәлегенә багышлыйм.*

Автор.



Сөнгатулла елга буена килеп утырды. Ул бирегә кызыл бозауларын арканларга дип килгән иде.

Монда үлән куерак, яшелрәк, сусылрак. Малтуар ярдан читтәрәк чемченүчән. Бозауларны да, яр ишелеп төшүдән шикләнеп, бик кырыйга китереп арканламыйлар. Шуңа күрә яр читендәге үлән иркенрәк үсә.

Утырганда ул җиргә таянган иде. Учы төпләрендә чык кибеп бетмәгән салкынча үләнгә кереп батты, ә бармак араларына туры килгән үсемлекләр калкып калды. Кулын алгач, уч эзе, кәгазьгә куеп, карандаш белән сызгандай, таянган урында аермачык беленеп торды. Бераздан уч эзе юкка чыкты.

«Үләндәге эз тиз бетә»,— дип уйлады ул.

Сөнгатулла сузган аякларын бөкләп утырды. Беләкләрен тезләренә аркылы салып, кулларын кушырды. Аның күләгәсе каршы яктагы комлыкка төшкән иде.

Җир салкынча иде әле.

Ә көн җылы, аяз, тын буласы. Кояш аның аркасын җылыта башлаган иде инде. Иртәнге салкынлык тәмам таралды. Су аккан тавыш тоныгайды, сүрелде.

«Су тавышы, кояш баегач, ачыграк ишетелә»,— диде ул үзалдына.

Бу турыда елга зур борылыш ясый. Яр текә, биек. Аста — яшел сулы тоба, ул тирән, төбендә — соры төстәге үзле балчык. Киң селтәнеп чапкан чалгы эзедәй яткан борылышта Сөнгатулла үзен ничектер кечерәеп калгандай тойды.

Аръякта авыл көтүе йөрер өчен сукаланмый калдырылган озынча болын. Кара-каршы торган урләр арасындагы тар иңкүлеккә кереп киткәнче, ул болында иртәләрен авыл көтүе таралып, чемченеп ала, көне буена колхозның ат көтүе утлап йөри. Болынның теге ягындагы үр кашы буенча таш юл сузылган. Ерак офыкны күгелҗем урман чикли. Уң кул якта — авыл. Ә елга буенча түбән төшеп, кечү юлын һәм тирән ерганакны үткәч, тагын бер болынга килеп чыгасың. Аның түрендә

---

ӘХӘТ ГАФФАР *(1949)— прозаик, драматург, «Әҗәт», «Гозер», «Бер йотым су», «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» һ. б. китаплар авторы.* ***Казанда яши.***

сигезле санын хәтерләткән буынтыклы сай күл. Ул болынга барып чыксаң, таулар белән инеш арасындагы киңлектә каласың. Тауларның итәге җәенке, түбәләре тоташ, тигез. Анда — югарыда — иген басулары, авыллар.

Ә аскарак юнәлсәң, Чулман ярына барып җитәр идең.

Сөнгатулла, кушырган кулларын аерып, артка таянды, аягын сузып җибәрде һәм күк йөзенә карады. Анда карлыгачлар оча иде. Ул тагын аягын бөкләп һәм кулларын кушырып утырды.

Кошлар яңа борнап чыккан балаларына җим ташый. Оялары шушы ярда.

Башын боргалап, Сөнгатулла карлыгачларны күзәтте. Берәрсенең үз оясына кыйгач якынаеп киткәнен җентекләбрәк караганда, бүтәннәренең житез очышы яшен тармакларыдай сызылып кала иде.

Сөнгатулла үзенең болай иркенләп утырганын хәтерләми. Эштән бушамады. Кайчандыр, кайдадыр аның хакында сүз кузгалган икән — моңа эшләгәне, эшләве, эшләргә тиешлеге сәбәп булгандыр. Кайвакытны аңа дөньяда тагын бер Сөнгатулла Тимершин дигән кеше яшидер, ә ул үзе шуңа күләгә сыман ияреп кенә йөридер шикелле тоела иде.

Ул иртүк эшкә чыгып китә иде. Таң атканнан күз бәйләнгәнче кырда. Төннәрне исерек килеш каршы алганы да булгалады. Андый чакларны урыны кече өйнең мич аралыгындагы тимер караватта, керле күлмәген, майлы чалбарын салып та тормый. Ә таң сызылганда, уянып, ишегалдына чыкса, үзен кичтән мунча кергәнен белә дә күңелен үкенү хисе били иде. Бәйрәмнәрнең ничек үткәнен дә ул гадәттә тоныкына сиземләргә өлгерә. Өлкән улы өйләнде, кызын кияүгә бирде, туйлар — әзерләнү мәшәкате, шатлык катыш моңсулыклары белән генә хәтерендә калган. Өлкән улы Мусаның армиягә китүе, аннары кайтуы да шулайрак. Киткән чагында борчуларны аяк астына салып таптарга теләгән шикелле эчелгән, ә инде ул әйләнеп кайткач, шатлыкларны тояр-туймас ярым-йорты сүз әйтелгәндер. Кече улы Фәрһад армиягә киткәндә дә шулайрак булды.

«Менә иртәгә, менә иртәгә дип яшәлде шул»,— дип көрсенде Сөнгатулла.

Ул, нииндидер хәрәкәт сизеп, аска карады. Тәбәнәк, куе таллыктан агып чыккан чишмәнең инешкә кушылган тамагында зур бер балык йөзә иде. Сазан бугай. Почмакланып торган ул урынны кояш нурлары үтәли яктырткан. Сөнгатулланың күләгәсе хәзер шул чишмә тамагы янына чигенгән. Күләгәсе урынында үзе булып, кулын сузса, Сөнгатулла ул балыкны сыртыннан тотып алыр иде шикелле.

Ул сак кына кулын читкә сузды, әйтерсең лә, балык янәшәдә, нәкъ кул астында гына. Балык аның кул шәүләсеннән өркеп, суга бөгелеп төшкән тал ботаклары астына качты.

Сөнгатулланың, менә иртәгә, менә иртәгә дип яхшы, матур, рәхәт тормыш итә башларга теләгән өмете дә гел алга качты да алга качты шул. «Иртәгә» дигән өмет тоттырмады. Әлеге көмеш балыктай, көндәлек мәшәкатьләрнең һәм ямьсез гадәтләрнең чәбәләнгән ботаклары арасына кереп качты, адашты.

«Иртәгә» дигән нәрсә сугышта йөргән чагында: «Менә җиңгәч, өйгә әйләнеп кайтырбыз, шунда ничек яшәргә икәнен белер идек!» — дигән нык ышаныч төсендә иде. Җиңделәр, өйләренә әйләнеп кайттылар. Сугышның башында атасы һәлак булды, ахырында абыйсын үтерделәр. Аларның күңелләрендә дә «җиңеп өйгә кайткач» дигән хыял йөргәндер.

Сөнгатулла, өенә әйләнеп кайтып, әнкәсе белән исәнләшкәннән соң, капка баганасы төбенә чүгеп утырды һәм тәмәке төреп кабызды. Күзне чагылдыргыч кояшлы көн иде. Яргаланган имән багана мич шикелле җылы. Капкалары әнә шундый дүрт баганалы. Арка терәрлек җылы баганалар барында яшәп булыр әле! Ул, иптәшен юатып, аның иңен каккандай, баганага киң учы белән суккалады да:

— Ничава, әни! — диде.

— Бик баганага терәлмә, улым. Төпләре черек. Аллаһе тәгалә кодрәте белән генә торалар,— диде әнкәсе.

Сөнгатулла кече капка белән олы капка асылган баганаың төбенә иелеп карады. Ул җиргә күмелгән урында божраланып черегән, тәрткәч, бармагы төбенә кадәр диярлек батып керде. Бактың исә, имән баганалар үзләре аның терәвенә мохтаҗ икән.

Тәбәнәк өйнең имән матчасы да сыгылган. Тәрәзә төпләрендәге яран гөлләр арасыннан саркып кергән ай яктысында өй уртасына тураеп баскач, Сөнгатулла үз иңендә баш очындагы түшәм йөген генә түгел, ә бәлки аяк астындагы нигез авырлыгын да тойды.

«Әйе... Фронтта үлеп калуың да бар иде. Ә монда һәр нәрсәне аякка бастырмыйча торып, үләргә ярамый икән»,— дип уйлады ул.

Җиңү артта калды. Ләкин җиңәсе нәрсәләр күп икән әле.

Тын, бик тын иде. Беркайчан да мондый тынлыкта калганы юк кебек. Чү, әнкәсе дә йокламый икән. Аналар йоклый алмаган төн бигрәк тә тын икән.

Ул баскыч төбенә чыгып утырды, тәмәке кабызып суырды һәм тракторын исенә төшерде. Үзен үк түгел, тавышын гына әле. Сагынган икән, сагынган.

Сөнгатулла «Коммунар»ын кабызгандагы төгәл һәм гайрәтле хәрәкәтләрен күңелендә барлап чыкты. Менә керосин кранын ачты шикелле. Карбюраторның ялтыравыклы төймәсенә басып, бармак битенең керосинга чылануын аермачык тойгандай булды. Аннары кытыршы учы агарткан кабызгычның шома тоткасыннан тотар да, кул һәм күкрәк көченең салкын мотор каршылыгы белән тоташуын сизгәч, бөтен җирне әйләндереп җибәрергә теләгән шикелле, кискен бер хәрәкәт ясар. Һәм уяныр иде авыл, уяныр иде! Почмактагы агач шүрлектә төрле савыт-сабаның вак кына дерелдәгән тавышы әнкәсенең керфек очларын тибрәтмәс идемени?

Йокысыз караңгы төннәр сугыш каберендә мәңгелеккә күмелеп калмаган, Сөнгатулланы алда көтеп тора икән әле. Авырлыклардан ышыкланыр өчен танк бронясы, туңганда җылыныр өчен мотор кайнарлыгы юк инде. Хәзер үз көчең генә таяныч.

Иртәгәсен, аны-моны карагач, ул бакча ягына чыгып басты. Бәрәңге җирен алабута баскандыр дип уйлаган иде. Чип-чиста икән.

Ул йолкынган салам түбә кыегы астында бөрешеп басып торды, тамырларын зарарламаска тырышып, әнкәсе кара җирдән яңа бәрәңге казып алды.

— Бәрәңгене яхшы утагансың, әни. Уңар бу.

— Утагансың дип... Тирес юклыкка ул. Кәҗә белән сарыктан алабуталы тирес чыгамы соң. Халык та егылып ашады. Орлыгы корыды аның. Үссә, утамас ием әле.

Азык хәле алама икән. Ул моңа кичә үк — келәт почмагына ятимнәрчә сыенган килене күргәч төшенгән иде. Аның төбенә соры, бака кабыгы эчедәй ялтырап торган куник каткан. Күрәсең, әнкәсе язын эрегән кар астыннан черек бәрәңгене җыйган да юып һәм киптереп төйгән. Өрәңге кисапның тоткасы сап-сары, әнкәсенең сөялле учы аны шомартып, ялтыратып бетергән. Кисапның баш-башларында да крахмал валчыклары җемелдәшә иде.

Төп ризыклары шул бәрәңге иде. Кәҗә сөте, сарык һәм бәтиләрнең йоны, ите налог түләүгә китте. Халык ашау хакында сөйләшмәде. Ни белән туклануына, җан асравына ояла иде бугай.

Ят аваз ишетеп, Сөнгатулла артына борылып карады. Бая арканлап куйган бозавы чиләкне аударган икән.

Сөнгатулла өенә төшкә генә кайтырга, шуңынчы елга буенда юанып утырырга, хәле җиткәнче түбәнге болында йөрергә чамалаган иде. Ул болай иркенләүнең беренче һәм соңгы тапкыр икәнен уйламады. Дөресрә-

ге, уйламаска тырышты. Хәзер инде Сөнгатулла өчен бөтен нәрсә соңгы тапкыр. Әлегрәк мондый уйга ышанмас, аны җаны-тәне белән кире кагар иде. Әлегә бу уй бик бәләкәй, зәгыйфь. Шулай да аның күңеленә тамыр җәяргә, көчле каусә җибәрергә һәм Сөнгатулланы караңгы күләгәдә калдырырга өлгерде инде. Хәер, шунысы хак: кешенең һәр мизгеле, һәр гамәле соңгы тапкыр, кабатланмас инде ул. Шушы яр буена көн саен килеп бассаң да, һәр көннеке соңгы тапкыр. Кичәге су аккан, яр ишелгән, үләннәр корыган булыр.

Төшкә кадәр өенә кайтмаска дип чыкканга күрә, арканланган бозавы янына кабат бармас өчен, ул аңа төшлектә эчертәсе апарасын да күтәреп килгән иде. Бозау шуны аударган. Сүс аркан чиләккә җитәрлек түгел иде. Борылганда бозау аңа арт аягы белән орынган, күрәсең.

Сөнгатулла: «Чиләкне читкәрәк куясы калган икән»,— дип үкенде. Ләкин үзен гаепләмәде. Бозауны яр читендәге сусыл үләнгә мөмкин булганча якынрак арканлаган иде.

Ул җиргә таянып басты да, бер генә адым атлап, чиләк янына чүкте. Аны утырткач, апара тимгелләтеп калдырган һәм еккан юеш үләндәге җебегән ипи, коймак, бәрәңгеләрне учына сыпырып алды. Алар йомшак, җылы. Тешләнмәгән, кабылмаган, ашалмаган. Җитмәгәнгә күрә кайчандыр бәрәңге кушып кына пешерелә торган ипи, бәби ашы итеп кенә илтелгән төче коймак, кабыгы да әрәм ителмичә, җиргә орлык итеп утыртылган бәрәңге бүген бозау чиләгендә. Әрәм димәслек, вөҗданны оялтмастай, мал-туарга гына ярардай бердәнбер ризык — кыяр кабыклары. Анысы да үз бакчаларында үскән түгел, кызлары алып кайткань.

Уенга атлыгып, ашык-пошык ашаганда алларына ипи валчыгы койсалар, Сөнгатулланың күз карашыннан уллары куырылып килә иде, бичаралар. Ә бүген ул он, тоз салып туглаган аксыл апарага бу икмәк телемнәрен үз куллары белән чыгарып салды. Хатыны кибеттән көн саен ике бөтен ипи сатып ала, аңа кызлары алып кайткан түгәрәк күмәчләр өстәлә, иртә-кичләрен калдык ипиләрдән сыерларына да өлеш чыга. Шулай әрәм-шәрәм ителгән икмәк авыл буенча күпме җыела икән? Бервакытны Сөнгатулла олы кызларының Казан читендәге дачасында, потлы чиләк тутырып, бөтен-бөтен дә, яртылаш та, чирек тә килеш шушылай җебетергә куелган ипине күреп: «Әллә монда берәр мал•асрыйсызмы, кызым?»— дип сораган иде. Аның: «Әчетеп, карлыган төпләренә сибәбез, эти. Бөтен кеше шулай эшли монда. Бик уңдыра диләр», дигән җавабына каршы ул телсез калган иде.

«Иллә дә туйганбыз икән соң!»— дип уйлады ул хәзер. Кайчандыр көн дими, төн дими һәм җитәкчеләргә карышусыз, тормыштан зарланмыйча, муллыкка менә бүген, менә иртәгә ирешербез дип, ачлы-туклы яшәделәр бит. Ә ул туклыкның, муллыкның үз учындагы шушы җебегән икмәк сурәтендә киләсен белсә, Сөнгатулла һәм авылдашлары әлек ни әйтер, ни эшләр иде икән?

Туклык килгәч, аракы эчү күбәйде. Ипинең кадерен җуйдылар.

Сөнгатулла төбенә бармак калынлыгы он апарасы утырган чиләккә ярган бәрәңге, инде уалган коймак, ипи калдыкларын тутырды.

Җирдә ярык бар икән. Апара суы шунда аккан.

Сөнгатулла монда килгәннән бирле беренче мәртәбә кычкырып:

— Әһә!— диде. Башын үләннән күтәреп, аңа бозау борылып карады.— Аша син, аша. Сиңа дәшүем түгел,— диде ул аңа.

Ярыкка бармак сыярлык. Бу урын ярдан чыгыбрак тора. Бирегә Сөнгатулла шуңа утырды да. Ярык шул чыгынтыны ике адым эчтәнрәк урап сузылган. Җәйге эсселек, көзге мул дым, кышкы туң, язгы җебү аны тагын да киңәйтер, тирәнәйтер инде. Ә ташу вакытында боз белән су аның астагы таянычын ашап юар да ярның бу өлеше, һичшиксез, упкынга убылып төшәр. Ярны борылышта актарылып аккан су ничек җебетер дә, бозлар кайданрак ашар икәнен чамаларга теләп, Сөнгатулла җиргә сузылып ятты һәм түбән карады.

Яр эчкә уелып кергән, куышланган. Аны керәшә оялары да челтәрләгән. Ләкин берсенә-бер керәшә кереп чыкмый. Алар читтәнрәк оча. Үзеннән өркәләрдер дип шикләнеп, Сөнгатулла арткарак шуышты. Тик керәшәләр ул ояларга барыбер якынаймадылар. Башын ярдан сузып, ул тагын аска карады һәм ояларның былтыргы икәнен аңлап алды. Керәшәләрнең яңа оялары читтәрәк икән. Ярның ишеләсен сизгәннәрдер, шәт. Ояларына ярыкка аккан яңгыр суларыннан дым да тарткандыр. Кошлар акыллы. Кешеләр генә бәлане аякка уралгач кына күрүчән.

Сөнгатулланың үз тормышын да шушындыйрак ярык уратып алган иде инде.

Аягын бөкләп, ул тагын торып утырды. Ябык иңбашы салынып төште. Аның үз-үзен шушы ишеләсе яр кантарыннан аерасы, күтәрәсе килде. Киләсе язда ул убылып төшәр, һәм ярсу ташкын аны җебетеп уар, уар да әллә кайларга илтеп таратыр.

«Бу — мин»,— дип уйлады ул яр башы турында. Әйе, Сөнгатулланың гомере дә тормыштан аерылу алдында инде.

«Мин тормыштан аерылмыйм, яшәүдән аерылам,— дип төзәтте ул үз-үзен.— Тормыш кала ул. Гомер бетеп бара, гомер».

Кояш күтәрелде. Иртәнге салкынлык эреде. Җил исә башлады. Томан таралды. Күләгә елганың уртасына житте. Су ике төстә инде: күләгәдә яшькелт, яктыда саргылт. Сайлыкта маймычлар ялтыраша. Зуррак балыклар төптә әле, җимләп йөриләрдер. Авыл ягында тавышлар күбәйде. Юлдан өч йөк машинасы бара, аларны бер мотоцикл узып китте. Болынны кыйгачлый кистергән юлда печән чапкычлар таккан көпчәкле тракторлар күренде. Артта бозауның үлән кушәгәне ишетелә. Авазлар һәм хәрәкәт, төрлесе-төрле яктан уратып алып, үзләрен тыңлаттыра һәм караттыра. Берсенә дә барып кушылырлык түгел. Аңа хәзер шушылай утырасы гына. Вакыты бар хәзер.

Эш шунда: Сөнгатулла ярты елга якын больницада ятып чыкты. Башта күрше рус авылындагы участок больницасында. Бавыры бер заманны төннәрен йоклатмас дәрәҗәдә авырта башлагач, яңа ел алдыннан күренергә барган җиреннән алып та калдылар. Йөзе сап-сары, шул ук төс күз агын да сарган, чәче соры камыл шикелле таушалган, сакалы җиткән, аяк-кулы хәлсез — кыяфәте боек, уйлары буталчык. Нинди эре сөякле зур гәүдәсенә дә бушрак иске бумази халат, арты тапталган күн чүәк кигәч, авыл урамының ике ягын бер итеп йөри торган Сөнгатулланың мыштым гына елыйсы килде. Кайвакытта шулай, юан тупыллар төбендә торган кул тегермәненә утырып, саран гына елаштырганы бар иде аның. Гадәттә моңа «бүтәнчәрәк, тормышның тәмен татыбрак, үкенмәстәйрәк яшәргә дә булгандыр бит миңа», дигән сагышлы уйлары сәбәпче була иде.

Аны сары авыруы белән чирләгән дип дәваладылар. Участок больницасында өч айга якын дару өстенә дару эчте. Тик йөзеннән сары төс югалмады, эч авыртуы басылмады, хәл кермәде. Нindидер бер йомыш белән Казаннан килгән доктор чал мыегының сул очын чәйни-чәйни аның рентген рәсемен карады да тиз көндә шәһәргә — үзе эшләгән больницага ятарга кушып китте.

Сөнгатулла элек-электән шәһәрнең өсте-өстенә менә язып утырган биек йортларын, җанга ятышсыз әллә ниткән исле һавасын, кайнап торган кешеле урамнарын өнәмәде. Анда барырга туры килгән саен, нәрсә алырга кирәклеген аңлатып, хатыны кәгазь биреп җибәрә торган иде. Шуны зур, каты учына йомарлап, кибетләрнең бер ишегеннән керә иде дә, халык агымын яраша алмыйча, беренче катта шактый әвәләнеп йөргәч, ит турагычтан чыккан шикелле ватылып, изелеп, бүреген я кепкасын култык астына кыстырып, икенче ишегеннән килеп чыга иде. Авылының киң, иркен кырларында, тыныч урамнарында йөрергә күнеккән Сөнгатулланың күңеле шәһәр тарлыгына, кысанлыгына буйсынырга теләми иде.

Больницаның онкология бүлегендә байтак яткач, аны шәһәрдә яшәүче кызы Мәрзия килеп алды. Иртәнге обходка кергән озын буйлы, зур күзлекле, чал мыеклы шул доктор шактый озаклап аның авыру тарихына карап торды да:

— Сөнгатулла туган, өеңә кайтасың киләме инде? Синең авыруың куркыныч түгел. Ике-өч ай авыррак булыр әле. Ләкин төз, узар,— диде.— Менә шушы рецептларда күрсәтелгән даруларны эчә тор,— дип, мөһерле кәгазьләр сузды.— Берәр айдан тагын күренеп китәрсең.

— Ярар. Рәхмәт. Исән булсам килермен. Гүр юлы түгел ич.

Ул, палатадагылар белән саубуллашып чыккач, үзенә зуррак пижаманың чалбар балакларына уралып, артсыз чүәкләрен лыштырдатып, беренче катка төшеп басты. Зур вестибюльнең саргылт-көрән шакмаклы плитә җәйгән идәнен яңа гына юганнар, дымлы таш, хлор исе килә иде. Кызын эзләп, як-ягына каранып алды. Ул көттермәде. «Главврач» дип язылган ишектән зур кәгазь капчык күтәреп килеп чыкты. Сөнгатулла кызының аякларын таш идәнгә тидерер-тидермәс җитез атлап килүенә сокланып торды.

Мәрзия, атасына бик туры карамаска тырышып, елмаеп кына сөйләште, хәлен сорашты, кәгазь капчыгын аңа сузып, кайда киенергә кирәклеген әйтте.

Ак буявы каушакланган кечкенә өстәл белән артсыз урындыктан гайре нәрсә булмаган, тәрәзәсенең аскы пыяла өлгеләре акка буялган эңгер-меңгерле бүлмәдә шактый озак киенде: үз киемнәре, әллә ничек, чит кешенеке сыман тоелды.

Биек пыяла ишекне авырлык белән генә ачып, Мәрзия башта атасын уздырды, аннары үзе яны белән генә суырылып чыкты. Больницаның авыр ишеге дөңк итеп ябылып калды. Ул тавыш Сөнгатуллага кышкы кабернең ләхет тактасына туң туфрак кантары бәрелүен хәтерләтте.

Әкрен генә атлап, баскычтан төштеләр. Биш потлы гәүдәсенең хәйран җиңеләйгәнен ул шунда тойды. Җил исеп китте. Сөнгатулланың үз авылларына таба очыплар китәсе килде. Ләкин моннан соң аяк атлау да авыр буласын тойды. Әүвәл җилләр әллә бар, әллә юк иде. Хәзер аңа җилнең арттан искәне генә юлдаш икән инде.

Әйе, гомер кими башлаган. Күңеленә килгән уе — киләчәктә үзен ни көтсә дә, карышуның инде мәгънәсезлеге, шуңа күрә һәр нәрсәгә тыныч кына әзерләнү кирәклеге белән килешеп:

— Яхшы,— диде.

Кызы аңа, үзенекен уйлап:

— Яхшы, әти, яхшы,— дип җавап бирде.

Соңгы баскычта тукталып, ул көннең, шәһәр күренешләренең матурлыгына карап торды. Асфальт мәйданчыкка су сиптергәннәр, аның дымлы җылысы биткә ягыла. Кыска гына калдырып чабылган үләннәрдә, саф, кытыршы яфраклы яран гөлләренең ал, кызыл чәчәкләрендә су тамчылары җемелди. Чәчәктән чәчәккә ялгыз бал корты кунып йөри, түгәрәк гөл түтәлен әйләндереп алган юеш таш буйлап сары кырмыска йөгерә.

Җиләс һава больница исе сеңгән кыска чал чәчен, битен яратып сыйпый кебек. Бу яктылык, бу ямьлелек элек тә булгандыр ич инде? Ә менә күреп җиткермәгән бугай. һәр язны шау чәчәккә күмелгән өе каршындагы шомырт, канәфер кичке һавага хуш ис тараткандыр. Ул әлеге исне хәтерләргә тырышты. Кая анда! Иген бөртеге көтеп, күпереп, сулап яткан юеш туфрак, техника мае, яңа борнап чыккан яшел уҗым, өлгереп килгән башак исе, бодай бөртекләренең сөтле сагыз тәме яхшы таныш. Хәзер инде аларга төрле дару исләре, дару тәмнәре дә өстәлде. Калганнарын тоярга вакыты җитмәде шул. Сугышта танкысында берәр исемсез биеклеккә таба ыргылырга яисә җимерек авылга тизрәк бәреп керергә ашыга иде. Аннан соң әле бу басуны, әле теге басуны тизрәк сөреп бетерергә, өйләнергә, яңа өен салып керергә, балаларын аякка

бастырырга омтылды... Тора-бара тормыш җиңеләйгәч, артка борылып карарга да, киләчәккә омтылырга да курка башлады инде. Аңа юаныч биргән бер генә нәрсә калган шикелле иде: кешеләр муллыкка, җитеш-леккә тизрәк ирешсеннәр өчен көн диме, төн диме эшләде. Хәзер менә больницадан чыгып килә һәм бөтенләйгә, монда башка беркайчан да килмәслеген белеп чыгып килә.

Кызының:

— Әйдә, әти,— дигәненә сискәнеп, үзеннән-үзе уңайсызланып китте. Карале син аны, әллә ниләр уйлап, башын кыңгыр салып басып тора икән ләбаса. Кызы белән янәшә озын, тар, кешесез урам буйлап атлаганда, үзендәге чит халаткә аптырап барды. Трамвай, троллейбус, автобус, төрле машиналар һәм кеше хәрәкәте белән тулган киң урамга килеп чыккач, такси тота алмыйча әрле-бирле йөгергәләгән кызына, җәяүлеләргә күз салгалап торганда ул калган бәхетенең шушы хәрәкәт дәртендә, кызының аны кайгыртуында, өйдәгеләрнең аны көтүендә икәнен уйлады.

Шәһәр һавасы әүвәлгечә авыр тоелмады, ул аның җанына, үз тракторы, үзе сукалаган басулар исе кебек үк, кадерле иде инде.

Бераз узып туктаган такси яныннан кызы елмаеп кул изәде. Автовокзалга барып җитеп, авылларына кайтучы автобусның йомшак утыргычына кереп сеңгәнче, Сөнгатулла эндәшмәде.

Кызы нидер сөйләде, сораштырды, аның кулын сыйпаштыргалады, атасының тыңламаганын аңлап, башын биек утыргыч аркасына терәп, күзен йомды.

Автобус тәрәзәсеннән урамда әле тегеләй, әле болай баручы, нәрсәдер күтәргән, каядыр ашыгучы кешеләр чагылып калды. Ә аңа ашыгырга кирәкми, ул беркая да соңламый инде. Фәкать көтәсе генә.

Автобус бөркүләнде, өске люклардан искән үтәли җил хәлне җиңеләйтмәде. Чайкалу оета иде. Ялкау гына сөйләшкәләп барган кешеләр бераздан һәммәсе диярлек изерәп бетте. Калка төшеп, Сөнгатулла тәрәзәнең өске өлгесен ябып куйды, тәрәзә пәрдәләрен сары ялкын игеп биеткән җиләс һава тынды. Шакмаклы күлмәк изүенең ике сәдәфен ычкындырды, челтәрле капрон эшләпәсен, пинжәген салып, тезенә куйды. Шунда эчендәге авырту уянды. Кызына сиздермәскә тырышып, пинжәгенең күкрәк кесәсеннән зәңгәр төймә даруын алып капты. Тәрәзәгә борылып, күзен йомган килеш, авыртуның басылганын көтте. Күзен ачса, ян-якта озын дулкыннар булып тибрәлгән арыш басуы буеннан баралар икән. Бераздан ямь-яшел бодай җире башланды. Былтыр эссе августта үзе сукалап, чәчеп калдырган басуларда да иген шаулыйдыр. Быел шуны җыя алыр микән? Әйе, вакыт үтә, син булсаң да үтә, син булмасаң да... «Мин булмасам да?!» Бу хакта гомерендә икенче тапкыр уйлаганын искәрде ул. Беренче мәртәбә 1944 елда. Ниндидер авылдан немецларны бәреп чыгарыр өчен барган рәхимсез сугышта җиңелчә генә яраланды. Фашист пулясы аны ут капкан танк эченнән яралы укчы-радистны чыгарганда куырып алды. Икенчесе җиргә төшкәч өтте. Иптәшен комлы үрдән түбән сөйрәгәндә, бер өлкән яшьтәге санитарга юлыкканчы, ярасын карый алмады. Өстәмә көчләр ярдәмендә, авылны алгач кына ауды. Җиңел җәрәхәт озак та үтми азгын ярага әйләнде, каны агуланды. Башта чокыр-чакырлы пычрак юлдан полуторкада, аннары хәтсез көннәр һәм төннәр поездда бардылар. Вагон ыңгырашкан, теш кысып сүгенгән, саташкан яралылар белән тулы иде. Үзен чолгап алган әле соры томаннан, әле төпсез караңгылыктан айнып, күзен ачкалаганда, корымлы морҗалары гына тырпаеп калган авыллар, зәңгәр күк йөзе, каршы юлдагы вагон ишегеннән аякларын салындырып утырган солдатлар, яшәреп килгән урман тәрәзәдән күренгәләп калды.

Түбән Түрә дигән шәһәрчек госпиталендә ярты елдан артык аунады. Тереләсенә врачлар үзләре дә ышанмады бугай. Ә ул терелде, савыкты. Җиңәсе, дошман җимергәнне, яндырганны, көл иткәнне төзисе, сала-

сы бар иде. Кырлар,— хатын-кызның көчсез кулыннан кыргыйланып беткән кырлар — көтә иде ич аны. «Сөнгатулла, жаныем», дип эндәшүче коңгырт күзле Зөлхиҗәсе дә көтә...

Ул сугышка кырык өченче елның кара көзендә, сугышның ачысын йөрәгенә үткәнче татып бетергәч алынды. Үзендә плугар булып йөргән Сәгыйдәгә иренең үлгән хәбәре килгән көнне. Сәгыйдә майлы, пычрак сырмасын салып ыргытты да кап-кара туфраклы юеш буразнага ятып, өзгәләнә-өзгәләнә елады. Кып-кызыл күлмәк итәге күтәрелеп, балык тәңкәседәй ап-ак ботлары буразнага сыя алмыйча бәргәләнде. Кичкырын иде. Сөнгатулла чыдый алмыйча, тракторына утырды да ары китте, борылып караганда Сәгыйдә җансыз басу уртасында учактай дөрләп янып ята иде шикелле.

Ул сугышка дошманнан ни өчен, кем өчен үч алырга икәнен яхшы белеп китте. Күрше Мәһируза апаның ире һәм аларның дүрт кызы, укытучы Асия апа, Гарифә әби, Сибгатулла абзый, сугышта сөйгәненең һәлак булу хәбәре килгәч, акылга җиңеләеп калган кыз — авыл чибәре Диләрә өчен, үсеп килүче, искергән бишмәтле, чабаталы, ямау салган итекле, ябык, моңсу ятимнәр үчен алырга, кулсыз-аяксыз калса да, дошманның бугазын теше белән чәйнәргә әзер иде ул. Авылга йөз егерме тугыз кара кайгы кәгазе килгән иде инде. Унсигез яшен ул шуның белән тутырды.

Сөнгатулла сугыштан киң җилкәле ир-егет булып, калын муен үстереп, бер орден һәм өч медаль, исеме язылган көмеш кесә сәгате тагып, күңеленә сугышның бар шәфкатьсезлеген, әшәкелеген, пычрагын, хәсрәтен җыеп, җаны картаеп кайтып керде. Аны өч-дүрт колхозга бер булган иске тракторга утырттылар...

Сугышта алган яра төзәлде, аннан чокырлы җөй генә калды. Ә хәзерге авыруы бөтән. Бөтән... Каян килде соң ул аңа?

...Былтыр язгы чәчү иртә, майның уртасында ук бетте. Шул уңайдан идарә алдынгы колхозчыларга акчалата премия бирде, механизаторларны, шомырт шау чәчәккә күмелгән чокыр буена алып чыгып, мулдан сыйлады. Сөнгатулла да күңеле булганчы утырды. Өй бусагасын атлап кергәч, утлы кисәү баскан шикелле, кискен авыртудан аңын югалта язып, ишек төбенә урталай бөгелеп төште. «Эчмәсләр, үзең теләп алган чир, рәхәтлән»,— дип сукранып, хатыны зур якның чаршау корган почмагындагы караватка — оныгы янына кереп ятты. Таң беленгәч, аның теш кысып, иренен тешләп ыңгырашуына куркып, югары очтан фельдшер кызны уятып алып төште хатыны. Ул чагында авыртуы узган шикелле булды, ә Яңа ел алдыннан тагын килеп чыкты.

Сөнгатулла Казан больницасында үзенә ясалган операциянең шикле төстә тиз узуын сизде. Врачлар да, үзе белән бер палатада ятучылар да, көн саен диярлек килеп йөргән, ә менә нәкъ операция көнендә күренмәгән кызы Мәрзия дә аны-моны сиздермәскә тырыштылар. Ә читләтеп сорашырга, белешергә теләмәде.

Соңгы вакытта ул каршыдагы җиденче палатада ятучы Галия исемле кыз янына кереп утыргалады. Кара чәчләренә караганда аклары күбрәк иде аның. Гаҗәп тә, сәер дә иде. Сул кулын икенче тапкыр кисканнәр. Сыкранмыйча әйләнеп тә ята алмый. Туймас авыруы тәненә, сөякләренә күчкән, диделәр.

«Минем белән дәвалана башлаганнар үлеп бетте инде, абый. Алардан соң дүрт ел торам инде. Барыбер үләсем килми бит әле. Утырып кына торырлык булып терелсәм дә, врачларга рәхмәтләр укыр идем». Ул моңсу елмаеп сөйләшә иде. Галия янына шприц тотып еш керәләр иде инде. Тик Сөнгатулла аның елаганын күрмәде. Галия яныннан:

— Теге кыз, аллага шөкер, бүген исән әле,— дип чыга иде.

Галия ул больницадан чыгарга өч көн кала иртән, авырулар ашаган-эчкән чагында әкрен генә вафат булды. Йөзе бөтен газапларыннан котылып елмайган, тыныч иде.

Кояш күтәрелгән саен, керәшәләренең очуы түбәнәйде, суга табарак якынайды. Алар ояларына югарыдан юнәлмичә, астан күтәрелә башладылар. Сөнгатулла: «Әйе, көн эссе, коры булыр»,— дип уйлады. Ул, үрелә төшеп, кул астындагы сары чәчәкне өзде дә, сабагын папирос шикелле тотып, иренено кыстырды. Әчкелт тәме тел очын чәнечте. Иреннәннән алып, ул сабак очына карады. Көпшәнең өзелгән урыны тирәли сөт саркып чыккан иде.

Больницадан кайткан чакта автобустан төшеп, сары чәчәкләр үскән юл читенә утырасы килде аның. Өйгә кайтудан һәм җир катылыгын, ышанычын тоюдан да яхшырак нәрсә юктыр. Хәер, монда утырудан мәгънә юк. Ике якта да урман, колач җитмәслек имәннәр шыкырдап тора. Кабыклары купкан, ертык чүпрәкләрдәй салынып төшкән, ботаклары сынык. Дүрт ел элгәре керәшен суыкларында корыдылар. Хәзер аларны кисәләр, әллә ничә җирдә моторлы пычкыларның күксел төтеннәре күренә, киселгән агачларны юл читенә әрдәнәләп өйгәннәр, зур учакларда ботак-сатак яна. Куаклар арасында ара-тирә каеннар агарып кала, алар сыгылып бөгелгән, моңсу, кай якка авышсалар да, ялгызлыкка дучарлар. Юкәлекләр дә нурсыз, араларындагы имәннәрне аударганда, аннары тракторларга сөйрәткәндә имгәткәннәр.

Ә чистарткан урыннарга нарат үсентеләре утыртканнар икән. Тернәкләнеп киткәннәр, яшел үлән арасыннан посып кына алтын бөреләрен тӧрткәннәр. Аларны юлдан ике буй киртә белән аерганнар. «Керү тыела», дигән язулы такта кадаклаганнар.

Түбән төшеп, автобус күпергә керде. Урман, корыган имәннәре белән сырхаулап һәм яшь наратлары белән яшәреп, артта калды.

Дөнья үзгәрә. Дөресрәге, үзгәргән. Шул үзгәргән өлеше генә Сөнгатулланыкы. Үзгәрә торганы һәм үзгәрәчәге бүтәннәргә кала. Дөньяның үзгәрә торган өлешен китүчеләр түгел, яшәүне дәвам итүчеләр генә күрә...

Шушыларны яңадан күңеленнән кичереп, Сөнгатулла яр буенда утырды да утырды. Бирелә бар нәрсә элеккечә. Суы ага, ә яр тора. Аның менә бу җире убылып төшәсен Сөнгатулла гына белә. Үзе шуның өстендә утырганга гына. Аның ярдан тар ярык белән аерылганын күргәнгә генә.

Иң зур, иң әкәмәт, иң шаккатыргыч, иң өнсез иткән үзгәреш аны авылында көткән икән.

Авылдан ярты чакрым чамасы ераклыктагы юлның тукталышында автобустан төшеп калдылар. Сөнгатулланың урам буйлап кайтасы килмәде. Исәнләшүләр, хәл-әхвәл сорашулар китәр инде. Кызы нәкъ шуны тели иде булса кирәк. Атасын кешеләр белән сөйләштерәсе, уйларыннан арындырасы, кешеләрнең хуплау сүзләре белән каефен күтәрәсе киләдер. Тик ул үзен авылдашларына күрсәтүдән тайчанды. Ни дисәң дә, ул элеккеге Сөнгатулла түгел шул инде. Кыяфәтенә ятсынып багарлар, күзенә туры карамаска тырышырлар, өйләренә кайткач, кызганып сөйләрләр. Башта хәл алырга кирәк. Өй һавасы, өй ризыгы килешми калмас. Хуҗалык эшләре онытырмасмы әле. Рәт керсен.

Шуңа күрә ул кызына:

— Турыдан кайтыйк,— диде.

Ихтимал, кызы аны тракторлар янына сугылып чыгарга, хезмәттәшләре белән күрешергә тели дип уйлап барадыр. Аларның өйләренә туры юл колхозның ындыр табагы, техника паркы, яшелчә бакчасы яныннан, елга аша салынган асылмалы басмадан, зират буендагы тугайдан уза. Аннары, зират белән бәрәңге бакчасы арасындагы ызаннан үтеп, арт капканы ачасы да, яссы ташлар җәелгән ишегалдына керәсе. Сөнгатулланың өйдән техника паркына кадәр ел тәүлеге эшкә йөри торган үз сукмагы бар.

Ул мастерскойга сугылмады. Әнә электр очкыннары. Шәт, улы Мусадыр, ул эретеп ябыштыру остасы. Эшләп тә күрсәтә ичмаса. Аһ, тагын әнә тимер чүкегән тавыш. Бусы — тимерче Баһау. Янына керсәң, потлы чүкечен кулыннан төшермәстән күтәреп ала да сандалга утырта инде. Ә һәйкәл итеп куелган «ЧТЗ»га былтыргы тургай оя корды микән? Мәңгелеккә тынган, ләкин күгәрмәгән ул трактор, пулеметка каршы барганда киселеп егылгач тезләнгән, соңгы сулышын алганда бармак очлары белән җиргә таянган сугышчы кебек, тимер тырнакларын кара туфракка батырып, әрем уртасында тора. Ә тургай оясы аның кайнар йөрәге иде шикелле.

Елга буена җиткәч, ул яр читенә чүкте, кулын, битен юды. Су җылымса, йомшак.

Шунда Мәрзия:

— Әти,— диде. Ике төенчеген дә басмага куйган, култыксага җайлап таянган. Сүзе бар иде, күрәсең.

— Әү, кызым.

— Сиңа әйтәсе сүз бар иде бит әле.

— Сон?

Су агымына карагач, Сөнгатулланың җиңелчә генә башы әйләнде.

— Муса абый өй түбәсен яңадан япты, әти.

— Ник?

— Ник дип... Хәзергесе ак — цинк калае.

— Кара, хуҗа булган, ә? Иркенләгән! Минем больницада ятуым ярамаган.

— Баз да бүтән — кирпечтән.

— Тиясе калмаган. Кирпич дым тарта ул.

— Кирпеченә сумала кайнатып сылады. Бер очтан — нигезне дә.

— Нигезне? Аның кай җире ярамаган тагын?

— Борчылма, әти. Хәзер нигез дә кирпечтән.

— Чә!

Үтә гаҗәпләнгәндә Сөнгатулла, шулай, «Чә!» дия иде. Бу аның ишеткән сүз мәгънәсенә төшенеп җитмәвен белдерә. Бу әле аның, сәерсенеп, колагын сагайтуы гына. Ишетте, янәмәсе, тик ни соң әле бу? Кабатлап әйтергә кирәк: әйе, бу аның үтә гаҗәпләнүе, ни дияргә белмичә, чак кына телсез калуы. Аныңча, язын бәрәңге базына су төшсә дә «Чә!». Кырык өч яшенә җитеп, хатын-кыз күрмәгән Сәлимҗан көтмәгәндә өйләнгәч тә «Чә!». Тупыл төбенә карга баласы егылып төшсә дә. Шуннан соң, яңа ишеткән хәбәргә күнеленнән тиешле бәясен биргәч, аның «Инде!» дип куя торган гадәте бар. Яңа нигез корыр өчен өйне җирдән күпме күтәрергә кирәклеген күз алдына китергәч, ул кызына:

— Инде!— дип, башын чайкады.

Мәрзия тавышын һич үзгәртмичә:

— Тәрәзә йөзлекләрен буямаган әле,— дип дәвам итте.

— Нинди тәрәзә йөзлеге ди ул?! Кычытмаган җирне кашып... Хәзер печән хәстәрен күрергә кирәк. Бигрәк тагын!

— Дөрес, әти. Тәрәзә йөзлеге качмас. Муса абыйны әйтәм: бигрәк җенле булып чыкты ул. Теңкәгә тиеп бетте: тук та тук өй мүкләп, йокы бирми.

— Мүкләп? Мин мүкләгән эченә тигәнмени?

— Авыз да ачтырмый, әти. Үзган юлы кайтканда балчык изеп аяк калмады. Үзенең бетон болгаткыч машинасы капка төбендә. Ярамый, янәсе! Имеш, мич измәсенә аяк-кул җылысы тияргә тиеш.

— Мич?! Инде дә, ә? Барлы-җуклы ярты ел югалып тору ярамаган! Мич булып мичнең башына җиткән... Миннән шәп тартып калды лабаса.

— Бусы да тамаша: бик яхшы тарта.

— Син, кызым, түбәдән нигезгә төштең, инде өйгә сыймыйсың.

— Ә матча матча ише генә түгел, әти. Күрсәң, исең-акылың китәр — сап-сары нарат.

«Янганнар бит болар, каһәр!— дип уйлады Сөнгатулла. Ләкин аңлаганын кызына белдерәсе килмәде әле.— Әйтмәгәннәр. Борчылып ятмасын, дигәннәр инде, мать честна!»

Су бөтерелеп-бөтерелеп ага иде. Аның күз аллары караңгыланып китте. Якты көнне болыт бастымыни. Колагы томаланды, әйтерсең лә, су астында калды. Аягының җегәре бетте. Кайтып җитәр, үзе каккан салкынча келәләрдә, тотка тимерләрендә учының җылысын калдыра-калдыра ишекләрне ачар, бусагалардан сак кына атлап, түшәм такталарының һәр сызыгын, һәр рәсемен карамаса да, күреп өй эченә узар һәм тыйнак кына, бәлки бераз ятсыныптыр, имән матча астында хатыны Зөлхиҗә белән күрешер кебек иде югыйсә. Кинәт ул үзен икегә бүленгәндәй хис итте. Күзгә каршына басса, үз чагылышы урынына гомер очрамаган кеше чагылышын күрер кебек. Ул чагылыш лачыннныкыдай үткер карашы белән больницадагы чатнаган көзгедән әллә ничә тапкыр аның йөрәген тырнап-тырнап алды инде. Кайсысы чын — шул көзгедәге керәшә ояларыдай эчкә баткан күзле шәүләме, әллә ул — Сөнгатулла үземе? Яңа йортта да торыр анысы. Аягы яңа баскычларга, ишек бусагаларына, кулы электр кабызгычларына, ишек тоткаларына күнегер, үз кадакларын кагар, такта ышкылар, яңа мичкә утын ягар, үз ашын ашар. Җайлашыр. Ләкин ялгыш өйгә очып кергән һәм тәрәзәгә һава дип бәргәләнгән кош шикелле, нишләсә дә, чиксез авырту гына тояр инде. Кызы әнә сөйли дә сөйли. Тавышы ерак, җил китергәндәй, өзек-өзек, әле ачык, әле тонык ишетелә. Гүя шәһәр кибетләре тәрәзәседәй зур, калын пыяла аша эндәшә.

— Идән... буяу... авыр... Казанда әле. Болай да матур, якты. Түшәмне Муса абый... Караватлар яңа... Кухняда гарнитур... Без төсле телевизор... кредитка. Искесен ирем сезгә кайтарып куйды. Күрше-күлән... савыт-саба... Җитәрлек. Орденнарыңны күрше Хаммат абый алып чыгарга өлгергән. Әни шунысына бик сөенде. Костюм-чалбар... әни үзе алды... таман...

Юк шул инде, таман булмас. Ябыкты Сөнгатулла. Ә кием-салымының буе тамандыр. Зөлхиҗә тазарыр дигән өметкә алдангандыр инде. Киемне аны балага гына үсәренә чамалабрак алалар.

Әх, Мәрзия!.. Юата инде бичаракай. Хәзерләп куя, янәмәсе. Атасының йөрәге ярылыр ди бугай.

Сөнгатулла тураеп басты да кычкырып көлеп җибәрде. Кызының сөйләвеннән кырт киселеп, сискәнүен, үзенә коты алынып каравын күреп тынды, тик чыдый алмыйча, гөлдерек тавышы белән элеккесеннән дә катырак итеп, рәхәтләнеп, башын чайкый-чайкый көлде.

— Әйттем бит мин аңа, кызым!

— Нәрсә-нәрсә?

— Әнкәңә дим.

— Нәрсә әйттең?

— Больниска бер килүендә страхавайның тиешлесен генә түлим, өйдә акча юк, дип кәҗәләнгән иде. Ирекле өлешен дә уч тутырып түләмәсәң, кара аны, фәлән-төгән дип җибәрдем. Шулай итмәсәң, палатага аяк атлыйсы түгел, мәйтәм. Икенче килүендә тагын түләмәгән, хәерсез. Коры калган алайса!

— Түләде, эти, түләде.

Сөнгатулланың әле генә көлгән, аннары кырысланган йөзенә канәгатьләнү төсмере чыкты. Җиңел сулап:

— Алайса, ярый,— диде.— Яндыгыз инде, ә? Дипломат икәнсең син, кызым. Белми идем. Яман хәбәргә яхшы хәзерләдең син мине... Күпме тиде соң?

— Нәрсә?

— Нәрсә булсын — страхавай.

— Биш мең.

— Әйбә-әт.



Алсу Тимергалина рәсеме.

— Колхоз булышмаса, ул биш мең генә чәп итәргә дә житмисе икән, эти.

— Нәфсе дисәң дә нәфсе соң хәзер кешедә... Биш меңгә таш пулат салып була! Кассада да ару гына үрчегән иде түгелме соң?

— Анысы да кереп бетте аның, эти.

Сөнгатулла тагын:

— Чә!— диде.— Инде дә шул хәтле кыланмасагыз...

— Бераз әҗәткә дә җыйгач, таман гына булды бугай.

— Әҗәт?!

— Әйе. Нигә?

«Әллә каккан казыкка тиклем янганнар инде?» Сөнгатулла, күңелендә уянган шушы шиге белән килешәсе килмичә, шул ук вакытта, кинәт әрләп ташлап, я ялгыш сүгенеп, кызын куркытмас, рәнҗетмәс өчен, тыштан тыныч кына:

— Зурдан купкансыз түгелме соң?—дип сорады.

— Зурдан дип... Ә абзар-кура?

— Абзар-кура?!

— Әйе, эти. Анысы да өр-яңа. Өй белән берочтан анысын да өр-яңадан корып ташладылар. Нигә калдырып торырга? Келәтне сиплисе бар дип, үзең дә әсканган идең, анысын да элеккесе өше генә итмәделәр — ындыр табагына тиң итеп салдылар.

— Кызым! Мәрзия!... Алайса, шыр ялангач калганбыз түгелме соң?

— Нинди шыр ялангач?.. Нинди шыр ялангач! Ул яңа мунчасы гына да ни тора! Син салган усак кына иде, мүк урынына да — салам. Бусы — нарат, кызлар чәче шикелле сап-сары сүс белән мүкләнгән.

— Мунча да көл булып очтымыни?

— Көл дип инде... Көлләрен, кисәү башларын, мотоцикл калдыкларын, өч алмагачны янгынның икенче көнендә үк бульдозер белән кырып-себереп, иске тегермән чокырына түктеләр.

Сөнгатулланың елап җибәрәселәре килде.

— Берни дә калмадымыни?

— Өскә кигән кием дә сабан туе мәйданына утырып чыккан «Жигули» инде. Әле ярый янгын сабан туе көненә туры килде. Көрәшчеләр батырга чыгуга — пожар. Бөтен мәйдан чапты. Ул җыелган халык, эти, ул халык! Хәйран-тамаша!

— Сөнгатулла Тимершиннең йорт-җире көлгә әйләнүен бөтен авыл җыйнаулашып тамаша кылуы хәйран булмыйни!

— Ни, эти, карап тормадылар.

— Тормаганнармы соң? Теш казырлык шырпы калмагач?!

— Алар башка өйләрне уттан саклады. Очыбыз белән янабыз дип курыккан идек.

— Ә Муса, каз сөзгән нәрсә? Муса нишләде? Бастырык буе гәүдәсе белән бер сандык та чыгармагач, Тимершин фамилиясен йөртүе харам!

— Ул мәйданда көрәшеп калды шул.

Җан ачуы белән сүгенәсе килүен басар өчен, Сөнгатулла бу юлы «Чә!» дип кенә калмады. Бу юлы ул:

— Кит әле! — диде.— Йорт-җире яна, ә ул көрәшеп калдымы? Кайтып та тормадымыни?

— Кайтты, ник кайтмасын ди. «Жигули» еның арткы утыргычына батыр калганы өчен алган биш йөзлек паласны җәйгән дә шуның өстенә дүрт пот ярымлы тәкә бәйләп салган.

— Ничек инде ул — бар халык янгынга чапкан, ә Муса бил алышып ятканмы?

— Кызык инде, эти, әйеме? — диде Мәрзия, көлгәндәй итеп.

— Бу хәтле дә үземә охшар икән, билләһи газим!

— Чат инде, эти, чат! Көрәш судьясы Гамбәр абзый да шаклар катты. «Без монда пожар сүндерәбез, ә батырны кем билгеләгән? Әйдәгез,

яңадан! Көрәштә мин судьямы, әллә Пушкинмы?»— диде.

— Хак әйткән.

— Абый: «Дөньяда ут чыкканда татар көрәшендә саф намустан да гаделрәк судья юк»,— дип кырт кисте.

— Ул да шәп әйткән ләбаса, шайтан!

Улының бу сүзләрен үзенең чуалчык хәтере җуймасын дигәндәй, Сөнгатулла эчтән генә:

«Дөньяда ут чыкканда татар көрәшендә саф намустан да гаделрәк судья юк»,— дип кабатлады. Йөрәк түрендә үлгәнче тотардай яхшы сүзләр. Улының сүзләре аның борчуларын, дулкынлануын баскандай итте. Су өстеннән чагылган нурлар һәм талгын җил битен, чигә чәчен, беләкләрен киптерде.

— Шуннан? — дип сорады ул.

Мәрзия:

— Шуннан... менә шул инде — яндык. Хәзер бар нәрсә яңа,— диде.

— Яхшы,— диде Сөнгатулла.— Кайтыйк, кызым.

— Кайтыйк, әти.

Сугыштан кайткач, бер кичне — тугыз тулып, чирек сәгать үткәндә Сөнгатулла капка төбендәге ташка чыгып утырган иде. Ул ташны яңа өйнең өрлеге астына почмакка салырга ниятләгән иде. Әйе, нәкъ шул вакытта. Чөнки көмеш сәгатен ачып караганы исендә. (Көмеш сәгать — комкор Рыбалко бүләге. Тора-бара ул сәгатьнең кирәге дә калмады кебек: авылда көндез дә, томанлы таңнарда да күз төшкән нәрсәләрдән, колак ишеткән тавышлардан вакытны минутлап беләсең). Шулай итеп, ул капка төбендәге ташка чыгып утырды. Һава йомшак. Ни җылымса, ни салкынча. Китапларда тәнгә рәхәт дип язалар. Эч пошмаганда, кәеф яхшы булганда шулайдыр. Көнбатыш матур алланып, көнчыгыш тыныч шәмәхәләнеп торганда бигрәк тә. Куе чиялектә өздереп сандугач сайрый, уенлыктан гармун тавышы, кызлар белән егетләрнең җырлавы ишетелә. (Ул чагында кичләрен җыелалар иде әле.) Ә боларга игътибар итмичә, күк йөзенә уйсыз гына карап торсаң һәм йолдызлар кимегән кебек тоелса? Андый чакта һава хозурлыгына ис китми шул. Әйе, ул кичне йолдызлар сугышта үлеп калган авылдашлары санынча кимегән сыман тоелды аңа. Җирдә солдат үлгән саен, йолдыз атылып юкка чыккандыр, ә яңалары балкырга өлгермәгән иде әле.

Аннары мәшәкать өстенә мәшәкать өелде. Эш күп хәсрәтне каплады, күңел яраларын төзәтте. Әкренләп кеше рәтенә керделәр. Рәхәт тормыш китте! Хезмәт көннәренә түләү артты. Тора-бара берәм-берәм өйгә телевизор, газ, суыткыч керде, идәнгә палас җәелде, стенага келәм эленде. Элек, сугыштан соңгы еллардагы сирәк-мирәк мәҗлесләрдә, туйларда, сабан туе бәйрәмнәрендә аз гына куела торган әче балның дәрәҗәсе бетте. Аракы күренә башлады. Аны шахталарга, чирәм-җирләргә китеп, туган якларына кунакка кайтучылар кунак-төшемгә дәшкәндә зур көчтәнәч итеп кенә куя иде. Аннары исә аракы табынның түренә үк менеп утырды, өстәлнең күркенә әйләнде.

Заманалар үзгәрде... Техника күбәйде. Комбайннар кырда сыер көтүе урынына йөри. Бөтен җирдә трактор. Бер хәбәрче Сөнгатулла турында: «Ул сукалаган җир Франция, Бельгия, Люксембурглар мәйданына тигез»,— дип язып чыкты. Нигә, бик ихтимал. Кайбер җәйләрне буада ник бер су коенып карасын. Әле ярый дөньяга ат булып яратылмаган — әллә кайчан аяк сузар иде! Ба! Камыт киясе булса, аңа чыдардае табылыр иде микән? Элек уңышы алты-җиде центнердан артмаган гектарлардан егермешәрне ала башладылар. Шунысы бар: туклыкка әллә ни ис китмәде. Күңелдә дә соң, каһәр! Әүвәл колхозның егерме бишләп баш дуңгызы булып, шулар бөтен яр буе болынын актара, кичү ташларын кубарып бетерәләр иде. Хәзер алар биш меңнән артык, комплекста гына торалар. Тик исләре бар дөньяны тутыра: сыек тиресләре

базларыннан ташып, инешкә агып төшә, ташлыкларга ләм булып ята. Су буен камыш басты. Колхозга да, председательнең үзенә дә шушының өчен ничә тапкыр штраф салдылар. Хәл үзгәрмәде. Аның караве түбәндәге рус авылында сыерлар комплексы. Соң инде, җәмәгать, татар кешесе гомер яратмаган дуңгызны күңел биреп карыймы соң? Монысын Сөнгатулла болай гына уйлады, сүз уңаеннан гына. Әйе, тормыш яхшы, күз генә тимәсен. Бер генә мисал: зиратта мәрхүмнәрне күмешкән өчен бирелгән хәер акчасы бишәр сумнан арта. Нәкъ бер шешәгә җитәрлек. Өчкә бөкләп, пистун кесәсенә тыгалар да кибет тарафына китәләр. Татарда мәрхүмне күмү табыны юклыгы билгеле, элек мәет өстендә аракы эчмиләр иде. Ләкин ул бишлекне кая куймак кирәк? Килешәме, килешмиме — сәүдә әйләнешенә кертәләр.

Менә нишләде замана. Кешеләр, әйтерсең, тормыш муллыгында югалып калдылар.

Сәрхүшлек ирләрне куе томан кебек басты. Эш башланганчы да салу, эш беткәч тә эчү. Шатлыктан да, кайгыдан да. Гаҗәп. Кесәдә акча тормый. Шунысы кызык: саклык кенәгәләрендә дә үрчи. Гүя авыллар буенча дәрвиш рәвешендә Хозыр-Ильяс пәйгамбәр үткән дә кешеләргә хәзинә базларын ачып калдырган. Борынгыдан акча белән эш итмәгән җир кешесе аның муллыгына әзер түгел һәм аңа күнегүе җиңелдән булмады. Ни гомер бушка диярлек эшләгән халык бер буын гомерендә тотрыклы хезмәт хакы ала башлады.

Ләкин хикмәт монда түгел. Яшәү тыштан гына җиңел. Асылы шул ук: һәр рәхәтнең каршы ягында хәсрәте бар. Крестьян хезмәте башлыча маңгай тире һәм җан канавыннан гыйбарәт. Бусы үзгәрмәде...

Ярый, яндылар. Ярый, көлен, күмерен кырып-себереп түккәннәр дә элеккесеннән дә яхшырак йорт-җир салып кергәннәр, мал-мөлкәт җиткезгәннәр. Шуннан? Көр кәеф, моң-зарсыз гына тоташ тынычлыкта яшәтәмени ул сине? Шуннан нәрсә? Шуннан...

Җирдән ялгыз болыт күләгәсе шуып үтте. Керәшәләрнең тавышы тынып торды. Ә очышларын үзгәртмәделәр. Ак болытны озатып калгач, Сөнгатулла учлары белән ике ягындагы үләннәрне сыйпады — әйтерсең лә, шулай итеп уйларын тәртипкә салырга теләде.

Әйе, шуннан... Шуннан ул басмага керде. Үзен көтеп торган кызы Мәрзиягә:

— Рәхмәт, кызым,— диде.

— Ярар инде, эти, ул хәтле нитмә... әрләмә безне. Үз-үзеңне дә бик бетәштермә.

— Мин бүтәнне әйтәм,— диде ул.

— Нәрсәне?

Басма аслы-өсле тирбәлә, атлап керүе читен. Мәрзия ике төенне дә бер кулына тоткан, буш кулын, аңа ярдәм итәргә әзерләнгәндәй, чак кына алга сузып тора.

— Больницада әйтсәң, әллә ничек...— диде кызы, атасының ни өчен рәхмәт әйтүенә төшенеп.— Әле болай да...

— Аңа гына чыдыйм әле мин, кызым. Бер елга куян тиресе дә чыдаган.

Бая йорт януын курка-курка гына сөйләсә дә, көләргә, шаяртырга көч тапкан кызының күзләре мөлдерәмә яшь белән тулып ялтырады. Елап җибәрмәс өчен ул тирән сулыш алды һәм аскы иренен тешләде дә кайтыр якка борылды. Ул тагын нәрсәнедер әйтеп бетермәгән кебек тоелды Сөнгатуллага.

Ярга менеп җиткәч, Сөнгатулла зират астындагы болын, койма, бәрәңге бакчасы аша йорт-җирен күзләде. Абзар-кура, яшел калай түбәле өйләре, мунчалары урынындагы корылмалар аңа бөтенләй таныш түгел иде. Бура почмаклары, түбә кыеклары, койма сызыклары аңа

бозылып, кушылып, агарып күренделәр — Сөнгатулланың күзе яшьләнде.

Өйләренә кадәр калган араны ул аяк астына гына карап узды. Такыр сукмакның әллә ничә төшендә кырмыскаларның нәзек кара чылбыры шуыша. Ул аларга да, суалчаннар чыгарган балчык өемнәренә дә басмаска тырышты.

— Әнә әни карап тора,— диде Мәрзия.

Сөнгатулла якты абзарның караңгы тәрәзәсендә таныш йөзне күреп алды. Зөлхиҗә. Аннары ул юкка чыкты. Зөлхиҗә аларны читкәрәк салынган мунча белән келәт арасындагы койма капкасын ачып каршылады.

— Сөнгатулла,— диде Зөлхиҗә. Әйтерсең лә Сөнгатулланы фәкать хәзер генә таныган, аның үз алдында икәненә хәзер генә ышанган.

— Нихәл сүң? — дип эндәште Сөнгатулла һәм капка баганасына тотынды.

Мәрзия тоткарланмады:

— Исәнме, әни,— дип эчкәре узды.

— Кайтып та җиттегезме? — диде Зөлхиҗә һәм Сөнгатулла тотынган баганага кулын куйды да Мәрзиягә:— Самавыр куя тор, кызым,— диде.

— Ярар, әни.

Мәрзия, келәт почмагыннан борылганда, аларга әйләнеп карады.

— Ярый,— диде Сөнгатулла. Ул ишегалдын тутырган көек һәм нарат чәереннең күпмедер вакыт җилләр дә тарата, яңгыр да юа алмаслык исен тойды. Янгын эзе байтак торыр. Янган капка баганаларының җирдәге көйгән төпләре берәр казу эшендә килеп чыгыпмы, туфрактан эрегән кашык, чынаяк китеге табылыпмы — үзен искә төшерер. Җир кеше эзен тиз тигезләсә дә, хәсрәтен озак саклый.

Зөлхиҗәияк астыннан бәйләгән яулыгының почмагын күзләренә тидереп алды. Сөнгатулла аның ирене калтыравыннан кычкырып елап җибәрүдән тыелуын күреп торды. Белә Сөнгатулла, сизә: Зөлхиҗәнең нечкә күңеле нишләгәнен, җанының канаты каерылган кош булып хәлсезләнүен, тәненең утка салган каен тузы булып куырылуын тоя. Шулай да Сөнгатулланың кайтуына шатланадыр. Йорт-җирнең соңгы казыгына кадәр януына үзен гаепле саныйдыр. Гомернең узулары инде ап-ачык икәненә төшенә микән соң? Озакламый тиңсез узачак гомерен күз алдына китерәме икән? Әнә күзләрендә мөлдерәп яшь бөртекләре җемелдәде. Ник елый икән? Ник кенә булмасын, аның сәбәпчесе ул — Сөнгатулла. Зөлхиҗәнең моңарчы да һәм моннан соңгы елауларына да фәкать Сөнгатулла гына сәбәпче, Сөнгатулла гына гаепле.

— Карчык,— диде ул. Көченнән килсә, бу сүзен кояш җылыларына, ай нурларына, су тәмнәренә, җилләр йомшаклыгына кушып әйтер иде. Сулышын тыйды, аңа төбәлебрәк карады. Зөлхиҗә тирән итеп тын алды, яулыгын аркасына җайлап япты. Зөлхиҗә, шулай итеп, үзен алда көткән авырлыкларга әзер торуын белдерде кебек. Шул ук вакытта бу — Зөлхиҗәнең, ире Сөнгатулла күкрәгенә башын куеп, сүзсез калуы белән дә бер. Тик болай эшләргә ул көндезләрен бик ятсына иде.

Зөлхиҗә, аны көтеп, күрешер вакытны төннәр буена күз алдына китереп чыккандыр, әйтер сүзләрен уйлагандыр. Сөнгатулла үзе дә күрешкәндә нишләсен больницадагы озын төннәрдә күз алдына китереп, әйтәсе сүзләрен эзләп ятты. Ләкин Зөлхиҗә көткән сүзләрнең берсен дә әйтмәде. Эштән өйгә Сөнгатулладан алданрак кайтып өлгергән һәм аны көтеп алган кебек итәргә тырышып:

— Кая, су салып торам, юын,— диде.

Ишегалдына үттеләр. Сөнгатулла үзеннән-үзе кул югычын күзләде. Шунда, ияләшкән урында икән. Әмма каккан багана да, югыч та яңа.

— Өшәнгәнсеңдер,— диде Зөлхиҗә, иңбашына салган ак сөлгене сузып. Сөнгатулла эштән кайткан һәм, әлбәттә, аек кайткан көннәрне ул: «Аргансыңдыр»,— дия иде.

Аның хәленә кереп, Сөнгатулла да һәрвакыттагыча диярлек, тик бу юлы үзенең алдавына үзе оялып:

— Карын ачты,— диде.

Мәрзия ак күмәч, хәлвә, ысланган балык, төрле конфетлар, өрек, йөзем җимешләре, кыяр, помидор кебек кала күчтәнәчләрен таратып салган өстәл тирәли утырырга өлгермәделәр, капка төбенә машина туктаганы ишетелде. Сөнгатулла түрдәге өч тәрәзәнең уртадагасына эленгән чәчәкле пәрдәне һәм челтәрне кайтарып, урамга карады. Муса кайткан. Атасын күреп, ул кулын болгады:

— Нихәл, әти!

Ишеккә тотынган килеш, бер аягын машина баскычына куйган шофер егет Габдразак та:

— Исәнме, Сөнгатулла абый! — дип эндәште. Һәм ике тапкыр машинасын кычкыртып алды.

Сөнгатулла тәрәзәне ачып җибәрде, җиңнәрен сызганган, йөзләре кояшта янган таза егетләргә көр күренергә тырышып:

— Нихәл анда? — диде. Ягъни колхозда, эштә, мастерскойда дию инде. Гомумән, авылда. Шул ук вакытта шәхси тормышыгызда да дию.

— Синсез — дөнья сансыз, Сөнгатулла абый.

Сөнгатулла, каршы йорт капкасыннан тол хатын Канәфия чыкканны күреп, тәрәзәне ябарга теләде.

— Өйгә керегез, нишләп анда гына торасыз? — диде ул, тәрәзә капкачына үрелеп.

— Юк, мин китәм,— диде Габдразак һәм, утыргычына утырып, машинасын кабызды.

Канәфия итәген учы белән сыпыргалап:

— Кайттыңмыни, күрше? — диде.

— Исәнме,— диде Сөнгатулла аңа карамыйча гына. Канәфиягә бу хәлендә күренәсе килми иде. Хәер, инде барыбер. Инде күптән барыбер. Ә кайчандыр... Хәзер ул күптәнге «кайчандыр»ның Зөлхиҗә белән бер кычкырышкач, ике көпшәле ау мылтыгы тотып йөргәне, куркытыр өчен аткан булып, шартлап ярылган көпшә кыйпылчыгының бармагын чәрдәкләгәне, шуны бәйләтер өчен Канәфия янына кереп, ачудан, хатыныннан үч алырга теләүдән, шунда куна ук калган кадәргесе генә күз алдына килде. Калганнары — «үпкән-кочкан — җилгә очкан».

— Габдразак, син теге тирәгә түгелме? — диде Канәфия, шофер ягына чыгып. Ләкин күзе Сөнгатуллада. Ә ул тәрәзәне япмады. Кыенсынды.

«Теге тирә» дип Сөнгатуллалар очында авыл советы, колхоз идарәсе, кибет яны йөртелә. Ә алар урамын «Тегермән очы» диләр.

— Юк, мин җәйләүгә,— диде Габдразак һәм, кузгалып киткәч, шапылдатып ишеген япты.

Канәфия аның артыннан:

— Ярый, алайсаң,— дип калды.— Савыгып булдымы соң, Сөнгатулла?

— Савыгуын савыктым, бугай. Ә калганын булдырып булмас инде пыжалый.

— Ярый алайсаң,— диде Канәфия һәм, кул сырты белән итәген сыйпап, китеп барды.

Кайчандыр (тагын кайчандыр) Сөнгатулла аның йөри белеп йөрүен карап калырга ярата иде. Бу юлы... Китте-барды. Кайчандыр (инде бөтен нәрсә кайчандыр кебек!) Канәфия аңа:

И алмалар, алмалар,
Бакчаларында ишек.
Кичә булган җаныеңның
Фамилиясе ничек?

Фамилиясен белмәдем,
Исеме Сөнгатулла.

Гомерлеккә булмаганда
Файда юк сынатуда,

— дип жырлаган иде. Китте-барды. Үзе китте, жыры калды. Хәзер тәрәзәне ябасы инде. Хәзер инде дөньяны ике катлы тәрәзә аша гына карыйсы: берсе — пыяла, икенчесе хәтер тәрәзәсе.

Юган кулларын сөртә-сөртә, Муса керде. Һәм эре-эре атлап килде дә атасын кочаклады. Гадәтенчә күтәрмәкче дә иде, ахрысы. Ләкин тимер кыршау кебек кыскан куллары кинәт бушап калды. Әх, бала! Атасының жиңеллеген орынуга ук тойды, хәле бүтәнчә икәнен аңлады. Муса авыр учларын аның иңенә салды, ике тапкыр сугып куйды. Атасын үзе белән тигезләргә теләде инде, тигезләргә! Әле кайчан гына ул үзе атасының шушылай иң кагуына, хуплау яки юату сүзенә мохтаж иде бит. Инде үзе атасын юатырлык ир булган. Ә Сөнгатулла? Эштән чыккан, инде йөгән дә кигезмәслек, фәкать ыңгырчак эзенә сукалап: «Әх, малкай!» — дип юмалыйсыны китергән карт алаша белән бер инде, бер.

— Яхшы, әти! — диде Муса аңа.

Сөнгатулла өйне күздән кичереп һәм хатыны белән кызы аның ни әйтәсен бер-берсенә карашып көтүен искәреп:

— Күргәнсең күрмешне,— диде.— Мондый йорт салуы...

— Тазалык булсын, әти.

— Яхшы, улым, яхшы.

Мәрзия жырлап торган электр самавырын, токтан өзеп, эскәтер жәелгән өстәлгә китереп утыртты.

— Чәй кайнады,— диде ул.

— Утырышыгыз,— диде Зөлхижә.

— Мәйсәрә килен кайда соң? — дип сорады Сөнгатулла.

— Жәйләүдә,— диде Муса.

— Ә Тукай?

(Бусы — Мусаның улы, аның оныгы. Күршедә бер балага Д'артаньян дип кушкач, Муса кычкырып көлгән иде. Аннары йодрыклап өстәлгә төйде дә хатыны Мәйсәрәнең кабарынкы корсагына яшерен күз төшереп: «Үзебезнекен алып кайтсак, бер исем кушып күрсәтмәсәмме!..»— дигән иде. Тукай — менә шуннан.)

— Су коенадыр.

— Йә,— диде Зөлхижә,— утырыйк инде.

Сөнгатулла өстәлгә таба атлады. Һәм югалып калды. Кая утырырга? Күнеккән урыны өстәл башында, ян тәрәзә буенда иде. Үткән-барганны карап калырга яхшы. Хәзер өстәл өйгә буйлый тора. Түргә утырса, тәрәзәгә аркан килеп чыга. Ишек ягыннан — тәрәзә ерак. Ә яннан... Ян-ян инде ул...

Ә Муса түргә утырды.

Сөнгатулла: «Ала-а-ай...— дип уйлады.— Малай хужага әйләнгән икән».

— Кайткан шатлыкка... әллә нитәбезме соң? — диде Муса һәм, уң кул ягындагы сервантның аскы капкачын ачып, түбән иелде.— Ә, әти? — Жавап көтеп, ул шуннан елмаеп күз кысты.

— Муса абый...— диде Мәрзия.

Муса Мәрзиягә күтәрелеп карады, нидер аңлап, урыныннан купты.

— Үз урыныңа утыр әле, әти. Шулай, Мәрзия, бу бөркүдә ниткән эчү ди. Әйеме, әти? — диде ул. Әмма Сөнгатулла аның тел төбен аңлады: шулай итеп, «сиңа ярамый» дип әйтүе инде.— Беләсең, әти: миңа бу нәрсә әллә бар, әллә юк... Утыр, әти, утыр.

Кабатлап әйтте. Үз ялгышын ашыгып төзәтүеме бу? Әллә атасына юл куюын белдерүеме? Өстәлнең үз ягындагы урындыкларын читкәрәк этәреп чыкты. Аны шундук аңлаган Зөлхижә икенче яктагыларын кузгатты.

— Тот, эти! Өстәлне борабыз! — диде Муса һәм, өстәл башын астан тотып, көлеп җибәрде.— Ату мин ниткәнмен... хуҗа булып беткәнмен монда.

Өстәлне борып, гомердән килгән гадәтенчә утырса да, Сөнгатулланың күңеле тынычланып бетмәде. Дөнья үз эзенә кайтты кебек. Менә ич, бар да әүвәлгечә: ул өстәлнең түр башында, тиешле урынында. Табын мул, ул янадан өйдә, хатыны, балалары янәшәсендә. Самавыр гөжли. Сүз күп, әллә ни яңалыгы, кызыгы булмаса да, гадәтилеге белән тансык.

— Печән хәстәрләргә вакытыгыз булмагандыр инде? — дип сорады Сөнгатулла. Шулай икәнен белсә дә сорады. Бу аның Мусага: «Печәнсез калмабыз бит?»— дип искәртеп куюы.

— Колхоз бүлер әле. Мәйсәрә белән миңа шактый тия ул.

— Люцер да салам белән генә булмый әле ул. Малга да төрлесеннән кирәк. Болын печәненә ни җитә инде. Ярар, үзем чапкалармын әле.

— Юк, инде, эти. Өшәнеп йөрисе түгел. Сиңа калмаган,— диде Муса.

Мәрзия апа, ашыгып, каршы төште:

— Калмаган дип... Этигә нәкъ үзе инде. Рәхәтләнеп чапсын!

Сөнгатулла: «Кыз бала — кыз бала инде. Күңеле сизгер»,— дип уйлады.

Мәрзия аның хәлен Мусадан яхшырак белә шул. Бу сүзләрен тагын юатып әйтте ул. Муса аны үлән чабарга да ярамаслык дип саный һәм шуны маңгайга бәрүнең килешмәгәнлеген дә чамалый.

Сөнгатулла чәйне тәлинкәсенә салып, ә тәлинкәне өч бармагына куеп, тансыклаган авыл чәен эчте.

— Кала суы чишмә суына житми инде,— диде ул.— Чишмәнең бурасын карыйсы бар әле.

— Яңарттылар инде аны,— диде Зөлхиҗә.

— Кемнәр?

— Идрис белән Хаммат.

— Мине көтмәгәннәр икән.

— Көтәргә — чишмәне язын ләм басты. Ә колонкалардан уңмадык — суы каты, тәмсез.

Муса:

— Әнә, торбасын өйгә үк керттем,— дип, кече өй ягына ымлады.— Табак-савыт юарга, үзең юынырга ярагач та яхшы. Тамаша! Мин үзем чишмә суыннан башканы эчмим.

— Нужасы төшми, шуңа эчмисең,— диде Сөнгатулла, улының һаваланыбрак сөйләшүен абайлый башлап.— Нужа төшсә, ат тоягы эзенә җыелган суны да ятып эчәсең аны,— дип өстәде ул коры гына.

Муса тәлинкәсен авыштырып, соңгы кашык ашны авызына күтәргән иде — кире куйды.

— Чә! — диде ул.— Нәрсә инде син... тик торганда.

Сөнгатулла киндер тастымал белән маңгаендагы тирне сөртеп алды.

— Шулайрак бугай шул,— диде ул, тамагын кырып.— Ярар, шул гәүдәң белән үпкәләп утырма әле. Алай да атаң белән киңәшсәң ни була?

— Нәрсәне әйтәсең?

— Әйдә, чыгып сөйләшәбез.

— Чәйне эчеп бетерим инде,— диде Муса һәм «моның нинди кыланышы инде бу?» дигән шикелле елмаеп, бер Мәрзиягә, бер анасына карап алды.

— Ярый, мин чыга торам алайса.

— Тамагыңа тагын бераз капкала әле, әз ашадың түгелме? — диде апа Зөлхиҗә.

— Туйдым, карчык. Ни бит... бөркү.

— Чәй эч.

— Булды дим инде.

— Тагын бер генә чынаяк. Варенье белән. Җиләген үзем җыйдым.

— Ярый, мин чыгыйм әле,— диде Сөнгатулла беркемгә дә карамыйча һәм, яңа иданнең ныклыгын чамалаган шикелле, сак, сыгылмалы басып, яшел йомшак чүәктән килеш кенә ишегалдына чыгып китте.

Ишегалды иркен, зур. Ләкин аның бер генә почмагында да ул үзенә таныш күләгә, чөй яисә кадак, гомер буена аяк астында буталып йөрсә дә, ташларга башка да килмәгән тимер кисәге (мәсәлән, күгәреп беткән борынгы бизмән, егерме кадаклы герблы гер, ватык домкрат) күрмәде. Монда барысы да ч и т иде. Аның ишегалдын ташлап чыгып китәсе, үз өенә кайтып керәсе һәм шунда берәр эш эшлисе килде. Ә болай ул үзенә бүтән кеше булып тоелды. Шул кадәр дә бүтән һәм чит, хәтта әнә шул кешенең дә үз өенә кайтасы, таныш балтасын кулга аласы яисә үз сыеры яткан абзарны чистартасы килүен Сөнгатулла бөтен җаны белән тойган шикелле булды. Аның да, батальоннан бер ялгызы гына исән калган ялгыз сугышчы кебек, үләсе килә иде. Аны да Сөнгатулланы соңгы упкынга китереп тәрәгән авыру белә-гән, ул да инде сәламәтләндерә алмый торган, файдасыз дарулар эчә-дер. Ташка басса, аның да сөяк кенә калган табан асты авыртадыр, учына тигәнәк угы гына тисә дә, каны чыгадыр. Ул да дөньяда көлепелмаеп яшәргә телидер. Әмма ишегалдының кыл уртасына баскан килеш аның да тавышсыз, күз яшьләрсез елыйсы килеп киткәндер. Аңа да тәрәзә пәрдәсе аша, ал чәчәкле кына гөлләре артыннан хатыны яшертен генә карап тора микән? Һәм, шулай булса, ул моңа әлбәттә кимсенәдер. Чөнки ул да, Сөнгатулла кебек, кызгануга дучар булган икән, нигә аннан дөнья хәлләрен, тормыштагы авырлыкларны яшерергә? Менә шушы өйне генә ал. Шундый-шундый хәл, йорт-җир, бөтен хуҗалык казыгынача янды, яңасын тиз бурап керергә, шөкер, көчтән килә, йортны урамга элеккечә яңы белән куйыйкмы, әллә каршымы дип киңәш сораудан гына ул — Сөнгатулла — җиргә ятып, үкереп елар, я ата-анасын калдырмый сүгенер, я вакытыннан алда гүргә керер идемени? Иңгә төшкән авырлыкларны бар сынны катырып һәм тез буыннарын калтыратмыйча күтәрмәгәч, ялганнарны, бармаклар каната-каната кәкре кадак төзләгән шикелле, турыламагач, мактауларга, ялагайлануларга өстән карамагач, рәнҗетүчеләрдән үч алмагач, яшәү яшәүмени ул?! Я чүкеч шикелле җиренә җиткереп сук инде аны, я сандал шикелле нинди генә сугуларга да бирешмә, нык тор.

Шулай икән, нигә мескенләнергә? Менә ул үзенең элеккеге сиксән ике килолы гәүдәсен, метр да җитмеш алты сантиметрлы буен, нинди хәлгә төштең, дип кызганып, балавыз сыгып, кимсенеп утырсынмыни? Танымаслык булып үзгәргәнме? Үзгәрсә ни. Ул үз-үзенә фәкать яхшылык кына тели. Аның өлешенә калган бар нәрсә канәгатьлек кенә бирсен. Күпмедер гомере бар икән, шуны якты хисләр, игелекле теләкләр, ярату, ышаныч, өмет, тыныч акыл, тапкан җаваплары, җавапсыз сораулары, яңа авырлыклар, авыр сынаулары белән яшәп бетерсен. Ул үз-үзенә җиңел үлем генә түгел, авыр яшәү дә тели әле! Шушының чыңга ашуы хакына Сөнгатулла әллә ниләр бирер иде. Ни генә эшләсә дә, барысы да авырлыклардан качып калыр өчен түгел, ә бәлки кешеләр арасында, кешеләр янәшәсендә кешечә яшәү хакына.

Шушыны аңласаң, үз бәхетеңне эзләү, үз-үзеңне тормышта раслау гөнаһ түгел. Иң мөһиме — бару, ахырынача алга бару, һәрвакыт алга гына бару һәм алда сине ни көткәннән курыкмау.

Сөнгатулла күңелендәге бу уйларны күрде, ишетте кебек.

Болдыр ишегендәге марля пәрдәне ачып, Муса чыкты.

— Шундый-шундый хәлләр, әти. Аптырап торасыңмы? — диде ул, һәм, баскычка утырып, пычак белән шырпы очлады да, авызын ачып, тешен казый башлады. Аның елмайган тыныч йөзе бер үк вакытта

газаплануга чыдый алмыйча бозылган рәвешкә керде. Сөнгатулла ишегалды уртасыннан аның янына килде, өйнең кирпеч нигезенә утырды. Муса шырпысын ташлады, тамашачы куеныннан тере әтәч тартып чыгарган фокусчы сыман, һаман елмаюын белә иде. Көне-төне эшләсә дә, йөзе тупасланмаган, тауш̧алмаган, какча, шома. Йөз сызыклары әле кайчан гына яшьлек, шаянлык чалымнары белән тулып тора иде аның. Боларны ирләрчә ныклык, катылык, җитдилек кысрыклап чыгарган. Ә Сөнгатулла аның тышкы кырыслыгы астында нечкә күңеле яшеренгәнен яхшы белә. Әйтик, моңсуланып киткән чакларында Сөнгатулланың, төнге кырны үз моңы белән тутырырга теләгәндәй, трактор кабинасында сузыплар торып җырлап җибәргәне бар. Ә улларына ишеттергәне юк. Атадан улларга кырыслык, җитдилек, намуслылык, ирлек күчсен. Башкасыннан мәхрүм калмаслар. Ә Муса алай уйламаган әнә. Бервакыт кич белән төнге эшкә төшешли су буеннан узганда ул Мусаның җырлаганын ишетте. Куак арасында ялгызы нишләп җырлап утыра, дип сагайса, Тукайга җыр өйрәтә икән.

Олы юлдан атлар чаба,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр-барын,
Сагындыра узганы.

— Әйдәле, улым, кушыл.

Олы юлдан атлар чаба...

Мусаның калын, күкрәк тавышына оныгының нечкә, чиста тавышы кушылгач, Сөнгатулланың күңеле тулды. Алар янына барып утырасы, җырга кушыласы килде — кыймады. Чөнки кызыксыну басты. Мусаның үз улына җыр өйрәтүен бүлдерү ярыймы соң. Качып тыңлау да әллә ничек әле. Ләкин юри тыңлап тормый ич, ирексездән тап булды.

Тукай атасын:

— Әти, әти, олы юл нәрсә ул? — дип бүлдерә.

— Олы юл... әнә аръяктагы асфальт юл шикелле зур юл инде. Еракка алып китә торган юл... Әйдә, яңадан...

— Әти, әти асфальт юлдан машиналар гына җилдерә ич, атлар юлы бүтән.

— Бик борынгы җыр бу. Аны чыгарганда асфальт юл да, машиналар да булмаган әле.

— Ә ни булган?

— Атлар булган... сугышлар булган... Дошман авылларны яндырган, шәһәрләрне җимергән... Әйдә, җырлыйбыз.

Олы юлдан атлар чаба,
Безгә кала тузаны.

Җыр бер мизгелгә текә ярлардан кире кайтарылган кайтаваз гына булып кала: Муса, көйне югары күтәреп сузганнан соң, тын алганда Тукай тагын түзмичә:

— Әти, әти, безгә ник тузаны гына кала? — дип сорый.

— Безгә түгел, улым. Тузан безнең бабайларга, бабайларның бабаларына калган... Ә бәхет, атлар шикелле, алар яныннан җилдереп кенә узып киткән. Бу җыр менә нәрсә турында. Бәхетне аны тотып алырга кирәк. Бөтен көчкә чабып барган атның ялыннан эләктереп алган шикелле. Белдеңме?

— Белдем. Ә бәхет нәрсә соң ул, әти?

— Бәхет? — дип кайтарып сорый Муса. Ничек җавап бирергә кирәклеген уйлаптыр инде. — Бәхет ул, Тукай, синең шикелле балалар авырмау... атаң-анаң булу... авыл булу... зират булу...

— Зират булу?

— Әйе, зират булу да бәхет. Зират юк икән, хәтер юк. Анда кем-

нәр күмелгәнен онытсаң, үзеңнең кем икәнеңне дә белмисең инде. Ә хәтер булмагач, үлгәннәр генә үле түгел, тереләр, исәннәр дә үле... Шуннан тагын... елга булу, юл булу... ашарга булу... Эшкә кемдер сине коллар шикелле куалаганга түгел, ә үз иркең белән бару, эшләгәнеңнең үзеңә дә икәнен белү. Бәхетнең очы-кырые юк инде аның, улым. Ә иң зур бәхет — үзеңнең бәхетле кеше икәнеңне белү. Ә моннан да зурысы, Тукай — бөтен кешеләрнең бәхетле икәнен күрү.

— Әти!

— Әү?

— Тагын бер бәхетне оныттың әле син.

— Кит әле! Я?

— Бабайны. Әбине. Бабаң белән әбиең булу да бик яхшы. Бигрәк тә минекеләр шикелле булса.

Муса эндәшмәде. Ихтимал, кан тамырлары бүртеп торган көчле кулын малаеның иңенә куйгандыр. Сөнгатулла үзе дә шулай итәр иде. Ул йомшак җилгә каршы яр сукмагыннан түбән төшеп китте, артта Мусаның:

— Әйдә, кушыл, улым,— дигәнен һәм аның калын күкрәк тавышына онытынын нечкә чиста тавышы ялгануын ишетте.

Олы юлдан атлар чаба,
Безгә кала тузаны...

Җыр елга суында бөтенләйгә агып китмәсә, искән җилдә очмаса, таллар арасында адашып калмаса, күкләргә ашып юкка чыкмаса, тузан булып, җиргә таралмаса, тракторын кабызып төнге кырга чыккач, улы белән онытынын җырлавына Сөнгатулла да кушылыр... Аның җыры күктә йолдыз атылгандай кыска инде кыскалыкка. Әмма бит ут йолдыз! Шул август төнендә мул атылган йолдызлар улы Муса белән оныгы Тукайның елга суында акмаган, искән җилдә очмаган, таллар арасында адашмаган, күккә ашып юкка чыкмаган, тузан булып таралмаган җыр-моңына төшеп чумдылар кебек.

Менә нинди кеше аның улы Муса. Улына җыр өйрәткән ата үлгәч тә яши.

Ул аңа ни дияргә теләгән иде әле? Ачуланырга бугай. Әллә шатланасы микән? Ни арада нинди йорт-җир житкереп кергән бит малай актыгы! Йортның терәге Сөнгатулладан башка бит ул!

— Ник чакырдың, эти?

— Ник, ник!..— диде ул аңа, ни әйтергә белмәгәч. «Бусы ник болай, тегесе ник тегеләй» дип бәйләнмәс, вакланмас бит инде. Шуңа күрә ул, тел төбен яшергән кебек: — Яхшы-ы-ы,— дип сузды.

— Йорт-җирне әйтәсеңме?

Сөнгатулла:

— Аны да,— диде.

— Безгә синең таза-сау кайтып керүең яхшы, эти.

— Таза-сау дип... үзең бирешмә, улым. Хәзер ышаныч синдә.— Арттырыбрак мактады ахрысы, ул: — Төпчек кайтканчы,— дип өстәде.— Син үзең дә башлы-күзле.

— Бөтенебез бер гаилә ич инде.

Сөнгатулла:

— Төпчек кайтканчы,— дип кабатлады.— Ул да башлы-күзле булыр. Озак тормас.

— Озак тормас... Мине дә тиз тоттың.

— Минем анда ни катнашым бар? — Сөнгатулла бер аяк астына, бер капка ягына карап алды.— Яхшы-ы,— диде ул тагын.

Сүз аның хакындамыни? Сүз бит алдагы яшәү хакында әле. Авыл кешесенең үз гомерендә ике олы мәшәкате бар: өйләнеп башка чыкканда, йорт җиткереп керү, тора-бара тагын берне салу — анысын гомер азагына кадәр исәпләп һәм бала-чагалары гаилә корып, үз йортлары белән

яшн башлаганчы житсен, диган чама белән. Шушы ике олы мәшәкатьнең бер ягында — кешенең дөньяга килүе, икенче ягында — дөньядан китүе. Бу — авыл кешесе үлгәнче кичә торган тормыш күпере. Кешенең эше кала; кылган эше шөһрәтле икән, исеме дә кала. Ә эш белән исем — дөньяда калдырган мирасың инде ул. Хәер, монысы сиңа түгел, монысы исәннәргә кирәк.

Чын егет икән Муса, менә нинди йорт җиткергән. Хәзер нык салалар инде — берәгәйле итеп. Ут-күз төшмәсә, гомерлек. Тынычлык кирәк. Һәммәсе сыяр. Ә төпчек улы Фәрһад? Менә көзгә өйләнеп кайтыр. Ул да сыяр. Ә өйләнгәч? Төп нигез, төп йорт — анныкы, төпчекнеке. Бусын ни алла иңдермәгән, ни мулла кушмаган. Бусын халык борынгыдан һәм мәңгегә хәл итеп куйган. Сөнгатулланың нигезе бар, ә йорты? Төпчеккә атасыннан ни кала? Улы тәгаен авылга кайтам дип китте бит.

— Бу йорт-жирне Фәрһадка калдырып чыгуы авыр булыр инде сиңа, Муса.

Сөнгатулла улының үзенә әллә ничек итеп — җанының кеше күзе, кеше уе җитмәслек тирәнлегеннән карап куюыннан куркып китте. «Ә-ә! Аңлашылды!..» — дип уйлады ул, әлегә улының күңелендә ни ятканын анык төшенмәсә дә. Яңа салган йорт-жирне энесе Фәрһадка калдырырга Мусаның йөрәге җитмәс, диган шик күңелен тырнап узды.

— Кайтса, бик калдырыр идем әле, эти.

— Кайтыр, ник кайтмас икән? Кайтмый кая барсын! Башта армиядән. Аннары китеп торыр. Укуын дәвам итәргә. Тәмамлар. Менә аннан кайтыр. Бөтенләйгә. Агрономга укып бетергән башы белән базарда ит чабармы әллә? Безнең нәселдә андыйлар булганы юк... Синең муеныңа кайтып атланмас анысы, моннан аң бул, әйе... Колхоз өйләре бер урам, әнәтерә. Унтугыз таш йорт.

— Тагын жидене салып яталар. Безгә дә шуларның берсен бирмәкчеләр иде. Рәхмәт дидем.

— Дөрес, нәрсә аны. Тәндә җан барында хәләл көч белән салган үз куышыңа ни җитә!.. Ә төп нигездә төпчек калырга тиеш. Бусы сиңамиңа карамый аның.

Беравык тын тордылар.

— Кайтса... Кайтса, ике дә уйлап тормас идем, эти.

— «Иде» дип син... Тел очыңа төер чыккыры нәрсә! Тфү-тфү диген! Әйе! Фәрһад ул баш бәясен белә торган егет. Күрәләтә утка кермәс! Хәер, безнең нәсел отчаянный инде ул... Җәренгә көрәшкә кем белән чыгасыңны уйла. Көрәш мәйданына салып, Фәрһад синең кабыргаларыңны санар әле ул, менә әйткән ие диярсең!

Сөнгатулла ишегалдын яңгыратып көлеп җибәрде. Онытылып көлсә дә, күз кырые белән тәрәзә пәрдәсенең күбәләк канатыдай ябылуын абайлады. Икенче тәрәзәгә дә кырын караш ташлады. Пыяласында кояш чагылганга, анысында ул-бу хәрәкәт сизелмәде. Тик шунысы тәгаен: Зөлхиҗә белән Мәрзия аны карап торган. Нишли икән бу диптер инде. Нишләсен, көлә әле Сөнгатулла абзагыз! Йорт-җир янган дип кара көеп утырырга монда... Кешесе ул түгел. Кем белә: Муса урынында үзе бил алышып ятса, бәлки ул да, ут-күз чыкты дип, сабан туе мәйданын чатыр чабып ташлап кайтмас, җиңгәнче шунда калыр һәм ахырдан көйрәгән кисәүләр өстенә кайтып кергәч:

«Дөньяда ут чыкканда татар көрәшендә саф намустан да гаделрәк судья юк»,— дияр иде, ә? Тимершиннәрнең каны кайнаса, кайнап күрсәтә инде ул! Кан кайнауга йөгән юк аңа.

— Яхшы, Муса,— диде ул.

— Их, эти! — дип, Муса көрәк кадәрле учларын нык тезләренә берьюлы сукты да аягына торып басты.— Бәла ялгызы йөрми икән шул!..

— Аяк астында ятмый диген.

Муса баскыч төбенә төшеп, сандалларын киярге иелгән иде, аңа күтәрелеп карады.

— Бәла аяк астында ятмый диген, дөресрәк булыр,— дип кабатлады Сөнгатулла.— Минем хәлне бәла дип санарга ашыкмый тор, яме?

Муса кулына алган кырык алтылы сандалиен баскычка ташлады, аның калай каптырмасы зыңлап куйды.

— Минем авыруны,— дип елмайды Сөнгатулла.— Янгын да... Үткән эшкә салават... Ничава!..

Муса сандалиларын аңа аркан борылып, баскан килеш аягына әлде дә каптырмаларын эләктереп тә тормастан, урамга юнәлде, кече капканы ачар алдыннан каядар читкәрәк карап:

— Әти, мин эшкә төшим инде, эш күп чак,— диде.— Кичен сөйләшеп утырырбыз.

— Ярый, ярый,— дип, ул Мусаның урам буенча бөтенләй икенче якка — су буена төшеп китүен бакча рәшәткәләре аша карап калды.

Яр биек, текә. Биек, текә яр читендә Сөнгатулла үзен кечерәеп калгандай тоя. Зур таш кантары янындагы кырмыска ише генә итеп. Кырмысканың зур таш кантары өстендә алай да, болай да йөргәне шикелле, Сөнгатулланың уйлары да биек, текә яр тирәсендә алай да, болай да йөри, айкала, актарыла: бер күтәрелә, бер төшә.

«Бу яр ишелгәннән ишелә, дугаланганнан дугалана,— дип уйлый ул бөтенләй башка нәрсә турында.— Яр ишелсә дә ярый, урын житәрлек. Адәм баласының гына яры чикле ул. Соңгы яры — кабер. Хәер, кеше башы чыдаса чыдый инде. Яра өстенә яра өстәлә... Әле тән ярасы, әле жан ярасы...» Уйларын кем беләндер уртаклашасы килә иде аның.

Муса:

— Әти, мин эшкә төшим инде, эш күп чак,— дип чыгып киткәч, жылы нигез ташына утырган килеш ялгыз калган Сөнгатулла бер кавым нишләргә белмичә торды. Капка күләгәсенә — шундагы бүрәнә-әхрәткә (бәлки Муса эскәмия дә ясап куйгандыр инде) чыгып утырасы килде. Тик базмады. Кешеләр узар, һәркайсы хәл-әхвәл сорашыр, кабат-кабат жавап кайтарырга күңеле тартмады. Капка төбе кичен тансык ул. Ул торды, бушаган чалбарын күтәрде, ике атлауга ук чалбары тагын билдән түбән оча сөягенә шуды. «Яңа каеш кирәк». Яргаланганга күрә элеккесен бумаган, больницада киенгәндә Мәрзиянең сумкасына тыккан иде. «Шуны тагып торасы инде»,— дип уйласа да, әлегә өйгә кермәде. Зөлхиҗә белән кызының сөйләшәсе бардыр, комачауламаска булды. Мәрзия кеше күңеленә сизгер, жай белә, артыгын сөйләп, әнкәсен куркытмас, шәт. Сөнгатулла мал-туар чәчкән йомычкалар өемен сәнәк белән жыештырды, исләре ишегалдына таралды. «Йомычка мунча тамызлыгына тамаша инде»,— дип уйлады ул. Имән бүкәнгә каптырып куелган балтаны алып карады. Мусаның кулы барган: балта жайлы утырган, чөйләнгән, уч төбе сапка жайлы ята. Баш бармагының тырнагын ышкып, үткерлеген тикшерде, канәгать калды. Аннары капка түбәсенең аркылы тотнагына эленгән чалгыга күзе төште, аны да алып, селтәп карады — иҗле иде. Бөгәлҗәсе шомырт та, тал да түгел, элмәдән ясалган, озакка чыдар. Чалгының сугылуы да шәп — тамчы да калҗаймаган. Әченә тагын жылы йөгерде: «Яши белер малай!» Чалгысы да тугызлы. Муса каерып бер селтәнсә, дөнья тикле жирне кырып ала инде. Үзенең дә үләнне кыеп-кыеп чабулары исенә төште. Хәзер алай итәргә дәрманы житмәстер. Шунысы сагындырып инде, хәерсез.

Сагындырып дип... кыймылдарлык чама бардыр әле анысы. Бәлки нәфсене басып керергәдер? Сукмактан менешли койма буенда кычыткан, алабута шәйләп калган иде, шуны ега торсаң да юаныч.

Шул уй белән бакчага таба атламакчы иде, исенә төшеп, олы капканың җепсәсенә әйләнеп карады — янавыч шунда, күнегелгән төштә, кул астындагы урынында икән. Муса бусын да искәргән. «Булдыклының булуы шунда күренә».

Тагын риза калып, ул:

«Барысын да минемчә итәргә теләгән»,— дип уйлады.

Кычыткан картайган, алабута орлыкланган инде. Алай да чабып киптерсәң, мал-туарга ярыйсы. Ул аларны җайлап кына егып чыкты, коймa буе чистарып калды.

Бәрәңгене тирән сызганнар, ләкин анда-санда кызыл таплар кыймылдаша — колорад коңгызлары. Үләт кыргырлары дисәң, үләтләре юк, ахрысы, ул хәшәрәтләрнең. Үрчеделәр дә соң! Бәла!

— Иманыгызны алам әле мин сезнең! — диде ул.

Керосинга чүпләп дөмектермәсәң, һични алмый каһәр төшкән нәрсәләрне. Каян килеп чыкканнардыр. Каза инде бер! Бәрәңгене уттан хәтәр корытучы хәшәрәтләрдән ул җирәнә, аларны күралмый иде. Тере бөҗәккә дә охшамаганнар бит, дуңгыз танаулар. Әйтерсең лә эчләре телевизорныкыише электрон белән тулы.

— Курск дугасы ясыйм әле мин сезгә,— диде ул.— Маршал Жуков юк-югын, әмма җир тазалыгы дигәндә крестьян кулына туплар, танклар кирәкми. Мин сезне хәйләкәрлек белән алдырам.— Аннары ул экрен генә: — Уйларга кирәк.— диде.

Кортлар кара җиргә, яшел бәрәңге яфракларына тамган кан тамчыларын хәтерләтә иде.

Шуннан нишләде? Сөнгатулла аягына басты, бозау янына килеп, аның муен астын кашып торды.

Шуннан соң, сукмак буендагы кычыткан белән алабутаны чапкач, ул яңа зиратны — чардуганнары затлы, агачлары яшь булган, зиннәтле истәлек ташлары куелган (исән туганнарның хәленә, үлгәннәрнең кадеренә карап инде) каберләрне күзеннән кичерде: ул югында артмаганнармы? Артмаганнарын күргәч, күңеле сөенде. Шул ук вакытта ахыргы кабернең кемнеке икәнен барлаудан тыела алмады. Урман каравылчысы булып торган Зариф Зәетовныкы — яхшы кеше иде, мәрхүм. Шуны ачыклаганда Сөнгатулла үз тәне тоярдай, үз аңы иңләрдәй дөньядагы барлык хәсрәтне, барлык тавышны бер генә мизгелгә туктатып торырга теләгән шикелле булды. Ул җан сызуы төсендә үтеп киткән бу теләгенең каян килгәнен тәгаенләп өлгермәде, тик Зариф Зәетов янәшәсендә үзе ятачагын ачык күрде инде. Әлегә аның, «ятуым ихтимал гына әле», дип үз уена карышасы килде. Әйе, анда кемнедер алданрак җирләп өлгермәгәннәр. Өлгермәгәннәр икән — яхшы. Әйе, Зариф Зәетов янәшәсендә ятарга була. Яхшы кеше. Яхшы. Ах, әлбәттә, әлбәттә,— яхшы кеше иде...

Ул, койманың рәшәткә башына тотынып, карашын иске зиратның түренә — каеннар куерак булган урынга күчерде. Ул тарафтагы агачлар кырык-кырык биш еллыклар. Анда үткән сугыш чорында һәм сугыш тынгач үлгәннәр җирләнгән. Кубесенең я бура, я такта чардуганнары таралып черегән инде. Агач утыртылганнарында я агачлары, таш куелганнарында я ташлары тора. Әнә теге кара тап ни нәрсә тагын? Каян килгән? Моңарчы юк иде ул. Иртә таңнан алып, төнгә чаклы, хәтта төнлә дә җәен димсең, кышын димсең, көзенме, язынмы үз өе яныннан кайда нинди тап, төс, шәүлә күренгәнне Сөнгатулла яхшы белә, бу аның канына сеңгән. Болар гынамы соң,— тавышларны, авазларны да. Кайдан нинди җил искәндә агач ябалдашлары ничек бөгелә, күләгәләр нинди озынлыкта булганда вакыт күпме — барысын да белә. Әйе, анда бу кара тап юк иде. Ни икән ул? Каеннарның кояш нурлары яктырткан толымнары астында, ак кәүсәләре арасында каралып тора.

Кызыксыну басты. Шул тирәләрдән әйләнеп кайтасы да килде. Иске зиратка күптәннән аяк басканы, әнкәсе каберен байтактан зиярәт кылганы юк. Элегрәк, мал-туар асрау авырга килгәндә, зират үләнен бүлгәләп чабалар, кайбер чакны аңа да тия иде. Хәзер ялгыз,

булышчысыз пенсионерлар, әле дә җомга намазына йөргән картлар гына бүлешеп чаба. Алар моны савапка саный. Зиратны чистарту ич. Авыл советына акчасын түлиләр, шул керем исәбенә үзләре үк зиратның коймасын төзек тоталар. Ә быел үләнне чапмаганнар икән әле. Чәчәкләр җителегән җуйган, кәлшә үләннәренең орлыклары җитешеп, зиратны саргылт-яшел төскә керткән инде...

Койма буйлап үз сукмагыннан су буена таба төшкәндә, яр читеннән яңа зиратка кергәндә һәм, иске зират канавын аркылы чыккач, инде түмгәкләр хәлендә генә калган исемсез каберләргә басмаска тырышып атлаганда, теге кара тап ак каусәләргә әле күмелә, әле тагын күренә, гүя качышлы уйный иде. Инде аңа туры юнәлеп барганда, ул күздән югалмады, үзе үк аңа якыная башлады кебек. Зурайганнан-зурайды, рәвеше үзгәрде, турайды, почмакланды. Сөнгатулла сагайды, чөнки аның яңа кабер ташы икәнен таныды. Тик менә ташы гына яңа микән, кабере дә яңа микән? Хәер, алар авылында таш яңарту дигән нәрсә юк: бу эш — гореф-гадәткә сыймый торган фигыль, әүвәлдән тыелган, ә халык гөнаһ санаган хәл. Хорафат, әлбәттә. Заманалар үзгәрде, тормыш бөтен, көн итүе җиңел,— борынгы гадәтләрне санга сукмыйча, яңартулары да бар. Тик ай-һай, ул моңа ышанмады. Бүтән халыкларда бу гадәти нәрсә. Алай гына түгел, сөякләрен казып, башка урынга күчереп җирләү дә бар. Ә бездә — шикле.

Тәмам якынайды. Таш астында кызыл балчыклы яңа кабер иде. Нигә сугыш заманында, сугыштан кайтып, авыр яраларыннан вафат булганнар тирәсенә җирләделәр икән соң?

Таш зур, кап-кара, көзгедәй шома, ялтыравык. Килеп җитәрәк, чүкеп уелган тонык язуын, сурәтен, өске уң почмактагы йолдыз рәсемен шәйли төште. Чардуганы да кара, дүрт кырлы, нык, авыр тимердән, дүрт баганасы башында җиз шарлар.

Туктады, күзен кысып, сурәткә карады.

Һәм таш артындагы каеннарның яшел чуклары, зиратның яшел үләннәре кара көеп килде...

Сөнгатулла бозауның сыртына суккалады, шулай итеп әллә аны сөйде, әллә, уйларыннан арынырга теләп, үзен тынычландырды. Аннары, чиләкне алып, борылышны әйләнеп узды да сөзәк ярдан су читенә төште, чиләгенә су тутыргач, өскә менде. Чиләк авыр, җиргә тарта иде, әллә нинә тапкыр кулыннан-кулына күчерде.

— Эч,— диде ул чиләкне бозау алдына куйгач.

Бозау эчмәде, ипи кисәкләрен, бәрәңге, кыяр кабыкларын ашады.

— Аударма,— диде Сөнгатулла һәм яр читенә барып басты. Башта ераклыкларга, аннары су агымына, бөтерчекләренә, өстә йөзгән чүпчарга, бака ефәкләренә, сайлыктагы җете яшел үсемлекләргә карап торды. Һәм шунда борылыш елдан-ел ашалып ишелә барса да, елга ярының артык киңәймәгәнен төшенде. Чөнки елга үз яраларын үзе төзәтә икән: бирге яктан ишелеп киңәйсә, аргы яктан язгы ташуда утырып калган ләм, ком белән күмелеп тарая икән.

Кешеләрнең тормыш ярлары да шулай түгелмени? Әйе, шулай.

«Бәлане бәла төзәтә, яраны — яра»,— дигән сәер уена сискәнеп, ул иген басулары өстеннән еракка, урманга карады.

— Ничек, ничек? — дип сорады ул үз-үзеннән һәм «Бәлане бәла төзәтә, яраны — яра» дигән уен кабат яңартты. Чыннан да, чираттагы бәлане зурраgы каплый, иске яраны яңасы оныттыра шул. Әнә, авырый иде — йорт-җире янды. Инде авырый гына иде, йорт-җире янган булган,— ә аларның икесен дә иске зираттагы кара гранит таш күңеленнән куптарып алды да яңа авыр кайгы иңдерде. Ә бәлки бәлагә — бәла, ярага яра өстәлә барадыр ул? Юк. Гранит таш барыннан да авыррак, кара көйгән каен чуклары һәм зират үләннәре барлык кайгылардан да карарак.

Шулай булгач, Сөнгатулла хәлендәге кешеләргә нишләргә кала соң? Кара көяргәме, җиргә иңәргәме? Юк икән, бирге яктан ишелгән яр аргы яктан туларга тиеш икән. Кешеләр Сөнгатулла кебек, нинди генә хәлләрдә калмасын, нинди генә бәлаләргә дучар булмасын, нинди генә яралар алмасын, аларның тормыш яры бөтен торырга тиеш икән.

Анда, зиратта яшәү ярыннан ишелеп төшә язган Сөнгатулланы соңгы мәлендә бер көч тотып калды. Ишелә башлаган яр кисәген үлән тамырлары шулай тотадыр.

— Матурмы?

Күз алдын кара ялкын баскан Сөнгатулла ишетмәде дә кебек.

— Ничек дим, бабай, матурмы?

Ул тагын эндәшә алмады әле.

— Бабай дим, бабакай!

Ул җиң очын тотып тарткалаганга кымшанмыйча, фәкать башын бора төшеп кенә карады — янына оныгы килеп баскан икән.

— Тукай...— диде Сөнгатулла, тик үз тавышын үзе ишетмәде.— Тукай улым,— диде ул бу юлы телен көчкә әйләндереп.

— Бу абый һәйкәле,— диде малай.

— Аныкы,— диде Сөнгатулла. Ул аның кулын капшап тотты — беләкләре сеңерле, җылы кул.

— Матурмы соң?

— Әйбәт һәйкәл,— диде Сөнгатулла, аның ни хакында әйткәнен, ни белән горурланганын аңлап.

— Абый үзе дә әйбәт.

— Әйбәт иде.

— Герой!

— Герой икән шул.

— Аны ак тартмага салып апкайттылар.

— Аккадыр. Бик еракта иде бит.— Сөнгатулланың «җәһәннәмдә» дип тә әйтәсе килде, тик оныгы җәһәннәмнең ни икәнен белми иде. Белер әле.

— Әти ул тартманы ачмакчые.

— Соң?

— Майор абый ачтырмады. Кызыл ситсыга төрделәр.

— Ул ак тартманы кайчан алып кайттылар?

— Сиңа ап... оп... апир...

— Миңа операция ясагачмыни?

— Шул көнне. Ник кайтмадың?

— Әйтмәделәр.

Малай уң кулын йодрыклап селкеде:

— У-у, әшәке кешеләр! Әйеме?

— Юк, әйбәт кешеләр! Мине җылар дип әйтмәгәннәр. Тәгаен шулай.

— И-и-и, менә әби җылады ул! Көне буе, төне буе, тагын көне буе, тагын төне буе. Аннары да. Гел елады. Яңгыр шикелле.

— Тагын кем елады?

— Күп еладылар инде. Әйтеп бетерерлек түгел.

— Шуннан?

— Ә мин еламадым. Пионерлар да.

— Молодец.

— Ә! Тагын солдатлар да еламады әле.

— Ник икән?

— Алар автоматтан атты. Өч мәртәбә. Җиде солдат берьюлы. Залп белән, бабай. Бөтен каргаларның коты очты! Майор абый да атты. Аның пистолеты бар икән. Ә минем пистолетым аныкыннан зуррак. Матуррак та.

— Шулай, улым. Синеке зуррак. Матуррак та.

— Ә кемнеке яхшырак? Минекеме, аныкымы?

— Синеке.
— Ник?
— Синеке атмый.
— Атмый торганы яхшыракмыни?
— Атмый торганы шул.
— Ә ник майор абый алышмады? Мин давай алмаштырабыз дигәнием.
— Алдалыйсы килмәгәндер. Синеке яхшырак ич.
— Абыйның автоматы булган микән?
— Булгандыр. Анда коралсыз ярамый.
— Аңа кирәк түгел ич инде. Ник миңа апкайтып бирмәделәр икән?
— Бирерләр әле. Зур үскәч. Зур үскәч, бер ир-егеткә дә мылтык тоттырмый калмыйлар.
— Ә мин үскәнче бетсә?
— Корал бетсә, бу бик яхшы, улым. Синең пистолетың бар ич инде.
— Бабай, ә бабай! — дип, Тукай ике тапкыр аның кулын тартып куйды.
— Әү, улым, әү.
— Минеке яхшырак булгач, ник солдатларга да шундыйны бирмиләр?
Сөнгатулла оныгының бу соравына җавап кайтара алмады. Алай да ул аңа түгел, ә үз-үзенә җавап биреп:
— Әгәр бар солдатка синеке шикелле мылтык өләшеп чыксалар, минем төпчек улым, ә синең абыең Фәрһадны үтереп җиргә күммәсләр иде,— диде.
— Абый үлдемени, бабай?
Сөнгатулла тагын җавап бирмәде.
— Геройлар да үләмени?
— Геройлар үлми, ә һәлак була, Тукай. Алар иң алдан һәлак була.
— Аның каравы безнең абыйныкы шикелле һәйкәл авылда беркемдә юк. Яхшы бит, әйеме, бабай?
— Бик яхшы, улым. Бездә генә булсын, шулай бит? — Ул оныгына нәкъ моның кебек һәйкәлләрнең башка җирләрдә дә барлыгын әйтмәде.
— Теге майор абый безгә яңадан килде. Ә эти аңа башка вакытта килергә кушты.
— Ник икән — белмисеңме соң? — дип, кызыксынмыйча гына сорады Сөнгатулла. Ул район хәрби комиссариатындагы майорның нигә тагын килгәнен әзме-күпме чамалый иде.
— Эти аңарга син кайткач килерсең дип әйтте.
— Минем кирәгем калмаган инде, эш эшләнгән,— диде Сөнгатулла, ияге белән кабер ташына ымлап.
— Ә Фәрһад абыйга йолдыз бирәсе булганнар. Алтын, ди! Хәзер аны синең кулга бирәселәр икән. Аласыңмы, бабай?
— Алмый кая барасың инде?
— Эти майор абыйга ни за шту алмыйм диде. Нәрсә диде әле? Хәзер, хәзер...— Сөнгатулла оныгының, кашын җыерып, исенә төшергәнен көтеп торды.— Ә! Фәрһадны герой итеп мин үстермәдем, этигә бирерсез, диде. Сиңа була инде, беләңме?
— Белдем. Әйе, аны мин үстердем, улым.
— Әби дә бит!
— Әйе. Ул да. Икебез үстердек.
— Син ул майор абыйны чакырт, йолдызны ал. Ә миңа тагарга бирерсеңме? Бирерсеңме, бабакай?
— Бирермен.
— Ипидер, диген.
— Ипидер, Тукай.
Шушында Сөнгатулла түзмәде, бөтен җаны белән ыңгырашып, ела-

маска тырышып еларга тотынды. Аның җилкәсе калтыравыннан малайның да кулы, иңбашы дерелдәде.

— Җылама, бабай. Бабай дим, җылама.

— Нишлим соң, улым? Җыламыйча җырлыйммыни тагын?

— Әйе, бабай, лутчы җырлыйк.

— Җырлый беләсеңме соң син?

— Белми ди сиңа — беләм!

Зираттагы тирән тынлыкта малайның нечкә чиста тавышы ишетелде. Киң кырдагы ялгыз тургай тавышы кебек.

Олы юлдан атлар уза,
Безгә кала тузаны...

— Кушыл, бабай,— дип малай яңадан башлады.

Сөнгатулла оныгы җаена төшеп: «Атлар уза»,— дип кушылды, әмма җырның: «Безгә кала тузаны»,— дигәнен малай тагын ялгызы гына дәвам итте.

— Ник туктадың?

«Тузаны гына кала шул»,— дип уйлады Сөнгатулла һәм, бите буйлап тәгәрәп төшкән күз яшьләрен оныгына күрсәтмәскә тырышып, пинжәгенең җиң очы белән сөртеп алды. Ул, ярым пышылдап, җырның: «Алда гомер бардыр барын»,— дигән урынын җырлаганда, малай тын гына торды, ә бабасының көйне югары күтәреп сузганнан соң тынын алганда, көтәргә түземе бетеп, ялгызы: «Сагындыра узганы-ы-ы...» — дип сузды. Ләкин кабатланып җырлана торган соңгы ике юлны алар бергә җырлап бетерде:

Алда гомер бардыр барын,
Сагындыра узганы-ы.

Малайның алда гомере барлыгын бар, әмма узганы сагындырмый иде әле. Ә Сөнгатулланың алда гомере бардырмы, юктырмы, тик узганы сагындыра иде инде.

— Минем монда икәнне каян белдең? — дип сорады Сөнгатулла оныгыннан.

— Мин су коена идем. Су буена әти төште. Сине карап торырга кушты. Мин карап тордым да артыңнан килдем — шул.

«Муса мәнә ни өчен эше ягына китмәгән булган икән бая».

— Атаң тагын нәрсә диде?

— Димәде. Кайтыйк инде, бабай.

— Кайтыйк,— дип килеште Сөнгатулла.

Һәм алар килгән эздән кире борылдылар. Алда — бабасының кендегенә җитеп килгән таза, чиста, кояшта янган, кашы-чәче уңган, аягына сандаллар, өстенә зәңгәр күлмәк, кыска чалбар кигән малай. Артыннан бабасы бара. Ул иркенәеп калган чалбарын бүтән күтәрми иде инде. Куллары тезенә җиткәнче бөкерәйгән. Ул эсседән качып үләнгә поскан, әмма алар узганда көче белән күтәрелгән озынборыннарны һәм әрсез бөгәлчәннәрне оныгының муенына, күлмәгенә кундырмаска тырышып атлады.

Һәр адымы саен кое бушлыгына баскандай булды. Мусага: «Йортҗирне Фәрһадка калдырып, башка чыгуы авыр булыр инде сиңа», дип әйтүенә каршы аның: «Кайтса, бик бирер идем әле, әти»,— дигәнен исенә төшерде. Аның мәгънәсе нинди леген, барлык хәсрәте, афәте нидә икәнен ишегалдында белмәвен үзенең бәхетле чагы дип санарга гына калды инде. Тик аны кире кайтарып булмый шул инде. Кешенең бәхетле чаклары артта гына икән. Башына төшмәсә, кеше алда үзен ни көтәсен, дөрестән дә, белми икән...

Аяк астында үлән кыштырдый: кунарга чамалап, тирәләрендә бөгәлчәннәр, кигәвеннәр оча. Оныгының муены тирләгән, үзе бер дә ба-

басына борылып карамый, ул Сөнгатулланы сүзсез әйдәп бара кебек.

Ул төпчек улы Фәрһадны соңгы юлга озата алмады. Фәрһад та аны озата алмый иде инде. Аның каравы Сөнгатулла оныгы Тукайга ияреп бара иде әле.

Ул, Сөнгатулла — бирге яктан аерылган, әмма ишелеп төшкәнче үлән тамырлары белән бар көченә туфракка ябышкан яр кисәге, ә оныгы — аргы якны тотырып килүче яңа яр кебек бугай. Биек, текә борылыш су агымын шуның белән тота.

Яр читенә үк килеп басса да, керәшәләр аннан курыкмый инде. Аның кошлардан: «Кошлар, балаларыгыз егылып төшкәндә, сез елыйсызмы?» — дип сорыйсы килде. «Балаларыгыз оя корганда, шатланып көлә беләсезме соң сез, кошлар?» Сөнгатулла: «Ә мин?» — димәде. Гомеренең узган кадәресендә елаган да, көлгән дә инде. Ә алдагысында? Елар, көләр чаклары булыр микән? Чын яшәү артта түгел, гел алда кала микән соң әллә? Әллә яшәү, алдан килгән чабышкы ат сыман, язмыштан гел алда чаба микән, ә? Сөнгатулла әлегә моны белми. Һәм моннан соң да беләчәк түгелдер инде.

Тирә-якта кошлар гына чыркылдаша. Ләкин Сөнгатулла аларны аңламый иде.

— Яхшы,— диде ул, кичен Муса белән икәүләп капка төбендәге эскәмиягә чыгып утыргач. Кичен барысы бергә тавык шулпасы ашап, коймак белән сөтле чәй эчтеләр. Эскәмия дүрт баганалы капканың ачылмый торган ягы турысында, бетон баганалы, утыргычы урталай ярып ышкыланган имән бүрәнә.

— Нәрсәне әйтәсең?

— Нәрсәне дип... Шуннан калганнарын.

«Шуннан» дигәннең ни икәне болай да аңлашыла инде — табында бөтенесен сөйләштеләр: Фәрһад ничек һәлак булган, ничек жирләгәннәр, ничек зурлаганнар.

— Бәби дә көтәсез икән...

— Әйе, әти,— дип, Муса көрән туфлиенең очын капшаган булды.

— Яхшы. Малай булсын.

— Мәйсәрә кыз көтә.

— Кирәк, кирәк. Югыйсә, бер бала — ярты бала ул.

Беравык дәшми утырдылар. Урамнан бая кайткан авыл көтүе исе таралып бетмәгән иде әле.

— Ниятең изге иде, Муса.

— Кайсысы?

— Кайтса, йорт-жирне...

Муса тирән итеп сулады да тынын чыгарганда:

— Һәй, әти! — диде. Һәм бу хакта сөйләшергә теләмәгәнен, хәзергә сөйләшүдән мәгънә юклыгын, ләкин хәсрәт юшкыннары күңел төбенә утырып беткәч, әле һичшиксез кайта-кайта сөйләшергә туры киләчәген белдереп: — Урак та житә-ә,— диде.

Капкадан Тукай чыкты. Атасының очкыннар тишкәләгән брезент пинжәген кигән. Пинжәкнең итәге жиргә тигән, жиңнәре салынып тора. Ул, шуңа чумып һәм аягын бөкләп, атасы белән бабасы уртасына кереп утырды.

— Ник моны кидең? — дип сорады Сөнгатулла.— Жылы ич.

— Шуны да белмисең, бабай! Озынборыннар тешләмәскә ул.

— Акылың алтын икән! — диде Сөнгатулла.

— Үзе белә ул. Ә, улым? — дип, Муса пинжәк башлыгын улының башына кайтарып салды.

— Су коенасыңмы соң? — дип сорады Сөнгатулла.

— Каз тәне чыкканчы, бабай!

— Кысла тешләмиме соң?

— Хәзер аларның эзе дә юк.
— Ник икән?
— Качып беткәннәр.
— Сездән куркыпмы?
— Бездән сиңа! Су ярамый аларга.
— Сезгә ярыймы?
— Безгә чуртым да булмый. Кыслаларга ярамый.
— Кызык икән!
— Кызык ди, бар! Суга өстәге комплекстан дуңгыз б...гы агып төшкәнгә ул, белдеңме?
— Кем әйтте?
— Кем булсын — эти. Ул бит халык күзәтчесе. Предкә штраф чәпәттерде. Әйеме, эти? Шул кирәк, икенче агызмас.
— Хәзер акмыймы соң инде?
— Акмаган кая, бабай, хужырак!
— Акмас,— диде Муса.— «Чаян»нан килгән хәбәрче язып чыкты инде. Вилдан Сәлмәновичның кесәсендә тагын җилләр уйный инде. Бу юлы — бер айлык эш хакы.
— Ә балык... балык бармы соң?
— Балык — дөнья! Ә тотучы юк.
— Ник?
— Тамак тук — шуңа,— диде Муса, улы өчен җавап биреп.— Олылар — тук, бала-чага — ялкау.
— Балык кибеттә дә пачкы. Алучы да юк. Алмагач, дуңгызларга гына ашаталар.
Сөнгатулла монысын белә иде.
— Ашыйлармы соң? — дип сорады ул Тукайны сөйләштерер өчен.
— Ашамас алар! Сыптыралар гына, абжурлар.
Бабасы белән атасы кычкырып көлде, Тукай әле берсенә, әле икенчесенә карады, тик йөзләрен күрмәде: брезент пинжәк башлыгыннан аның борын очы гына чыгып тора иде.
Урам буйлап күрше Хамматның кайтып килгәнен алар тын гына көттеләр. Сөнгатулла аның ягына карамаска тырышты.
— Утырамсыз? — диде Хаммат килеп җиткәч. Исәнлек-саулык сорашмады. Иртән генә күрешкәнмени.— Кайттыңмы, күрше?
— Болай соңарып каян киләсең әле? — дип сорады Сөнгатулла. Бераз кыймылдап, аңа утыр дигән ым бирде.
— Идарәдән, корт чаккыры.
Капка ачып-япкан тавыш ишетелде. Каршы йорттан Идрис чыккан икән. Машина-трактор таптап, үлән заты калмаган урамнан ул, туктыйтуктый, җирдән нидер карый-карый килде.
— Самакатың ватылдымы әллә? — дип кычкырды аңа Хаммат.— Ындыр табагына төш, шөрепләрен кысып, майлап җибәрермен.
Хаммат ындыр табагындагы техниканы карый иде.
— Син үз шөрепләреңне кара — бер тартсам, микроскоп белән дә җыя алмассың!
— Ник бәйләнәсең әле син, Идрис? — дип, Хаммат урынында кыймылдап куйды.— Тик торганда...
— «Тик торганда, тик торганда!» Тотарсың сине тик!
— Нишләгән әле мин?
— Нишләгән? Ә жукларың?
— Ник минеке булсын алар? Бөтен авылны басты! Ачуыңны БМОга язып җибәр. Колорадо штаты губернаторын судка бир — алар коңгызы.
— Аларныкы сиңа! — Идрис тал ботагы белән ялтырап торган пычак тоткан — чалгы бөгәлҗәсе юнган җиреннән торып чыккан, сөйләшеп утырганда бер очтан шуны ясап бетерү нияте дә бар, күрәсең. Ул, тимер аягын сузып, каршындагы утын «кәҗә»сенә утырды.
— Син башта кеше белән күреш,— диде аңа Хаммат.

— Күрше белән мин гомергә житәрлек итеп күрешеп куйган инде, әйеме, кордаш? — диде Идрис, Сөнгатулланы пычаклы кулы белән сәламләп.— Син үз жукларыңны өйрәт, Хаммат.

— Нәрсә өйрәт, нәрсә өйрәт?!

— Безнең якка чыкмасыннар.

— Мин чыгараммыни аларны? Карале, ә?! — дип Хаммат кулларын жәйде һәм юлга чыгып басты. Бер коңгызны шәйләп, аягын, тәмәке төпчеген сүндергәндәй, шуның өстендә боргалагач, ул кире килде.— Ник аларны минеке дип бәйләнәсең әле?

— Синеке булмыйни? Сыртларын кара — ала-кола. Кем иртән дуст сиптереп йөрде? Ә? Әйтәм жирле Актырнак исни дә борынын жыера. Хәзер жукларың миңгерәүләнгәннәр дә миңа кыйгачлаганнар. Тапканнар йомшак кеше! Ябырылганнар!

— Син дә сиптер — ябырылмаслар.

— Бәрәңге тәмсезләпме? Тимер аяк белән Берлинга барып житеп фашист башын ярганны, боларны гына дөмектермәм мәллә? Ә, кордаш?

Сөнгатулла аны хуплау урынына рәхәтләнеп көлеп жибәрде. Ул күршеләренең хәл-әхвәл сорашмавына, кайгысын уртаклашып, юату сүзләре әйтмәвенә, уен-көлке белән шулай кызык тапкан булып әрепләшүләренә, гамьсезләр дип, башта сагаеп, сәерсенеп үк алган иде инде. Аларның бу гамәлләре үзе өчен икәненә төшенгәч, ул эчтән торган саен ризалыгы арта барып, куанып, күңеле рәхмәт хисләре белән тулуын тоеп утырды.

— Идарәгә ник чакырткannар? — диде Идрис. Ул, әйтмәсәң дә ярый дигәндәй, ак ботакның урта жирен һич көчәнүсез уя бирде.— Кичә култык астыңа төенчек кыстырып меңдең бугай. Социалистик милеккә кул сала башламагансыңдыр ич? Анда, ындыр табагында, нәфсеңне котыртырлык мал байтак.

— Култык асларын тикшерер көнгә калдыңмыни инде?

— Ник чакырткannар соң? Минем тимер аякны кәжүнни дип белгәннәр, ә? Бар әле, имеш, Хаммат — синең күршең, әйт әле аңа: сәгать жидегә телефонга дәштеләр, янәмәсе. Срочно килеп житсен, имеш!

Хаммат тагын йөренеп килде. Идрис артына басып, аның юнганын иелеп карап торды.

— Латвиядән дәшкәннәр дисәм, ни әйтерсең? — диде ул.

— Латвиядән? Ник идарәгә чакырткannар, ник авыл советына түгел?

— Кичке жидедә нинди авыл советы? Бикле ич инде ул.

Идрис аны үтә бер үҗәтлек һәм ләззәт белән аптырата бирде:

— Шуннан?

— Шуннан... дәшкәннәр — шул.

«Дәвам ит» дигәндәй, Идрис аңа күтәрелеп карады. Хаммат бу сорау алуның шаярту икәнен аңлый, ләкин шул шаяруда баш бирү аның җенене тия иде — Сөнгатулла үз күршеләренең холык-фигылен яхшы белә.

— Ник дәшкәннәр? — диде Идрис. Ул Хамматның сөйләп бетерәсе килгәнен сизә, ә мондый чакта бераз өскортып тору фарыз. Ул, чалбар балагын күтәреп, юнып бетергән агачның уелган жирен тимер аягына куйды да, әйләндергәләп, пычак сабы белән тукмап йомшартырга, кыздырырга тотынды.

— Ник дәшсеннәр? — жырларга! — дип, Хаммат «Әлбәттә, жырларга, тагын нигә булсын!» дигән кыяфәт белән үз урынына килеп утырды.

— Жырларга?! — диде Сөнгатулла. Ул: «Болар ни кыландыра?» дип аптыравын бер мизгелгә онытты да кебек. Аны: «Болар ни сөйли?» дигән кызыксыну басты. Ул, әйтерсең лә, тыны житкәнче тирән су төбенә чумган да, ниһаять, өскә калыккан, күкрәген тутырып сулыш алган, хәзер ярга таба йөзә һәм каты жиргә аяк басачак, аннары көт-

кән кешеләре янына барачак — ул үзендә менә нинди җиңеллек, иркенлек, хәтта омтылыш уяна башлавын сизенде.

Бу юлы Муса түзмәде:

— Җидегә дәштеләр дисезме әле? Наряд вакытындамы? — диде.

— Наряд түгелие шул. Идарә утырышы бара ие. Ян өстәл башында районнан килгән бер эшләпәле дә утыра. Килеп керәм. Латвиядән телефонга дәшкәннәр, мәйтәм, көтим әле. Ярый, көт, диделәр. Утырдым. Көтәм. Аны-моны сөйләшсәләр дә, тегеләрнең дә күзе телефонда. Алар да көтә. Шуннан — чылтыр-р-р, алам: «Вас вызывает Дуболт».

— Дубулты,— дип төзәтә Муса.— Ерак җир, начар ишетелгәндер.

— Булыр сиңа начар! Почмактан хатын дәшкән ише генә. Карасам — Хәйдәр Монасыйпов.

Хәйдәр Монасыйпов — алар авылыннан, шушы очтан чыккан язучы иде. Китапл*ары басыла, аның хакында газеталарда язып, радио, телевизордан сөйләп кенә торалар. Әмма авылга кайткан чакларында бер дә алай, «мин язучы», дип тәкәбберләнеп йөрми: тездән ләм, билдән су ерып балык тота, көзен кайтса, сазлык бетереп, үрдәк атам, дип йөри. Өйләре йозакта, ачкычы Хамматларда.

— Кара син аны! Ул бот күтәреп, түшәмгә төкерә-төкерә ял итеп ятсын, ә мин монда аксый-туксый, Хамматны телефонга дәшәргә йөгерәм! — дип, Идрис артка борылды да чартлатып төкереп куйды.

— Ял тими аларга, сөйләгәне бар. Язалар. Көнгә унбишәр сәгать утырам дигән була.

— Кайчан гына йоклый икән соң ул?

— Анысын хатыныннан сора инде, күрше.

— Я, ни диде соң, ни диде?

— Теге чакны кызың туенда җырлаган җырыңның сүзләрен әйт әле, онытты ди бу. Күзем маңгайга менде, җәмәгать! Кемдә нәрсә кайгысы, ә?!

— Туктале, тукта! Ул туйга биш былтыр иң инде — ничек онытмаган, ә? Ну баш та бар инде үзләрендә, kah-hәр!

— Онытмаган? Онытканга соравы ич инде.

— Сүзләрен диң, ә? Әйттеңме соң?

— Әйттем — җырлап ук бирдем!

— Ә идарәдәгеләр? Көлделәрме? Көлми ни — адәм страмы бит! Җәһәннәм астыннан җыр даулап шалтыратмаса...

— Көлмәделәр, парин.

— Предтән эләккәндер үзеңә. Уттай эш эстендә утырышларын бүлеп, телефонга җыр җырлап яткач.

— Эләкмәде. Җырладылар алар. Кушылып. Район начальнигына хәтле җырлады. «Вәт!» — диләр. Тегене мактыйлар. Халыкны ярата, янәмәсе.

— Халыкнымы, әллә синеме?

Хаммат йодрыгын яссы күкрәгенә дыңгылдатып сугып алды:

— Мин халык түгелмени? Халык!..

Идрис агач ботагын чүкеп бетерде, йомычка арасыннан таяк башы актарып тапты да чалгы бөгәлҗәсен ботинкасыннан чишеп алган шнур белән сак кына шуңа кигертеп бәйләп куйды.

Шушы рәвешчә күз бәйләнгәнче сөйләшеп утырдылар. Тукай бабасының кочагына елышып, изерәп йоклый иде инде.

Ишегалдыннан Зөлхиҗәнең әкрен генә:

— Сөнгатулла,— дип чакырганы ишетелде.

— Керәм,— дип эндәште ул. Тукайны кочаклаган кулын алып, аны атасына таба авыштырды. Оныгы йомшарган һәм жылы иде.— Ярый, вакыт,— диде ул әңгәмәдәшләренә. Торды, учына йөткергән булып, аларның җавабын көтте.

— Яхшы,— диде Идрис.— Кер.

Алар утырып калды. Сөнгатулла аларга да кереп китәргә вакыт икә-

нен аңлады. Ләкин аның артыннан ук кузгалышмадылар. Югыйсә, аның өчен генә, аның күңелен күреп, аны юмалап кына утырганнар булып чыга бит.
— Керәм,— дип кабатлады ул капканы ачканда. Ишегалдындагы әнгер-меңгердә Зөлхиҗә басып тора, актан киенгән, култык астына ак сөлгегә уралган төенчек кыстырган. Сөңгатуллага эчке киемнәр тоткан, күрәсең.
— Әйдә,— диде Зөлхиҗә.
Алар мунчага таба юнәлделәр. Мунчаның пәрдә эленгән тәрәзәсе тоныкъ кына яктырып, уты яссы ташларга төшкән. Зөлхиҗә артыннан мунчага Сөңгатулла да керде.
Алачыкта җылы, җыйнак иде. Кадагаларда пар-пар каен һәм имән себеркеләре, мәтрүшкә бәйләмнәре элеп куелган. Шулар астында бер-берсенә күз салмыйча, тын гына, тик оялмыйча, моның инде бөтенләйгә, ахырга кадәр шулай булачаган икесе дә аңлап чишенделәр. Теге чактагыча, бик күптән, тормышларының иң башындагыча, беренче тапкырдагыча кебек иде...
Озынча эскәмиядә термос, бер пар ак чынаяк. Почмакта күгәрмәс калайдан ясалган мичкә, аңа салкын су салынган, эмаль чүмеч эленгән.
Зөлхиҗә эчкә үтте, җайлы утыртылган ишекне үз артыннан ашыгып япты. Сөңгатуллага кайнар дулкын килеп ягылды. Бар нәрсә тынып калды. Ул шундук кереп китмичә, бераз басып торды әле. Зөлхиҗә җайлыйсын җайласын, үзе урнашсын, аның янәшәдә икәненә күнексен, озакка сузылган ялгызлыгыннан арынсын, элеккеге уйлары белән хәзер сөйләшәсе сүзләре арасындагы күперне узсын. Су тавышы ишетелде — Зөлхиҗә ләүкәнең кайнар такталарына салкын су койды һәм кайнар судагы себеркесен әйләндергәләде ахрысы. Сөңгатулла мәтрүшкә чәчәгенең бер тармагын өзеп, татлы исен иснәде. Аннары пинжәк кесәсеннән пыяла савыт чыгарып, учына ике дару сәдәбе бушатты да тиз-тиз йотып җибәрде. «Вакыт»,— дип тынычландырды ул үз-үзен һәм теге чактагыча, бик күптән, уртак тормыш башлагандагыча шаяртып сүз катуларның, яшерен карашларның, якынлыкның инде беркайчан да кабатланмаячагын аңлады. Теге чакта алар беренче тапкыр икәүләшеп кара мунчага кергәндә юка бозга аяк баскан шикелле булган иде. Хәзер аяк астында калын, нык идән иде инде.
Сөңгатулла эчкә узды. Алар усак такталарыннан ясалган тәбәнәк эскәмияләрдә тирләп утырдылар.
Ә бит шушылай үз-үзләрен һәм бер-берсен яхшы тоеп, тыныч кына уйланган һәм көткән мәлләрдә Зөлхиҗәнең җырлап җибәргән чаклары да бар иде!

Баш куям тезләреңә,
Яшь коям эзләреңә.
Әллә ниләр бирер идем
«Аһ!» дигән сүзләреңә...

«Аһ!» итүләр бүтән булмас инде.
— Мунча яхшы,— диде Сөңгатулла.
— Яхшы,— диде Зөлхиҗә.— Тик безнеке дә ким түгел иде.
— Әйе, дан тотарлык иде.
— Чабын,— диде Зөлхиҗә.— Себерке гөбердәп тора.
— Ә син?
— Мин аннарырак. Миңа кирәкмәс тә инде,— дип, Зөлхиҗә аягына басты, әмма бөтен буена түгел. Әйтерсең лә түшәм аңа тәбәнәк иде. Түгәрәк алюмин табакка алмаш-тилмәш кайнар һәм салкын су салды. «Алсу» дигән шампунь савытының бөкесен борып ачты.
Сөңгатулла утырган җиреннән:
— Каяле, хатын! — диде.

— Нәрсә?
— Ят!
— Кая?
— Ләүкәгә — кая булсын ди тагын!
Сөнгатулла себерке җебеп яткан озын цинк тагарактан чүмеч тотып су алды да, мич капкачын ачып, ташларга су җилпеде. Ишек ачылып ук китте, бөтен мунчаны, резин шар кебек, өреп тутырган кайнар пар ише булды. Үпкәләр тыгыз кайнар пардан кысылып килде.
— Ят дим мин сиңа! — дип кабатлады ул һәм себеркесен соңгы тамчы суына кадәр баш очында селеккәләп какты.
— Әйдә мин сине чабындырам,— диде Зөлхиҗә. Ул, парга чыдамыйча, башын игән дә куллары белән кочкан, гүя кемдер сукканны көтеп, бөрешеп утыра иде.
— Ятар идең соң,— диде Сөнгатулла үпкәләгән шикелле.
Зөлхиҗә ләүкәгә менеп, йөзтүбән сузылып ятты. Сөнгатулла аның тәне буенча себерке йөгертеп узды. Зөлхиҗә «уй!» дип куйды, әмма түзде, тәне җыерылып килде, тик шундук йомшап та төште. Сөнгатулла аның тәненең күзгә күренеп кызаруына сөенде. Себеркене торган саен кискенрәк бәргәләп, тагын ике мәртәбә чапкач, ул чүмечкә салкын су чумырып алды да, кыска гына селтәнеп, Зөлхиҗәнең аркасына җилпеде. Хатыны тагын «уй!» дип кычкырды, тәне тагын башта киерелеп, аннан рәхәт йомшап төште.
Шуннан соң ул чалкан әйләнде, тулысы белән себерке ихтыярына буйсынды.
— Ә хәзер чыгып чәй эч,— диде Сөнгатулла.— Миңа да ясап куй.
Күптән мунча кергәне булмаганга, ул озак чабына алмады, бераз юангач, Зөлхиҗә янына алачыкка чыгып утырды. Өрә-өрә бөтнекле чәй эчтеләр.
Элеккеге кайнарлыкның, дәртнең эзе дә калмаган икән. Алар икесе дә гап-гади юыну кирәклеген генә үтәделәр. Мунча б и р ә торганны бөтен тулылыгы белән а л у теләкләре суынган. Фәкать һәркайсы үз алдына бер-берсе хакында уйлады һәм ул уй аларның уртак кайгысы белән өртелгән иде инде. Авыр иде.
Сөнгатулла хатынының кызарган, су һәм тир тамчылары белән булган йөзенә карамаска тырышты.
Алай да бик рәхәт иде!
— Юыныйк инде,— диде Зөлхиҗә.
— Юыныйк...
Тагын эчкә уздылар. Мунча пары йомшарган иде, каен яфрагы исе бөркелеп тора. Зөлхиҗә бармаклары белән таманлыгын чамалый-чамалый ике табакка да су салды, мунчаланы гөбердәтеп сабынлады, әйләнмичә генә аңа сузды. Ул алды да аның янәшәсенә үк басып:
— Әйдәле, карчык, сине үзем юындырыйм әле,— диде.
— Арканы гына у.
— Юк, баштанаяк дим.
Зөлхиҗәнең аркасы тураеп килде, тәне сагайды.
— Ник? — диде ул.
Һәм Сөнгатулла үз хатынын баштанаяк юындырып чыкты. Тез чокырларына житкән озын, әмма юкарган чәчен юарга кыймады, юа алмавына төшенде. Кешеләр үз чәчләрен үзләре юа. Сөнгатулла хатыны Зөлхиҗәне үз гөнаһларыннан арындырырга теләгән шикелле юындырды. Ул моңарчы бер-берсеннән үзләренә алырга мөмкин булганны ахырынача алып бетергәннәрен аңлады. Бер-берсенә кирәк булган һәр нәрсә бирелеп беткән икән инде.
Алар мунчадан бергә чыктылар. Зөлхиҗә агарып болдыр баскычыннан күтәрелде дә карангылыкка кереп китте. Ә Сөнгатулла беркавым ишегалдында басып торды әле, күкне күзәтте. Йолдызлар ачык күренә, аңлаешлы иде.

Шуннан соң төпчек улы Фәрһад кабере янына китте. Авыл тәмам тынып, айның яшькелт нурында оеп ята иде инде. Зиратта чикерткәләр генә зыңлый, әллә нидә бер карга тынычсызланып, каркылдап куя, кайдадыр ялгыз эт өреп ала, елга ягыннан су аккан тавыш килә. Дөнья тыныч, ә җан елый иде.

Урам ягыннан зират рәшәткәләренә тотына-тотына кайтты. Кайберләре, җепсәнең череп тузган, кипкән урындагылары какшаган, кайсылары кубып ук чыккан икән.

«Алыштырасы булыр,— дип уйлады ул.— Җепсәләрен алыштырасы, рәшәткәләрен кагасы». Кеше таянган һәр нәрсә нык, ышанычлы булырга тиеш!

Мәйсәрә киленнәре аларга урын-җирне олы якка җәйгән. Үзләре кече якка ятканнар. Мәрзия белән Тукай диванда. Ай яктырткан нык идәннән сак кына басып түргә узганда ул Тукайдан кала берсенең дә йокламаганын тойды. Көткәннәрдер.

Аны әле тынычмы, тынычсызмы икәне билгесез йокы басканда Зөлхиҗәнең яшьле керфекләре ачык иде әле.

Иртәгесен ул беренче эш итеп елганың биек, текә борылышы турысындагы тугайга бозау арканларга китте. «Ниме дип бу су буенда каңгырып утырырга әле?»

— Кайтыйм мин, бозау,— диде ул. Аркан казыгын каккан тукмагын аяк очы белән куерак үлән арасына тәгәрәтте. Гадәттә ул аны үзе белән йөртә иде. Ул арканлаганда гына хаҗәт, шуңа күрә иртән апкайтасың. Элек кичен бозау алмага килгәндә казыкны суырып кына чыгара торган иде. Бүген һәм моннан соң да шулай итәренә ышанмады. Көче бүтән иде инде. Хәзер җай белән генә, иплә кенә кирәк. Ни белән каккан, шуның белән бәргәләп чыгарырга туры килер.

— Анда нишләрмен соң инде? — диде ул авыл ягына карап. Кичәге төнне исенә төшерде. «Зират коймасын тәртипкә кертсәм генә инде».

Муса яңа рәшәткәләр кайтарып, кояшка киптерергә өйгән, җепсәлекләре дә бар, баганалыклары да байтак. Савaплы эшкә тоткан өчен сүз әйтмәс.

— Мин дә хуҗа ич әле,— диде ул.

Кайтып җиткәч, зират коймасының кайсы җепсәләрен, күпме баганасын алыштырырга, ничә рәшәткә кирәклеген чамалап чыкты. Балтаны кайрагач, чүкечнең сабы ничек утырганын сынагач, кадакларны барлагач кына эшкә кереште. Яхшы коралны ул, гармун шикелле, иплe булырга тиеш дип белә.

Кайбер көнне алыштырасы черек җепсәдәге рәшәткәләрне кубарды, аннары җепсәләр юнып, баганаларга беркетте; кайсы көнне, төбен казып, яңа багана утыртты, тигез итеп рәшәткәләр какты. Үзе генә түгел, оныгы Тукай белән бергәләшеп. Җепсәнең юан башын үзе күтәрә, нечкә очын Тукай тота. Баганаларны уртаданрак күтәрергә тырышты, оныгына көч килүен теләмәде. Рәшәткә ташыганда гына аларның көче тигез кебек иде — һәркайсы көченнән килгәнчә ала. Иске рәшәткәләрне ягa бардылар. Баганаларны, җепсәләрне койма астына салып калдырдылар.

Утырып бер ял иткәндә Тукай:

— Утынга ярамыймыни болар? — дип сорады.

— Ярамый шул.

— Ник ярамый?

— Ызгыш чыкмасын дип.

— Нинди ызгыш?

— Зират ул бөтен кешенеке бит, олан. Аның һәр әйберсе җәмәгатьнеке. Җәмәгать әйберсен бер генә кешегә алу килешми,— диде Сөнгатулла.— Сүзе чыга аның. Ә сүз арасына ызгыш кушылуы бар.

— Искеләре урынына без яңаларын кагабыз ич. Үзебезнекен!

— Ярамагач ярамый инде, улым. Без аңа калганмыни?

Сөнгатулла үзен тынычландырырга тырышып эшләде. Зөлхиҗәнең алҗырсың, өзлегерсең дигәненә дә карамады. Муса белән килененең эндәшмичә генә юл куюына да кимсенмәде. Ул зират турысыннан узып киткән кешеләрнең үз хакында ни уйлаганнарын, я ни уйламаска тырышуларын да чамалады: берәүләре үләргә әзерләнә ди бугай, икенчеләре: «Кара моны, бирешәсе килми, үҗәтләнә!» дип гаҗәпләнәдер. Ә ул үзе фәкать тынычланырга ниятләп йөрде. Йөрәге тыныч кешегә көн дә бәйрәм ул.

Беркөнне озаклап яңгыр яуды. Ул яшен яшьнәүгә, башта бәреп, аннары коеп яуган яңгырга тәрәзәдән карап утырды, озаклап пыскырга керешкәч, тәрәзә төбендәге китапка күзе төште. Кулына алды. Лев Толстой томы икән, русча. Сөнгатулла диванга барып ятты. Башта сакаллы картның рәсемен карады, аның тирән карашлы күзләрендә чагылып торган акыл чаткысы әсәрләтте. Әйтерсең лә үзенең көзгедәге төбәп баккан күз карашын күргәндәй булды. Аннары ул арткы биттәге эчтәлекне укыды — ни язган икән? Андагы «Яшәү турында» дигәне кызыксындырды. «Кая әле!»,— дип уйлады ул һәм, укуы авыр булса да, торган саен бирелеп китеп, яңадан тәрәзә янына, яктыга күчеп утырды.

«Үләрмен, гомерем бетәр дигән фикер башыма килә дә газаплый һәм куркыта, чөнки үзеңә-үзең кызганыч. Ә нәрсә үлә? Миңа ни кызганыч? Гап-гади итеп караганда, мин кем?»

Сөнгатулла әллә нишләп китте. «Димәк, мин, Сөнгатулла Гәрәй улы да кызганыч инде, ә? — дип уйлады ул.— Тукта, ник алай булсын?» — дип карышты, теләктәшлек эзләп, алга таба укуын дәвам итте.

«Ләкин беркем дә егерме ел элек булган кебек түгел бит, һәркөнне үзгәреп тора. Миңа ни кызганыч соң? Юк, тегесе дә, бусы да кызганыч түгел, диләр. Үземне аңлавым, үземне м и н иткән нәрсә кызганыч».

Сөнгатулла бераздан бу катлаулы, ләкин соңгы көннәрдә якын, фәкать үз күңелендә генә яшәгән аермачык фикернең бик гадиенә, аңлаешлысына тап булды. «Керә торган капкадан кергәнсең, ә чыга торганыннан чыгарга теләмисең... Беләсең бит, бу син туганда гына барлыкка килгән нәрсә түгел: ул синең җан иясе буларак тууыңа бәйле түгел һәм шуңа күрә аның үлеменә дә бәйле була алмый».

Яңгыр вакытында Сөнгатулланы йокы баса башлаган иде, китап аны сагайтып, айнытып, уйларын яктыртып җибәрде. Юк, ул үз хәле белән килешмәде, китапта үзенә таяныч, юаныч эзләмәде. Ә менә яшәүнең мәңгелек икәненә тагын бер тапкыр ышанды, шуны аермачык күз алдына китерде. Менә ич: ул, үләчәге тәгаен билгеле кеше, зират коймасы төзәтә! Бу бит иң элек аның  ү з е н ә  түгел, бәлки башка кешеләргә кирәк.

Гаҗәп, Сөнгатулла бу юлы үзе турында: «Үләчәге тәгаен билгеле кеше», дип уйлаудан качмады. Ләкин бөтен тәне һәм аңы белән, «кешеләргә кирәк», диюенә каршы төште. Аларга гына түгел. Җир йөзенең нинди торуына исәннәр белән бер тигез дәрәҗәдә үлеләр дә җаваплы. Шул исәптән зиратларның ничек торуына да. Торачагына да! Шунсыз эшеңнең тере чагында да кирәге юк.

Тормыш. Ул әнә нинди икән! Элек ул, авырмаганда, йөрәге тибүен сизмәгән дә шикелле йөри иде. Ә  т о р м ы ш  нәрсә соң ул? Толстой, бәлки, хаклыдыр да. Акыллы язган. Нәкъ менә сине юаткан сыман. Әйе, яшәлде. Сөнгатулла үз-үзен беркайчан кызганмады. Үз гомерен сугышта да кызганмады, эштә дә жәлләмәде. Гомер аңа, тиздән бу дөньядан китәсен аңлагач кына, кызганыч тоела башлады. Анысы да су, агач яфраклары шавының, аяк табанын рәхәт кытыклаган үлән салкынлыгының, мунчада каен себеркесе белән чабыну ләззәтенең үзеннән соң да каласын ачык күз алдына китергәч кенә. Ә хәзер, улы Фәрһад һәлак булгач, аңа үз гомере бөтенләй кызганыч тоелмый иде инде. Аңа анасы:

«Үз балаларыңның үлемен күрергә язмасын, я ходаем!» дип теләк тели иде. Язмыш шуңа дучар итте. Хәзер ул анасы теләгән бу теләкнең барлык авырлыгын һәм авыртуын татыды. Ни үзгәрде соң? Сөнгатулланың үз-үзен кызгануы улын кызгану белән алышынды — менә ни үзгәрде. Ә бу кызгану аны таштай бастырып тотмый иде инде. Гаделлек тантанасы, башка кешеләр гомере хакына эшләнгән эше белән кешеләр арасында калган улы Фәрһад өчен горурланырга гына була. Сөнгатулланың нәрсәсе үзгәрде соң? Ул тормышның мәңгелек икәнен аңлады: су ага да, кала да. Фәрһад юк инде. Анык каравы Муса белән Мәйсәрә яңа кеше каршыларга әзерләнә.

Сөнгатулла аз йоклый башлады. Көндезләрен талчыгып, черем итәсе килгәндә дә кайтып йокламады. Чын-чынлап яшим дигән татар кешесен йокы чире борынгыдан читләтеп үткән. Йокы — үлемнең агайэнесе. Беркөнне, ничектер шушы хакта сүз кузгалгач, ул Тукайга:

— Иртәнге вакыт — көннең яшьлеге, өйләгә кадәр — балигълыгы, төштән соң ирлек чоры житә, кич картлыкка тиң, ә төн исә көннең үлеме,— дип аңлатты.

Оныгы:

— Көн үлмәсен өчен төнлә әз йокларга кирәкмени? — дип сорады.

— Кирәк кадәр йокларга ярый. Тик йокың уяу булсын — үлем төнлә сагалый.

— Ә Фәрһад абый? Ул тугры булган!

— Шуңа күрә дә герой. Герой кеше үлми ул, олан.

Фәрһад... Фәрһад! Озакламый авыл Советы председателе Вәлиша Хужин аны кичке жыелышка чакырды. Районның хәрби комиссары киләсе икән. Нигә икәнен әйтмәде: моны бөтен авыл халкы белә иде.

Бөтен гаиләләре белән бәйрәмчә киенеп бардылар. Культура йорты халык белән шыгрым тулы. Анда ниләр булганына, кемнең нәрсә сөйләгәненә Сөнгатулла төпченеп илтифат итә алмады. Сәхнәдә үзе белән янәшә утырган Зөлхиҗәне йөрәге тотмасын дип юаткалады, колагына иелеп, әледән-әле тынычландырырдай сүзләр әйтергә тырышты. Төпчек уллары Фәрһад Тимершиннең Алтын Йолдызын һәм Ленин орденын ата белән анага кулларын ике куллап кыса-кыса биреп жибәрделәр.

Икенче көнне алар орден белән Алтын Йолдыз медален бергәләшеп Фәрһадның армиягә киткәнче кешелеккә киеп йөргән куе зәңгәр костюмына тагып куйдылар. Елашмадылар. Әйе, елашмадылар. Чөнки алларындагы уллары фоторәсемнән елмаеп, ә яннарындагы оныклары куанып тора иде.

Фәрһад! Фәрһад... Аның кабере турысындагы койманы төзәткән чагында Сөнгатулла багана төбен үтә ярсу казыды, баганаң иң тазасын утыртты, жепсәнең иң турысын сайлады, рәшәткәләрне бар дөньяны уятасы, уяу тотасы килеп, иң яхшы дусларга да, иң начар дошманнарга да ишетелерлек итеп, бар көче белән какты.

Шушыннан соң Сөнгатулла Тимершин бер ел да егерме өч көн торды. Әйе, торды. Ә яшиселәр алда калды, алда.

Бу дөньяның ул ишеткән соңгы тавышы былтыр олы жирдән аерылган яр башының тере үлән тамырларын өзә-өзә, тоба суына убылып төшүе булды.

Каршы сөзәк ярга яңа катлам ком һәм ләм утырганын ул язгы ташулар узгач күрде.

Ә аңа кадәр, узган елның кыш башында, ул икенче оныгы — яңа Фәрһадның дөньяга килү авазын ишеткән иде.

*Әлмәт, 1985*

## Равил Мирхәйдәров

# ОРЕНБУР ШӘЛЕ

ХИКӘЯ



Әледән-әле Фәрит сулышы белән туң тәрәзәгә өргәләп утыра. Калын бозда, ниһаять, «күз» ачылды. Тик әнкәсен ул аннан да күрә алмады. «Бүген дә поезд соңлаган, ахрысы»,— дип уйлады Фәрит пошынып.

Быел кыш суык һәм карлы килде, шуңа күрә тәрәзә пыяласын сыр-сыр боз каплап алган иде. Аннан әллә ни яктылык үтмәсә дә, ишектән өргән кебек салкын бәреп тора. Фәрит, аның каршында утырып тәмам туңгач, исенә төшеп, бусага белән ишек арасына кыстырылган иске юрган кисәген рәтләргә кереште. Шуннан кереп кай арада җир идәнгә сыланып өлгергән ап-ак кар «онын» себереп алды. Бу хәлне ярый әле әнисе күрми калды, югыйсә бүген дә, «ник ишекне яхшылап ябмадың, ник өйне суыттың» дип ачуланыр иде. Әйе, җылысы бетеп барган мич авызына хәзер үк бер-ике шакмак кизәк ташласаң бик ярап куяр иде дә, «кизәкне бетерәсең» дип әнисенең тиргәвеннән шүрләде Фәрит. Кышның әле уртасы да җитмәгән диярлек, ә кизәктән сарай почмагында туфрак өеме генә калып бара. Киләсе базарга кадәр ягулыклары әллә җитәр, әллә юк.

Шуларны уйлый-уйлый, Фәрит өйнең иң җылы урынына — мич буендагы сәке түренә менеп утырды һәм әнисе кушып калдырган эшне дәвам итте. Ничәнче көн эшли инде Фәрит, ә кылыннан арындырасы кәҗә мамыгы һаман кимеми. Киресенчә, кулга тоткан, язгалаган саен ишәя генә сыман. «Дебет эше үрчемсез ул» дип тикмәгә генә әйтмиләрдер шул. Дебет шәл бик җылы, бик йомшак та бит, мәшәкате күп шул аның. Иңгә салганда йомшак тоелсын, кабарып, күпереп тә торсын, ә үзе балдактан үтәрдәй юка да; җиңел дә булсын өчен аңа күпме кул көче керә, күпме күз нуры түгелә. Фәрит бер кат язып, кылдан аралаган ул дебет-мамыкны әле Гөлсем апа үзе дә тагын бер кат тетәр, язар — ая агачына ике рәт итеп чәнчеп куелган камыт энәләре аша кат-кат чыгарып аялар, түбереннән арындырыр. Аннары Фәния апасы аны бик оста итеп эрләр, бәйләгәндә өзелмәсен дип неп-нечкә фабрика җебен — «пу-

---

РАВИЛ МИРХӘЙДӘРОВ (1941) — *прозаик, рус телендәге «Оренбур шәле», «Безне онытмагыз», «Дамба» һәм башка китаплар авторы. Ташкентта яши.*

тинкә»не кушып катар. Шуннан соң гына Гөлсемдәй түзем, оста шәлчеләр аны һәркем сокланырдай иттереп «дебет шәл»гә әверелдерерләр.

Фәрит өй эченең тәмам каранғылана, шомландыра баруын тоеп, «нишләп Фәния апам кайтмый инде» дип тә борчылды. Дөрес, төштән соң укучы сигезенчеләрнең ара-тирә соңлап кайтуын да беләү ул. Тик әниләре дә кайтмаган көнне нишләп соңлый соң әле Фәния?

Башка көннәрдә дә Фәрит өчен иң бәхетле, иң рәхәт вакыт кичке чәйдән соң гына башлана диярлек. Нәкъ шул сәгатьләрдә инде әнисенең дә көндәлек ыгы-зыгысы тәгәлләнгән, Фәния апасы да кайткан була. Алар тиз-тиз генә ашап-эчәләр дә, җылы сәке өстенә, мелт-мелт килеп янган керосин лампасы тирәсенә утырышалар. «Дебет эшен» бергәләп дәвам итәләр. Гөлсем апа шунда, күңелләрен җилкендереп, эшкә тагын да һәвәсләндереп, балаларын мактап та куйгалый.

— И улым, күзең очлы шул синең, бөтен Мәрдүктә дә синдәй оста кыл чүпләүче юктыр,— дигән була. Сәке читендәрәк мыштым гына мамык тарткалап, зур каба янәшәсендә җеп эрләп утыручы Фәния дә өлешсез калмый, билгеле.

— Бармакларың шул чаклы сизгер, җебең тигез, кызым, шәлче булып тугансың син,— дип мактый аны әнисе.

Хәер, аларны әниләре генә түгел, күрше-күлән дә һәрчак хөрмәт белән телгә ала, «бигрәк сүз тыңлаучан үзләре, йомышка йөгереп кенә торалар» дип сөйли.

Ә инде өч хатынның берсе шәл бәйләп көн күргән Мәрдүк бистәсендә Гөлсемнең иң уңган шәлче икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Аның шәлләре һәрвакыт тиз кабаручан, тигез бәйләнгән һәм матур бизәкле булалар. Чөнки ул бер бизәкне дә ашык-пошык эшләми: үзенә үзе бик таләпчән. «Күз» төшерә-төшерә шәл бәйләүчеләрне җене сөйми аның. Җиренә җиткереп эшләргә иренәсең икән, алынма!

Әнә бит бистәнең иң көяз һәм иң көйсез хатыны кибетче Нюра Кожевякина да Гөлсемгә ялына. Югыйсә, Мәрдүктә «сатучы Нюрка» белән эшнә булырга теләүчеләр азмыни? Күп алар, берсе дә кибетчене кире бормас иде — хәзингә әлегә ул баш, ул хуҗа. Ул сиңа бер үк әйберне күп итеп тә, «тамызып кына» да җибәрә ала. Шундый кире беткән, үзсүзле кеше инде Кожевякина. Ә менә бер букча мамыгын күтәреп үзе Гөлсемне эзләп килгән. Фәритнең әнкәсе бу хәлгә бик сөенде, билгеле. Шулай да әүвәл:

— Нүрә, дебетең әйбәт күренә, төсе дә бик килешле икән. Кушып катарга шундый күмгелт төстәге путинкәм дә бар-барын. Тик мамыкның кылы ишлерәк күренә: кимендә ике атна чүплисе булыр. Йомышыңны тиз үти алмам. Өстәвенә, өч шәлне килешеп эшли башладым, хакын инде китерделәр... Нишлим икән? — диде.

— Юк, юк, көтәрмен, миңа бит ул бүген-иртәгә генә кирәкми әле, Гөлсем. Аллага шөкер, иңемдә шәлләрем бар. Син былтыр бәйләп биргәнне дә күргән берсе мактый, кайчан бәйләттең, өр-яңа бит диләр. Бусының төсе матуррак, шуңа гына кызыккан идем.

Шулай диде дә Нюра, бер мәл тирә-якка карангалап сабыр гына утырды, аннан соң Гөлсем бөтенләй киреләнмәсен диптер инде:

— Бәйләү хакына бер пот оным әзер,— дип өстәде. Ә үзе борылгалап, саман өйнең карланган почмакларын тагын бер кат күздән кичерде.— Караңгы төшкәч Фәрит минем яныма килсен, сабын әрҗәләрем бар не, алып китәр.

Нюраның күңеле йомшаруын шәйләп өлгергән Гөлсем шунда:

— Бер такта чәй белән чак кына шикәр дә өстә инде, җаным, дебетеңнең эше күп ич,— диде.

Нюрка бер мәл түшәмгә текәлеп торды да әйтте:

— Килештек. Онны хәзер үк барып аласыңмы?

— Хәзер үк, Нүрә, хәзер үк! — дип, Гөлсем апа ашыга-ашыга киенеп чыгып та китте.

Бу сөенечтән тыела алмыйча Фәрит җир идәндә биеп алды. Он! Димәк, иртәгә әнкәсе аларга төче күмәч пешерәчәк...

Инде шул Кожевякина төенчеге белән атнадан артык утыра Фәрит. Тикмәгә генә чәй-шикәрләр өстәргә килешмәгән икән шул кирпечтәй кызыл битле, мичтәй юан Нюра түтәй. Мамыгы энисе чамалаганнан да чүплерәк, түберлерәк икән ләбаса.

— Нүркә алдатмас,— диде кич утырырга кергән күрше казах хатыны Науша апа да.— Дебетне дә бит ул безнең авыл картларыннан чәй-шикәргә генә алышып ала.

Гөлсемнең никтер бу сөйләшүне дәвам иттерәсе килмәде. Янар-янмас ут яктысында күз нярмәс тизлек белән озын шәл энәләрен йөртүен генә белде. Бу тынлыкта ике нечкә энәнең бер-беренә бәрелгәләп чеңчек иткәләүләре генә ишетелгәли иде. Фәния белән Науша апа исә, үз эшләреннән аерылмастан, ара-тирә аңа карап куйгалыйлар. Андый чакта Фәниянең ачык йөзеннән: «Мин дә шулай матур итеп бәйли алырмынмы икән?» — дигәнне генә шәйләп була. Энисе малаеның дебет кылы чүплим дип, лампа куыгына борын төртеп утыруын күргәч, Фәриткә карап:

— Тагын бөкрең чыгаргансың, бабаймы әллә син? Кызлар сөймәс үзеңне,— дип кисәтте.

Бу кисәтүдән соң Фәрит чак кына артка чигенгәндәй итте, инбашларын турайтып куйды. Тик, каһәр төшкере вак кыл бөртекләренең мамык артына сыена-сыена яшеренеп калырга тырышулары сәбәпле, ул тагын ут яктысына тартылырга, бөкресен чыгарып иелергә мәҗбүр булды.

Мондый «күңелле» кич утыру кичә булды. Ә бүген Фәрит энә бер ялгызы калды. Боз каткан кечкенә сыңар тәрәзәдән кергән яктылык сүрелгәннән-сүрелә бара. Энисе белән апасы һаман да күренмиләр әле. Кичке эшкә утырганчы дәрес хәзерлисе дә бар ич Фәритнең. Нишләп болай соңлый соң бүген энисе? Фәрит инде ике-өч мәртәбә тышка чыгып та карап керде аны. Шулай йөри-йөри өйне тәмам суытты да шикелле. «Әллә поезд бик әзгә туктаганга, теге вакыттагы кебек төшә алмыйча, күрше станцага чаклы киттеләрме икән? Шәл бит ул бияләй түгел, куеннан чыгару белән сата алмыйсың аны. Вагоннан-вагонга йөри-йөри дә арып беткән чаклар була. Әгәр шунда берәр усал кеше очраса, тартып алып китсә!» — дип борчылды малай.

Әйе, андый хәлләр дә ишетелгәли әле. Сугыш бетүгә инде ел тула, ә андый яман халык һаман кимеми, хәтта ишәя сыман әле.

Хәер, станциядә шәл белән сату итәргә ярамаганны, милициянең аратирә аны «конфисковать» иткәләвен дә белә Фәрит. Ул, күрше Рәбига карчык төсле, битен сыпырып алды да, «бүген Вәлиҗанов абый дежур торсын иде» дип пышылдады. Энисе Гөлсем беркөнне үк инде: «Алышбиреш итүчеләрне станцага ияләштергәне өчен имеш Вәлиҗанны эшеннән алалар икән», дигән яман сүз ишетеп кайткан иде. Ул китсә, хәлләр мөшкелләнәчәк.

Ә бит шул дебет шәл, дебет пирчәткә, йон оекбашлар тотып станция тирәсендә тукланучылар әле әзме? Ярты бистә диярлек. Гөлсемгә инде, вагон тирәләрендә бик чуалма, ябып куябыз, дип кисәтүләр дә булгалады. «Әллә чынлап та энине ябып куйдылармы икән?»

Күңеленә шундый уйлар килгәч, Фәритнең башта күз төпләре дымланды. Аннары ул чын-чынлап үкереп еларга ук керешге.

Караңгы ишек төбеннән әнкәсенең:

— Чү, ни булды улым, ник елыйсың? — дигән тавышын ишеткәч кенә сискәнеп китте ул. Һәм ананың суык сеңгән сырмасына барып капланды. Тик елавыннан тиз генә арына алмады.

— Булды, балам, син зур ич,— диде аңа энисе.— Өйдә бердәнбер ир затыбыз бит син, кеше күрсә көләр үзеңнән.

Шулай дип сөйләнә-сөйләнә Гөлсем апа аны суык куллары белән башыннан, аркасыннан сыйпарга керешге. Аннары:

— Әнә, күр, нәрсәләр алып кайттым сезгә бүген. Хәзер үк мичкә ягармын, чәй кайнатырмын,— диде.

Тиздән казан тирәсеннән майда кыздырылган бавырсак исе килә башлады, плитә өстенә куелган чәйнек капкачын биетергә кереште. Шул арада Гөлсем апа лампага яңа филтә, яңа куык куеп җибәрде. Өй эче шундук яктырып киткәндәй булды. Хәтта Фәриткә өйнең сәкегә каршы почмактагы бәсе дә тоныкланып калгандай тоелды. Ишекне ачып керү белән Фәния дә, сөенечен яшерә алмыйча:

— Бүген саткансың, ахры! — дип куйды.

— Саттым, кызым! Чишен тизрәк!

Тик Фәрит кенә, киез итекләрен салып торган Фәниягә үпкәсен белдереп:

— Бигрәк соң кайттың! Көтә-көтә дә арып беттем! — диде.

Чишенеп табын янына утыргач, Фәния әниҫеннән:

— Ничек булды, әни, сөйлә әле? — дип үтенде.

— Мәскәү поезды бүген бик соңлап килде,— дип сөйли башлады әниләре.— Аны көтә-көтә урамда йөреп тәмам туңган идем. Инде китимме әллә дип торганда гына шул яктан сузып кына паровоз кычкыртты. Тавышыннан ук сизәм, түземсезләнеп сузып кычкыра бу. Мәскәүдән килүче скорый, мин әйтәм. Шул арада килеп тә туктады. Тик тышта җил, суык — ник берәү чыксын вагоннардан. Шуннан арт урамдагы Нәгыймә апагыз әйтә, әйдә Гөлсем киләсе станцага чаклы утырып китәбез, шунда берәр җае чыгар шәт ди. Тик ул сүзен әйтеп бетермәде, якындагы вагоннан яшь кенә бер хәрби кеше килеп чыкты.

— Мамаша, күпмегә ҫатасыз шәлегезне? — ди бу. Ә җилкәсе аша яшь, чибәр генә хатыны да карап тора. Безнең шәлләрне тәрәзәдән күреп, мөгаен, үзе ирен чыгаргандыр. Бу шәлне инде атнадан артык тотып өшеп-туңып йөргәнне беләсез. Шуңа, ахрысы, боларга мин иң җүн хакны әйттем дә бирдем, ходаем.

— Алайса вагонга менмәссезме соң? — ди теге чибәр хатын. Ире шундук кул биреп тартып та алды үземне. Ә хатыны шәлемне шундук бөркәнеп, ишек буе зур көзге каршына барып көязләнә, карый да башлады. И-и, күрсәгез аларның ул көзгесен, вагонын — искиткеч инде менә. Бөтен нәрсә пөхтә, елкылдап тора инде. Ә теге хатын, көзге каршында боргаланган арада:

— Килешә бит! Бигрәк әйбәт инде үзе! — ди. Аннары поездның озак тормасын исенә төшерде, ахрысы, кабатлап: — Җиде йөзгә бирәм дидегезме әле? — дип сорады.

Курка калдым тагын. Сатулашырга ниятли икән, дим. Җиделән дә кимгә бирмим, дип торам күңелемнән. «Җиде шул»,— дидем дә шәлемне алып төенләргә керештем. И-и, сөйкемле кеше һәрчак сөйкемле инде ул. «Вадим, сигез йөзне түлә, шәле бик әйбәт, миңа ошады,— ди бит матуркаем. Һәм шунда үз итеп кочып алды үземне.— Апа да изге теләктә калсын, рәхмәт аңа!» — ди. Мин дә: «Рәхмәт, дучка, рәхмәт»,— дидем.

Тик күземә яшь тулып кына харап итте, әфицәрнең күпме акча биргәнен дә санап тора алмадым. Күпме бирделәр, шуны кесәмә салдым да куйдым. Инде вагоннан чыгып җитәм дигәндә генә тагын куып җитте бу көмеш погонлы кеше. Кулыма бер төргәк тоттырды.

— Мамаша, монысын да алыгыз, бу минем паек. Консерва белән печенье,— ди бу, рәхмәт төшкере.

Әйе, сохарига тартым ул коры печенье Фәриткә бик ошады. Ә консерва итеннән иртәгә аш пешерергә сөйләштеләр.

— Бар бит дөньяда шундый яхшы кешеләр. Үзләре дә бәхетле шул, ходаем бәхетләрен сакласын,— дип тәгәлләде сүзен Гөлсем апа.

Аннары ул, җылы күкрәкчәсенең эчке кесәсеннән бер төргәк акча алып, аларны ашъяулык читенә таратып салды.

— Кузгалып баручы поездлан сикереп төшүемә үзебезнең бистә хатыннары чорнап алды үземне. Беришенә бурыч кайтарасым бар, кем-

нәрдәр әҗәткә алырга өмет итә. Кемгә ун, кемгә утыз сумлап өләшкәннән калганы менә шушы. Алла боерган булса, без бу якшәмбедә Фәрит белән базарга чыгарбыз, берәр чана кизәк сатып алырбыз, авыллар килә алса бу суыкта,— дип, Гөлсем апа ашъяулык читендәге акчаның бер өлешен аерыбрак куйды. Аннары бер өчлек алып Фәриткә сузды.— Мәгез, бусы сезгә кинога.

Әйе, хәзер үк шулай эшләмәсәң, соңыннан тиенен дә балаларга дип аерып булмасын белә иде Гөлсем.

— Ә болары тагын бурыч түләргә китәр, Матвей карттан бу кышта өч мәртәбә пима төпләттек, бусы аңа булыр. Нүркәгә дә мин тиеш әле, хәзер үк бирмәсәң, кибет ишеген дә ачып керә алмассың...

Сөйләнә-сөйләнә ул тагын ике-өч утызлыкны аерып куйды. Шулай аера торгач, ашъяулык кырыенда көндәлек кирәк-яракка бер яшел өчлек, бер-ике бишлек белән берничә берлек акча гына торып калган иде.

— И-и, ходаем, болай булгач яшибез әле, кул-аяклар сау булсын да, сездәй булышчыларым яшәсен,— дип, балаларын юаткандай итеп әйтеп куйды Гөлсем апа. Аннары яраткан улының башыннан сыйпап, сөеп алганнан соң, табынны җыярга кереште.

Озакламый алар тагын якты лампа тирәсенә тезелешеп утырып, көндәлек эшләренә тотындылар. Башка көннәрдән аермалы буларак, бүген барысының да күңеле көр, әниләре хәтта ямьле Агыйдел буйларын, сихри «Кара урман»нарны искә төшереп, ишетелер-ишетелмәс кенә көйләп, моңланып утыра. Җырын бүлеп ара-тирә шәл сырларын санап алгалый. Әйе, шәлнең һәр җөе төгәл, санаулы шул аның. Кайсы бизәккә ничә җөй, кайсы телгә ничә сыр төшәсен даими рәвештә санап, тикшереп барасы.

Шулай күпмедер утыргач Фәния генә:

— Әни, икенче чирек тәмамланып килә, укыган өчен түләмәдек, ахры, мәктәптән чыгармаслармы мине? — дип кыяр-кыймас кына әйтеп куйды.

Гөлсем апа бер мәлгә тынып калгандай булды. Аннары:

— Борчылма, балакай. Кузнецов абыегыз мәктәп директоры булганда андыйны эшләмәс,— диде.— Укуыңны да бик мактый, күргән саен, «унны бетерсен инде Фәния, белемлеләр заманы хәзер, белем алсын» дип тора. «Сугыш бетте инде, ярдәмен дә иткәләрбез», дип кайчан гына әйткән иде әле үзе. Кумас, һич кумас ул сине, кызым.

Дөрес, Гөлсем апа үзе уку мәсьәләсендә элек башкачарак фикер йөртә иде. Кулы эш белсә, шәл бәйләргә өйрәнсә, кыз балага җиде класс белем дә бик җиткән диебрәк йөри иде. Кулы эшкә ятышлы кешенең болай да ким-хур булганы юк дип белә иде. Аннары бит әле укытыр, кеше арасында йөртер өчен аның адәм арасына чыгардай рәтлерәк киемсалымы да кирәк. Мәктәпкә рәхмәт инде, укырга төшәр көннәрдә генә бу кадәрен үзләре кайгыртты. Беркөнне Кузнецов чакыртып алды да: «Менә Гөлсем апа, шуннан кызыгызга кием сайлагыз»,— ди. Ә анда төрле-төрле төстәге пальтолар, төшкә дә кермәгән йон күлмәкләр, җылы-җылы киез итекләр — Мәрдүктәгечә әйтсәң, «пима»лар икән. Шуларның барын да төенчекләп күтәртеп җибәрде директор. Балалар укысын дип, шулай ярдәм итеп торган бер заманда «кумаслармы» дип борчыласы юк, әлбәттә.

— Бер дә борчылма, кызым. Тырышып укуыңны гына бел. Икенче юлы уку өчен дә түләрбез,— дип өстәде ул аннан.

Үзе шунда мәктәп директорының тагын бер яхшылыгын исенә төшерде. Сугышта үлүчеләрнең балаларына әзме-күпме пенсия түләнә, ә аларга ул никтер юк иде. Гөлсем апа аптырагач ярдәм сорап тагын аңа барды. «Юрий Александрович, собес безгә пенсия түләми — сугыштан алган кәгазегездә «үлде» дигән сүз юк, «юкка чыкты» дип кенә язылган диләр. Ничек алай булсын, барлык Мәрдүк ирләре бер көнне эшелонга төялде, күбесе берьюлы әлеге Мәскәү янында һәлак булды, бөтен солдаткалар бер тирәдә кайгы кәгазьләре алдык, аларга акча түләнә, миңа

юк», диде. Кузнецов та боларның барысын да белә иде: эшелон озатышкан да ул, кайгы кәгазьләре килгәч, халыкны мәктәпкә җыеп, матәм кичәсе уздырган да ул булды.

— Авылдашлары белән бер сугышта йөргән, әле көлке сөйләп, әле хак сүз әйтеп, һаман кешe күңелен күрә торган бер тугры бәндә, өстәвенә әле партийный үзе — нишләп юкка чыксын ди. Мәрдүктән киткәндә үк вагон башлыгы иткәннәр иде ич,— диде Гөлсем апа.

Шул хакта сөйләшеп аңлашкач, алар кабат собеска юл тоттылар. Тик бу юлы Гөлсем апа анда Кузнецовка ияреп кермәде — урамда көтә калды. Керсәм, тыела алмый, шундый зур кеше алдында тагын тегеләр белән әйткәләшә башлармын, хур булырмын, дип шикләнде. Озак, бик озак торды алар янында Кузнецов. Шәт ике сәгатьләп булгандыр. Һәм һич көтелмәгәнчә, бик ачулы кыяфәттә, кем беләндер әрепләшә-әрепләшә килеп чыкты. Бер читтәрәк көтеп торган Гөлсем апа каршына якынлашкач кына бераз тынычланды Кузнецов. «Монда булмый. Югары оешмага язам. Сабырың җуйма»,— гына диде ул аңа. Шуннан соң да бер генә язмады әле Кузнецов. Мәскәүгә үк житте шикелле. Әмма үзенекен итте, балаларга чак кына булса да акча юллап бирә алды. Шуңа күрә Гөлсем апа мәктәп директоры хакында сүз чыкса балаларына да даими:

— Тормыш ул Кузнецов ише яхшы кешеләр аркасында алга бара,— дип кабатлый иде.

Ачык далада, жиде жил чатында утырган Мәрдүкне декабрь азагындагы бураннар бөтенләй күмеп китте диярлек. Әле аннан, әле моннан бөтерелеп килгән жил кешеләрне аяктан ега, этеп-төртеп җибәрә иде. Шул сәбәпле ике-өч көн инде Фәритләр мәктәпкә йөрмиләр. Әмма өйдә дә бик жылы түгел. Тәбәнәк саман йортның морҗасыннан үкереп елаган жил авазы ишетелә. Ишек-тәрәзә тирәләреннән жил дулап өреп тора. Жылы тормас өен жылытам дип Гөлсем апа көн-төн диярлек санаулы кизәк кантарларын мичкә ташлый. Шулай итеп, аларның Фәрит белән алган соңгы олау кизәкләре дә бетеп килә иде. Ә бит буран болай котырынса, тагын берәр атнадан кизәкне әжәткә түгел, акчага да табып булмаячак. Кайсы авыл кешесе мондый буранда кизәк сатам дип базарга килсен ди. Шул уй борчый башлады Гөлсемне. Юл ачылса, кизәксез утырмасын да белә Гөлсем — тирә-як авыл казахлары аны яхшы таный, аңа ышаналар, бик үтенсә, әжәткә дә берәр олау ягулык калдырып китәчәкләр иде. Тик менә көне бер дә рәтле түгел дип пошынды ул.

Һәм шундый борчулы көннәрнең берсендә, өй ишеге киң ачылып, анда таныш йөз күренде. Гыймай абзый иде бу. Бу өйгә ул сирәк килә — килсә шатлык алып килә торган иде. Гадәттә, ул нәкъ шушындый жил-буранлы берәр кичтә пәйда була. Хәер, ишек ачылуга әүвәл аның үзен түгел, туптулы зур капчыгын күреп аласың. Әйе, әлек ул шул дәү капчыкны ишек катына кертеп утыртыр да, чоланга чыгып, байтак кына вакыт шап-шоп китереп киемнәрен кагар, өс-башын рәткә китерер. Икенче әйләнеп кергәндә инде аның бер кулында туны, икенчесендә зур казах малахае булыр. Ә гимнастеркасы аның шәп тә шәп инде.

Фәния аны һәрчак диярлек бер үк сүзләр белән каршы ала. Бу юлы да:

— Гыймай абый, сиңа бит станца аръягыннан ук килергә кирәк, күзгә төртсәң күренмәс шушындый кичтә ничек итеп тәвәккәлләдең? Адашырмын дип бер дә курыкмыйсың, ахры?! — дип сорады.

— Мин бит, кызым, сугышның беренче көненнән разведкада йөрдем. Яу беткәндә фронт күләмендәге разведчик идем.

Сүзгә Фәрит тә кысылды.

— Ә нишләп минем этине очратып үзегез белән алмадыгыз! — диде ул.

— Әй, бала, фронтта кем белән кая барасын сорап тормыйлар шул. Ә атаң Шакир белән без эшелоннан төшүгә үк аерылыштык. Бер коман-

дирга минем буй-сын бик ошады, ахрысы, шундук «әйдәле, батыр» дип үзенә ияртеп алып китте.

Гөлсем апа баштарак әңгәмәгә катнашмады, мич, казан тирәсендә кайнашты. Чәй табынын хәстәрләгәч кенә:

— Болай йөреп берәр бәлага тара күрмә тагын, Гыймай,— дип, ишек төбендәге капчыкка ымлады.

Гыймай абзый бер ара Чапайныкына охшаган мыегын сыпыргалап утырды. Аннары күзен нурландырып Гөлсемгә туп-туры карады:

— Юкка хафаланма, тире китерәм, тире алып китәм мин синнән. Ә мамыгы аның безгә өстәмә мәшәкать кенә, белсәң. Тире заводы аннан зыян гына күрә: таралмаган тирене тарап, кыркылмаганын кыркып утырырлык кеше юк анда. Ничек килә, шулай чанга тутырабыз, аннары җәфаланып ул чанны сәнәк белән чистартабыз, тагын күпмедер тире саласы урынга анда укмашкан шул мамык әвәләнә. Шуңа күрә күпме химикат әрәм-шәрәм китә. Ә син тарасаң — кругом файда.

— Әй, дәүләт малына тигән сыман, шикләндерә шул бераз.

— Шуңа күрә күз ачкысыз буранда киләм дә синга: ил бәндәсе аны-моны уйламасын дим. Юкса бит һичкемнән куркасы юк, урлап алынган мал түгел.

Шул арада Гыймай абзый, көчле куллары белән зур капчыгының авызын чишеп, идән уртасына туңган кәҗә тиреләрен бушатырга керешә. Тире өстендә күпереп торган мамыкларын тоткалап:

— Моны харап итү ярый торган эшме? Шәлгә бармаса, аннан ничаклы пирчәткә әмәлләрлек бит! — диде.

Гөлсем дә инде идәндә, тире өстендә иде. Ул да кызыгып куйды.

— И-и, бусы менә бигрәк затлы дебет,— дип сөенә-сөенә сөйләнде.

— Ә мин сиңа ни дим! — дип куйды Гыймай канәгать төстә. Аннары тунын алып аның ике кесәсеннән ике авыр төргәк чыгарды. Чүпрәккә төрелгәнендә зур кайчы икән. Аны Гөлсемгә сузды.— Менә, кайрадым, сүземдә тордым. Рәхәтлән.

Икенче төргәктә тире заводы үз кирәк-ярагына дип кайнаткан катаркатмас сабын булып чыкты. Гыймай кул югыч янына килеп, сабын күбекләндерә-күбекләндерә дәү кулларын юарга керешә.

— Сабынны бер дә җәлләмәгез. Әллә кайлардан килгән ул тире, чирле хайванныкы булуы да мөмкин, тотынган саен сабынлап кулыгызны юыгыз,— дип кисәтте. Һәм шуннан соң гына Гыймай абый, бик канәгать кыяфәттә, самавыр янына килеп утырды.

Декабрь ае никадәр усалланмасын, барыбер суыклар чигенде. Морҗасына чаклы кар көртләре астында калган Мәрдүк авылы тагын җанланды, көннән-көн иркенрәк сулый башлады.

Хәзер исә паровозның семафорга җитәр-җитмәстән үз итеп, сузып-сузып кычкыртуын ишетүгә, урамнар җанланып китә. Бар халык «станца» ягына ашыга. Фәритнең дә бу көннәрдә тагын да үсеп, «зураеп» йөргән чагы. Чөнки Гөлсем апа аңа да башка малайлар белән бергә шул «станцага» төшәргә, поездлар каршы алырга рөхсәт иткән иде. Ә Мәрдүкнең үскән үҗәт малайлары шул паровозлар бушатып калдырган шлак арасыннан көнлек ягулык табалар.

Дөрес, соңгы көннәрдә олыларның боек күңелен язырдай «җылы» хәбәрләр дә булгалап алган иде. Моңа, беренче чиратта, Гөлсем Гөлсем түгел, солдаткалар бик сөенеште. Айлап-көнләп эш хакы түли торган чын оешма, шәл бәйләүчеләр артиле ачыла икән дигән хәбәр таралды Мәрдүктә. Кулы эш белеп тә, кайда эшләргә белмәүчеләр өчен моннан да артык сөенеч булырга мөмкинме? Күпереп, тәнгә җылы, җанга рәхәт биреп торучы ул йоп-йомшак «ырымбур шәле» артиле ачылуы шәлчегә генә түгел, бар халыкка көтеп алынган бер сөенеч иде шул. Шуңа күрә ул хәбәрне Мәрдүк халкы былтыр җиңү шатлыгын кабул иткәндәй каршы алды.

Лерон **ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

**М. А. Офицеров,**
КПССның Тәтеш райкомы беренче секретаре.

# ИДЕЛНЕҢ ТЕКӘ ЯРЫНДА

Иртәнге саф һава күңелне күтәрүчән. Әгәр шул чакта Идел ярында да булсаң, тирә-юньнең матурлыгына сокланып туя алмыйсың. Уйлар да еракка, тарих тирәнлегенә кереп китә. Борынгы Болгар җирләре бу. Шуңа да хәтердә үткәннәр яңарадыр...

Әллә ни тирәнгә кермичә, йөз ел чамасы элек булган хәлләрне генә күз алдына китерик. Иделдә заманы өчен мәшһүр «Кавказ һәм Меркурий» пароходы йөзә. Сембердән Казанга барышы. Тәтештә тукталыш ясый ул. Палубада төрледән-төрле пассажирлар. Шулар арасында туганнары белән бергә Володя Ульянов та бар. Аның бөек революцион көрәштә беренче чыныгу бирәчәк шәһәргә — Казанга барышы.

Татарстанның көньяк-көнбатышында башкаладан шактый читтә урнашкан безнең төбәк, бер караганда, чорның шаулы хәлләреннән читтә торгандыр шикелле. Юк, һич тә алай түгел. Халкыбыз тарихының һәр талпынышы Тәтештә дә шактый эз калдырган. Крестьян күтәрелешләрен дә кичергән бу яклар. Емельян Пугачев хәрәкәтен өйрәнүче бөек Пушкин да Тәтеш өязе аша узган. Безнең төбәктә буйсынмас «Потемкин»чы матрос Николай Галайкинның кабере саклана. Никифоровка авылы исә күренекле революционерка Вера Фигнер туган җир буларак дан тота...

Дөньякүләм танылган химик Гыйлем Камай безнең Тәтеш җиреннән юл алган. Бүген шәһәребезнең бер урамы Гыйлем Камай исемен йөртә. Төбәгебезнең матурлыгы, халкының зирәклеге атаклы графика рәссамнары Кукрыниксларның берсенә — Михаил Куприяновка иҗат оеткысы булып иңгән. Тәтеш яклары — шулай ук дөнья чемпионы исеменә — биш тапкыр, Олимпия уеннары чемпионы исеменә ике тапкыр ирешкән баһадир штангачы, профессор, медицина фәннәре докторы Аркадий Воробьев, язучылардан Максуд Сөндекле, бертуган Гали һәм Яхья Халитовлар, чуваш шагыйре Михаил Сеспель ватаны.

Халык депутатларының Тәтеш Район Советы бинасында «1918 елны биредә шәһәрдә Совет власте игълан ителде» дип язылган мемориаль такта эленгән. Бу җиңүгә күп корбаннар аша ирешелә. Азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән халык өстенә кулаклар, аларның иярченнәре, патша ялчылары, ак чех бандалары ябырыла. Күпләр кан коюлы бәрелешләрдә һәлак була. Бүген халык ул батырларның исемен мәрмәр һәйкәлләргә уеп яза, якты хатирәләрен буыннан-буынга илтә.

Властьны үз кулларына алган крестьяннар коммуналарга, кооперативларга берләшә башлыйлар. Оештыручылары большевиклар була. Аларга ярдәмгә комсомол яшьләр килә. Менә алар, ялкынлы җитәкчеләр: Павел Бекшанский, Василий Блинников, Һади Маликов, Исхак Казаков; гражданнар сугышы батырлары Дмитрий Фуражков, Дмитрий Карасев, Василий Рыжков һәм башка дистәләгән фидакарьләр. Яшь властьны ныгыту, аңа ярдәм итү өчен һәр һөнәр иясе кулыннан килгәнчә булыша. Мәсәлән, төбәктәге халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен атаклы врач, медицина фәннәре докторы Аркадий Михайлович Боголюбов бик нык тырыша. Ул үзенең бөтен гомерен, сәламәтлеген, белемен Тәтешкә биргән, соңгы сәгатенә кадәр безнең шәһәрдә яшәгән.

Совет иленә нигез салган беренче көрәшчеләргә гайрәтле яшь буын алмашка килә. Яшьләр Ватанга тугрылыклы булып, аны күз карасыдай сакларга кирәклеген тирәннән аңлап үсәләр. Тик тыныч төзелеш көннәре фашистик Германиянең көтелмәгән һөҗүме аркасында тукталып кала.

Тәтешнең үзәгендә күкләргә ашырдай булып көмешсу биек һәйкәл басып тора. Аны уратып алган чыршылар, батырлыкка баш иргә килүчеләр кебек, тынып калган. Бөек Ватан сугышында ил иминлеген саклауда катнашкан 12 мең якташыбызның яртысы диярлек яу кырында мәңгелеккә ятып калган. Җиде каһарман Советлар Союзы Герое исеменә лаек. Алар арасында Кече җирдә булган тиңдәшсез бәрелештә дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплаган рота парторгы Сәләхетдин Вәлиуллин да бар. Ике егетебез — Петр Малкин белән Николай Зотов Дан орденының өч дәрәҗәсен дә алалар.

Күп кенә фронтовиклар сугыш кырында күрсәткән батырлыкларын яшьләрне тәрбияләүдә матур үрнәк булып бүгенге хезмәттә дәвам иттерәләр. Михаил Никишин, Эдуард Трофимов, Иван Булыгин, Фәттах Һадиев, Леонид Дмитриев, Мария Евсеева, Николай Мочалов, Иван Лапаев, Анна Бусаргина һәм уннарча башка ветераннарыбыз КПССның район оешмасы эшендә иң нык, ышанычлы таяныч булып тора. Сугыш батырлары рәтенә хезмәт алдынгыларының яңа сафлары кушыла. Социалистик Хезмәт Геройлары Клавдия Линькова, Михаил Зотов, Сәетгәрәй Габбасов кебек уңганнарыбыз белән чын-чынлап горурланырга мөмкин.

«Алга» колхозының игенче механизаторы Сәетгәрәй Габбасов турында аерым сөйлисе килә. Аның җитәкчелегендәге бригада районда беренче буларак хезмәтне оештыруда группа подряды ысулын үзләштерде. Ул чагында аны «Ипатов методы» дип йөртә идек әле. Нәтиҗә көткәндәгедән дә яхшырак килеп чыкты. Бригада ул еллар өчен бик зур уңыш җыйды: һәр гектардан 33 әр центнер. Социалистик Хезмәт Герое Сәетгәрәй Габбасов КПССның XXV съездында делегат буларак катнашты.

Хәер, «Алга» колхозының уңышларында бер бригаданы гына аерып алып мактау бик үк дөрес тә булмас. Гаҗәеп тырыш, саф күңелле, гомум эшкә тугрылыклы кешеләр яши монда. Русы, татары, чувашы кулга-кул тотынып, җилкәгә-җилкә куеп бердәм тырышалар. Кырчылыкта да, терлекчелектә дә зур уңышлар шул бердәмлектән килә. Сәетгәрәй агай күрсәткечләренең, халык әйтмешли, аягы җиңел булды. Хәзер аңа охшатып эшләүче алмаш та өлгерде: Рәмис Мохтаров, Рәмис Галиәкбәров кебекләр өлкән игенчедән һич тә калышырга теләмиләр. «Алга» колхозы игенчеләренең әнә шулай җиң сызганып, заман таләпләренә йөз белән борылып яңача эшли башлаулары районның бүтән хуҗалыкларына да үрнәк булып тора.

Монда матур гадәтләр байтак. «Алга»га кергән Бакырчы авылы янында торф чыганагы бар иде. Еллар буе шушы җирдән 100 мең тонна чамасы органик ашлама алдылар. Ниһаять, торф бетте. Аның урыны иләмсез чокыр-чакырга әйләнеп калды. Колхоз председателе Әдһәм Чукмаровның бу хәлгә эче пошып йөри. Артык түзә алмый, белгечләр чакырта, шушы ташландык җирне матурлыкка, кешеләрнең ял итү урынына әйләндерү чарасын табарга тырыша. Җир тигезләнә, анда Җиңү паркына нигез салына, сулы чокырларның чите ныгытыла, буага балык җибәрелә. Яр буенда комлык булдырыла. Агачлар утыртыла. Рәхим ит, гаиләң белән кил да рәхәтләнеп күңел ач! Монда бөтен колхозың белән ял итәргә, сабан туе бәйрәме үткәрергә дә мөмкин. Кунаклар кайта икән, аларның да күңеле күтәреләчәк.

Күңел биреп эшләүче кеше ял иткәндә дә аптырап утырмый ул. Шушы колхоздан әле генә мактап телгә алынган Рәмис Галиәкбәров, мәсәлән, ял көннәрендә өздереп гармун уйный, үз уенына кушылып җырлап та җибәрә. Һәвәскәрләр чыгышына Галиәкбәровлар бөтен гаиләләре белән катнашалар. Рәмиснең өлкән дусты игенче Әмир Садыйков та бик оста гармунчы. Тальян гармунын аның кебек бераү дә өздерә алмый кебек. Сәхнәгә Әмир агай да гаиләсе белән бергә чыга. Моннан тыш ул тирә-юньгә яхшы таныш «Көләч» ансамблендә дә катнаша. «Алга»ның һәвәскәрләре берсеннән-берсе кызыклырак. Зиновий Морозкин, мәсәлән, милләте белән чуваш, үзе татарча да, русча да җырлый. Биюдә дә Зиновий — районда бер.

«Ильич юлы» колхозыннан да шундый ук матур мисаллар китерергә була. Хуҗалык нык. Кассасында миллион сумнар акчасы бар. Ул сыер ите әзерләү буенча специальләште. Хәзер бу колхоз район сатарга тиешле итнең өчтән бер өлешен җитештерә. Хуҗалыкны инде утыз елдан артык Ленин орденлы председатель Ибраһим Садыйков җитәкли. Терлекчелектәге уңышларны саный башласаң, иң алдан ирле-хатынлы Кадрия һәм Хәбир Шәрәфуллиннар, ферма мөдире Вера Кузнецова телгә килә. Шикәр чөгендере үстерүчеләрдән аксакалыбыз Варис агай Миңнуллин аерылып тора. «Ильич юлы», «Алга» колхозлары ныклы тәртип белән яшәү ягыннан да үрнәк булырлык. Өзеп әйтүе кыен, шулай да, мәсәлән, «Дружба» колхозының соңгы вакытта алдынгылар сафына басуында югарыда телгә алынган хуҗалыкларның эш алымнарын өйрәнү, һичшиксез, уңай тәэсир иткәндер. Колхозның сөтчелек фермасы хуҗалык исәп-хисабы нигезендә эшен үзгәртеп корды. Нәтиҗәсе сөенеп туймаслык. Хәзер монда һәр сыердан уртача 3,5 мең литр сөт саву гадәткә әйләнде, 4 мең литр савучылар күренеп килә.

Кешене үз эшенең чын хуҗасы итеп тану аның иҗат мөмкинлекләренә чын-чынлап канат бирә. Моннан ун еллар элек артта сөйрәлүче «Авангард» колхозының тәртипле,

нык хуҗалыкка әйләнүен дә мин шул яңалык белән аңлатыр идем. Җитәкчеләр — председатель М. Лабазов, парторг Е. Курков һәм башкалар һәр эшкә халык белән киңәшеп тотыналар.

Хезмәттәге һәм көнкүрештәге күркәм яңалыкларны «Заря», «Красное Знамя» кебек башка колхозлардан да күпләп санарга мөмкин. Хуҗалыкларыбыз һәм материаль, һәм әхлакый яктан ныгый, көчле техникага, укымышлы белгечләргә байый бара. Бу ныклык кешеләребезнең дә һәрьяклап күркәмләнүенә китерә.

Районыбызның күрке булып саналучы ату кырларының даны бөтен илне шаулата. Аңа фронтовик, гаскәри хезмәт кешесе Солтан ага Яруллин нигез салды. Аның шәкертләре күп мәртәбә дөнья, Европа, Советлар Союзы күләмендә чемпион булдылар. Мәшһүр Яруллин мәктәбенең эшчәнлеге хакында документаль фильм төшерелде, аерым китап басылып чыкты.

Тәтеш якларында борынгы заманнардан ук шаулы тормыш кайнаган дидек. Аннан соң күп сулар аккан. Шактый үзгәрешләр, кан коюлы яулар кичергән Тәтеш Екатерина II чорында (1781 елда) рәсми төстә шәһәр итеп таныла. Шәһәрдә педагогия училищесы, авыл хуҗалыгы техникумы, ике урта мәктәп, музыка мәктәпләре һәм бик бай музей бар. Промышленность предприятиеләреннән урман хуҗалыгын, юл төзү участогын, балык заводын, ит комбинатын һәм РАПО оешмаларын санарга була. Аларның һәркайсында егерме биш колхоз-совхозыбыздагы кебек үк дәртле хезмәт кайный. Шунлыктан киләчәккә төзелгән зур планнарыбызның үтәлүенә дә ышанычыбыз нык.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

Эльмира Шәрифуллина

# КАБАТЛАНМАС ШӘХЕС ӨЧЕН

Озын буйлы, какча гәүдәле ул. Кулында һәрвакыт дипломат булыр дигәннәр иде. Кызганычка каршы, үзен очрата алмадым. Әмма эшләгән эшләре белән таныштым. Ул дәвалаган, ул тәрбияләгән балаларны күрдем. Әниләр, балалар консультациясе хезмәткәрләре белән сөйләштем.

— Сирәк очрый торган мәрхәмәтле кеше.

— «Булсын!» дип эшли,— диделәр аның турында.

— Сергей Викторович Попковмы? Балаларны ничек яратканын күрсәгез икән сез аның! Кайчакта нәниләрен биләргә кулы ятмаган аналар очрый. Менә төреп күрсәтә инде шуларга! Шаккатып карап торасың,— ди кызын бассейнга йөртүче Тәбрия Мөбәрәкшина.

Балалар консультациясе мөдире Сергей Викторович Попковка карата күп әниләрдә әнә шундый ихтирам, хөрмәт һәм ярату хисе. Кама Аланындагы һәр әнигә, һәр балага якын таныш ул.

Бассейн дигәннән... Моннан ике ел элек ачалар аны. Хәер, «ачалар» сүзе дөрес тә булмас. Балалар консультациясе дип аталган бүлмәнең бер ягына төзиләр. Башта поликлиниканың баш врачы Олег Владимирович Образцов белән Брежнев шәһәрендәге бассейннарны карап кайталар. Дирекция белән киңәшәләр. Торак өчен төзелгән бүлмәнең ничә кубометр су сыйдыруын, күпме авырлыкны күтәреп тора алуын исәплиләр. Һәм тиз арада төзеп тә куялар. Дөрес, юрганыңа карап аягыңны сузасың, дигәндәй, бассейн әлегә бәләкәй. Балаларын йөртергә теләгән әниләр күп булса да, бер генә смена эшли. Болай эшләү медицина хезмәткәрләре җитмәгәннән түгел (билгеле, шәһәрдә бу һөнәр ияләре дә бик кадерле!), бәлки шартларның тиешенчә булмавыннан килә. Әйтик, түшәмнәр, стеналар юешләнмәсен, һава артык дымланып китмәсен өчен.

Ике атналык нарасыйдан башлап, яшь ярымга кадәр зурлыктагы егерме җиде бала йөри анда. Хәзер инде алар арасында үз чемпионнары да бар.

Мәсәлән, аркада йөзү һәм су астында озаклап тору буенча үткәрелгән ярышта Гөлназ Мөбәрәкшина беренче урынга чыга. Кызның әнисе:

— Жюри членнары арасында ят кешеләр булгач, бераз каушады әле,— ди.

Балаларның уңышы әниләренең тырышлыгына бәйле. Бала тәрбияләүгә бөтен күңелеңне биреп, аның сәламәтлеге өчен кайгыртып, дәресләргә системалы йөргәндә генә уңышка ирешеп була.

— Кызыма яшь ярым. Бүгенге көнгә кадәр бер генә дару да капканы юк. Ә минем исә иң зур теләгем шул. Аны спортчылардан да бигрәк сәламәтрәк, физик яктан чыныккан итеп үстерү...

Бу — Гөлназның әнисе Тәбрия ханым сүзләре генә түгел, балаларын бассейнга йөртүче барлык аналар фикере.

Бассейн мәсьәләсенә, гомумән дә, бирелә зур игътибар бирелә. Мәсәлән, Гөлназ кебек ике атналык чагында ук йөзә башлаган малайлар һәм кызлар, бернинди өзеклек ясамыйча, урта мәктәпне тәмамлаганчы бассейнга йөри алачаклар. Чөнки балалар бакчасы да, мәктәпләр дә һәркайсы шушы җайланма белән салына. Киләчәктә, бәлки, Брежневтагы кебек зур спорт комплексы да калкып чыгар һәм су белән чыныгу Кама Аланы кешеләре өчен яшәүнең гаҗәеп ләззәтле төренә әверелер. Әнә бит, әйтергә теле, аңлатырга сүзе булмаган сабый бала, йөри башлаганчы, йөзәргә өйрәнгән. Су күргәч талпынып, ашкынып тора. Андыйларның башка балаларга караганда, күпкә тәвәккәл, шат күңелле булуларын да инкарь итмиләр. Димәк, Кама Аланының

даны атом электр станциясе белән генә түгел, якты йөзле кешеләре, мәшһүр язучылары, спорт чемпионнары белән дә дан тотачак әле!

Башлангычлар бар да инде. Мәктәпнең район шахматчылары ярышында беренче урынга чыгуы зур тырышлык турында сөйли. Мәктәп каршындагы утыз түгәрәк арасында: ирекле көрәш, самбо, дзю-до, аэробика кебек спортка бәйле түгәрәкләрнең аерым урын алып торуы да игътибарга лаек. Бу түгәрәкләрнең күбесенә шефлар — махсус белгечлекләре булган АЭС эшчеләре җитәкчелек итә. Мәктәптә спорт өчен ике зал булуы да өлкәннәрнең балалар, аларның көчле һәм дәрманлы кешеләр булуы турында кайгыртуын раслый. Нигә кайгыртмаска? Киләчәктә үзләре белән рәттән басып эшлисе төзүчеләр ич алар! Урта мәктәпне тәмамлаганда балалар ташчы, балта остасы, сылаучы яки буяучы таныклыгы алып чыгалар. 1985/86 уку елында шундый чыгарылышның беренчесе булды. Унбиш укучыга өлгергәнлек аттестаты белән бергә II—III разрядлы һөнәр иясе таныклыклары тапшырылды.

1983 елда 32 укучысы була мәктәпнең. Хәзерге көндә исә 800 дән артык. Кама Аланындагы балалар һәм эшче көчләр турында сүз алып барганда һич кенә дә төгәл саннар кулланып булмый. Чөнки ай саен, якынча, егерме-егерме биш бала туып тора. Балалы гаиләләр килә. Әмма төгәл саннар да бар. Әйтик, теге яки бу бинаның бәясен атарга була. 1568 балага исәпләнгән 7559 квадрат метр мәйданны биләүче мәктәп — төгәл ике миллион сумга төшкән.

Унбиш отрядны берләштерүче пионер дружинасы шушы як герое Дмитрий Карпович Привалов исемен йөртә.

— Кама Аланы авылы 1773 елда төзелгән,— дип сөйли өлкән укытучы Валентина Васильевна Федосеева.

Халкы төрле яклардан бәхет эзләп килгән качкыннар булган. Телләр төрле, күңелләр бер дигәндәй, күп төрле милләт халкы яшәсә дә, Кама буе матурлыгы барсын бердәй тәэсирләндергән, күрәсең. Авылга шул вакытта ук Кама Аланы дип исем кушканнар. Шактый күп күренекле кешеләре, хезмәт һәм сугыш ветераннары булган авылның. Бүгенге балаларны шулар үрнәгендә тәрбияләргә омтыла укытучылар. Авыл урынын зур биналар каплап калдырса да, яхшылык белән батырлыкны бернинди таш плитәләр дә күмә алмый. Изгелек дигәнең хәтер аша, элекке нигезен искә алганда, күзләренә яшь килүчән Валентина Васильевналар аша буыннан-буынга күчә! Хәзер бу хөрмәтле укытучыны мәктәп музее директоры итеп билгеләгәннәр. Өч бүлектән торачак әлеге музей, һичшиксез, бай хәтерле булыр. Кама Аланының үткәнен дә, бүгенгесен дә сөйләр. Чөнки әзерлек беренче көннәрдән үк башланган. Шәһәр нигезен, АЭС нигезен салырга дип, җиргә батырылган беренче чүмечнең беренче балчыгы да алып куелган. Беренче фоторәсемнәр, беренче күренешләр, беренче төзүчеләр, беренче язмалар.

Беренчеләр!

Бу исемлеккә әлеге төзелешнең нигез ташларын салучыларны гына түгел, яшь буынны — шәһәрнең киләчәген тәрбияләүче беренчеләрне дә теркисе килә.

Кама Аланы урта мәктәбенең беренче һәм бүгенге директоры Альберт Сәйфуллович Бакиров — нәселләрендәге утыз алты педагогның берсе. Гаиләләрендәге җиде ир туган арасында өченче мәктәп директоры. Бу саннар үзләре генә дә әлеге зур гаиләдә балаларга булган мәхәббәтнең буыннан-буынга, каннан-канга күчүе турында сөйләмимени!

Укытучылар коллективы да тәҗрибәле, махсус белемле педагоглардан тупланган. Алтмыш укытучының кырык бише югары, унөче махсус урта, икесе тәмамланмаган югары белем белән.

— Әгәр безгә класс җитәкчесен сайлап куярга кушсалар, без яңадан да Гөлчәчәк Хизбулловнаны сайлар идек,— диләр эшләре буенча да, укулары буенча да мәктәптә иң алдынгы V А классы укучылары. Үзләре үк аңлатып та бирәләр:

— Чөнки ул дөньядагы иң матур укытучы... Күңеле белән дә, безгә мөгамәләсе белән дә,— диләр.

Матур укытучылар, дөресрәге, күңелләре һәм эшләре белән матурлар күп икән Кама Аланы мәктәбендә. Шушы ук сүзне III В лар үзләренең Тәнзилә Шәриповналарына карата әйтәләр. Билгеле, сөйләшә һәм саный китсәң, башкаларга да бирелер иде бу бәя. Балаларның укытучыларын шулай хөрмәтләве шатлыклы күренеш. Әмма мәктәптәге эшләрнең матур булуы белән генә, киләчәктә без күрергә теләгән акыллы да, эшлекле дә, тәртипле дә кешене тәрбияләп буламы?

— Әгәр ата-аналарның балаларын тәрбияләүгә керткән өлешенә билге куярга кушсалар? Әйтик, сез, егерме тугыз эти-әнинең ничәсенә «5» ле билгесе куяр идегез? — дип сорыйбыз, югарыда телгә алынган Тәнзилә Рәхимовадан.

— Яртысына була микән?— ди ул, уйланып.— Юк, өчтән беренә генә. Ә менә Надямның әнисе Ольга Минхвановна Кимга хәтта «6» лы куяр идем. Шуның кадәр

дә күңел биреп, әйтелгәннәрне төгәл үтәп, бөтен көчен биреп тәрбияли ул кызларын.

Яшерен түгел, балаларын күңел биреп тәрбияләүчеләр янында сабыеның көнкүрешен үз агымына ташлаучылар да бар. Үз агымына гынамы?

Көннәрдән бер көнне поселок советы председателе янына бала җитәкләп керәләр. «Юындырдым, ике көн тәрбияләп үземдә тоттым. Өйләрен эзләп карадык, кайда торганын белми. Инде сезгә алып килдем,— ди мәрхәмәтле хатын.— Ә чәчен тарый алмадым, бөтенләй киезләнгән, тиресе җәрәхәтләнер, зиһененә зыян килер кебек.

Нишләргә? Өч яшьлек баладан бик җентекләп торган җирен сорап карыйлар. «Шунда» дип алып китә, барып җиткәч, анда булып чыкмый. Йөри-йөри көн кичкә авыша башлый. Баланы яңадан поселок советына алып кайталар. Яңадан табын әзерләп, тамагын туйдырырга утырталар. Шул чакта үз йомышы белән бер әби килеп керә. Һәм күрше кызының поселок советында сыйланып утыруына гаҗәпләнеп:

— Бәй, Плеханова, син түгелме соң бу? Нишләп монда утырасың?— ди.

Менә шулай. Сабый бала, ике төн, өч көн буена югалып торып, исерек әти-әнисенең гаменә дә кереп чыкмаган. Баксаң, бу өйдә тагын өч бала бар икән әле. Балаларының киләчәгенә гафу ителмәс дәрәҗәдә салкын караучы бу анага, балаларның аталарына ни дияргә? Дөрес, хөкүмәтебез укытыр. Ач-ялангач та булмаслар. Әмма ана сөте белән кергәнне, алтыга кадәр сеңгән гадәтне — бала күңеленнән кем генә юып төшерә алыр икән? Кызганыч, тик андыйлар да бар шул.

Күңелен авырттырмас өчен икенче баланың исемен атамыйк. Ул әбисе-бабасы белән тора. Аларга булыша. Күршеләре дә начар дими. Укытучылар да хурламый. Бары тик сәер яклары булуын, вакыт-вакыт йомылып калуын, киреләнүен яки кисәктән кызып китүен әйтәләр.

— Барлык уңышсызлыкларына әнисе сәбәпче. Өяла ул әнисе өчен. Аның тотнаксыз тормышы хурландыра баланы.

— Яхшыдан яман булып туды аның әнисе. Нәселләре начар түгел, юкса. Әтисе усал иттереп, әнисе әйбәтләп әйтә иде. Юк, әшәке юлдашларыннан аерыла алмады. Бу баланы да төрмәдән алып кайтты. Калдырды да тагын чыгып олакты...

Авылдашлары шулай сөйли. «Олакты» диләр. Җирәнеп, чирканып телгә алалар. Аяныч, билгеле. Ләкин... кайдадыр, кайчандыр шушындагы кешеләрнең битарафлыгыннан (нәкъ сөйләгәннәре тарафыннан булмаса да) килеп чыккан фаҗига түгелме бу? Бу хатын турында: «Хаталанды»,— дип сөйлиләр.

Кайдан башлана соң безнең хаталар? Үскәч, үзенең, һичшиксез, кибетче буласын хәл иткән укучы нигә әле укытучы булам дип сочинение яза? Ник әллә нинди матур сүзләр эзләп әлеге һөнәргә мәдхия җырлый, икейөзләнә?

Ник көчле укучы пычракка баткан итеген көчсезләрдән юдырып ләззәтләнү кичерә?

Бер мәл тын калып, уйлашыйкмы әллә? Уйлашырлык, уйга калырлык бит.

Төп хаталарыбызның берсе — үз балаларыбызга үзебез хуҗа булмауда түгелме? Мәктәпкә артык салынып, үз вазифаларыбызны онытып җибәрдек шикелле. Шуның өстенә тәнкыйтьләргә остардык. Бала алдында укытучысын хурлап, аның соңгы таянычын сындырырга да күп сорамыйбыз. Ә бала ун ел буе шул мәктәпкә йөрергә, шул укытучының каршына утырып белем алырга, тыңларга, җавап бирергә тиеш. Сез көлеп яки нәфрәтләнеп караган кешедән ул инде кирәкле белемне, кирәкле тәрбияне ала алырмы?

Кайчакта бик мәгънәсез итеп: «Акчасын ала бит, укытсын!»— дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Һәркем хезмәте өчен хак ала, монысы табигый. Ә менә бала алдында шундый тотнаксызлык күрсәтеп, акчага гына һичкайдан табып булмый торган хисләрне үтерүебез табигый түгел. Балаларына изгелек теләүче аналар, аталар бу юлга басмый.

Витя Арлянский турында «Алтын балык» балалар бакчасында сөйләделәр. Үзләре ясаган әйберләрдән күргәзмә оештыра башлагач, бәйләгән җиңсә алып килгән. Беренче карашка ышанырлык та түгел. Биш яшьлек малай бер күзен дә төшермичә, бизәкләрен бутамыйча шулай тигез итеп бәйләм бәйләсен, имеш? Ныклап уйласаң, бернинди гаҗәпләнерлек урын юк. Әнисе дә, әтисе дә буш вакытларын бары тик улларына багышлыйлар икән. Ял көннәрендә күрше балаларын да ияртеп, урман-су буйларына китәләр. Кыш көне исә кар әвәләп, уенчык йортлар салалар, чаңгы шуалар. Нинә төрле һөнәре бар икән Витяның? Велосипедта йөри, шахмат уйный, чаңгы шуа, рәсем ясый, бәйли, чигә, фотога төшерә һәм ясый... Әти-әнисенең дә, әнисенең дә беренче булышчысы. Өйдә генә түгел, балалар бакчасында да шулай. Һәр нәрсәне урынына кую, бүлмәне җыю, гөлләргә су сибү, иптәшләренә булышу барысы да аның эше.

Тагын бер йортның ишеген шакыйбыз. Кама Аланы, сигез-унсигез. Түгәрәкләнеп утырган гаилә. Гөлнара пианинода уйный. Нәни бармакларының клавишларга

кагылган һәр мизгеле моң булып тарала. Кыз, көй уңаена сизелер-сизелмәс кенә чайкалып, җыр башлый. Җыр — кошлар турында, балыклар, чәчәкләр турында. Шигырен дә, көен дә үзе уйлап чыгарган. Сүзләреннән — кешелеклелек, көеннән — мәрхәмәтлелек агыла сыман. Бәлки, тиздән нәни сеңелесе турында җыр язар ул. Бишенче туганнары хакында. Һәр туганы, әти-әнисе, хәтта әтисенең кунакка килгән аласы да — җырга тиң кешеләр. Әнисе Рәйсә Бариевна Сабирова, төп хезмәтеннән тыш, мәктәпнең ата-аналар комитеты председателе. Үзенең биш нәние өстенә мәктәптәге күп баланың ата-анасына да киңәшләр бирә. Аларның нинди шартларда яшәвен белә.

Без әле генә акчага да сатып алып булмый торган кешелеклелек турында сөйләштек. Ничек тәрбияләнә икән соң бу сыйфат балада? Улым яки кызым, мәрхәмәтле булып үс дип, өзлексез тукып тору җитәме? Әллә, кемгә нинди ярдәм кирәк, вазифа бүлешеп тормыйча, шунда йөгергән биш бала атасы Дамир Сабировлар үрнәгендә бөреләнәме бу сыйфат? Гаиләдәге кешеләрнең бер-берсенә карата һәрвакыт кайгыртучан мөгамәләсе мисалындамы әллә?

Әнә ич, Рушад мәктәптән кайта да язның суык көнендә дүрт бала тапкан Тошка янына йөгерә. Әтисе суыткычтан алып колбаса, әнисе сөт бирә. Ә Рушад, үзе утырып ашаганчы, эт балаларын, баладан яңа котылган әнкә этне туйдырып кайта.

— Миңа ияләнеп беттеләр инде. Күтеп торалар,— ди ул, шатланып.— Тошка башлы икән! Торба астына кереп балалаган. Анда үзенә дә, балаларына да җылы.

«Баш» ягына килсәң, Рушад үзе дә төшеп калганнардан түгел, укытучы сөйләгәннәрне эләп кенә ала. Бик күп матур әдәбият укый. Әтисе кебек. Укырга алты яшьтән кергән Рушад. Анда да укулар башлангач, ике айга соңарып. Беркөнне мәктәпкә бара да белешеп кайта бу. Рөхсәт алгач, дәресләргә йөри башлый. Аннан, арыптырмы, туктап кала. Әти-әнисе малайның үз иркенә куялар. Рушад исә берничә көннән үҗәтләнеп укый башлый. Хәзер III класста. Отличник.

Саный китсәң, матур гаиләләр, кызык мисаллар күп. Аларга сокланмыйча мөмкин түгел. Ә менә балаларына игътибарсыз булып, аларның киләчәген куркыныч астына куйган кешеләргә бары тик нәфрәтләнеп кенә калу җитә микән?

«Мин ялгыз ана». «Мин фәлән кадәр бала тапкан кеше. Тел генә тидереп карагыз... Шартлар тудырмаска хакыгыз юк»... Баласын калкан итеп, бер оешмадан икенче оешмага кереп, әле тегене, әле моны даулап йөрүчеләр сүзе бу. Ана булу хисләре белән теләсә кайда теләсә ничек сату итәләр, рольгә кереп, өстәл сугып, бәхет даулыйлар. Кирәксенеп, кадерләп, сөеп үстерер, игелекле иттереп тәрбияләр өчен түгел, астыртын ниятләр, явыз максатлар белән тапкан диярсең! Күрәсең, шулай да үзеңне ана кеше дип, исәпләп буладыр... Җидешәр баласын кочаклап тол калган аналар! Менә кайчан сагынып искә алабыз без сезнең сабырлыкны һәм горурлыкны! Сездәге итагатьлелек һәм кече күңеллелекне!..

Дөрес, шартлары килеп бетмәгән, җитеп җитмәгән урыннар күп әле поселокта. Балалары белән тулай торакта яшәүчеләр дә, өйдәш булып торучылар да бар. Әмма йортлар салына, квартиралар бирелә, балалар бакчаларга урнаша торалар. Көнендә — сәгатендә түгел, билгеле. Түзәргә дә, чыдарга да туры килә. Әнә бер-бер артлы тезеп куелган балалар бакчасына гына күз салыйк. Ихата әйләндерелгән, агачлар, чәчәкләр утыртылган. Уен мәйданчыклары әкияттәгечә бизәлгән. Бинаның эченә узсаң — яктылык, чисталык, тәртип.

— Теле ачылып җитмәгән яки дөрес ачылмаган балалар белән аерым эшлибез. Гәүдәләрен төз тотуына, инсафлы итеп ашауларына да игътибар итәбез. Әллә ни әһәмияте юк кебек күренгән бу сыйфатлар — нәкъ менә кешене кеше күзенә матур итеп күрсәтүче гадәтләр. Ә без ул матур кешеләр турында бүген дә, иртәгә дә кайгыртырга тиеш,— ди тәрбияче Ландыш Вәлиуллина.— Балаларны бакчаның зиннәтле заллары, йомшак келәмнәре түгел, мавыктыргыч һәм табигый тормышы җәлеп итәргә тиеш.

Хәзергә махсус белемле тәрбиячеләр җитешми. «Алтын балык»та утыз ике тәрбияченең унсигезе генә тәҗрибәле һәм махсус белемле. Калганнары балаларын үзләре белән йөртү өчен урнашканнар.

Бүгенге көндә Кама Аланында бакча яшендәге 1100 бала булуын искә төшерсәк, шуларның 960 ы әлеге, бөтен шарты китереп төзелгән балалар бакчаларына йөри. 100 балага вакытлыча иске «Кояшкай» бакчасын ремонтлауны күздә тоталар.

Күргәнебезчә, кыен хәлләрдән чыгу, өзеклек булдырмау өчен шартларны вакытлыча да тудырып торырга кирәк. Вакытлыча төзелгән ишегалды клублары, вакытлыча ачылган музыка мәктәбе... Тора-бара аларның һәркайсы үз бинаалары, үз бинаалары... 

Уңай яклар, кимчелекләр, чишелеш көтеп торучы мәсьәләләр... Әйтик, бүгенге көндә чаң сугар мәсьәләнең берсе — су. Чистартылган җылы су җитми. Бу исә һәр төрле йогышлы авыруның килеп чыгуына куркыныч тудыра. Икенчедән, балалар больницасының, шул исәптән зурларныкының да, үз вакытында ачылмавы врачларны хафага сала. Җитмәсә, ашыгыч ярдәм машинасы да бер генә. Түбән Камага җибәргән авыруларны, урын юк, дип, еш кына кире боралар. Җитмеш километр ераклыкка барып, кире борылган авыруның хәлен күз алдына китерегез инде!

Әлегә авырлы хатыннар да шул юлны үтә. Көн саен диярлек яңа кеше туып торган яшь калада бала тудыру йортының проект хәлендә генә булуы бик сәер. Төзелеп бетсә, бөтен Татарстанда бер буласы икән үзе! Утыз ятакка исәпләнгән бу больницада һәр анага 80 квадрат метрлы мәйдан булачак!

Өйләрнең бер-берсенә бик якын салынып, яшел мәйданның, балалар мәйданчыкларының азрак булуы да — әч пошырырлык хәл. Дөрес, яшел мәйдан, проектта каралган дүрт квадрат метрдан җиде квадрат метрга арттырылган. Ә балалар мәйданчыкларына кул җитмәгән әле. Былтыр йортлар каршына куелган тимер атынгычлар, авыр һәм дөрес ясалмаулары белән шактый күңелсезлекләр китереп чыгарган.

Җитешсезлекләр җитәрлек. Әмма Кама Аланында мөкиббән китеп үз һөнәрен яратучы, бала язмышы, кеше сәламәтлеге өчен көрәшүче билгечләр бар. Алар һәрвакыт уяу, һәрвакыт сакта.

«Яңа шәһәрнең йортлары тиз салынуы белән генә түгел, уңайлы, матур булулары ягыннан да кешеләрне сокландырырга тиеш... Хәзер өлгергән өйләребездә яшь буын — киләчәк көннәребезнең хуҗалары яшәячәк. Алар якты тормышта гына түгел, өйләрнең дә иң матурында торсыннар! Һәм, әлбәттә, үзләре дә һәр яктан яхшы булсыннар иде!»— дип язды «Камгэсэнергострой»ның йортлар төзү комбинаты начальнигы, Татарстанның атказанган төзүчесе Марат Шакирович Бибишев.

Изге теләккә кушылабыз. Киләчәкнең горур, үзенә бер кабатланмас шәхесен без нәкъ шулай — гомум көч, акыллы кайгыртучанлык белән генә тәрбияли алабыз!

## Флүс Латыйпов

# «ДОШМАН», «ДЕМОН» ҺӘМ БАШКАЛАР...

— Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы исеменнән Роберт Әнәс улы Новиковны РСФСР Җинаять кодексының 146 нчы статьясы, «б» һәм «д» параграфларында каралган җинаять эшләүдә гаепле дип табарга һәм дүрт елга ирегеннән мәхрүм итәргә, гомуми режимдагы хезмәт белән төзәтү колониясенә җибәрергә; 145 нче статьяның икенче өлешендә каралган җинаять эшләүдә гаепле дип табылган Роберт Рөстәм улы Хәмидуллинны ике елга ирегеннән мәхрүм итәргә, әмма җәмгыятьтән аермыйча да төзәтү һәм тәрбияләү мөмкинлеген искә алып, җәза срогын ике елга кичектереп торырга, балигъ булмаганнар комиссиясе аша җәмәгать тәрбиячесе билгеләргә!

Талап алган әйберләрен ияләренә кире кайтарырга...

Гаепләнүчеләр эскәмиясендәге ике яшүсмернең йөзләре агарып калды. Бер-берсенә карамаска тырышып, икесе дә судьяга текәлделәр.

Юк! Юк! Болай булырга тиеш түгел иде бит. Нәрсәдер әйтер, ниндидер йомшартучы, ярлыкаучы чараларны тагын искә алып үтәр кебек...

Әмма судья бүтән дәшмәде. Кулындагы хөкем карарын өстәлгә салып, озак дәвам иткән утырыштан арыганлыгын белдергәндәй, сул кулы белән маңгаен сыйпап алды. Аның янындагы халык утырышчылары нәрсәдер пышылдаштылар, ярым буш залдагы шаһитлар һәм якыннары, кызыксынып кергән кешеләр урыннарыннан кутәрелә башлады.

— Суд утырышы шушының белән тәмам.

Әле һаман ниндидер могҗизага, үзенә ниндидер ташлама буласына өмет итеп, үзен аз булса да җәлләячәкләренә өмет итеп утырган Роберт Новиков шунда гына, кире кайтарып булмаслык аяныч белән, инде процессның тәмам булуын аңлап алды.

Бетте! Барысы да бетте!.. Хөкем залындагы кешеләргә, сары тактадан ясалган аркалы озын эскәмияләргә, тәрәзә аша күренеп торучы йортларга күз салды. Кышкы кояшның кичке шәфәкъ балкышыннан сирпелгән нурлар бүлмәдәге бар нәрсәне кызылсу төскә буяган. Әйтерсең лә, алар да әле өметләнә, Роберт белән бергә газаплана, аның кичерешләренә кушыла. Берничә мизгел эчендә җәзаның котылгысыз икәне дә, залдагыларның да, судья һәм утырышчыларның да инде берни белән дә ярдәм итә алмавы башына барып җитте. Күзләре залда утыручы әбисенеке белән очрашты. Кульяулык чите белән күз кырыйларын сөртүче әбисенең куллары калтыранганын абайлап өлгерде һәм бөтен хөкем процессы буенча үзен болардан өстен, горур һәм берникә исе китмәс супермен итеп күрсәтергә тәләп утырган егет, кинәт кенә үзенең тез буыннарының ниндидер бер җирәнгеч хәлсезлек белән йомшап китүен, бармакларының дерелди башлавын сизеп алды. Әле генә кәгазьдәй агарган битенә кызыллык йөгерде, колаклары кызыша башлады. Янында утырган адашы Роберт Хәмидуллинга, яшьләренә тыгылган әбисенә тыелгысыз, бер сәбәпсез ачуы кузгалды.

— Әйе, мин гаепле, гаепле. Тик бер юлга гафу итегез! Аермагыз мине дусларымнан, мөмкинлек бирегез миңа кешечә яши башларга! Төзәлермен мин, төзәлермен! Шаяру гына, уен гына иде бит болар,— дип кычкырасы, ялварасы килде.— Нигә бу судьялар шулкадәр кырыс, нигә кешене гафу итә белмиләр икән?! Моңа кадәр өйдә дә, үзе укыган интернат-мәктәптә дә барысы да ничек җиңел, шома бара иде ләбаса. Тотып бер ачуланырлар,

я булмаса, күп дигәндә, «икеле» куярлар иде дә, шуның белән барысы да бетәр иде...

Һаман ышанып җитми иде әле ул. Болар барысы да бер куркыныч төш кенәдер. Өйдән милиция килеп алу да, сорау алулар да, тикшерүче кабинеты да, төрмә камерасы да, һәм ниһаять, бу суд та чын түгелдер.

Шушы уйларына икенчесе килеп кушылды. Әллә нинди зәһәрлек белән сорады ул:

— Ә шәһәр урамнарында кеше талап йөрүләрең чынмы? Бугазларына пычак терәп яшьтәшләреңне, үзеңнән кечкенәләрне чишендергәндә алар нәрсә хис итте икән? Өерегез белән кысрыклап акча даулаганда алар нәрсә кичерде икән?! Җавап бир! Аларны кызгана белдеңме? Кешеләргә миһербанлык күрсәттеңме?..

Бу сорауларны, әллә каян, миенең нинди дер билгесез караңгы почмагыннан яңгыраучы сүзләрне ишетәсе килми иде аның. Тик бу сүзләр читтән түгел, ә эчтән килә, кайтаваз шикелле дулкын-дулкын булып, кыяларга бәрелеп сынган, бәргәләнгән дулкын булып калтырана, сорый, талап итә:

— Аларны кызгана белдеңме? Үзеңнең кушаматың «Дошман» булганга горурланып йөргәнеңне хәтерлисеңме? Ә «дошман» сүзенең нәрсә аңлатканын беләсеңме? Нәрсә ул, кем ул дошман!

Бу сүзләрнең вөҗдан сүзе, күңелендә йоклап яткан намусның уяна башлавы икәнен аңлый алмый иде әле ул. Хәер, аны аңлаудан әлегә ул шактый ерак. Уйланыр вакыты да, урыны да алда. Озын-озак дүрт ел эчендә ниләр уйланмас та ниләр генә кичерелмәс!..

— Суд бетте! Киттек!

Янындагы солдатларның берсе эндәшә икән. Уйларын шул бүлде. Җанга авырттыргыч яра ясап, әрнеткеч сызлау өстәп торган уйларының бүленүенә хәтта сөенеп куйгандай булды. Үзеннән ике-өч яшькә генә өлкән солдатлар сагы астында якты залдан чыгып, суд бинасының ремонт бара торган караңгы һәм кысан коридорына атлады.

Күз кыры белән генә, җәза срогы ике елга кичектерелгән Роберт Хәмидуллинның чыгып китүен күреп калды. Тик тегесе аңа борылып карамады. Әллә карап та инде күрмәмешкә салышты. Новиков әлегә моны аңларлык хәлдә түгел, аның үз кайгысы кайгы, үз уйлары җанын кыйный. Хәер, карамаса да, берни әйтә алмыйсың. Хәзер алар тормышның икесе ике ягында. Шушы кечкенә генә залда ук инде дөнья икегә бүленгән. Бер ягында яктылык, ирекле тормыш, дуслар, уку, хезмәт, үзеңчә яшәү мөмкинлеге, икенче ягында исә тоткынлык.

Әле кайчан гына аерылмас дуслар исәпләнгән ике адашның юллары шулай аерылды. Дуслык! Хәер, урамда бергә тырай тибүне дуслык дип атап, бу бөек төшенчәне мыскыллламыйбызмы соң?!

Үпкәсен, ачуын һәм гарьлеген эченә йотты Роберт. Әле кайчан гына барысы да үтәр, яшьлектәге бер шаяру гына булып калыр иде кебек. Әмма шаяруның да чиге бар икән!.. Уеннан уймак чыга дигән сүзләр шулмы соң әллә?

Энисе оештыра торган эчкечеләр мәҗлесендә үзләрен бәйсез һәм тәкәббер тотарга яратучы ир-атларның, бераз төшереп алгач, гитара чиртеп «черный ворон» дип җырлаганнары исенә төште. Менә кайда икән ул җырларның асыл мәгънәсе. Әнә хәзер үзен дә шундый машинага утыртып каядыр алып баралар. Ә башта уйлар айкала, тәмәке төтене белән тулган сөремле бүлмәләрдә ишеткән түгел, ә башкалардан, өлкәнрәкләрдән әйтелгән кисәтүләр яңара.

Әйе, әйе! Кара эшләпә кигән күзлекле абзый нәкъ менә шулай: «Уеннан уймак чыгар дип уйламыйсызмы?» — дип сораган иде. Әй, ул чакларны кире кайтарып булса!..

...Көзге караңгы кичләрнең берсе иде ул. Иртәдән башланган вак, әллә нинди сыек яңгырның туктарга исәбе юк. Шәһәр өстендә инде утлар кабынган. Юеш асфальтта үткән-сүткән машиналарның нуры чагыла, төрле төстәге неон рекламаларның яктылыгы күлдәвекләр өстендә дерелдәп кабатлана. Әмма көн ямьсезлеге дә, муенга агып төшеп, тәнне чиркандырып торучы вак тамчыларның салкынлыгы да тәэсир итми аларга. Урам тулы халык! Кешеләр эштән кайта. Ә алар — «Дошман», «Демон», «Штопор», «Монах», «Седой» һәм башкалар әнә шул тар тротуарларны иңләп киләләр. Бу урамнар, чатлар, мәйданнар аларныкы! Әйе, аларныкы! Аларның үзләре генә

белгән дөньялары, үзләре бүлеп алган биләмәләре бар. Башка малайлар тыгылып карасын! Хәер, алар кебек төркемләп йөрүчеләр күп түгел. Кемнәрдер укый башлады, кемнәрдер эшкә керде... Ә шушы урамнарга хуҗа булып калган «Дошман» әле бирешми. Хуҗа булу хисе исертә, иптәшләренең бердәмлеге, якынлыгы йөрәген җылыта. Берсен-берсе уздырырга тырышып кычкырып сөйләшәләр, көлешәләр. «Дөнья безнең кулда. Алда бетмәс-төкәнмәс яшьлек, көч, дәрт!»

Шулай күпме барганнардыр, кайсыдыр әйтә куйды:

— Нәрсә, «туган»нар, әллә җылынып алабызмы?

— Ә сәмәнең күпме соң?

— Ил төкерсә, күл була,— дип җавап кайтарды арадан берсе. Тапкырлыгына масайгандай, үзе үк кычкырып көлеп җибәрде.

— Җитмәсә, «шакалить» итәргә дә була. Безнең «Монах» оста мондый эшкә.

«Монах», ягъни Роберт Хәмидуллин, үзенә аерым игътибардан тагын да кәпрәеп китте ахры, тавышын калынрак чыгарырга тырышып җавап кайтарды:

— Җитмәсә, момент оештырабыз аны.

«Шакалить» итүнең нәрсә икәнен барысы да яхшы белә. «Балалар дөньясы» универмагы янында кечерәк яшьтәгеләрне сагалап тору дигәнне аңлата ул. Ялгыз бала килеп чыгуга уратып алалар да, күпме акчасы бар — кесәсен бушаталар. Күп чыкмый чыгуын, әмма утыз-кырык тиеннән дә шактый җыела. Исән-имин котылган малайлар исә артларына да карамый элдертәләр. Хәер, бер ялгызың алты-җиде үсмергә каршы торып кара!

Ул көнне аңа ук барып җитмәде җитүен. Һәркайсының өйдән эләктереп чыккан «сәмәне» бар икән. Кесәдә йөри-йөри таушалып, бөгәрләнеп беткән берлекләр, сүрән яктылыкта салкын елтыраучы көмешләр, саллы бакырлар Новиков учына җыелды.

Аракы кибете янында сузылган чиратка басуның мәгънәсез икәнен беләләр. Шуңа күрә арада иң озыны булган Новиковның үзенә кәсепкә керешергә туры килде.

— Абзый кеше, бер-ике «бормотуха» алып чыгып бир әле,— дип эндәште ул өстенә нейлон куртка, башына ниндидер төссез кепка кигән ирләрнең берсенә.

— Нигә үзең басмыйсың? — дип сорады тегесе.

— Әнә ич, «мент»лар тора. Кертмәсләр...

— Һа, алар сиңа карый дип беләсеңме?! Аларга исерекләр кирәк.

— Ну... Болай ышанычлырак. Әйдә, брат, кысмырланма,— дип ашналарча тонга күчте Роберт, әңгәмәдәшенең артык нәзберек түгел икәнен чамалап.

— Бир алайса...

Бераздан кулларына ике портвейн эләккән яшүсмерләр якындагы йортларның берсенә, ярымкараңгы ишек төбенә кереп киттеләр. Шешәне, чалбарын бушата төшеп, корсагы янына тыккан иде. Аның шома салкынлыгы ничектер чиркандыргыч тәэсир итте Робертка. Хәер, бер-ике йотым ясагач, чиркангыч суыклык юкка чыгачак. Монысын белә ул. Күз алдында әнисенең әчеп шешенгән йөзе пәйда булды. Әнә ул елмаеп, гәүдәсен туры тотарга тырышып Роберт янына килә, аны кочаклап, сөяргә маташа. Авызыннан әшәке ис аңкый. Роберт аны төртеп җибәрә дә бүлмәнең икенче почмагына китә. Ә әнисе, кызарган күзләреннән яшь агызып, үзенекен, эчкән саен кабатлый торган сүзләрен тәкрарларга кереша.

— Син минем йөрәк парәм, минем хатам да, шатлыгым да...

Исерек телдән әйтелгән бу сүзләр инде Робертка тәэсир итми. Күп кабатлаудан шомарып, мәгънәсезләнеп беткән алар. Хәер, әнисе Роберт белән күрешеп, очрашып торырга бик ашкынмый. Нишләптер, назлы, чын күңелдән яратып әйткән сүзләрен дә, ана мәхәббәтен дә хәтерләми ул. Я әбисендә, я әбисенең әнисендә елап калганы, әнисе чыгып киткәндә кулын сузып, очкылык тота башлаганчы үксегәне генә әллә нинди яман төш шикелле исенә төшә. Ә үсә төшкәч, Дербышкидагы интернат-мәктәп, үзе шикелле үк һәрнәрсәгә шикләнеп, менә-менә әтием, я әнием килер дип, көне-төне билгесез көтү, нәрсәгәдер өметләнү белән яшәгән малайлар һәм кызлар... Үскән саен өметләр кими барды. Кайчандыр бер-берсенә маңгай астыннан шикләнеп карап торган малайлар үзләренең башкалардан аерымлыкларын, хәтта өстенлекләрен аңлый башладылар ахры. Монда һәркем үзенә үзе

хужа. Монда көч һәм кыюлык кирәк! Баш бирмим, кыерсытмасыннар дисәң, үзеңә дә башкалар шикелле булырга, йодрыгыңны эшкә җигә белергә кирәк. Укытучыларга, тәрбиячеләргә әләкләргә ярамый. Бусы — язылмаган закон. Кемнең дә булса шундый гадәтен сизеп алсалар, аңа көн юк. Укытучылар — дәрестә, тәрбиячеләр дәрестән соң берничә сәгать синең янда була. Ә башка вакытта үз көнеңне үзең күрәсең. Телисең — укы, телисең — тырай тибеп йөр...

Подъезд тәрәзәсе төбенә килеп урнаштылар. Роберт инде тән җылысы белән җылына башлаган яшькелт шешәне суырып чыгарды, әнисе янына килеп йөрүче ир-атлардан күргәнчә, фыртланып, бөкене тешләре арасына гына кыстырып тартып алды да ике-өч йотым ясады. Җылымса портвейн әйләнә буйлап кулдан кулга китте.

Озак йөрүдән ярсынган үсмерләр тынычланып, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, әңгәмә корып җибәрделәр.

— Кара әле, «Дошман», берәр җиргә урнашмадыңмы? — Бу сорауны «Монах», ягъни Роберт Хәмидуллин бирде.

— Урнашты ди...

— Нәрсә, әллә теләмисеңме?

— Бар, урнашып кара,— диде Новиков ачу белән һәм теш арасыннан чертләтеп идәнгә төкерде.— Китапта гына бит ул барысы да ал да гөл. Ә үзеңә килеп терәлсә, нәрсә икәнен тиз белерсең.

— Сөйлә инде, кайсы заводта булдың? — дип малайлар шаулаша башлады.

— Кайсында булса да барыбер түгелмени? Килеп кергәч тә иң элек ничә яшьтә дип сорыйлар. Нинди һөнәрең бар, имеш,— диде Роберт, сүзләрен сузып-сузып, малайларга таныш булмаган берәүне үчекләргә теләгәндәй.— Кайсы училищеда укыдың, янәсе. Һөнәрем юк, интернатта сигез класс бетердем, унбиш тулды, дигәч, йөзләре үк үзгәреп китә. Бездә, имеш, сезгә ярардай эш юк. Менә, һөнәр училищесы тәмамлаган булсаң, табар идек. Тагын берәр елдан килерсез. Бәлки нәрсә дә булса табарбыз, янәсе... Ә миңа бит бүген, хәзер кирәк. Хәзер!

Роберт ачу белән шешәне тартып алды һәм инде төбендә генә калган болганчык сыекчаны тамагына койды. Сүзне дәвам итәргә мөмкинлек бирмәделәр. Ишек ачылып ябылды һәм башына кара эшләпә, өстенә озын плащ кигән, кулына кәкре башлы таяк тоткан күзлекле берәү килеп керде. Ул башкалар шикелле, күрмәмешкә салышып, малайлар төркеме янынпан җәһәт кенә узып китмәде, киресенчә, туп-туры алар янына юнәлде.

— Нәрсә, егетләр, күңел ачабызмы? — диде ул ничектер үз итеп һәм дустанә булырга тырышып.

Үткән-сүткәннәрнең күрмәмешкә салынуына, я булмаса, ачуланып кычкырынуына күнегеп беткән үсмерләр шикләнеп ир-атка текәлделәр. Берсенең авызыннан бер сүз чыкмады.

— Нигә дәшмисез, алты-җиде кеше берәүдән курыкмыйсыздыр ич?!

— Юк, курыкмыйбыз! — Малайлар көлештеләр. Бу кешенең ниндидер сабыр тынычлыгы, үз итеп сөйләшүе арадагы киеренкелекне алып ташлагандай булды.

— Алайса, сезнең белән сөйләшергә ярыйдыр бит.

— Ә нигә ярамасын ди?!

— Бер сорау бирим әле. Полк командиры итеп билгеләнгәндә Аркадий Гайдарга ничә яшь булган? Беләсезме?

— ?!

Малайларның иңсәләрен җыерып, бер-берсенә карашып алуларын күргәч, ир кеше сүзне үзе дәвам иттерде:

— Уналты. Нәкъ уналты яшьтә була. Ә сезгә ничә яшь?

— Унбиш...

— Уналты...

— Уналты ярым...

— Сез дә командир була алыр идегезме? — диде ир кеше.— Шул хакта уйлап караганыгыз юкмы? Ни өчен уналты яшьлекләр гражданнар сугышында, Бөек Ватан сугышында олылар башкара алмастай эшләрне үтәп чыккан? Аларга ышанганнар, аларга куркыныч заданиеләр биргәннәр. Өлкәннәр белән иңгә-иң торып илгә файда китерү өчен тырышканнар. Ә сез?..

— Нәрсә, «ә без»... Безгә кем задание биргән? Кемгә кирәк без? — дип ачу белән җавап кайтарды Новиков.— Олыларга, сезгә сөйләү рәхәт ул...

Аны «Штопор» бүлдерде:
— Борчылма, Робик. Син дә командир ич. Безнең командир!
Новиков баягы ачуын басып, таныш түгел кеше белән ризалашкандай әйтеп куйды:
— Ә нигә булмаска! Билгеләп карагыз!
— Мәнә мин дә шуны әйтергә теләгән идем. Әмма нигә билгеләгәнне кәтеп торырга?!. Үзегезгә шөгыль таба алмыйсызмыни? Ә болай төркем-төркем җыелып, кеше куркытып йөрүдән нинди мәгънә?! Кемгә файда сезнең болай йөрүдән? Үзегезгәме, кешегәме, эти-әниегезгәме? Пыскып яшәмәгез! Пыскып янган учакның җылысы булмый аның...
Таныш түгел кеше, үзе дә сизмәстән, Робертның авырткан ярасына кагылды.
— Нигә әле сез безгә мораль укыйсыз? Кем сорады сездән?
Үсмерләрнең ачуы кабара башлаганны сизгән ир-ат арткарак чигенде.
— Ну-ну! — диде ул кисәтүле тавыш белән.— Мин милиция чакыртырга да күп алмам. Уеннан уймак чыкмасын!
Башланмаган икенче шешәне кыстырып, малайлар шаулашып чыгып киттеләр. Эшләпәле кеше башын чайкап, аларга карап калды.
Төркем икенче подъездда урнашты.
— Минем яшьтә булып, үзе эшкә урнашып карасын иде ул.— дип уйлап алды Новиков һәм әле күптән түгел генә Вахитов районы халык судында булып үткән күренеш ирексездән хәтерендә бөтен ачыклыгы белән яңарды. Кемне хөкем итәләр диген. Әнисен — Татьяна Новикованы.
Үзе өчен күп яңа нәрсә белде ул анда. Билгесез әтисенә дә, яңа яклары белән ачылган әнисенә дә күңелендә рәнҗү катыш ачу уянды.
Суд председателенең сүзләре һаман да колак төбендә яңгырап тора кебек.
— Новикова Татьяна Александровна — 1955 елда туган. 1971 нче елда, тугызынчыда укыганда, классташыннан бала тапкан. 1975 нче елда кияүгә чыга, өч елдан соң иреннән аерыла. 1980 нче елга кадәр заводта эшли, аннан соң — төрле җирләрдә. Хәзер беркайда да эшләми. 1983 нче елдан бирле, төрмәдән кайткан Игорь белән, язылышмыйча гына, ир белән хатын булып яшиләр. 15 яшьлек малае интернатта тәрбияләнә.
1986 елның май азагында иренең әнисе белән бер танышларының өенә үтеп керәләр һәм түбәндәге әйберләрне урлыйлар. Кара портфель — бәясе 10 сум, «олимпийка» — бәясе 10 сум, зонтик — бәясе 30 сум, шарф — бәясе 50 сум, ике пар перчатка — бәясе өчәр сум, чәшке бүрек — бәясе 120 сум. Болардан тыш ике банка куертылган сөт, бер шешә көнбагыш мае, бер банка иваси консервы...
Үзен интернатка илтеп тыккан әнисенең шөгыльләренә шунда гына күзләре ачылды Робертның. Ә барысы да әйбәт кебек иде бит. Каникулларга кайтканда: «Эшлим, улым, эшлим. Мәнә хезмәт хакын гына алыйм да»,— дип ничек сөйләнә иде, юкса.
— Әни, миңа да кроссовка алыйк әле!
— Алырбыз, улым, алырбыз.
— Ә син мине интернаттан алырсыңмы?
— Алырбыз, алырбыз, улым...
Җаваплары шулай ышандыргыч һәм беркатлы иде аның. Вәгъдәләр ява, әмма берсе дә үтәлми.
Әнисе кулга алынган, шаһит сыйфатында сорау алуга чакырыла башлаган көннәрендә үзенең язмышы, үзен ни көтүе турында ачыргаланып уйланды Роберт. Тик үтәлмәгән вәгъдәләрдән, өлкәннәрнең күз йомуыннан, суздә — бер, эштә икенче төрле булуны күрүдән ваемсызлыкка гадәтләнгән күңелендә һаман бер өмет яшәде: барысы да үтәр әле, бетәр әле. Бер мин генә түгел!.. Бер мин генә түгел!
Әмма бу вакытта инде аны күптән милиция эзли иде. Бауман районы милициясе. Вакыт тәгәрмәчен кирегә әйләндереп булмый. Вакыйгалар да, тәгәрмәч калдырган эз шикелле бер-берсенә тоташып килә. Аларны өзеп булмый. Кылган гамәлеңнән икенче, өченче, дүртенче вакыйга үсеп чыга.

* * *

Җәй урталары иде. Бауман районы эчке эшләр бүлегенә яшүсмерләрдән гаризалар керә башлады. Эчтәлеге бер — көпә-көндез, шәһәр уртасында

пычак яки башка корал белән янап, чишендергәннәр, әйберләрен талаганнар. Гаризаларда талаучыларның төс-бите түгел, ә ничек киенүе сурәтләнгән. Тик шәһәр урамнарында нәкъ менә шулай киенгән яшьләрнең йөзләрчә, меңнәрчә булуын искә алсаң, тикшерүчегә тотыныр өчен җеп очын табу шактый кыен иде. Барысы да мода галәмәте. Зыян күрүчеләр, ни эшләптер, күзләренә иң беренче чалынган билгеләрне генә язганнар. Аягында кроссовка, өстендә «олимпийка»... Фамилияләре дә, исемнәре дә билгеле түгел — бары тик кушаматлар.

Тикшерүче, кече лейтенант Әлембаев янына Казан техникумнарының берсендә укучы Рәфикъ Габдуллинны чакырды.

— Әйдәгез, тагын бер кат ул көнне баштанаяк искә төшерик әле: кайда очраштыгыз, нәрсәләр турында сөйләштегез? Бер генә детальне дә онытмаска тырышыгыз! — диде ул алдында утыручы чандыр егеткә.

— Егерменче июль иде ул. Көндезге сәгать берләр тирәсе. Киногa бара идем. Бауман урамында яныма унҗиде яшьләр тирәсендәге озын буйлы бер егет килеп туктады. Тик торганда: «Син кайсы районнан, малайлар төркемендә йөрисеңме?» — дип сорады.

— Нәкъ шундый сүзләр белән әйттеме ул?

— Юк, ул башка төрле сүзләр белән сөйли.

— Шул сүзләр беләнрәк сөйләргә тырыш. Кешенең сөйләме дә кайчагында күп нәрсә бирә.

— «С пацанами мотаешься?» — дип сораган иде инде ул,— дип дәвам итте Рәфикъ.— Мин аңа беркем белән дә йөрмәгәнемне, кайда торганымны әйткәч, ул тагын сорау бирде:

— Ә син минем каян икәнне беләсеңме?

— Юк.

— Кремльдән мин,— диде ул ниндидер бер яшерен сер хәбәр иткәндәй.

— Булса ни?! Мин бернинди төркем белән дә йөрмим, йөрергә дә теләмим.

— Йөргән булсаң, мин сине шушында ук бәреп ташлар идем. Хәер, хаҗәтең шул хәтле генә. Курыкма, мин сиңа берни дә эшләмәм. Бер сорау гына бар. Кеше саны өчен Кольцога кадәр бергә барыгыз әле! Юкса, монда мине кыйнарга мөмкиннәр,— диде бу егет. Ә минем белән ул чакта унбер яшьләр тирәсендәге күрше малае да бар иде.

Киттек шулай. Берничә тапкыр ташлап китәргә дә омтылып карадым. Әмма ул һаман саен кулымнан тотып: «Курыкма. Әнә Тукай һәйкәле янына гына җитик тә, кире китәрсез»,— дип тынычландырып, ялынып диярлек килде... Кем белгән бит аның шундый икейөзле икәнен?!.

Рәфикъ үкенечле итеп, авыр сулап куйды.

— Миңа аның әйберләре дә ул кадәр жәл түгел. Кешенең шундый мәкеренә, пычрак хәйләсенә ышанганыма җаным кыйнала.

Кече лейтенант яшүсмер егет күңелендәге рәнҗүне, аның бу вакыйганы олы бер фаҗига сыман кабул итүен яхшы аңлый иде. Әйе, намусыңа кул сузудан да тирәнрәк җәрәхәт калдыручы нәрсә юктыр бу дөньяда.

Егет бераз тын гына утырды һәм яңадан вакыйга агышын исенә төшерә башлады.

— Тукай һәйкәле янындагы бакчада безнең янга тагын бер малай килде. Алар үзара нәрсәдер пышылдашып алдылар, анысын ишетмәдем, яңасы миңа кулын сузды:

— Әйде, танышыйк! Мин — Витя!

Мин дә кулымны суздым. Шуннан соң тагын беренче егет сүз башлады:

— Әнә бакча артында төзелеш бар. Андагы чокырда Суконка малайлары булырга мөмкин. Шуларны гына карап килик! Аларны күрсәң, шунда ук чабып китәрсең.

Бу вакытта күрше малае бакчадагы эскәмиядә утырып калды. Без өчәүләп чокырга төшеп киттек. Төшеп җитү булды, егетләрнең беренчесе әллә каян гына пычак тартып чыгарып, муеныма китереп терәде:

— Ә хәзер олимпийкаңны һәм трикоңны сал! (Минем өстә кызыл, өряңа спорт костюмы иде).

— Салмыйм! — дидем мин. Ул пычакны муенга ачу белән тагын да катырак төртеп, кабатлады:

— Сал! Юкса үзеңә үк начар булыр!

Тагын әллә нинди янау сүзләре әйтте инде ул, исемдә калмаган. Шунысын ачык хәтерлим, икенче егет аңа берничә тапкыр: «Ташла инде, «Дош-

ман», кирәкми, чишендермә».— дип әйтеп карады. Үзем дә сизми калдым, олимпийканы тартып та алды, шунда кулымдагы сәгатемә күзе төште. «Командирские» дигән сәгать, туган көнемә бүләк иткәннәр иде.
Аннан соң берни дә булмагандай, ант итәргә тотынды:
— Шушында эскәмиядә көтеп торыгыз. Без «Сәламәтлек» комбинаты янына гына барып киләбез дә әйберләреңне кире кайтарырбыз...
Пычакны исә миңа ташлап калдырды:
— Хәзергә синдә торып торсын. Юкса мине алып китүләре мөмкин.
— Сез көттегезме соң? — дип сорау бирде Әлембаев.
— Көттек. Өченче яртыларга кадәр диярлек көттек. Килмәделәр.

Талауда катнашкан үсмерләрнең берсенең «Дошман» кушаматлы булуы, икенчесенең исеме Витя икәнлеге генә мәгълүм. Хәер, аларның да дөреслеккә туры килүе шикле. Җинаять кылыр алдыннан кем генә үзенең дөрес исемен әйтер икән.
Дружиначыларның Куйбышев мәйданы, Тукай һәйкәле янындагы бакчада күзәтеп йөрүе дә шактый озак берниндн нәтиҗә бирмәде. Әмма, кем әйтмешли, сабыр иткән — морадына җиткән. Ниһаять, инде берничә тапкыр ачыктан-ачык талау белән шөгыльләнгән төркем җинаять өстендә кулга алынды.
Җинаять эшендәге нечкәлекләрне, дөреслекне ачыклауга, тикшерүгә озак вакыт кирәк булмады. Эш Бауман район халык судына тапшырылды.

Хөкем бара. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә мөстәкыйль тормыш юлын башлап та җибәрергә өлгермәгән ике яшүсмер. Судья Ринат Касыймовның мондый эшне беренче тапкыр гына каравы түгел. Мәктәп эскәмиясендә утырырга, яисә завод-фабрика цехларында хәләл көче белән хезмәт итәргә тиешле үсмерләрнең аяныч язмышлары беркайчан да битараф калдыра алмый аны. Әмма җинаять эшләнгән. Кеше хокукына, аның кешелек дәрәҗәсенә каршы тупас һәм мәсхәрәле җинаять эшләнгән. Никадәр кызгансаң да, хәлләренә керергә тырышсаң да, законны читләтеп үтеп булмый. Аның каршында бар кеше дә бертигез. Ләкин шунысын да онытырга ярамый, һәр җинаять кинәт кенә эшләнми. Бала туганда ук җинаятьче булып тумый. Шунлыктан Ринат Гыйлемьярович иң элек җинаятьнең бөтен нечкәлекләрен кат-кат тикшерә, чагыштыра, анализлый, шушы хәлнең килеп чыгуында, җәмгыятькә куркыныч тудыручы кеше үсеп килүдә кемнәрнең гаебе бар икәнлеген дә билгеләргә тырыша.
Хакыйкатьне эзләү турында соңыннан сөйләве генә җиңел, ә менә конкрет хөкем эшендә аны табу, ай-һай, кыен, дөреслеккә бару юлында күпме четереклекләр һәм чуалчыклар була! Ә судьялар ялгыша алмый, ялгышырга тиеш түгел. Суд ялгышы кеше иреге белән генә түгел, кайчагында хәтта аның тормышы белән дә бәйле.
Менә шуңа күрә дә Ринат Гыйлемьярович судта җинаятьнең ничек эшләнүен, гаепләләрне ачыклау, китерелгән матди һәм әхлакый зыянны гына түгел, ә бу яшьләрнең яшәү рәвешен һәм нинди шартларда тәрбияләнүен дә җентекләп өйрәнергә булды. Алар «Эш»кә теркәлгән беркетмәләрдә дә бар барын. Әмма якыннары, туганнары, иптәшләре утырган залда тагын бер кат боларны күз алдыннан үткәрү — аларның күпмедер дәрәҗәдә үзләренә дә кагылганлыгын искә төшерү булыр. Җинаятьче алар күз алдында үскән, өлгергән ләбаса.
Бер-бер артлы сораулар бирелә. Болгатылган су тынып, аның өстендәге шәүләләр һаман саен ачыграк күренә барган шикелле, унбишуналты яшьлек бу үсмерләрнең дә тормыш көзгесе чынбарлыкны дөресрәк күрсәтә бара.
— Роберт Хәмидуллин, сез Новиков белән кайчан таныштыгыз?
— Бер класста укыган идек. Аның кушаматы «Дошман». Тукай скверына берничә тапкыр килдем. Анда «Демон», «Седой», «Штопор» кушаматлы малайлар белән таныштым. Мин — «Монах». Шунда берничә тапкыр йөрдек, вак малайлардан акча алып...
Судка Роберт Хәмидуллинның әбисе генә килгән иде.
— Робертның әнисе бик яшьли эшкә кешеләр тәэсиренә эләкте шул,— дип башлады ул сүзен. Үзенең кызы турында шулай сөйләү авыр, ай-һай, авыр иде аңа, күрәсең.— Эчә башлады, икешәр-өчәр көн кайтмый йөри. Өйдәге әйберләрне урлап сатуга хәтле барып җиткәч инде...

— Әтисе кайда иде соң?
Судьяның соравына игътибар итеп тормастан, тагын үзенекен дәвам итте:
— Җитмеш тугызынчы елда эшләмичә йөргән өчен хөкем иткәннәр иде аны. Бер елдан соң кире кайтты кайтуын. Хәзер менә тагын кияүгә чыгып йөри... Ә этисе... этисе, әле Робертка дүрт яшь чакта ук үлгән иде.
— Хәзер кем белән торасың, Роберт?
Битен каплап урынына утырган әбигә бүтән сүз кушмады судья. Сорауны онытына бирде.
— Мин хәзер әбием белән торам. Әниемнең ана хокукын алганнар иде инде. Хәзер аның кайда икәнен белмим...
Ике яшүсмер, ике язмыш... Ләкин алар үзләренең рухи гариплекләре белән бер-берсенә никадәр охшаш һәм аяныч иде. Ринат Касыймовка болар инде күптән аңык, әмма хөкем процессы үз чиратында дәвам итә. Үсмерләрнең чыгышы, бер караганда, ярлыкау сорагандай, икенче караганда, иң газиз кешеләренә — әниләренә гаепләү булып та яңгырый кебек.
— Әнием хөкем ителде, хәзер төрмәдә...
Роберт Новиковның сүзләре бу. Әнисе артыннан тайгак юлга кереп киткән малай тәүбәсе.
— Ул мин талап алып кайткан әйберләрнең кайберләрен аракыга алыштыра иде. Икенче һөнәр училищесында укый башлаган идем дә, әниемне утырткач, ташларга мәҗбүр булдым. Әбиләремдә кунып йөри башладым. Стипендия юк... Эшкә урнашырга тырышып карадым.
Залда киеренке тынлык урнашты. Хәтта халык утырышчылары да күзләрен читкә, тәрәзәгә төбәгәннәр. Язмыш чатында чарасыз калган малайның фаҗигасе һәм мәрхәмәтсезлеге дә, җаваплылык хисен югалтуын аңлау да катлаулы тойгылар — кызгану катыш нәфрәт хисе уята иде.
Тагын судья тавышы яңгырады:
— Новиковның законлы вәкиле, әбисенең әнисе нәрсә әйтер?
Сиксән яшьлек Анна Александровна инде мәгълүм булганнарга нәрсә генә өсти алыр? Сорауны биргәндә аның нинди дә булса яңалык әйтә алуына артык өметләнмәгән дә иде Ринат Гыйлемьярович. Әмма әби, һәр сүзен кистереп, аларны аерып-аерып куйган кебек, куллары белән һаваны яра-яра сөйли башлагач, нык ялгышканын аңлады.
— Әйе, әйтәм, барысын да әйтәм,— дип кереште ул.
Шактый өлкән яшьтә булса да, әле күзлек тә кимәгән, таза, нык карчыкның талпынуы, оныгының малаен яклауга, саклауга күтәрелүе иде бу.
— Дүрт яшенә кадәр Роберт миндә яшәде,— дип дәвам итте ул.— Аннан соң аны миннән алып киттеләр, ә җиде яше җиткәч, әбисе интернатка урнаштырды. Малай янына берәрсе барып йөргәндер дип беләсезме?
Әби, җавап көткәндәй, тирә-ягына карап алды. Әмма эндәшүче булмагач, элеккеге кайнарлыгын сүрелдермичә, тагын ярып-ярып сала башлады:
— Юк. Беркем дә йөрмәде. Чәршәмбе саен мин бара идем. Беркем дә аның тәрбиясе белән шөгыльләнмәде. Ә сигезенче классны тәмамлагач, әнисе үз янына алды. Нигә кирәк ул сиңа. Ник аласың? дип, сорап карадым. Дөресен әйтим, аңа аракы һәм «айгыр»лардан башка бернәрсә дә кирәкми иде. Тупаслыгым өчен гафу итегез, йөрәгемә чыдый алмаганга күрә сөйлим. Ә ул... ә ул... «Әгәр балам булмаса, мине утыртачаклар» дип җавап кайтарды. Малай түгел, калкан кирәк иде аңа. Чаршау. Качып ятарга.
Әби, судья, прокурор, адвокатларга карап, тынычрак тавышка күчте:
— Әле сиксән өч-сиксән дүртенче елларда ук Совет районы милициясенә әйтеп карадым мин, алкоголизмнан дәваларга җибәрегез дип. Балигъ булмаган баласы барларны җибәрергә хакыбыз юк, диделәр.
Моннан да ачы фаҗиганең булуы мөмкинме икән?! Карчык, бер әйткәч, барысын да әйтеп бетерим инде, дигәндәй, яңадан тавышын күтәрде. Үз мәнфәгате белән генә, аракы сөременнән айный алмый яшәгән, баласын да, авыру анасын һәм әбисен дә оныткан оныгына гаеп ташлау җиңел идемикән аңа?! Әйе, чын гаепләү, кырыс һәм катгый хөкем иде бу. Ана хөкеме!
— Ул, ул һәлак итте улымны, ул юлдан яздырды. Бала аның аркасында юкка чыкты. Хәзер үзе төрмәдә чери әнә... Мин бер үзем генә яшим, ялгыз карчыкмын. Күпме гомерем калгандыр... Бик, бик авыр миңа, ансыз тагын да авыррак булачак. Үтенәм сездән, алла хакына коткарыгыз баланы!
Әбинең йөзендә шулкадәр тирән газап билгеләре иде, Ринат Гыйлемьярович үзен борчыган сорауны бирергәме-бирмәскәме дип шактый икеләнеп торды... Әмма ачыклык кертми калырга ярамый.

— Совет районы милициясенә нинди үтенеч белән мөрәҗәгать иткән идегез? Шуны төгәлрәк әйтегез әле.

— Мин әнисен ана хокукыннан мәхрүм итүләрен, мәҗбүри рәвештә дәваларга озатуларын сорадым. Ә милиция хезмәткәрләре чара күрмәделәр.

Хөкем карары белән бергә Совет районы эчке эшләр бүлегенә карата шәхси билгеләмә кабул ителде:

«Суд Новиковның берничә авыр җинаять эшләвенә Совет районы эчке эшләр бүлегенең хезмәт вазифаларына җавапсыз каравы да сәбәп булган дип саный. Хәлбуки, әбисенең әнисе Анна Александровна аларга берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән. Татьяна Александровна Новикованың беркайда да эшләмичә даими эчкечелек белән шөгыльләнүен, әхлаксыз тормыш алып баруын белә торып, аның улына начар йогынтысыннан саклап калу, ана хокукыннан мәхрүм итү һәм дәваларга җибәрү буенча чара күрмәгәннәр. Моннан тыш Роберт Новиковны эшкә урнаштыру буенча берниндн ярдәм күрсәтелмәгән.

Шуннан чыгып, суд Совет районы Эчке эшләр бүлеге җитәкчеләре игътибарын бәхетсез гаиләләрдә тәрбияләнүче яшүсмерләр арасында җинаятьләрне кисәтүдә, гражданнарның гаризалары белән эшләүдә җитди кимчелекләр булуга юнәлтә».

Билгеләмәне суд составы бертавыштан кабул итте.

Инде нокта куярга да ярыйдыр иде кебек. Әмма күңелгә бер уй тынгылык бирми. Новиковлар, Хәмидуллиннар моның белән генә бетмәс бит. Алар урынына яңалары килү ихтималын беркем дә инкарь итә алмый. Кешене кеше итеп тәрбияләүдә кайдадыр хата җибәрелгән икән, җәмәгать байлыгын урлаучы, я булмаса башкача хокук тәртибен бозучы иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайтуга ук иң тәртипле адәмнәрнең берсенә әйләнер дип кем әйтә ала? Андый хаталар, ай-һай, озак һәм авырлык белән төзәтелә.

Миңа калса, яшь буынга тәрбия бирүдә без **Хезмәт**нең, баш хәрефләрдән языла торган хезмәтнең дәрәҗәсен киметә төштек кебек. Унынчы классны тәмамлаганчы кем тырай тибеп йөри? Яшьләр! Мәктәпне тәмамлагач та, армиядән кайткач та, әле ял итәм дигән сылтау белән күпме егетләр урам таптап йөри?!

Яшьләр мәсьәләсе дигәч тә, гадәттә, нәрсә турында сөйли башлыйбыз. Буш вакытны дөрес оештыру, ял итү өчен мөмкинлекләр тудыру, яшьләр кафесы ачу, дискотека булдыру... Бу исемлекне әле тагын күпме сузып булыр иде! Теләсә нәрсә турында сөйлибез, хезмәткә урнаштыру турында гына ләм-мим. Әйтәсе килгәнем шул: спорт та, дискотека да, башка төрле күңел ачулар да яшьләр тормышындагы социаль патологиядән, алар арасында таралган ялган престиждан коткара алмый. Урамга — урам, кварталга квартал каршы сугышулар, урлашу, эчкечелек, наркотиклар куллану да шуннан башлана. Күптән түгел үзәк газеталарның берсендә унбиш-уналты яшьлек үсмерләрнең үзләре турында ачыктан-ачык язган берничә хаты урнаштырылган иде. Аларны тетрәнмичә уку мөмкин түгел. «Унбиш яшемдә мин тормышта мөмкин булган бар нәрсәне дә: исерткечне дә, наркотикларны да, сексны да татып карадым!» — дип яза Пермь шәһәреннән Света исемле кыз. Ростов өлкәсендәге техникумнарның берсендә укучы Андрей исемле егет группадашларының гадәти көн тәртибен төзеп җибәргән. «Һәр иртәбез хәбәр алышудан башлана. Кичә кем кайда булган, төгәлрәк әйткәндә, күпме эчкән, нинди таблетка йоткан, нинди кыз белән йоклаган».

Күңел ачсыннар, ял итсеннәр, буш вакытларын кызыклы үткәрсеннәр дип, кул кушырып утыруның «гүзәл» нәтиҗәләре шушыдыр ахрысы. Илебездә барган үзгәртеп кору, яңалык яшьләр тормышына да үтеп керер дип өметләнергә кирәк. Әмма бүгеннән башламасак, иртәгә соң булуы мөмкин. Көче, энергиясе ташып торган, белеме, теләге булган яшьләрне нигә, хәл кадәренчә, эшләтмәскә, җәмгыятькә файдалы хезмәткә тартмаска?! Теләге бар чагында! Ул теләкнең дә озакламый юкка чыгуы мөмкин ләбаса.

Бу яктан алганда, мин авыл яшьләрен бәхетлерәк дип саныйм. Алар кечкенәдән үк әти-әниләренең нинди хезмәт белән шөгыльләнүен күреп үсәләр, кул арасына керә башлыйлар. Дүртенче, бишенче класс укучыларының әтиләре белән бер комбайнда ярдәмче булып эшләүләрен күреп гаҗәп-

ләнгәнем дә, сокланганым да бар. Эшлиләр, хезмәтнең, хәләл көчең белән табылган акчаның кадерен белеп, аңлап үсәләр. Районнан, үзәктән җитәкчеләр килгәндә ул малайларны, әлбәттә, ярдәмче дип атамыйлар. Кайсын ишерәләр, кайсын «әтисе янына карарга килгән» дип кенә җибәрәләр. Авыл малайлары әнә шулай, рәсми кешеләрдән качып-посып, ишеренеп булса да эшкә өйрәнә, дөнья тоткасы булырга әзерләнә. Эшлим дип, ярдәм итәм, дип торганда аңа бер каршы төштең, ике каршы төштең, өченчесендә ул инде теләмәячәк. Монысы гасырлар тәҗрибәсе белән расланган нәрсә.

Яңадан шәһәр малайлары турында уйланам. Кайсысының гына әтисенең заводта яки фабрикада ничек, нәрсә эшләвен күргәне бар икән?! Белсә, заводның исемен, әтисенең һөнәрен белер. Ә ул ясаган кайнар детальне тотып караганы, шул детальләрдән җыелган машинаны яки җиһазны күреп горурлык хисе кичергәне бармы? Юктыр, минемчә. Теләгәндә, яшь буында аталары эше белән горурлык уятырга, лаеклы яшь алмаш тәрбияләргә омтылганда, заводлар янында укучы яшьләр өчен цех яисә участок ачып булмыймыни?! Килсен, өйрәнсен, эшләсен, әти-әниләре белән шунда аралашсын! Тик кая ул! Без ул хакта уйламыйбыз, каядыр ашыгабыз, кабаланабыз. Ә эшләргә теләүче яшьләр завод коймасының тышкы ягында кала. Аларның хәзер үз дөньясы, үз мәшәкатьләре. Ничек телиләр, шулай яшиләр.

Судта Новиков эше тәмамланганнан соң мин үземчә кечкенә генә тәҗрибә ясап карарга булдым.

— Сигезенче классны бетергән малай сездә эшләргә тели. Дөрес, һөнәре юк. Әмма бик эшлисе, өйрәнәсе килә. Андый үсмерләрне аласызмы? — дигән сорау белән берничә завод һәм фабриканың кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать иттем. Җаваплар күп төрле булды, әмма эчтәлеге бер:

— Кирәкми!

— Бездә балалар бакчасы түгел.

— Һөнәр училищесына керсен!

— Андый эш юк шул!

Әгәр тәртибе чамалырак малай дип тә җибәрсәм, минем белән сөйләшеп тә тормаслар иде. Шунысын яхшы аңладым.

Малайлар дигәч, тәртип-тәрбия дигәч, мәсьәләнең тагын бер четерекле ягы килеп баса. Хәзерге балаларга ир-ат тәрбиясе җитмидер кебек. Әйдәгез, бергәләп күз алдына китереп карыйк. Бала туды. Бер елдан соң ул яслегә, бакчага китте. Аннан соң — мәктәп. Боларның барысында да хатын-кызлар эшли. Кайчандыр шулай кирәк булган. Ясле белән бакчасында шулай булырга тиеш тә. Ә мәктәп... Кайбер саннарга игътибар итик. Татарстандагы 30 меңнән күбрәк укытучының нибары 6 меңнән чак кына артыгы ир-атлар. Инде укытучы булырга әзерләнүче яшьләрне карыйк. Казан дәүләт педагогия институтында белем алучы 2732 студентның 791 генә егетләр. Шул исәпкә армиягә алынганнар да кергән. Чөнки алар, закон нигезендә, академик ялда исәпләнә. Гаскәри хезмәт үтүчеләрне чигерсәк, ул сан тагын да кими төшә. Ә педучилищелар турында сөйләп тә торасы юк. Республикадагы ун училищеда нибарысы бер йөзләп егет укый. Уйландырырга, борчырга тиешле саннар болар! Балалар тәрбия процессында ир-атларның катгый сүзен, холкын да өйрәнергә тиештер ләбаса. Атасыз гаиләләрдә үсүчеләр бигрәк тә. Ә андыйлар бездә, кызганычка каршы, шактый. Статистик мәгълүматларга караганда, хәзер илебездәге һәр өч никахның берсе таркалып бара. Шәһәр җирендә ул тагын да күбрәк. «Тормышымда кемнән үрнәк алырга?» дигән сүз риторик буш җөмлә генә түгел. Әйе, безнең мәктәпләрдә хезмәте белән укытучыларның да, укучыларның да, ата-аналарның да ихтирамын казанган йөзләрчә хатын-кызлар эшли. Дан һәм хөрмәт аларга! Әмма тулы кыйммәткә ия тәрбия бирик дисәк, мәктәпкә ирләрне кайтарырга тиешбез. Үзенең яшьлеген искә алган һәркем ир укытучыларга балаларның аерым бер ихтирам, ихтирам гына да түгел, олылау белән баш иеп карауларын, үзләренә үрнәк итеп санауларын әйтә алыр иде. Нигә без аларны хезмәттән һәм ирләр тәрбиясеннән мәхрүм итәбез соң әле?!

Язмабызны бөек фикер иясе Карл Маркс сүзләре белән тәмамлыйсы килә. Моннан йөз илле еллар чамасы элек үк ул болай дип язган: «Акыллы иҗтимагый стройда тугыз яшькә җиткән һәр бала җитештерүчән хезмәттә катнашырга тиеш. Түләүле җитештерүчән хезмәт, акыл тәрбиясе, физик күнегүләр һәм политехник укытуны бергә кушу эшчеләр сыйныфын аристократия һәм буржуазия дәрәҗәсеннән нык югары күтәрәчәк».

Тәлгат Галиуллин

# ТАРИХ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ

Ничәмә-нечә гасырлар буенча язучылар, художниклар, философлар кешенең рухи эзләнүләрен, эчке гүзәллеген, матурлыгын тулырак ачу гамәлендә иҗат газаплары кичерәләр. «Нинди гаҗәеп күренеш ул — кеше, акылы аның ничек камил. Аның сәләтләре, сурәтләре, хәрәкәтләре берни белән дә чикләнмәгән»,— дип соклана Шекспирның Гамлеты. Безнең Х. Туфан нәрсә ди: «Талантлы син, Кеше туганым, Сәләтле син һәрбер иҗатка».

«Табигать таҗы» һәм иң олы казанышы булган кешегә һәрьяктан тулы һәм объектив бәяне марксизм тәгълиматы бирде. Октябрь революциясе бөтен җәһәттән җитлеккән гармоник шәхес тәрбияләүне яңа социалистик җәмгыятьнең кичектергесез һәм иң мөһим иҗтимагый бурычларының берсе итеп калкытып куйды.

Безнең чорда кеше өчен көрәш яшәешебезнең эчке халәте генә түгел. Ул — ике дөнья, ике әхлак арасындагы идеологик бәрелешнең кыл үзәгендә ята. Җир шарында кеше өчен ачыктан-ачык көрәш бара. Бу көрәштә дөньяны образлар ярдәмендә иңләү һәм сурәтләүдә чикләнмәгән мөмкинлекләргә ия әдәбиятның әһәмияте ифрат зур булуы бәхәс уятмас шикелле.

30 еллар уртасында иҗат ителгән «Ант» поэмасында Х. Туфан кешеләр арасындагы иҗтимагый контрастны, әхлакый дифференциацияне бик ачык күз алдына бастырган иде:

Син беләсең, кордаш,
Җир йөзендә
Тик ике тип халык бар хәзер:
Берсе аның —
Аңы-җаны белән
Бөтенләйгә безгә ят нәсел.
Ике дөнья, кордаш,
Икесе дә
Ана баласы да баласын,
Кеше белән Адәм арасы күк
Ерак ләкин алар арасы.

«Намуслы һәм кешелекле кеше» белән аның капма-каршысы арасында аерма тәгаен күренеп тора. Ләкин бит әле шәхеснең үз эчендәге, үз рухындагы каршылыкларны да җиңәсе бар. Аның җанында бер үк вакытта «мәхәббәт һәм нәфрәт» кайнарга, шәхеснең индивидуаль омтылышлары белән тирәлек арасында кискен каршылыклар яшәргә дә мөмкин (романтик әсәрләрнең күбесендә нәкъ менә шул конфликт үзәктә ята).

С. Есенинның иске белән яңа, авыл белән шәһәр арасындагы якынлыкны, туачак гармонияне вакытында аңлый алмавы поэзиясенә драматик мотивлар алып керә, вакыты белән ялгыш нәтиҗәләргә китерә. Башлангыч чор иҗатларында шул ук рухтагы үсеш каршылыкларын Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Бурнаш кебек шагыйрьләр дә читләтеп үтә алмадылар.

Яңа шәхес, заманның алдынгы герое кайсы яклары белән аерылып тора, нинди сыйфатлары белән үзенә җәлеп итә соң? Шәхси омтылышлар белән җәмгыять ихтыяҗ-

лары арасындагы мөнәсәбәт нинди булырга тиеш? Индивидның ихтыяры тарих таләбенә ни рәвешләрдә яраша ала?

Татар совет поэзиясе үзенең беренче адымнарыннан башлап безнең көннәргәчә шул сорауларга җавап эзләвен дәвам итә. «Кайберәүдә хәзер ике «мин»,— дип Такташ борылыш чорының бик үзенчәлекле бер сыйфатын образлы калкытып куйган иде. «Гасырлар һәм минутлар» поэмасында ул яңа шәхес турындагы уйлануларына, аны аңлавына кулай идеал геройны тарих күтәргән революция титаны Ленин образында таба. Юлбашчының даһи эшчәнлегендә Һ. Такташ иҗтимагый-политик ихтыяҗ белән шәхси омтылыш ниятләрнең кушылуын, идеал бердәмлеген күрә.

Һ. Такташ сызган юлны хәзерге татар шагыйрьләре дәвам иттерәләр, Ленин образы белән бергә, халкыбызның иҗтимагый үсешенә, мәдәниятенә өлеш керткән батыр йөрәкле, олы затлы уларының тормыш юлларын һәм эшчәнлекләрен мәңгеләштерү юнәлешендә киеренке идея-эстетик эзләнүләр алып баралар.

Хәзерге поэзиядә тарихи шәхесләрнең, олы язмышлы кешеләр эшчәнлегенең мәгънәсен, безнең көннәргә якынлыгын аңларга омтылыш мөһим бер тенденция буларак яши. Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Гатауллиннар Ленин, Кол Гали, Бәхтияр Канкаев, Мулланур Вахитов, Тукай, Такташ, Габдулла Кариев, Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, А. Алиш, Х. Мөҗәй кебек шәхесләрнең эшчәнлеген, батырлыгын, тормыш юлын мемуар характерлы дисталәгән шигырь-поэмаларында гәүдәләндерделәр. Г. Хуҗиның «Идел поэмасы», Ш. Мөдәрриснең «Безнең якташыбыз», И. Юзеевның «Ленин дәшә безгә» әсәрләрендә бөек юлбашчы образын мәңгеләштерү юлында җитди адым ясала.

С. Хәкимне күп еллар дәвамында Ленин һәм тарих, Ленин һәм халык, Ленин һәм аерым индивидлар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр диалектикасы борчыды, кыю эзләнүләр юлына алып чыкты. «Ленин фәрманы белән», «Баһавиның моңы», «Язгыз, җир уллары», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» кебек әсәрләрдә бу олы тема шигъри тирәнлек һәм нәфислек белән гәүдәләндерелә. Шагыйрь тормышта, чынбарлыкта булган вакыйга-хәлләрне алып, аларны хыял һәм талант көче белән баетып, чорның актуаль әхлакый-фәлсәфи проблемаларын калкытып куя.

Үзенә бер эзлеклелек белән С. Хәким Тукай образын шигъриләштерде. «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы» поэмалары сугыш алдыннан языла. «Тукай дәфтәреннән» бәйләме һәм «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы 1971 елда тәмамлана.

«Очты дөнья читлегеннән...» поэма-трагедиясендә И. Юзеев та Тукай образына мөрәҗәгать итә. Ул Тукай яшәгән һәм иҗат иткән тарихи җирлекне хәзерге укучыга мөмкин кадәр тулырак һәм тегәлрәк җиткерү нияте белән юлга чыга. Безнең алдан шагыйрьнең фаҗигале һәм шатлыклы, авыр һәм сөенечле вакыйгалардан торган, халык бәхете, яңа поэзия өчен көрәш белән узган кыска һәм гыйбрәтле тормыш юлы уза. Реалистик әдәбиятка нигез салучы Тукай наданлык һәм мөкләнгән искелек калдыклары, фанатизм белән көрәштә үзен корбан итәргә әзер торган ачык, тулы монолит образ булып күтәрелә. Әсәрнең нигез өлгеләре итеп, бер яктан, Тукайның реаль тормышы һәм биографиясе алынса, икенче яктан, поэманы ул иҗат иткән әсәрләр, образлар, ситуацияләр тукландыра. Шул ике линияне укучыга сиздермичә органик кушып бара алган очракларда И. Юзеев җитди уңышка ирешә.

Татар шагыйрьләренең тарихи нигезгә таянып иҗат ителгән шигырь-поэмаларында берничә юнәлеш ачык төсмерләнә. Күпчелек әсәрләрдә документаль төгәллеккә ирешү, тарихи шәхес характерын тулы ачу максаты алга куелмый. Иң мөһиме: сурәтләнгән вакыйга-хәлләргә мөнәсәбәттә шагыйрьнең үз уй-кичерешләрен ачу һәм тарихи шәхес эшчәнлегенә игътибар юнәлтү. Р. Харис «Мулланур», «Камил Якуб» әсәрләрендә, Фатих Кәримгә багышланган шигырьләр бәйләмендә һәм бигрәк тә «Җәлилчеләр» дип исемләнгән шигъри циклында катлаулы ситуацияләргә, ассоциатив образларга киң таяна. Татар халкының күренекле революционеры Мулланур Вахитовның соңгы көненә багышланган поэма һәркайсы мөстәкыйльлеккә ия берничә кисәктән тора. Ленинның каһарман юлдашы ничек үтерелгән? Аны дошманнар атып үтерганнәрме, асканнармы, әллә кулын бәйләп суга ташлаганнармы? Өч мөмкин вариант, өч композицион чишелеш. Һәркайсы Мулланурга ихтирам уята, вәхшилеккә нәфрәт тәрбияли.

«Җәлилчеләр» сурәтле фикерләү үзенчәлекләре, кеше психологиясенең иң тирәндә яткан катламнарына үтеп керүгә омтылышы белән «Мулланур» поэмасына якын торса да, үткәндә ирешелгән казанышларны кабатламый.

Гомуми керештән һәм яңа буынга мөрәҗәгать рәвешендә язылган соңгы сүздән башка циклда Җәлилнең үзенә һәм аның көрәштәшләренә багышланган унике тарихи сурәтчә бирелә. Җәлил белән бергә үлем җәзасына хөкем ителгән тарихи шәхес исеме белән аталган һәр шигырьнең үз фикер сөреше, композициясе һәм шигъри табышы бар. Үлем алдыннан сөйләнгән монолог, үз-үзең, вөҗданың һәм якыннарың белән әңгәмә формасы ачыктан-ачык, бернәрсә дә яшермичә, ярымтоннарга, нюансларга төш-

мичә, батырларның иң изге уй-фикерләрен ачып бирүгә юл ача. Мәсәлән, Гайнан Курмаш фашизмга чиксез нәфрәтен әйтеп салгач, шундый нәтиҗәгә килә: «Шатланырлар, әүвәл безнең туплар, ә аннары — Җир һәм кешелек». Абдулла Алиш: «Юк, күрмәссең, дошман, йомшамам — әкияти ныклыгына рухның сабый ышангандай ышанам», дип көчне үз иҗат юнәлешеннән ала. Фуат Булатов дошманнан өстенлеген революцион традицияләргә таянып расլый:

Сатылма!—
Без чаткыдан хаклык яклы ялкын
кабызучы көчләр затыннан.

Кыскасы, Р. Харис һәр героеның үзенә генә хас билге-сыйфатын таба алган (Муса Җәлил турында гына яңа сүз әйтү кыен булган шагыйрьгә), һәм бу бәя ышандыра: чөнки ул һәркайсының шәхси биографиясеннән, характерыннан үсеп чыга. Шуңа күрә һәр образ-сурәтнең үз мәгънәсе, фәлсәфи-этик эчтәлеге бар.

Р. Харис «Соңгы сүз»ендә киң гомумиләштерү юлына килеп чыга: «Без батырлык эзләп яшәмибез, батырлыкка ләкин без әзер...», «Матурлыктан туа батырлык».

Тарихи әсәрләрнең беришесендә шагыйрьләр вакыйга-хәлләрнең тормышчан сурәтен сакларга тырышалар. Р. Харисның «Камил Якуб» әсәре шуңа ачык мисал. Поэма геройның фетнә күтәргән батальон турында үзалдына уйлануы белән башланып китә. Ләкин революциягә бирелгән, дәртле, омтылышлы кеше буларак, ул кул кушырып, язмышка томанлы пыяла аша карап утыру юлын сайламый. Камил Якуб эш һәм хәрәкәт кешесе. Мондый шәхесләр тарих колы түгел, алар аңа үзләре актив тәэсир итәләр. Баш күтәргән анархист төркем белән очрашу геройның үлеме белән тәмамлана. Абдулла хәзрәтнең «руслар Казан астында татарларны кыралар» дигән коткысы үз әшәкелеген эшли. Батальонга вакытында игътибар җитмәү дә үзен сиздерә. Солдатлар ач-ялангач, күптән акча алмаганнар, аңлату эше дә тиешле югарылыкта тормаган. Кара эш каннары ярсыган халыкны тетрәндереп тә, айнытып та җибәрә. Үзләре үк бу пычрак эшне башкарган алты кешене аталар. Димәк, Камил Якуб үзенең үлеме белән кешеләрнең күзе ачылуга ярдәм итә. Шагыйрь оптимизмының чыганагы да шунда.

Мулланур белән Камил Якубның үлемнәре, җәлилчеләрнең соңгы төннәре, кичерешләре аларның тарихи эшчәнлегенең әхлакый-этик кыйммәтен тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә. Р. Харис каләме тудырган геройлар тарих агымына ияреп китмиләр, «тарих басымына» баш бирмичә, аның белән идарә итәләр. Бу хәл шәхесне интеллектуаль күтәрә, үстерә, тарих белән мөнәсәбәтендә мәгълүм бәйсезлек тәэмин итә.

Шунысы үзенчәлекле: шигъри әсәрләрнең күбесендә геройның батыр эшчәнлеге ачылмый, ул кадрның тышында кала. Мулланур да, Камил Якуб та, җәлилчеләр дә тормыш юлларының иң соңгы сызыгын үтәләр. Әйтик, М. Кәрим дә «Салават» трагедиясендә Пугачев восстаниесе җиңелеп, Салават кулга төшкәннән соңгы ситуацияне үзәккә ала. һәркем кылган эшләре өчен вөҗданы, намусы алдында җавап тота. Аларны үзләрен көткән җәзадан бигрәк, киләчәк хөкеме уйландыра, борчый. Бу ситуация Җәлил һәм аның көрәштәш дуслары өчен аеруча зур әһәмияткә ия. Аларның көрәше, үлемне батырларча каршы алулары илләренә, якыннарына барып җитәрме? Дөрес бәясен алырмы? Менә шул әхлакый сораулар борчый тарихи геройларны.

«Кол Галигә», «Туры Тукай» шигырьләрендә Ш. Галиев элгәрләренең тулы һәм кабатланмас иҗат портретларын бирү максатын алдына куймый. Ул алар өчен иң характерлы, иң асыл сыйфатларны төгәл сайлап алынган детальләр ярдәмендә калкытып куюга ирешә. Тукай халкына, намусына, идеалына турылыгы белән дан казанган, үткен сүзе белән дошманнарының, руханиларның җелегенә төшкән. Ул «Бөек булган, боек булмаган».

«Кол Галигә» шигыре дә шундый ук афористик, күп сыйдырышлы бетемгә ия: «Галиме дә мөмкин кол итәргә, чын шагыйрьне булмый кол итеп».

Поэзиядә тарихи тема кителмәгән яклары белән һәм шактый сәер борылышларда ачылып куя. Мәсәлән, Г. Афзал «Гомер», «Дон Кихот белән әңгәмә» кебек шигырьләрендә бик борынгы һәм урта гасырларга «сәяхәткә чыгып китә». Шагыйрь Гомер белән Дон Кихотның әдәбиятта, тарихта урнашкан сурәтләренә турылыклы: зәңгәр күк.е Иониядә туган ак сакаллы, сукыр Гомер юлны таяк белән капшап, ил буйлап, «лира уйнап, озын җырлар җырлап» үтә, Хуҗа Насретдинның «энесе» Дон Кихотның (бу инде үзе кызыклы аналогия, шигъри табыш) «йөзе җитди — исең китәрлек». Г. Афзал «үзе тере дастан» Гомер һәм пират сатканнан, фашист атканнан соң да үлемсез калган Дон Кихот белән сокланып яшерми, аларның яшәешендә безнең көнгә якын чалымнар күрә: «Лира чыңлый, Гомер җырлый, эш кешесен зурлап». Шуңар да аның әсәрләре үлемсез.

«Гомер» һәм «Дон Кихот белән әңгәмә» шигырьләренең нигезендә явызлык белән яхшылык, вәхшилек белән гуманизм арасындагы антагонистик бәрелеш кебек — Җир

шары хәтәр сынау көннәрен кичергән безнең чорда аеруча актуаль яңгыраган иҗтимагый коллизия ята. Үзәктә яткан идеяне, әхлакый уйлануларны тарих мисалы раслый: «Агамемнон бик тәкәббер, таш бәгырьле иде. Таш бәгырьле усал иргә хәтәр үлем килде». Һәм тагын бер гомумиләштерү: «Явызлык һәм көч артында бәхетсезлек тора».

«Дон Кихот белән әңгәмә» шигыре Г. Афзалның «Шатланды күңел, сафланды» циклының бөтен эчтәлеген, рухи пафосын чагылдырган, кеше акылына, зиһененә дан җырлаган оптимистик сөземтә белән тәмамлана:

Кешелекле акыл үләмени,
Кешелекле фикер — гомерле.

Р. Фәйзуллиның «Әшфанда» шигырендә лирик герой, әйтерсең лә, тарих белән бүгенге көн уртасында тора. Кайбер тарихи чыганаклар буенча, галим, язучы, табиб, безнең чор атамасы белән әйткәндә, җәмәгать эшлеклесе Әбугалисина Әшфанда туган. Шунда узган тантаналарда катнашкан шагыйрьнең өермәле хисләре, хыялы тарихи үткәнгә алып китә:

Сәмум җил булыпмы,
күчәр ком булыпмы,
очкан кош булыпмы?—
мин монда булган идем күк...
Шул арада меңләгән ел үтеп киткән.

Ул дәвердән соң дөньяга даһи улын бүләк иткән җир әллә ни үзгәрмәгән дә: «Күк түбәнәймәгән, Таулар өелмәгән. Диңгезләр күченеп килмәгән...» Шунда да шагыйрь күзе, шагыйрь күңеле физик үзгәрешләрдән олырак, шәһәрне бәйрәмчә таш киемгә киендергән рухи үзгәреш күрә:

Яңалык шул:
Әбугалисина дигән рух кабынган
кешеләр күңеле күгендә.

Кыскасы, тарих үзе сайлап, безгә китереп җиткергән шәхесләрне үзәккә алган әсәрләргә ихтыяҗ кимеми. Алар яшь буынны коммунистик тәрбияләү эшенә мөһим өлеш кертәләр.

Хәзерге поэзиядә барыннан да бигрәк аерым шәхесне тарих һәм бөтендөнья проблемалары югарылыгына күтәреп сурәтләүгә, фәлсәфи тирәнлеккә, фикер белән тойгыны бер үремтәдә тасвирлауга һәм күпсыйдырышлы формага өстенлек бирү тенденциясе арта.

Тарих һәм поэма, тарих һәм шагыйрь... Төрле яссылыкларда яткан бу төшенчәләрне нинди җирлектә янәшә куеп, бер үремтәдә карап була икән? Дөрес, шигърият үткәнгә сәяхәт ясаган, теге яки бу дәвернең «көч сызыкларын», әхлакый-фәлсәфи эчтәлеген характерлар бәрелеше, лиризм, кичереш динамикасы, мавыктыргыч сюжет аша ачкан әсәрләргә бай. Пушкин, Лермонтов, Блок поэмаларын, М. Җәлилнең «Алтынчәч», Х. Туфанның «Ант», Н. Исәнбәтнең «Әбугалисина» кебек тарих һәм фольклор материалына таянып, үткән аша чор проблемаларын киң гомумиләштерү юлына чыккан әсәрләрен искә төшерик. Аларның һәркайсы 30–50 еллар татар поэзиясе өчен ачыш булды.

Илнең данлы үткәнен, ерак тарихын үзәккә алган әсәрләрдә халык рухын, зиһен көчен үзендә туплаган сәнгать чараларын читләтеп үтү мөмкин түгел. Шуңа күрә драматург һәм шагыйрь Н. Исәнбәт «Әбугалисина» драма-поэмасында сюжетының табигый ачышы белән үк халык иҗатына, аның легендасына, әкиятенә килеп чыга. Бирелә фольклор тарихи, мәгънәви һәм этнографик материал буларак та зур урын тота. Шагыйрь, халык иҗаты ачышларына таянып, чынбарлык белән легенданы иркен һәм табигый кушып алып китә алган.

Әсәрнең төп образы легендадан, әкияттән үсеп чыккан. Н. Исәнбәт «Әбугалисина»ның керешендә болай дип яза: «...бу әсәрдә Әбугалисинаның тарихи үз шәхесе алынмый, бәлки легендага кергән тарихи үз сурәтчәсе генә алына» (Совет әдәбияты, 1959, 7 сан, 38 б.). Шуңа күрә поэмада фольклор аһәңе бик көр һәм үзенчәлекле яңгырый. Халык иҗаты йогынтысы чор атмосферасына, шул заманның иҗтимагый-этик коллизияләренә үтеп керүдә дә, Әбугалисина образын яктыртуда да, авторның уйлану рәвешендә дә ачык сизелә. Поэмага хас композиция төзү осталыгы да, символик фикер агышы да, язмышлар бәрелеше дә күпмедер күләмдә халык иҗаты закончалыклары белән аңлатыла. Шагыйрь, соңгырак дәверләрдә туган йолалар белән берләттән, халык

иҗатының тотемизм чорына мөрәҗәгать итә, аның им-томнарга, җен-парийләргә ышануына барып тоташкан иң борынгы һәм хәзер югалып бара торган катламнарын «аякка бастыра». Менә кол кызлар җыры:

Тфү, тфү, үзең сакла,
Дошманнарның күзен капла!
Бибкәй сылу айдан сылу,
Җеннәр гашыйк булган хәтта.

Вакыйга шул ук Болгар шәһәрендә бара. Автор халыкта, фольклорда яшәп килгән «болгар читек», «болгар олтан» шикелле гыйбарәләрне әсәрендә дә бик оста трансформацияли:

Аягыңдагы читегең,
Болгар икән олтаны,
Болгар читек, саурый башмак —
Синдер кызның солтаны.

Халык иҗаты традициясенең көчле агымы Әбугалисина телендә нык сизелә. Карап торырга гап-гади геше. Башкалар шикелле үк шатлана да, кайгыра да белә, шаян да, кырыс та була ала. Менә Гали уңышсыз мәхәббәте аркасында нишләргә белмичә аптырый, ары сугыла, бире сугыла һәм ахыр чиктә үзен юк итәргә карар кыла. Әбугалисинаның халык иҗатыннан уңышлы сайлап алган мәкале гашыйкны, салкын су сипкән шикелле, айнытып җибәрә:

Егет кеше җор булыр,
Йөрәгенә түзми хур булыр.

Галинең хан кызы белән бергә буласы тәгаен ачыклангач, Әбугалисинаның теленә дә, халык иҗатының салкын чишмә шикелле чылтырап аккан, шаян, уйнак юмор бәпчекләре килеп керә:

Минем киленем булыр да,
Синең күңелең булыр.

«Әбугалисина» поэмасында фольклор укучыны үзәккә алынган тарихи чорга алып керү, характерларны ачу, сурәтен халык тормышы, аның көнкүреше белән бәйләү юлында җитди чыганак булып хезмәт итә.

Борынгы фикер иясе, шагыйрь, галим Әбугалисина үзенең оптимистик рухы, тынгысызлыгы, туктаусыз яңага, яктыга омтылышы белән безнең көннәр рухына якын тора.

Җәмгыять камилләшкән, әдәби фикерләү дәрәҗәсе үскән саен, кешенең хезмәтен, зиһен казанышын, катлаулана барган хисси дөньясын халыкның тарихи, иҗтимагый һәм рухи тәҗрибәсе яктылыгында өйрәнүгә ихтыяҗ үсә. Шуңа күрә тарихи темага мөрәҗәгать итү үткәнгә кичү түгел, ә заман төшенчәсен киңрәк контекстка куеп, борынгы белән хәзергене бер үремтәдә өйрәнүгә омтылыш буларак кабул ителә.

Татар халкы тарихының олы һәм аянычлы вакыйгалар белән бәйле бер чоры — Болгар дәүләте язмышы сүз осталарын һаман да борчый, уйландыра, үзенә тартып тора, фәлсәфи, әхлакый һәм фәнни эзләнүләр юлына алып чыга.

Табигый сәләтенең әлегәчә ачылмый яткан кыйблаларын ялтыратып җибәргән, хаклы рәвештә җәмәгатьчелекнең уңай бәясен алган «Кубрат хан» романында М. Хәбибуллин шул дәвергә килеп чыга. Тормыш таләбенә сизгерлек күрсәтеп, Р. Харис («Ант суы») белән Г. Рәхим («Аяз көнне яшен») дә яңа әсәрләренең үзәгенә халык тарихын алдылар.

Әйтерсең лә, сүз осталары үткәннең олы бер сәхифәсе турында язарга сүз куешканнар да, вакыты җиткәч, форсат табылгач, шул изге хыялларын тормышка ашыру юлына чыкканнар.

Жанр хасиятләре, тарихны сурәтле күзаллау рәвешләре белән бер-берсеннән аерылып торсалар да, хронологик яктан бу әсәрләр, бер җепкә тезелеп, бер-берсен дәвам иттереп киләләр.

«Кубрат хан» романында борынгы Болгар дәүләтенең Византия кебек атаклы мәмләкәтләр белән «сыңгә» күчеп, тигез диалог алып барган куәтле һәм данлыклы чоры тасвирлана. Әмма әсәрнең соңгы өлешендә Кубрат хан дәүләте мәкерле һәм явыз хәзәрләр белән коточкыч авыр сугышта олуг абруен югалта һәм нәселен, киләчәген саклап калу өчен, буш төбәкләргә таралырга мәҗбүр була.

«Ант суы» поэмасының үзәгендә соңрак дәвер ята. Болгар халкы, Идел-Чулман

буенда ныгып, рус һәм башка күрше дәүләтләр белән уртак тел табып, бәхетле гомер кичерә. «Акыл теше» баш очында үткен кылыч төсле асылынып торган фаҗигане җиңел генә уздырып җибәрергә әмәлен таба.

Г. Рәхим әсәрендә тарихи ситуация үзгә. Гөрләп үсеп, шаулап чәчәк атып утырган Идел буе Болгар дәүләте сабан туе көннәрендә Бату хан урдалары тарафыннан тар-мар ителә, халкы, шәһәрләре, байлыгы пыран-заран китерелә. Кыскасы, өч әсәрдә дә бер үк халык башыннан төрле чорда узган, язучы хыялы белән тулыландырылган, типиклаштыру иләге аша үткәрелгән тарихи хәл-вакыйгалар, шул олы җирлектә ачылган кеше язмышлары ята. «Кубрат хан», «Ант суы», «Аяз көнне яшен» әсәрләрен шуның өстенә, язучылар алдында киң идея-эстетик перспектива ачкан, үткәннең тирән катламнарына, мифик аң калдыкларына үтеп кереп, тормышны диалектик каршылыклары аша һәм үсештә күрсәтүнең чикләнмәгән, аек хыялны шартлы киртәләр белән чикләмәгән социалистик реализм методы якынлаштыра. Тарихи полотноларда совет әдәбияты иҗат методының көче һәм киләчәге аерата ачык төсмерләнә.

Әлеге әсәрләр язылу өчен тышкы объектив сәбәпләр дә, җылы җәй шикелле, бик уңайлы килеп торды. Рус дәүләте белән Идел буе болгарлары арасында солых актына кул куелуга мең ел тулды. Кубрат баласы Аспарух хан нигез салган Болгария үзенең юбилеен билгеләп үтте (шул уңай белән СССР үзәк телевидениесе «Аспарух хан» исемле ике серияле тарихи-нәфис кино күрсәтте). Бу вакыйгалар, гасырлар көзгесе кебек, милли тарихның яңа сәхифәләрен ачып, киң җәмәгатьчелекнең күңел күзләрен уятып, зиһеннәрен тернәкләндереп җибәрделәр.

Мәсьәләнең икенче мөһим ягын да истән чыгарырга ярамый. Халык тарихында яшәү белән үлем тартышкан хәтәр моментларга, олы үзгәреш-борылышка китергән вакыйгаларга игътибар әдәбиятта тарихилык принцибының ныгуы турында гына түгел, олы темага алынырлык язучы кадрлар булуы хакында да сөйли. Димәк, татар совет әдәбиятында да ерак гасырлар тавышын аңларлык, үткәнне иңләрлек, хыялга бай, үз иленең язмышын интернационализм киңлекләреннән килеп бәяләргә лаеклы язучылар күтәрелеп чыккан, үсеп җиткән. «Ант суы» белән «Аяз көнне яшен» поэмалары шуның ачык мисалы.

Р. Харис белән Г. Рәхим тарих безгә китереп җиткергән мәгълүматлардан, вак-төяк детальләрдән өскәрәк күтәрелеп, тышкы охшашлыкның, имитациянең алдаучан мәкеренә «баш бирмичә», халык һәм дәүләтләрнең олуг максатларын, әхлакый идеалларын тасвирлау юлына чыгалар. Сәнгать әсәрендә, бигрәк тә поэмада, баш-аяк белән үткәнгә чумуның хаҗәте юк, ул алым ахыр чиктә гайре тарихилыкка, догматизмга алып килергә мөмкин. Дөрес, поэмаларда шул чор тудырган тарихи исемнәр дөреслеге бар (бигрәк тә «Ант суы»нда). Әмма алар поэма тукымасына килеп кергәч, әсәрнең идеологик юнәлешенә, шагыйрь ихтыярына, стиленә һәм сурәтле фикерләү ысулына буйсыналар. Шуңа күрә поэмалар үзәгендә яткан тарихи вакыйгалар һәм хәлләр дөреслегеннән бигрәк, сүз фикерләүне һәм хәтта кичереш динамикасын хәрәкәткә китергән, юнәлеш биргән тарихилык турында барырга тиеш. Бик аз сакланган елъязмалар, ташъязмалар, халык иҗаты әсәрләре, буыннар хәтере безгә китереп җиткергән истәлекләр автор позициясенә, максат бердәмлегенә, фикер һәм хис агышына, шулай әйтергә яраса, хыял үзе хаклыгына, «матурлык законнары»на буйсына. Социалистик реализм методының идея-эстетик принциплары тарихи материал белән язучы хыялы тудырган матурлыклар арасында тәңгәллекне, ярашуны табу юлында якты маяк булып тора. Модернизм поэзиясеннән аермалы буларак, авторның фантазиясенә максатлы һәм перспектив юнәлеш бирелә, фикерләү киңлеге, композицион иркенлек һәм ритмик сыгылмалылык тәэмин ителә.

Бу төр поэма элгәрләренең вакыт сынавын үткән ачышларына таянып, чор алып килгән сыйфатларга бай. Яңачалык поэмаларның лиризм белән тирәнтен сугарылуында да, шәхси башлангычның мәгънәви, структур роле үсүдә дә күренә. Ләкин монда да поэма үзенең жанрлык хасиятләрен югалтмый, проза яисә лирика эчендә «эреми».

Р. Харисның «Ант суы» поэмасында традицияләр белән яңачалык арасындагы мөнәсәбәт, теманың үзенчәлегенә бәйле рәвештә, башкарак борылыш алган һәм бу алым шагыйрьне шактый кызыклы һәм гыйбрәтле эзләну-уйланулар юлына алып чыккан. «Ант суы» ифрат гадәти, прозаик, әмма гаять оста сайлап алынган деталь белән башланып китә: «Таш ташладым мин Иделгә... һәм, табигый, таш батты». Бу хәбәр дулкын уены белән вакыт агышы, үткән белән киләчәк арасындагы киеренке һәм каршылыклы мөнәсәбәтләр турында уйланулар юлына алып чыга. Лирик герой үзенең хисләре артыннан дулкыннарга ияреп китә, күп тарихи шәһәрләр кырыннан уза. һәр җирдә үткәннең һәм данлыклы, һәм фаҗигале эзләре ярылып ята... Елгалар үзләре дә тарих сәхифәләренең шаһиты: «Угра суының тарих шикелле бормалары». Дулкын вакыт белән ярышып карый, кирегә китү юлларын да эзли. Аңа туктарга ярамый, торгынлык — фаҗига: «Туктадымы, дулкын үлә, хәтер өзелгәч кеше үлгән кебек, хәрәкәт беткәч тормыш үл-

гән кебек». Берсен-берсе кысрыклап, өелеп-өелеп килгән чагыштырулар тарихны «мең елга артка» чигерергә мөмкинлек бирә. Хыянәтченең ялган һәм мәкерле сүзенә ышанган князь Владимир Болгар иленә яу чабарга җыена. Дөньяның ачысын-төчесен күп татыган анасы мондый ашыгыч адымны хупламый. Һәр сугыш рус хатыннарының «күз төпләрендә уларының, ирләренең вакытсыз каберләре карасы» булып эзен калдырган. Владимирның анасына җавабын шагыйрь ишетми, ә поход кичектерелми, башлана.

Һәртөрле «суешка — кан коешка каршы» күтәрелгән лирик герой Болгар иленә юл ала, андагы үсешне, мул тормышны, гөрләп чәчәк атып утырган шәһәрләрне, авылларны күреп чын йөрәктән соклана, бәйрәмгә әзерләнүләргә эчтән сөенә. Ике олы халык арасында орыш башланса, «Чуен кою мичләреме», «фонтанлы шушы мунчалармы, рус, әрмән бистәләреме һәлакәткә дучар булачак?.» Шагыйрь Болгар патшасы Мөхәммәткә киңәшен биреп калырга ашыга: юл икәү генә, я сугышка әзерлән, я затлы бүләкләр юлла. Бу — бүгенге «көннең ямен арттырачак киңәш».

Ил һәм дәүләт хуҗасы якыннарына, киңәшчеләренә әйтәсе килгән фикерен халык мәкаленә ышанып тапшыра:

Таш атканга
без дә әллә таш атыйкмы,
Әллә инде аш атыйкмы,
Әллә, илчеләр җибәреп,
сүз катыйкмы?

Аксакал киңәше — аек акыл җимеше: «Туганына таш атучы җансыз таш булып аунасын». Бу киңәшкә дә вакыйга агышына, конфликт чишелешенә бәйле рәвештә үзгәртелгән, халыкның мең еллык тәҗрибәсен эченә алган мәкаль нәтиҗә ясый: «үче озынның гомере кыска, кешенең дә, халыкның да...» Биредә бүгенге көн проблемаларына, аларны чишү, хәл итү юлларына да киная ачык ярылып ята. Шуңарда лирик герой сугышчыларның киеренке, җитди йөзләрендә бүгенге көн кешеләре чалымнарын күрә.

Болгарлар белән руслар арасында сугыш булмый кала. Аек акыл өстенлек ала. Ике куәтле дәүләт арасында килешүгә кул кую — күп еллар тыныч тормыш өчен нигез салган олы тарихи вакыйга. Бу бәйрәмне шагыйрь буяуларны кызганмыйча, шатлык хисен яшермичә тасвирлый:

Мөхәммәт бармак шартлатты—
пулатның ян ишегеннән
җиде сылу кыз килеп керде
чулпыларын чылтыратып.

Шагыйрь солыхка кул кую тантанасын тасвирлау юлында халык иҗатына, мифологиясенә таянып, шул чорның колоритын бирүгә ирешә. Мәсәлән, җиде кыз әкиятләрдә һәм бигрәк тә бәетләрдә гаять киң очрый торган сан («Җиде байның җиде кызы җиде төндә тудык без», «Җиде байның җиде кызы җидесе дә бик маһир» һ. б.) Аның төбендә бик ерактан килә торган, табигатьтәге, ай хәрәкәтендәге үзгәрешләрне күзәтү нәтиҗәсендә туган тирән мәгънә ята. Галәм җиде дөньядан, күк җиде өлештән тора диган бик борынгы ышану ислам диненә, халык иҗатына үтеп керә һәм соңгысында образлы күзаллауның бер ысулы буларак урнашып кала... Р. Харис менә шул традицияләрне үзенчә үстереп җибәрә, аңа яңа буяулар, төсләр, бизәкләр өсти.

Гәрәй Рәхимнең «Аяз көнне яшен» либреттосында, әйткәнебезчә, халык тарихының иң аянычлы, ин фаҗигале бер эпизоды — Идел буйларында дәррәү үсеп, гөрләп утырган Бөек Болгар дәүләтенең Батый хан урдалары тарафыннан тар-мар ителү вакыйгасы үзәккә алынган. Бер яктан, әсәр чал тарих вакыйгаларын мөмкин чаклы конкрет яктыртуга, табигый яңгырашны сакларга омтылуы, икенчедән, жанр үзенчәлекләре таләп иткәнчә, мажаралы, фантастик күренеш-хәлләргә бай булуы, төгәл ритмикасы, образлы теле белән үзенә җәлеп итә. Шул җирлектә Болгар патшалыгы җиңелгәч, илдәшләрен Казан ягына алып киткән халык улы, курайчы, батыр егет Илбакты белән Габдулла хан кызы Алтын Туташ арасындагы романтик мәхәббәт тә аклана, әсәрнең кырыс эчтәлегенә җылылык, лиризм бөрки, борынгыдан күчә-күчә килгән халык җырларының моңы үзенә бер шигъри атмосфера тудыра, көйнең саркулы агышы өчен җай тудыра. Хор башкарган җырлар эчтәлекне тулырак ачу максатына буйсындырылган.

Илбактының мәхәббәте олы. Әмма ул мәхәббәт ләззәтенә бирелеп, ил мәнфәгатьләренә кул селти торган шәхес түгел. Ил язмышы — аның язмышы. Чәчәк атып утырган Болгар иле урынында хәрабәләр һәм көл үрләре генә калгач та, аны халыкның килачәгенә ышаныч ташламый.

Шул рәвешле, Г. Рәхим вакыйга-хәлләрне эзлекле үстерү, образларны типиклаштыру

юлында халык сүз сәнгатендә кабул ителгән әлгеләргә киң таяна. Халык эпосы үрнәгендә, шагыйрь милләткә хас иң гүзәл, иң күркәм сыйфатларны үзендә туплаган шәхес образын тудырырга ирешә.

Типиклаштыру, уңай геройны сурәтләү алымнарын үстерү белән беррәттән, драма-поэма халык иҗатының мифологиясен, легендасын һәм җыр, мәкаль жанры казанышларын да «тәненә сеңдерә». Мәсәлән, әсәрнең сюжет канвасында халыкның бик борынгы дәверләр чатында туган ышану ырымнары әһәмияткә ия.

Батый хан чирүенең Болгарга килеп җитү хәбәре карт хан Габдулланы аягыннан ега. Язмышка ышану нигезендә туган соңгы сүзендә ул үз үлемен ил җимерелүе белән бәйли:

> Батухан чирүе — минем әҗәлем ул...
> Батухан чирүе
> Болгарның да әҗәле булыр дип куркам...

Казан шәһәре турындагы беренче хәбәрне ил батыры Илбакты халыкка әкиятләр башламы, легендалар алымы белән җиткерә.

> Моннан ерак-еракта,
> Чулманның аръягында,
> Кара урман эчендә,
> Елантау итәгендә
> Кабан күле буенда,
> Бөек Болгар иленең
> Иң төньяк почмагында.

Болгар шәһәренең капкасын ачып дошманны керткән Батухан шымчысы Караханны Илбактыга ыргытыйм дигән елан чагып үтерә. Сөрән салучы бу вакыйгага үз бәясен бирә: «Еланны елан чакты».

«Ил батыры», «әзмәвер», «Идел-йорт», «аһ-зар елый», кебек гыйбарәләр, «Кунак булсаң кунак бул. Илче булсаң тыйнак бул», «Кара елан белән очрашу ул Яхшы хәбәр түгел, яманга» кебек мәкальне хәтерләткән әйләнмәләр халыкның үз иҗатына, сөйләм теленә барып тоташа.

Шулай да әсәрнең жанрлык хасияте таләп иткәнчә, шагыйрьнең сурәтле фикерләвенә иң якыны — халыкның җыр стихиясе. Аның мотивлары һәм алымнары әсәрнең буеннан-буена үтә һәм аңа җылылык, лиризм бәрки.

Әле карап үткән тарихи-драматик әсәрләрне якынлаштырган төп хасият — бер чорда язылган булулары гына түгел. Аларның үзәкләрендә халык үткән юлны, тарих сәхифәләрен истәлек-риваятьләр аша иңләү ята. Ләкин аларны «сакаллы борынгы»га багышланган әсәрләр дип атау дөрес булмас иде. Тарихилык принцибы, социалистик реализм методының чикләнмәгән иҗат мөмкинлекләре, заман төшенчәсен киң мәгънәдә аңлау чорның иң киеренке, актуаль проблемаларын кыю рәвештә калкытып кую мөмкинлеген бирә. Тормыш дәреслегенә тугрылык хәтернең әхлакый офыкларын киңәйтә, ватан һәм аның киләчәк бәхетле язмышына ышаныч — шагыйрьләрне киң гомумиләштерүләр юлына алып чыга. Сүз осталары вакыйгалар турында эзмә-эз сөйләп бирү юлына басмыйча, шартлы, фантастик алымнарга киң таянып, тарих белән бүгенге һәм киләчәк арасындагы якынлыкны, каршылыкны аңларга тырышалар.

Хәзерге поэзия җәмгыятьнең рухи тормышына, халәтенә бәя бирү белән генә чикләнмичә, тарихи тәҗрибәгә, тарихи аңга мөрәҗәгать итеп совет кешесенең эчке дөньясы нинди кыйммәтләргә таянып үсүен күрсәтә.

Югарыда китерелгән мисаллар кешене һәм тарихны тасвирлау алымнарының күп һәм төрле булуын раслый. Бер төркем шагыйрьләр әзер материалга, документаль башлангычка таянып, тарихи шәхесләр эшчәнлеген яктыртуга зур көч куялар. Аны шартлы рәвештә «рациональ» образ дип атап булыр иде. Икенче төр образларда реаль һәм «хыялый» башлангычлар кушылып китә, нәтиҗәдә тормышның күп якларын, рухи дөньяны киңрәк иңләгән, шагыйрьнең үз биографиясен дә эченә алган эпик әсәрләр туа. Өченче очракта тарихи шәхес образы тулысы белән шагыйрь хыялында формалаша, аның дөньяга субъектив карашы җимеше буларак туа.

Нәтиҗә рәвешендә шуны әйтәсе килә: социалистик реализм методының киң идея-эстетик платформасы кеше белән хәлләр, кеше белән тирәлек, кеше белән тарих арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, актив, эшлекле, гармоник кешене тасвирлау юлында совет язучылары алдында чикләнмәгән иҗат мөмкинлекләре ача.

Библиография

# ТАНЫШУ ДӘВАМ ИТӘ

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы[1] өч китаптан торырга тиеш дип уйланылган. Сурәтләү вакыты шактый зур булган кебек, әсәр үзе дә дәвамлы вакыт аралыгында языла. Аның 1977 елда укучыларга ирешкән беренче китабы 1962—1976 елларда, ягъни ундүрт ел эчендә иҗат ителде. Ә быел укучы кулына килеп кергән икенче кисәгенең барлыкка килүе исә язучының 1980-85 еллардагы хезмәте нәтиҗәсе.

Романның беренче кисәге белән танышуга нәкъ ун ел вакыт узган... Һәм менә тагын безнең күз алдында Нурия, Солтан, Шаяхмәт, Нәҗия кебек иске танышлар, Майский, Әхнәф, Чишмәбай, Мөхәммәтша кебек яңалары.

Аларның күбесе үз индивидуаль сөйләмнәре, холык-гадәтләре, уңай һәм кимчелекле яклары белән ачыла баралар, үз дигәннәренчә хәрәкәт итәләр. Бу инде автор күңел күзе белән күргәннәрне укучыларга да образлы итеп җиткерә алган дигән сүз.

Китапның аннотациясендә болай диелә: «Идел кызы» романының икенче китабында язучы Г. Ахунов төп героиня Нурия Уразаеваның сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы тормышын сурәтли». Әйе, Бөек Ватан сугышы совет халкы өчен олы сынау еллары иде. Кемнең кем булуы нәкъ менә шушы вакытта бөтен тулылыгы белән ачылды да. Г. Ахунов та моны тирәнтен аңлап эш итә. Безнең Нуриябез инде бу вакытта врач була, медицина институтының гистология кафедрасында аспирантура узып, фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Сугыш башлангач, Казанда һәм Иж буендагы бер авылда, тагын Арчада госпитальләрдә эшли. Ул, җимерелгән Сталинградка барып, фәнни конференция эшендә дә катнаша. Шулар өстенә кырык беренче елның аерата салкын кышында, утын әзерләү артыннан йөреп, салкын да тидерә. Иренең фаҗигале үлеме кайгысын да кичерә ул.

Боларны укыгач, уйга каласың. Онытылмастай күренешләр күп шул биредә. Бигрәк тә Зартугай авылында медицина пунктында эшләгән чагында аның фельдшер Курамшин белән колхозчы хатын Ниса корган ятьмәгә эләгү ихтималы булган урында, героиня өчен борчыла башлыйсың. Ләкин сизгер күңелле Нурия бу хәйләгә тиз төшенә һәм тегеләрнең үзләрен фаш итә.

Татар совет язучылары сугыш вакыты хатын-кызлары турында күренекле әсәрләр иҗат иттеләр. Г. Бәшировның Нәфисәсе, М. Әмирнең Саниясе, Миңлекамалы, Фатыймасы — шуларның аеруча уңышлылары. Инде алар янына Г. Ахуновның Нуриясен дә өстәп буламы соң? Алар дәрәҗәсенә күтәрерлек героинямы бу? Юк булса кирәк. Ни өчен дигәндә, автор бу хатынны үз стихиясендә, ягъни медицина өлкәсендәге нечкәлекләр чолганышында нык-лап сурәтләп бирә алмый.

Авыл кешеләре яки нефтьчеләр турында язганда, Г. Ахуновның да каләме нык. Бу турыда инде күп язылды. Ләкин врач, алай гына да түгел, галим хатын Нурия турында язганда, Г. Ахунов кешеләр арасындагы гадәти мөнәсәбәтләрдән ары китә алмый, ягъни тирән профессиональ нигездә конфликтлы ситуация китереп чыгармый.

Образ алдына куелган олы максат кына аны калку итеп ачуын онытмаска кирәк. Ә биредә көнче, хөсетле Татьяна Васильевна белән ике арада булган кытыршылыклар да бары тик шәхси симпатия-антипатиягә генә нигезләнә. Мин-минлеге хәттин ашкан бу хатынга «ягымлылык ысулы белән тәрбияләү» нәтиҗәсендә Нурия үзенең йогынтысын ясый. Шулай итеп, тора-бара аның юлыннан бу киртә дә алып ташлана.

Профессор Майскийга килгәндә, бу образ интеллигентлыгы, чын фән кешесе булуы, туры сүзлелеге, киң күңеллелеге белән индивидуаль образ булып гәүдәләнә. Ә инде аның капма-каршысы буларак, проректор Сапаров, бер-ике генә күренеп калуына карамастан, тәмам бюрократлашкан чиновник буларак шәйләнә. Нурия белән Майскийның әлеге җитәкче кешегә визитлары сурәтләнгән битләр язучы тарафыннан аеруча бөртекләп, психологик һәм интеллектуаль нигезләп эшләнгән.

[1] Ахунов Г. Идел кызы. Икенче китап. Казан, 1986.

Китап битләрендәге күп санлы персонажлар белән аралашып яшәүче Нурия, әлбәттә, укучы алдында намуслы, эшчән, кыю, һәм гаиләсендә тугры, акыллы хатын булып күзаллана. Тормыш өермәләре аны шәһәрдән авылга, аннан тагын икенче җирләргә куып йөртә. Шушы кыенлыклар эчендә ул гражданлык ягыннан һәм, гомумән, кеше буларак тагын да чыныга, ныгый төшә. Әнә шулай укучы бу образның эволюциясен бөртекләп күзәтә.

Шулай да, миңа калса, укучы Нурия образы өчен азрак борчыла. Чөнки, аның җилкәсенә нинди авырлыклар төшсә дә (фәнни-тикшеренү эшләрендә аңа, гомумән, берниндп киртә юк, барысы да аңа яшел урам биреп, хуплап кына торалар), ахыр чиктә Нуриянең җиңәчәге, кыен хәлләрдән чыгачагы әйтмәсәң дә аңлашылып тора.

Бу әсәрдә укучыны, Нуриядән бигрәк, Солтан, Чишмәбай образларының язмышы борчый. Әсәр үзе Солтанның яла ягылып, партиядән чыгарылуы белән башланып китә. Нух Галләм дигән бер бәндә, имеш, Солтан колхозлашу елларында крестьяннарны күмәк тормышка өндәгәндә, чамадан тыш мавыгып, рөхсәт ителмәгән алымнар кулланган дип шикаять яза. Җитмәсә тагын сыйнфый дошман булган мулла кызына өйләнгәнлеге дә өсти. Үз язмышы хәл ителгән партия җыелышында Солтан эшнең дөресендә алай түгеллеген тиешенчә аңлатып бирә алмаган. Әсәрнең буеннан-буена Солтан үзенең партия билетын кире кайтару гаме белән яши, республика һәм илнең иң югары партия органнарына мөрәҗәгать итә. Ләкин, үзенең намуслы исемен торгыза алмыйча, һәлак була. Шушы фаҗигагә кадәр укучы романны аеруча кызыксынып укый, аннан соң инде игътибар акрынлап сүрелә. Ә моннан шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: беренче китапның үзәген Габбас образы тәшкил иткән кебек, бирёдә алгы планга Солтан образы килеп чыга.

Романның беренче кисәгендә без Солтанны сөйкемле яшүсмер егет буларак күргән һәм аның революцион көрәш эченә кереп китүенә куанган идек. Утызынчы елларда инде ул авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә күп көч салган коммунист, Казан Җир төзүчеләр техникумы директоры. Ләкин утызынчы еллар ахырында килеп туган шартларда намуслы кешеләргә яла ягу өчен әллә ни көч куярга кирәкми иде. Солтан да әнә шулай итеп күңелсез хәлгә тарый. Бу аның рухына гына түгел, сәламәтлегенә дә зыян китерә. Солтан, кайгы-хәсрәтеннән аерылу өчен, җырчы булып та карый (монысы бераз сәеррәк килеп чыга чыгуын), үзенең халык мәнфәгатьләренә тугрылыгын башка юллар белән дә расларга омтыла. Шул ук Җир төзү техникумында завхоз вазифаларын да тырышып башкара. «ВКП(б) сафларында булу синең яшәвең иде бит. Синең көрәшең, бөтен барлыгың иде».— ди ул үз-үзенә.

Автор ярлы крестьян Садыйк балаларының советчыл булуын аларның эш-гамәлләрендә шактый тулы итеп күрсәтүгә ирешкән. Солтан турында инде сүз булды. Шәяхмәт исә революцияне яклап сугышкан, хәзер — авыл райкомында беренче секретарь. Аларның Мөхәммәтша дигән туганы Ижевск заводында кызыл гаскәр өчен корал коя, эшче намусына кер кундырмый. Әтиләре Садыйкның берара кулаклар йогынтысында булуын искә алмасаң, бу нәсел чын мәгънәсендә алдынгы карашлы кешеләрдән тора. Гыйбадулла Ядкаров дигән бераү, Айдаровлар нәселен өнәп бетермәсә дә, дөреслекне танырга мәҗбүр. Ул Солтанга болай ди: «Сезнең кан — Айдардан. Шакир хаҗиларга, Алабуганың урман хуҗаларына каршы бунт күтәреп, себер киткән Айдардан сезнең кан». Шәҗәрәсе әнә кайдан килгән, ихлас советчыл күңелле Солтанның, дөреслекне таба алмыйча, каңгырып йөрүе һәм ахырда шул көе дөнья белән саубуллашуы китап укучыны борчуга сала.

Солтанның кеше буларак эчке дөньясы Нурия сүзләреннән дә бик яхшы аңлашылып тора. «Бу дөнья кешесе түгел иде бит Солтан... Үлем аның өчен куркыныч түгел иде. Дөнья малы аны кызыксындырмады, идея кешесе иде бит. Ул бит беркайчан да үзе өчен яшәмәде.» Солтан образының идеяэстетик кыйммәте бүгенге яшь буынга яшәү мәгънәсенең асылын ачып бирүдә, кешенең тормыш ваклыкларыннан өстен торырга тиешлегенраслауда.

Әсәрдәге икенче бер якты образ Чишмәбай турында сүз алып барганда халкыбызның талантлы, киң күңелле, батыр йөрәкле булуына мең дә беренче тапкыр инанасың. «Кулыннан гөлләр тама» дип әнә шундый кешеләр турында әйтә торганнардыр инде. Чишмә суыдай бертуктаусыз игелек кылып торган Каюм исемле бу кешене, әнә шулай яратып, халык Чишмәбай дип атый. Ул чит җирләрдә шактый каңгырып йөргәннән соң, туган авылына кайтып төшә. Бәлки, бүтән бераүнең авылдагы кешеләр арасына килеп өстәлүе күзгә артык ташланмас та иде. Әмма яңа күтәрелеп килүче колхозда Чишмәбай кулы белән ат абзарлары, башка терлек-туар каралтылары үсеп чыга, тегермәнгә җан керә, гүзәллек һәйкәле сыман, чишмә янында матур йорт пәйда була. Каюм-Чишмәбай, Солтан кебек үк, өзелеп ярата да белә. Үсмер килеш Габбас муллага икенче хатынлыкка бирелгән Хәнифәгә булган сөю хисләрен гомере буе йөрәгендә йөртә.

Ике дистә елдан соң әйләнеп кайткач, ул Хәнифәнең Шәфика, Мәхмүт, Әхмәт исемле балаларын үз канаты астына ала. Хә-

нифә белән икесенең уртак бәхете булып Шамил исемле балалары дөньяга килә. Күрәбез. Чишмәбай чын мәгънәсендә табигать баласы. Аның бәхетле тормыш белән яшисе, җирне матурлыйсы, балалар үстереп, аларның куанычын күрәсе килә. Әмма әшәке кешеләрнең хөсетле күзләре аңа да җитә. Сөйкемле Каюм-Чишмәбай да әләк корбаны була. Авылдашлары да моның нахак икәнен белеп торалар. Ләкин алар яла ягучы Бүре Бадулы дигән шыксыз кеше белән әчелешле булырга теләмиләр. «Ник дисәң,— ди хикәяләүче,— аның явызлыгы өстен чыкты». Иң аянычлысы шул, Чишмәбайның гаепсезгә утыртылуын белә торып, райком секретаре Шәяхмәт Айдаров намуслы кешене аралап калу эшен ахырына кадәр алып бармый. Солтан тарафыннан «син районның хуҗасы, нәрсә карадың?» дип маңгайга тәрәп куелган сорауга ул «мин нишли алам» кебек сүзләр белән акланырга тели. Шул ук Шәяхмәт энесе Солтан турында «мин синең туры сүзле икәнеңне, күңелеңдә бер генә алдау-ялганлау булмаганны сал агызган заманнарда ук аңлаган идем» дисә дә, аның дөрес исемен кайтару өчен кайнарланып көрәшкә ташланмый. Мондый хәрәкәтсезлек аның үз репутациясе өчен артык хафалануыннан килә булса кирәк. Ә бу әйбер исә укучы алдында Шәяхмәтнең абруен төшерүгә китерә. Автор уйланмасы буенча яңа җәмгыятьнең тоткасы булырга тиешле Айдаровлар токымының тормышка җайлашуын күрергә теләми укучы. Партия Үзәк Комитетының Январь (1987) Пленумы бездә «социализмның өстенлегеен ачарга һәм файдаланырга мөмкинлек бирә торган прогрессив үзгәртеп коруларны тоткарлау механизмы хасил булуын билгеләп үткән икән, бу экономик үсешкә генә түгел, бәлки кешеләрнең әхлакый якларына да турыдан-туры кагыла. Хаксызлыкны, күреп тә, аны әйтми калдыру, болай әйтсәм, бумеранг кебек үземә икенче яктан китереп сукмасмы икән дип курку, әнә шул әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итәргә ымсынып та, тоткарлау механизмы нәтиҗәсендә күтәрелгән кулны кире төшерү җәмгыятебезгә никадәр зыян китерә килде. Бу күзлектән чыгып караганда, Шәяхмәт Айдаровның кулында зур хокуклар булган кешенең, практик адымнар ясамыйча, «менә ул эшне эшләргә мин сиңа киңәш итәм» дип читтә калырга теләве бу образны бизәми. Бертуган абыйсы эшче Мөхәммәтша аңа дөресен ярып сала: «Теге заманнарда сиңа Шаукымлы Шәяхмәт дип юкка кушамат такканнар. Шикләнүчән Шәяхмәт дип әйтәселәре калган. Беләсеңме, иптәш партиоиный секретарь, җир йөзендә йөз ел куян булып яшәгәнче, бер ел арслан йөрәкле булып яшәвең әйбәтрәк».

Дөрес, бирдә утызынчы еллар атмосферасын исәпкә алмый булмый. Әмма үзе иҗатта шактый кыю булган Г. Ахунов геройларын да хәлиткеч адымнар ясарга сәләтлерәк итеп сурәтләргә тиеш иде кебек.

Романдагы тискәре образлардан Бүре Бадул тормышчанрак килеп чыккан. Һәрхәлдә ул үз холык-фигыле, индивидуаль сыйфатлары ярылып яткан кеше булып күзаллана. Чамасыз физик көчкә ия булуы, аның өстенә кайнарлыгы, эш рәтен белүе, теләсә нинди кыен хәлдән чыгарга юл таба белүе белән хәтта укучыда үзенә карата җылы караш тудыра. Балалары — сугышта үлгән Тәхәви, интендантлык хезмәтендәге Җиһангир, колхоз байлыгын җайлы гына үз оясына ташып ятучы Ниса, кече уллары Ширияздан, Мифтах, Харис, кечкенә кызы Мәхмүзә — барысы да яшәр өчен тернәкләнеп туган, терелекләре белән аерылып торалар. Бүре Бадул — йорт җанлы крестьян. Җимертеп эшләвен дә, умырып ашавын да булдыра. Хатыны бар өстенә үзе күз төшереп йөргән Хәнифәгә әллә кайлардан әйләнеп кайткан Чишмәбай өйләнгәч, ул бу «яшь кияүнең» сөякләрен сындырганчы кыйнап ташларлык дуамал да. Болар һәммәсе аның кулыннан килә. Шәяхмәт сүзләре белән әйткәндә, «ул кулакка әйләнеп бара — үз йортына мал-мөлкәт ташучы каракка». Ләкин Бүре Бадул мондый эшләрен бик яшертен, кеше бәйләнмәслек итеп башкара. Тик шулай да бу образ кылган гамәлнең аның характерыннан килеп чыгуы шарт. Әйе, Бүре Бадул әйбер урларга, үзенә ошамаган кешенең якасыннан алырга, сугып аның тешен сындырырга мөмкин. Моңа укучы тамчы да шикләнми, чөнки аның холкына бу бик туры килә. Тик шулай да, аның авылдашлары өстеннән шикаять язарга каләм тибрәтүе ясалма төсле тоела. Шәяхмәт аның турында «соңгы елларда танымаслык булып үзгәрде» дисә дә, Бүре Бадулның ялачы булып әверелүен психологик нигезләү автор тарафыннан җитенкерәми. Канәгатьсезлек әнә шуннан килә булса кирәк.

Ә менә аның абыйсының малае булган Нух Галләмнең Солтан өстеннән кара кәгазь әмәлләве бик табигый килеп чыга. Әйе, Нух Галләм кебекләр моны эшли алалар. Бу чиркангыч бәндәнең, үзен җиңелчә яралап, сугыштан тылга качарга маташуына да укучы шикләнми. Аның шушы әшәке нияте фаш булгач, төрмәдән фронтка җибәрелгән Чишмәбай тарафыннан атып үтерелүе дә укучыда теләктәшлек кенә уята. Ялачының берсе әнә шулай үз җәзасын ала. Инде укучы Бүре Бадулы белән Чишмәбай арасындагы конфликт ни рәвешле чишелер икән дип кызыксынып кала.

Ә менә төп героиня булган Нурия турында моны әйтеп булмый. Әле өченче кисәкне укымасак та, беләбез, аның белән

барысы да яхшы булыр. Ул фән докторы да, профессор да булыр, абруй да казаныр. Чөнки аның үсеш юлы ботак-чатаксыз туры бара. Ә мондый шомалык укучының игътибарын бик җәлеп итми.

Романның сәнгатьчә эшләнеше турында сүз алып барганда, Г. Ахуновның татар әдәбияты классикларыннан килә торган сурәтләү чараларына тугры булуын канәгатьләнү белән билгеләп үтәргә туры килә. Ул сүзгә, аның яңгырашына, аларны урнаштыруга бик игътибарлы. Менә бу юлларны тыңлап карыйк әле: «Бер генә кош та күкене уздыра алмый икән бит. Сандугачның тавышы бер аланга җитә, урман күгәрченнәре баш очында гөрли, бөркет булып бөркетнең каркылдавы, күп булса, бер кварталга ишетелә торгандыр. Әнә күке, бәләкәй генә бер кошчык, урманны бөтенләе белән кочаклап, барлык аваз-өннәрне үзенә буйсындыра, кеше булып кешене — табигатьтәге иң бөек затны тынып калырга, җир йөзендә күпме яшәргә икәне хакында уйланырга мәҗбүр итә».

Язучы җәйге урманны күз алдына китерә дә бастыра, шул ук вакытта табигать турында үз уйлануларын укучылар белән бүлешә, аларны да әйләнә-тирә турында үз карашларын булдырырга өнди. «Акылның да миңа кешедән откнаы түгел, үз башымда туганы кадерлерәк».— ди икән, Г. Ахунов башкаларның да мөстәкыйль уйлый, анализлый белүен хуплый. Шул ук вакытта ул тагын болай дип тә өстәргә онытмый: «Адәм баласының күңел болыты үзе кичергәннәрдән генә түгел, ата-бабалар сөйләгәннән дә җыела». Дөрес, мин боларны өр-яңа фикерләр дип әйтергә теләмим. Хикмәт аларның сәнгатьчә тукымада кояш яктысында төрле төсләргә кереп ялтыраган пыяла китекләредәй матур булып урнашуларында. Кайвакыт бер уңышлы табылган гыйбарә дә образны тәгәл ачуга китерә бит. «Белешмәне бал белән балландырып, бик тиз алырмын» дигән җөмлә ришвәтче Нисаның портретын тулыландыручы әһәмиятле өстәмә булып кабул ителә.

Шул ук вакытта әсәрдә автор тарафыннан уйлап бетерелмәгән яки игътибарсызлык сәбәпле җибәрелгән төгәлсезлекләр дә очрый. Билгеле булганча, кафедра мөдире бервакытта да үзе боерык чыгара алмый. Кафедра әгъзасы хакында бары тик коллективның утырышында гына коллегиаль рәвештә нинди дә булса хөкем ясалырга мөмкин. Шуңа күрә 115 нче биттәге «Иртәгесен аның (кафедра мөдире Майскийның — Ф. Г.) имзасы куелган приказ стенада эленеп тора иде инде» дип әйтү бу очракта дөрес була алмый. Янәшәдәге 114 нче биттә тагын бер аңлашылмаучылык бар. «Комиссия Атаманованы профбюро бүлмәсенә чакыртты» диелә биредә. Тикшерелә торган мәсьәлә бу очракта, чыннан да, профбюро эшчәнлегенә карый, аннан соң, автор әйтүенчә, Нурия Уразаева үзе дә профбюро председателе. Ләкин шул ук биттә «биредә партбюро һәм кафедра сайлаган комиссия эшли» дип әйтелә, ягъни профбюробыз бик тиз генә партбюрога әйләнеп куя. Бу исә сәхнәгә җилән киеп кергән артистның ялгышып иңенә толып салып чыгып китүен хәтерләтә. Тагын да арырак китсәк, ягъни 135 нче биттә, Нурия «кафедраның өлкән ассистенты булып эшли башлады» диелә. Ассистент ассистент инде ул, аның олысы-кечесе булмый. «Тәрәзә буенда калын сайгаклыктан каккалап куйган агач өстәл тора» (203 бит) дигән җөмләдә дә мәгънә хатасы бар. Чөнки куаклык, агачлык, утынлык була, әмма сайгаклыкны күз алдына китерүе кыен. Бу очракта «калын сайгаклардан» дип әйтү кирәк иде. Ә менә 208 нче биттә «мәктәп директоры Муратов бер үк вакытта колхозда ревкомиссия башлыгы да булып эшли иде» диелә. Аз гына ары киткәч, Бүре Бадулы әлеге Муратовка «иптәш сыйфат комиссиясе» дип эндәшә. Ә бит ревкомиссия белән сыйфат комиссиясе — икесе ике нәрсә. Солтан Айдаров, партия Үзәк Комитетына хат язганда, «хәзерге көндә читтән торып Финанс-экономика институтын тәмамлыйм»— ди (240 нчы бит). Укучы белеп тора, Солтан бу вакытта әлеге институтның бары тик беренче курсын гына тәмамлаган була. Шуңа күрә «институтта укыйм» дип язу дөреслеккә күбрәк туры килер иде. Шундыйрак алга сикереш Әхнәф Айдаров белән дә була. Ул җир төзү техникумын гына тәмамлый, 251 һәм 258 битләрдә автор аны институт тәмамлаган югары белемле белгеч дип атый. 277 нче биттә «ун гәрәнкә бәрәңге» диелә. Гәрәнкәне без шалкан кебегрәк яшелчә әйбере дип беләбез. Ә авырлык үлчәме гөрәнкә дип әйтелә һәм языла. Әйбәт әсәр тукымасында мондый әйберләрнең булуы әчне пошыра, ул романның сыйфаты кимүгә китерә.

Г. Ахунов әзләнүчән һәм әйтелгән фикерләргә колак сала белүче язучы. Ул әсәрнең тулаем өч кисәген бергә эшләгәндә, әле аны тагын сүтеп корыр, трилогия камилләшә төшәр. Татар совет әдәбиятында шактый үзенчәлекле булган һәм киң колачлыкка омтылган әсәргә таләп тә зур. Авторга иҗатында уңыш теләргә генә кала... Ә ахыр нәтиҗәләрне өченче китапны укымыйча чыгарып булмый, әлбәттә.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

**Азат Әхмәдуллин**

# УЛ КАБЫЗГАН УТЛАР ҺАМАН ЯНАР

Классика — киләчәк буыннарны гомер буе озатып бара торган, иң җитлеккән иҗат. Бүгенге сәхнәбез Г. Камал һәм М. Фәйзи, Ф. Бурнаш һәм Т. Гыйззәт кебекләрнең драма һәм комедияләре белән дә бай һәм төрле. Бу каләм осталары иҗат иткән аерым пьесалар хәзерге тамашачыны төрле чорларга алып китә, җәмгыять һәм халык узган тарихи дәверләрнең төрле яклары белән таныштыра, дулкынландыра, шатландыра һәм нәфрәтләндерә. Алар арасында да аерата бәхетлеләре бар: иҗат җимешләре зур активлык белән бүгенгенең әдәбиятын һәм сәнгатен тудырыша, әсәрләре — бүген язылган кебек яңгырый, безнең көннәр укучысына һәм тамашачысына аерата якын.

К. Тинчурин драматургиясе дә шул төргә керә. Соңгы елларда һәр театр сезоны шушы драматург әсәре буенча куелган спектакль белән ачыла, республикабыз театрлары репертуарында аның дистәләгән пьесасы ныклы урын алып тора. Соңгы елларда гына да аның «Зәңгәр шәл» һәм «Ил» мелодрамалары, «Җилкәнсезләр», «Американ», «Сакла, шартламасын!», «Назлы кияү», «Хикмәтле доклад» сатирик комедияләре, «Сүнгән йолдызлар» трагедиясе, «Казан сөлгесе» музыкаль комедиясе һ. б. уйналды һәм уйнала килә. Бу җәһәттән аның белән үткәндәге бер генә драматург та ярыша алмый.

Моның сәбәбе нидә? Кайсы яклары белән К. Тинчурин пьесалары тамашачы күңелен бүген дә, язылганнарына 50—60 еллар узгач та, бердәй били һәм дулкынландыра?

К. Тинчурин әсәрләренең көчен иң беренче бер формациядән — капитализмнан икенчесенә — социализмга күчү чорындагы аерата мөһим проблемалар үзәккә куелган булу билгели. Сыйнфый азатлык өчен көрәш иң югары ноктасына җиткән моменттан торып драматург иске, җимерелеп бара торган җәмгыятьне бәяли, фаш итә. Бу фаш итү дөньяга иң алдынгы караштан чыгып эшләнә. Һәм, тагын да әһәмиятлерәге, зур талант тарафыннан эшләнә. Драматургның сатирик таланты яңа туып килүче җәмгыятьнең үсешенә аяк чала торган якларны һәм кешеләр характерларын да күреп алып бәяләргә ярдәм итте. Болар бүгенге татар сәхнәсе өчен әлегә кадәре беленеп бетмәгән хәзинә. Бу хәзинәдән дөрес һәм урынлы файдаланганда, ул әле яңадан-яңа сәнгать ачышларына алып киләчәк.

Бүген театр бу хәзинәдән ничек файдалана соң?

Якын тарихка күз салыйк. К. Тинчурин иҗаты яңадан да халыкка һәм әдәбиятка кайтарылган чорда,— ә бу — 50 нче еллар,— милли театрыбыз авырлыклар кичерә иде. Драматургия үсешен «конфликтсызлык теориясе» тоткарлап торды. Бу вакытларда театр репертуарлары югары художестволы пьесаларга, бигрәк тә заман темаларына багышланган пьесаларга, аерата комедияләргә чын мәгънәсендә кытлык кичерде. Шул яктан Тинчурин һәм Бурнашларның вакыт сынавын узган әсәрләре сәхнәгә яшәү сулышы һәм икенче яшьлек өргәндәй булды. Сәхнә үзенә җитмәгән, тамашачы зарыккан комедия һәм сатиралар белән баеды. Комик һәм сатирик персонажлар, көлке һәм мыскыл ситуацияләре театрларның идея-художество чараларын җанландырды һәм бу өлкәдәге мөмкинлекләрен әр-яңа бер югарылыкка күтәрде.

К. Тинчурин драматургиясе, иң әүвәл, әче көлүе белән көчле һәм актуаль. Аның каләме астыннан чыккан 20 дән артык пьесаның (өчесе — соавторлыкта язылган пьесалар) 11-е комедия төренә керә. Төп сюжет сызыгы буенча килеп караганда музыкаль драма һәм мелодрама төренә кергән пьесаларда да (мәсәлән, «Зәңгәр шәл»,

«Ил») сатира һәм юмор зур роль уйный. Язучы иң беренче комедия жанрында зур идея-эстетик ачышлар ясады, татар драматургиясен сәнгатьчәлек ягыннан яңа баскычка күтәрде, аның тематик чикләрен киңәйтте. Театрыбыз әле бүген дә бу мирасны аңлау һәм үзләштерү юлында тора, аның бу җәһәттән әле бүген дә күп эшлисе бар.

Театр классиканы яңача, хәзерге көн югарылыгыннан торып укырга омтылды һәм омтыла килә. Бу яктан режиссерлар һәм артистлар К. Тинчурин әсәрләрендә әле һаман да ачылып бетмәгән яңа мөмкинлекләр күрәләр, әзлиләр һәм еш кына табалар да. Мисал өчен, «Сүнгән йолдызлар» пьесасын алып карарга була. Драма итеп язылган бу әсәрнең нигезендә куючылар һәм актерлар фаҗигале язмышлар күрделәр. Нәтиҗәдә «Сүнгән йолдызлар» Академия театры сәхнәсендә халыкчан трагедия дәрәҗәсенә җиткерелеп яңгыратылды. Пьесадагы коллизияне иҗтимагый конфликт дәрәҗәсенә күтәреп яңгыратуы өчен спектакль югары бәяләнде.

Соңгы елларда сәхнәдә уйналган әсәрләрнең күпчелеге комедия. Үткән җәмгыятьнең черек һәм көлке якларын да, Совет властеның беренче елларында баш калкыткан яңа төр мещанлыкны да бүгенге сәхнә, иң беренче, Тинчурин югарылыгыннан торып фаш итә,— монда шиксез уңышлар бар. Театр бу әсәрләрдә чагылган оптимизмны — бөек үзгәрешләр рухы тудырган оптимизмны — тулы саклауга ирешә. Алай гына да түгел, аны аерым спектакльләрдә (иң беренче, «Җилкәнсезләр» һәм «Американ»да) тагын да үстереп һәм ныгытып, социалистик революция мөмкинлек биргән үтергеч көлүнең ышанычлы нигезләрен булдырды.

Әлбәттә, классиканы торгызу шома гына бармый. Бу яктан К. Тинчурин әсәрләре дә чыгарма түгел. Мәсәлән, 50 елларда, Татар дәүләт академия театры «Зәңгәр шәл» һәм «Казан сөлгесе»н куйгач, шактый бәхәсләр булды. Аларның асылы Академия театры кебек дәрәҗәле сәхнә музыкаль пьесаларга урын бирергә тиешме, юкмы мәсьәләсенә кайтып калды. Хәлбуки, татар театры 20—30 еллардагы зур уңышларга ирешкән музыкаль жанрны яңадан торгызу өчен көрәш башлаган иде, татар тамашачысының яраткан сәнгать төренә алга үсү өчен яңа мөмкинлекләр ачты.

Төрле вакытларда, төрле уңай белән һәм төрле формада чагылган мондый фикер каршылыкларына карамастан, театр К. Тинчурин драматургиясен яңадан торгызу өлкәсендә эшләвен һәм эзләнүләрен дәвам иттерде һәм зур уңышларга ирешә. 1958 елда татар драматургиясенең иң гүзәл үрнәкләреннән берсе булган «Җилкәнсезләр» трагикомедия югарылыгына күтәреп куелды. Буржуаз җәмгыятьнең терәү баганалары ролен уйнарга тырышкан «тәрәккый пәрвәр» сәүдәгәр Нуретдиннар һәм Мисбах хаҗилар, аларның халуе Батырхан кебекләр, Нуретдиннарны яңа шартларда алыштырып килгән нэпман Зәйнетдиннәр — боларның һәммәсенең дә — соңчиктә һәлакәткә дучар булганлыгы тарихи дөреслек фонында сәнгатьчә югары сурәтләнде.

Театр белгече И. Илялова Татар дәүләт академия театрының 60 еллар ахырыннан алып, бүгенге көннәргә кадәрге иҗат гомерен «Яңа дәвер» дип атый. Бу дәвердә сәхнәбезнең йөзен билгеләшүдә К. Тинчурин драматургиясе мөһим роль уйный. Бу чорда Академия театрында, югарыда искә алынган «Сүнгән йолдызлар»дан тыш, драматургның иң күренекле әсәрләреннән булган «Американ», «Назлы кияү», «Зәңгәр шәл», Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Хикмәтле доклад», Минзәлә театрында «Ил» һ. б. куела. Шулардан мисалга «Американ» комедиясен генә алу да җитсә кирәк. Ярты гасыр элек язылган бу әсәрне Академия театры коллективы нәкъ менә бүген язылган кебек яңгыратты. «Американ»да милли художестволылык традицияләрен баету юлы бик анык билгеләнгән,— дип язды бу спектакль турында «Правда» газетасы.— ...пьеса идея ниятенең төгәллеге һәм заманча сурәтләү чараларын эшләүнең нәтиҗәлелеге аркасында бүгенге тамашачыга якын» («Правда», 1970, 1 август). «Американ» һәм «Назлы кияү», һичшиксез, милли театрның сатира һәм юмор арсеналын баетты, төрләндерде.

Кызганычка каршы, К. Тинчурин әсәрләре буенча куелган барлык спектакльләр турында да болай әйтеп булмый. Иң соңгы елларда бу мирасны Академия театрында көчәеп киткән сатира һәм көлү юнәлешенә буйсындыру тенденциясе барлыкка килде. Җәмәгатьчелек бигрәк тә «Казан сөлгесе»нең соңгы куелышындагы көчләп көлдерүләргә, кәмитлеккә каршы чыгып, берьяклы характер ала барган бу мавыгуга бик урынлы тәстә борчылу белдерде.

Бу тенденциянең аерым уңышсыз нәтиҗәләре бигрәк тә «Зәңгәр шәл»нең соңгы куелышында ачык төс алды. Академия театры аны К. Тинчуринның 100 еллыгы алдыннан сәхнәләштерде. Бу — әсәрнең алтынчы мәртәбә куелуы, электәгеләреннән алга узып, аның әлегә кадәр акцент ясалмаган, ачылып җитмәгән якларын ачарга тырышу булды. Театр билгеле бер дәрәҗәдә классик әсәрне, тамашачы һәрчак сөеп

---

[1] Фәттах Нурихан. Быел тагын «Казан сөлгесе».— «Социалистик Татарстан», 1986 16 ноябрь; Нуруллин И., Мәхмүтов Һ. Данлы традицияләрне үстерү хакына.— «Социалистик Татарстан», 1987, 17 апрель.

кабул итә торган мелодраманы яңача укырга дигән теләгенә ирешә алды. «Яңача булсын!» дигән омтылышка хәтта тулысынча ирешелгән дип тә әйтә алабыз. Ләкин яңалык ни кадәр уңышлы, кайсы яктан уңышлы? Аңар мисаллар бар, билгеле. Мәсәлән, оригиналь мезансценалар һәм өр-яңа сценография ярдәмендә халкыбызның якты рухын, оптимизмын, гореф-гадәтләрен, акылын чагылдырган сабан туена хәзерлек күренешләре. Хезмәт кешесенең буйсынмас характерын, бунтарьлыгын чагылдырган качкыннар пәрдәсе дә төгәл эшләнүе, драматург фикерен тулы әйтүгә ярдәм итүе белән игътибарга лаеклы. Актерлар уенында,— аларның үзләре өчен дә, тамашачы өчен дә,— яңалыклар күп: Котдүс ишанның дүрт хатыны гына да ни тора!!



*Икенче рәттә сулдан икенче Кәрим Тинчурин*

Шулай да пьесаның бу куелышы каршылыклы хисләр һәм канәгатьсезлек тә уята. Төп хикмәт — әсәрнең сәхнәдә берьяклы чишелешендә. Куючылар (художникны да кертеп) әсәрдә иң беренче сатира күрәләр. Ишан хәзрәт, аның авылдагы куштаннары, ул алдап-йолдап, алар җилкәсендә рәхәт яшәгән кешеләр, бозыклыкка чыгып баручы ишан хатыннары — болар, әлбәттә, драматургның үзе тарафыннан да тәнкыйть утына тотылалар, мыскыл ителәләр. Ләкин мыскыл итүнең дә, көлүнең дә төрле-төрле дәрәҗәләре бар. Әгәр дә драматург сатира язса, вакыйгаларны сатирик үткенлек җирлегенә корса, сатирик гиперболалар да, шаржлык та урынлы да, кирәк тә була. Мәсәлән, «Американ» комедиясендәге кебек. Ләкин «Зәңгәр шәл», гәрчә анда сатира-юмор билгеле бер роль уйнаса да, сатира түгел, мелодрама. Ә мелодраманың, мәгълүм булганча, үз максаты һәм үз законнары бар.

Инде алда әйтелгәнчә, социалистик революциянең беренче елларында К. Тинчурин, драматург буларак, талант көчен асылда иске җәмгыятьне фаш итүгә, туып килүче тормышның һәртөрле дошманнарыннан көлүгә юнәлдерде. «Йосыф-Зөләйха», «Сакла, шартламасын!», «Тутый кош», «Казан сөлгесе», «Американ» кебек әсәрләрнең үзәгендә дистәләгән гаять оригиналь комик һәм сатирик образлар тора. «Зәңгәр шәл», «Ил» кебек пьесалар исә иң беренче, драматургның үз иҗатында уңай герой эзләүгә борылышлары белән дә кызыклы иделәр. Мондый герой иҗат итүне ул мелодрама жанрыннан башлый: татар драматургиясендә инде традицияләре булган өлкәдә яңа сүз әйтә, мелодраманы М. Горький күрсәткән һәм өметләнгән югарылыкка күтәреп, аның мөмкинлекләреннән тулырак файдаланырга омтылыш ясый. Әле Бөек Октябрьгә кадәр үк М. Горький тупикка кереп баручы театр сәнгатен коткару өчен мелодрама жанрын җанландырырга, аңа яңа идея-эстетик эчтәлек бирергә кирәклеген әйтеп чыккан иде. Пессимизмга каршы булу, тормышка актив мөнәсәбәтне яклау мелодрама алдына куела торган төп таләпләр булырга тиеш, диде бөек пролетар язучы, моның өчен мелодраманың романтик эмоциональлек

белән сугарылуы зарур. «Мелодрама чиктән тыш гади психологизмга — хисләрне һәм вакыйгада катнашучыларның үзара мөнәсәбәтен гадиләштерүгә — корылганга күрә дә, авторларның теге я бу геройга үз симпатияләрен һәм антипатияләрен ачык һәм билгеле төстә ассызыклаулары кирәк».— дип язган М. Горький («Искусство коммуны», 1919, 2 март).

«Зәңгәр шәл»— тулысы белән шул рухтагы әсәр. Драматургия һәм театр тарихы ноктасыннан караганда да, татар сәхнәсендә уңай геройның ныгуы җәһәтеннән дә аның әһәмияте Булат һәм Мәйсәрә сызыгы белән бәйле сюжетка барып тоташа. Бунтарь характерлы, үз бәхете өчен куркусыз көрәшүче кызу канлы кешене драматург алгы планга чыгара. Бу сюжет сызыгына бәйле төстә гаять җанлы, драматик хәрәкәт көче ягыннан да, образлар системасы белән дә гаҗәеп дәрәҗәдә оста эшләнгән пәрдә — урмандагы качкыннар пәрдәсе — юкка гына кертелмәгән. Нәкъ менә шушы пәрдәдә иҗтимагый көрәш мотивлары үткен куела, яңа җәмгыять өчен барган көрәш елларында тамашачы бик теләп һәм якын күреп кабул итә торган, бүгенге көн тамашачысына да якын булган, сыйнфый азатлык файдасына булган сүзләр сөйләнә. (Сүз уңаеннан әйткәндә, пьесаның бу урыннары соңгы куелышта беркадәр кыскартуларга очраган һәм мондый «төзәтүләр» әсәрнең иҗтимагый яңгырашына зыян китерәләр). Революциягә кадәрге мелодрамадан, сентиментализмга һәм тышкы эффектлылыкка корылган, геройлары язмышка буйсынырга мәҗбүр ителгән мелодрамадан аермалы буларак, социаль конфликтка корылган мелодрама туа.

К. Тинчуринның сәхнә кануннарын сизгер тоючы зур оста булуы монда да ачык күренә. Ул төп сюжет сызыгына зарар китермәстән, киресенчә, аны көчәйтерлек һәм җанландырырлык итеп кенә Котдүс ишан белән бәйле сатира сызыгын да суза. Татар әдәбияты динчеләрне, мулла-монтагайны фаш иткән, адәм көлкесенә калдырган әсәрләргә бай. Хәтта, әйтергә мөмкин, бу яктан ул башка төрки халыклар әдәбиятлары арасында аерылып тора. Мондый әсәрләр янәшәсендә «Зәңгәр шәл»нең лаеклы урыны бар. Чыннан да, ишан хәзрәт, аның мөрите «дәрәҗәсен» алган Җиһаншакарак, хәзрәтнең дүрт хатыны, авылның динле карт-корысы һәм байгурасы, ат карагы Миңлегали һ. б. ярдәмендә иске тормышта зур роль уйнаган дини фанатизмны фаш итә.

Спектакльгә килик. Аның авторлары, инде әйтелгәнчә, игътибарны сатираны көчәйтүгә юнәлткәннәр. Ишан хәзрәтне, аның иярченнәрен һәм гаиләсен фаш итү яңа бер югарылыкка күтәрелгән. Ләкин бу югарылык — реалистик дөреслеккә илтүче детальләрне үстерү юнәлешенә баруда түгел, ә саф сатира элементларын көчәйтүдә һәм шаржлыкны арттыруда, сатирик гиперболага омтылуда. Менә шунда инде әсәрнең мелодраматик сюжет сызыгына зыян китерә торган хәл туа да. Элекке куелышларда да тамашачы ишанны хайвани теләкләренең колы дип кабул итә, аның әүлиялык, изгелек кабыгына төренгән рухи әчтәлеген — бозыклыгын бик яхшы күрә һәм аңлый иде. Инде хәзер аның хайвани теләкләре һәм омтылышлары соң чиккә җиткереп күрсәтелә: яшь кызлар янында ул калтырый ук башлый, төртеп җибәрсәләр дә гадәти генә егылмый, штан төпләрен күрсәтеп, мәтәлчекләр атына... Яки, менә ишан хатыннары. «Изге» карт тарафыннан дүрт стена арасына ябып куелган бу «фәрештәләр»нең наданлыгы һәм азгынлыгы, миһербансызлыгы һәм оятсызлыгы инде драматург тарафыннан җитәрлек үк ышандырырлык итеп күрсәтелгән. Аларның ялчы Галәви белән бәйләнешләрен генә карагыз. Бозыклыкта ишанның үзеннән бер дә калышмый торган бу кешенең Мәйсәрә хакында «гомер булса, бәлки, ишан хәзрәт анысыннан да гошер чыгарыр әле» дигән сүзләреннән аңлаган кеше күпне аңлый инде, югыйсә. Ләкин әсәрне сәхнәгә куючыларга болар гына аз. Ашка китәр алдыннан хатыннарның барысы да дип әйтерлек Галәви белән иң вульгар кыяфәттә үбешеп чыгалар. Болар ни бирә инде мелодрамага, нәрсә белән баета? Киресенчә, Мондый күренешләр һәм арттырулар янәшәсендә Мәйсәрәнең күңел сызланулары вагая һәм ышандыру көче кими. Сатирик ассылыкта чаманы белми уйнау психологик ассылыкта да «уен» китереп чыгара. Мелодрамада психологик примитивизм янына сатирик примитивизм өстәлә, күз яшьләрен «сыгып чыгару» янына көчләп көлдерү килеп кушыла — әсәрнең бөтенлегенә зыян килә. Шуңа күрә дә кайбер тамашачыларның «безнең халыкта алай булмаган инде, бигрәкләр дә үз-үзебезне мыскыллыйбыз» диюендә хаклык бар. Җитди мелодраматик ситуация мондый вульгарлаштыруларны күтәрә алмый. Сәхнә кануннарына да, характерларның логик бөтенлегенә дә, телгә дә гаять сизгер булган К. Тинчурин жанр төрләрен (мелодрама белән юмор-сатираны) һәм сәнгать төрләрен (сәхнә уены белән җыр-музыканы, бию-акробатиканы) берләштерүнең гаҗәеп үрнәген биргән. Бу бербөтенлекне җимермәс өчен аерата саклык кирәк. Драматург жанр төрләрен аларның һәрберсе синтетик бербөтенгә үзеннән өлеш кертә һәм бу бербөтенне үзенә генә хас булган үзенчәлекле сыйфатлар белән баета торган итеп куша алган. Шуның белән бергә синтетик бербөтен булып оешканда һәр сәнгать һәм жанр төре тегеләйме-болаймы бүтәннәргә

һәм бербөтенгә яраклаша, үзе дә яңа сыйфатлар ала. Шуңа күрә бу музыкаль мелодрама инде сәнгать һәм жанр төрләренең механик кушылмасы итеп түгел, ә яңа бер органик художество бөтенлеге дип кабул ителә. Мондый бербөтенне сатирага буйсындырырга тырышу, ягъни башка сәнгать һәм жанр үзенчәлекләрен сатирага гына әйләндерү спектакльне берьяклы иткән. Нәтиҗәдә спектакльнең тулы сурәте бозылган,— анда сатира чуан булып бүлтәеп тора. Сатира ташкыны уңай геройны да, психологик кичерешләрне дә, хәтта социаль яңгырашны да җуя, бөтенләй юк җуймаса да, шактый төссезләтә.

Ике дөнья арасындагы аермаларны К. Тинчурин, шул рәвешчә, төрле сәнгатьчә чаралар ярдәмендә күрсәтте: асылда сатира һәм юмор байлыгы белән аерылып торган бу иҗатка, шулай да, бер генә төрле карашны алга сөрү ярамый. Театр эшлеклеләребез шул хакыйкатьне тирән аңлаганда гына бу гүзәл мирасны тулы көчкә эшкә җигәргә, бүгенге тамашачыны иске җәмгыятьне күралмаска, буржуаз мөнәсәбәтләргә нәфрәт белән карарга, хәзерге тормышыбызның матурлыкларын кадерләргә өйрәтергә мөмкин.

## Баян Гыйззәт

# ЯҢА СӘНГАТЬ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ

Атаклы драматург, режиссер, артист, җәмәгать эшлеклесе Кәрим Тинчуринның йөз еллыгын совет җәмәгатьчелеге зур тантана белән билгеләп үтә. Моннан 60—70 еллар элек язылып та, хәзерге сәхнәдә һаман да үзәк урынны алып торган атаклы «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр», «Американ», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» һәм башка бик күп талантлы пьесаларның авторы К. Тинчурин бүген дә тамашачы теленнән төшми, спектакльләре тулы заллар җыя, кешеләр күңелендә яңадан-яңа якты фикерләр, тирән хисләр уята. Тукай, Әмирхан, Ибраһимов, Такташ, Җәлил, Туфан кебек, Тинчурин исеме дә культура тарихыбызның якты сәхифәләренә мәңгелеккә язылган.

Кәрим Тинчуринның бөтен гомере татар театры белән бәйле булып, ул сәхнә сәнгатен халык тормышының аерылмас бер өлеше, аның үзаңы үсешендә зур урын тоткан куәтле көрәш коралы итеп саный иде. 1920 елда ук ул зур ышаныч һәм өмет белән бу турыда шулай дип белдерде: «Пролетариат театры, һәр милләтнең үзенә махсус хосусиятләрен саклап, юксыллар тормышының көзгесе булу белән бергә, аның ышанычлы коралы да булачак» («Кызыл дөнья», 1920, 7 декабрь, Самара). Шушы изге максат белән рухланып, ул үзенең зур талантын, тырышлыгын, көчен яңа, совет татар халык театры төзүгә багышлый: берсеннән-берсе гүзәл пьесалар иҗат итә, театрга җитәкчелек итә, режиссерлык сәнгатен үзләштерә, җаваплы рольләрдә сәхнәгә чыга, театрның барыр юлларын ачыклаган теоретик хезмәтләр яза. Татар совет театрын социалистик реализм юлына алып чыгу өчен барган көрәштә К. Тинчурин хәлиткеч рольләрнең берсен уйный.

К. Тинчуринның тормыш юлы — үз кул көче белән көн күрүче крестьян гаиләсендә туып үскән, үзенең эш сөючәнлеге, тырышлыгы аркасында җәмгыятьнең алдынгы көчләре сафына баскан, үз иленә бирелеп хезмәт иткән талантлы халык улы үткән юл ул.

Кәрим Тинчурин 1987 елның 15 сентябрендә хәзерге Пенза өлкәсе Бедно-Демьян районы Таракан (хәзерге Аккүл) авылында туган. Яшьтән үк эшкә өйрәнгән Кәрим бик иртә үз көнен үзе күрә башлый. Авыл мәдрәсәсендә уку белән генә канәгать булмыйча, ул Казанга юл тота. Җәйләрен эшләп, кышын атаклы Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укып, ул 1905 ел революциясен каршылый. Үзенең Ф. Әмирхан кебек алдынгы карашлы шәкертләре белән танылган бу уку йорты да демократик хәрәкәттән читтә калмый. К. Тинчурин да алдынгы яшьләр белән бергә төрле яшерен җыелышларда катнаша башлый, революционерлар белән аралаша. Шуның өчен бер төркем шәкертләр белән бергә ул мәдрәсәдән чыгарыла. Моннан соң ул төрле контораларда эшләп көн күрә башлый, үзлегеннән укуын дәвам итә, торган саен яңа гына оешып килә торган театрга якыная бара, театр өчен пьесалар яза, шигырьләр язып бастыра.

1910 елда К. Тинчуринның тормышында кискен үзгәреш була: бер генә спектакльне дә калдырмыйча театрга йөрүче яшь, матур, белемле егет белән «Сәйяр» труппасының җитәкчесе Габдулла Кариев таныша һәм труппага эшкә чакыра. Яшь талантларны ачуда аеруча зирәклеге белән танылган Г. Кариев бу юлы да ялгышмый — Тинчурин да күренекле артист булып үсә. Кариевның үзеннән кала татар режиссура сәнгатенә нигез салучы булып танылa.



*Сулдан уңга: Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, Габдрахман Мангушев. Уртада Г. Кариев*

Труппага кергәненең беренче елларыннан ук Тинчуринга җаваплы рольләр тапшыра башлыйлар. Мәсәлән, 1913 елда инде ул Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә Вурм образын иҗат итә. Вакытлы матбугат яшь артистның уңышын тиз күреп ала һәм аңа алдан ук зур киләчәк билгеләп, болай дип яза: «Мәкер һәм мәхәббәт»тә Үзбәк әфәнде (К. Тинчуринның ул чорда сәхнә псевдонимы) сезон ахырында хаин Вурм ролен шаян тәкъдир (югары бәягә лаеклы) бер дәрәҗәдә уйнап, ошбу роле аркасында критиканың дикъкатен җәлеп итте, вә әгәр тырышса, киләчәктә бик файдалы бер артист булачагын күрсәтте» («Аң», 1913, II сан). Аннан соң уйнаган Гата («Кызганыч бала»), Закир («Бәхетсез егет»), Газиз («Яшьләр»), Сөләйман («Тигезсезләр»), Хлестаков («Ревизор»), Незнамов («Гаепсез гаеплеләр»), Гали («Яшь гомер») рольләрен уңышлы башкарып, Тинчурин җәмәгатьчелекнең ышанычын тулысынча аклады. Театр сәнгатенең серләренә ул торган саен тирәнрәк төшенә бара. 1916 елда инде Г. Кариев аны «Сәйяр» труппасының режиссеры итеп куя һәм К. Тинчурин Кариевның иң якын ярдәмчесе һәм фикердәше булып әверелә. К. Тинчурин «Сәйяр»да үзенең артистлык таланты ягыннан гына түгел, укыган кеше, белемле булуы белән дә аерылып тора. Күрәсең, «Сәйяр» труппасының җитәкчеләреннән берсе булып күтәрелү өчен боларның һәммәсе кирәкле булган.

Татар мәгърифәтчеләре байрагы астына баскан, үз халкына социаль һәм милли тигезлек таләп иткән куәтле хәрәкәткә кушылган башка бик күп алдынгы яшьләр кебек, К. Тинчурин да үзенең эшчәнлеген бер генә өлкә белән чикләми, чын-чыннан яңару, уяну чоры кичергән халыкның улы буларак ул да давыллы көрәшкә ташлана. Театрда эшләүнең беренче көннәреннән алып, аны бетерергә тырышучы карагруһлар, патша цензурасы, полиция кебек явыз дошманнарга каршы катлаулы көрәш башларга кирәк була. Татар телендә пьесаларның аз булуы беренче тапкыр Казанда кыш буена эшләргә калган «Сәйяр» труппасын бик авыр хәлгә куя, чөнки театрга йөрүче тамашачы әле аз була, ай саен бер яңа пьеса куярга туры килә. Димәк, әлегә уйналмаган әсәрләр табарга, язучыларны театрга тартырга, үзеңә бу жанрда ныклап эшкә тотынырга кирәк. Шулай итеп, «Мөназәрә» (1906) комедиясеннән соң тукталып калган әдәби иҗат эше яңадан кабынып китә; бер-бер артлы «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910—12), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1916), «Ач гашыйк» (1916), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) исемле пьесалар барлыкка килә.

Әмма яшь автор беренче әсәрләре белән үк татар театрының явыз дошманы булган патша цензурасы белән йөзгә-йөз килеп бәрелә: аның беренче пьесалары ук

сәхнәгә куюдан тыела. К. Тинчурин чигенергә, цензурага баш иярга, иҗаттан туктарга уйламый. Ул хикәя жанрына күчә, шул ук фикерләрне прозада үткәрә башлый һәм 1914—1918 еллар арасында утызга якын хикәя язып бастыра.

К. Тинчуринның хикәяләрен берничә төркемгә бүләргә мөмкин. Аларда буржуаз җәмгыятьнең черөп таркалуын күрсәткән әсәрләр дә бар, герман сугышына каршы язылганнары да, ярлы халыкның изелеп яшәвенә протест та, дошманнарга каршы сатира да, лирик җылылык белән сугарылган мәхәббәт күренешләрен сурәтләгән әсәрләр дә бар. Гомумән, К. Тинчурин, прозаик буларак, сюжет кору остасы, гаҗәеп матур йөгерек телгә ия булган, берничә гади алым белән үзенчәлекле характер төзи белүче язучы булып формалаша һәм шактый тиз танылып өлгерә. Аның бу талантын хикәяләре басыла башлаганга бер ел үтәр-үтмәс күреп алалар. «Аның журнал вә газеталарда дәрәҗ ителгән (басылып чыккан) милли вак хикәяләре һәркем тарафыннан сөелеп укыла» дип языла «Аң» сәхифәләрендә («Аң», 1915, 11—12 сан).

К. Тинчуринның революциягә кадәр язылган сәхнә әсәрләре арасында «Беренче чәчәкләр» драмасы аерым урын алып тора. Биредә аның эстетик карашлары аеруча ачык билгеләнгән. Әсәрнең төп конфликты, аның проблематикасы ике шәкертнең тормыш максатлары турында сөйләшүендә ачыла. Кыям: «Шәхси файда өчен эшләнгән эшне мин эштән санамыйм... гомуми файда өчен, халык файдасы өчен безнең ни эшләгәнебез бар?» Кыям белән бергә укып, соңыннан мулла булган Хәкимҗан, үз тормышыннан канәгать булуын белдереп һәм, димәк, кешенең дөньяда яшәвенең максатын билгеләп, болай ди: «Җан тыныч, өс-баш бөтен, тамак тук». Драмада әнә шушы ике төрле караштагы яшьләр арасында көрәш бара. Әсәрнең баш герое булган Хәмит авызыннан әйтелгән сүзләрдә без Тинчуринның үз фикерләрен ишетәбез кебек. Ул да бит шул максатлар өчен көрәш алып бара: «Аларга (халыкка) аң кертергә кирәк... бу безнең бурычыбыз... Минем тоткан юлым шул: халыкта үзен-үзе аңлау хисе уятырга кирәк» (әсәрдән өзекләр 1913 елгы кулъязмадан алына). Менә шушы фикерләр патша цензурасы аша үтә алмый да инде. Шул сәбәпләр аркасында Февраль революциясенә кадәр, ягъни патша цензурасы бетерелгәнче, «Назлы кияү» комедиясеннән башкалары сәхнәгә куелмый киләләр.

Революцион вакыйгалар якынлашкан саен төрле политик лагерьларның позицияләре ачыграк беленә бара. Татар театры коллективлары, шул исәптән «Сәйяр» дә демократик карашларда нык торып, бу җаваплы көннәрдә халык ягында була. 1917 елның көзендә «Сәйяр» сәхнәсендә М. Горькийның «Мещаннар», Г. Коләхметовның «Яшь гомер» кебек революцион драмалары куелу моның ачык мисалы булып тора. Бу спектакльләрнең Мулланур Вахитов төзегән Мөселман социалистлар комитетына багышланган булуы да күп нәрсә турында сөйли иде.

Гомумән, бу җаваплы көннәрдә «Сәйяр» труппасы җитәкчеләре ачыктан-ачык халык күтәрелешенә кушылалар. «Татар театры тарихыннан» дигән китапларында (Мәскәү, 1926) элекке «Сәйяр» артисты В. Мортазин һәм язучы Т. Ченәкәй бу турыда менә нинди кызыклы факт китерәләр: «Хәтеребездә: 1917 елның май бәйрәме иде, бөтен татар буржуазиясе рия йөзеннән (икейөзлеләнеп), аерым группалар булып бәйрәм иткән вакыт, театр галәменең Габдулла Кариев, Тинчурин, И. Кули кебек бик күп активы мөселман социалистлары байрагы астында оешкан эшче, солдат, солдатка кебек хезмәт ияләренең демонстрация сафында җанлы рәвештә катнашып үткәрделәр».

Октябрь революциясе татар театры тарихының яңа дәверен башлый. Хәзер әдәбият һәм сәнгатьнең үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр булдырыла, аның юлындагы барлык киртәләр алып ташлана. Театр дәүләт күләмендәге әһәмияткә ия булган мөһим оешма дәрәҗәсенә күтәрелеп, ул хөкүмәт карамагына алына, аңа эш шартлары тудыру өчен җитәрлек күләмдә дотация билгеләнә, артистлар даими хезмәт хакы ала башлый, театр биналары бирелә, күләмле әсәрләрне дә куярга көче җитәрлек зур труппалар төзелә. Бу шартларны күрү бәхетенә ирешкән татар артистлары яңа халык сәнгате тудыру өчен җиң сызганып эшкә керешәләр. К. Тинчурин шул вакыйгаларның үзәгендә, шул эшләрне башлап йөрүчеләрдән була.

1918 елның көзендә, акчехлар һәм аклар армиясен Казаннан сөреп чыгаргач, урындагы партия һәм совет органнары тарафыннан К. Тинчуринга җаваплы эш йөкләнә: ул дошман армиясе Казанга кергәннән соң эшләүдән баш тартып, таралып киткән «Сәйяр» труппасын яңадан җыеп, Беренче татар совет театры труппасы төзергә тиеш була. Шулай итеп, яшь совет республикасы партиянең культура өлкәсендәге политикасын тормышка ашыра да башлый.

К. Тинчурин төзегән труппа ул еллардагы татар театры үсешендә төп юнәлешне, аның үзенчәлеген, идея-эстетик эзләнүләрен билгеләде. Театр җитәкчесе буларак, К. Тинчурин эзлекле рәвештә партиянең культура өлкәсендә үткәрә торган чараларын тулысынча яклап, аларны тормышка ашыру өстендә эшли башлый. 1919 елның февра-

ләндә ул «Вак милләтләр театры хакында бер-ике сүз» дигән махсус мәкалә белән чыга. Бу мәкаләсендә ул совет театрының ныклы идея һәм оештыру нигезләрен салган партия документларының, совет хөкүмәте карарларының әһәмиятен аңлата. Аннары мәкаләдә театр төзелешенең киң программасын уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен хәл итәргә тиеш булган бурычлар ачыклана. Билгеле булганча, 1919 елның 26 августында чыккан «Театр эшен берләштерү турында декрет»ка В. И. Ленин имзасы куелган иде. Әлеге мәкаләсендә К. Тинчурин Совет властеның милли культураны үстерү турындагы кайгыртучанлыгы белән рухланып, сәнгать эшлеклеләренә ялкынлы чакыру белән мөрәҗәгать итә: «Мең-мең шөкер... Татар театрының хәзерге дәвере — эшләр өчен иң күңелле бер дәвер, татар театрының хәзерге барышы көткәннән артык файдалы нәтиҗәләр тудырачак. Бары эшләргә кирәк! Эшләргә! Эшләргә! Татар сәхнәсе шәрәфенә (хөрмәтенә), санаигы нәфисә (матур сәнгать) хөрмәтенә керешегез эшкә! Өязләрдә, авылларда театрның изге һәм нурлы байрагын күтәрегез!»

К. Тинчурин үзе «театрның нурлы байрагын» югары күтәргән күренекле шәхесләрнең беренчеләреннән булды.

Югарыда искә алынган мәкаләдәге фикерләрне, уйлануларны дәвам итеп, К. Тинчурин шул елның көзендә «Кызыл армия» газетасында «Мулланур иптәш Вахитов һәм татар театры» исемле мәкалә бастыра. Мәкаләдән күренгәнчә, М. Вахитов татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү буенча киң программа төзегән булган. Ул эшнең бөтен катлаулылыгын белеп, аңлап, аны хәл итү юлларын билгеләгән, анда яңа сәнгать кадрлары хәзерләү өчен махсус уку йортлары ачу, театрларны биналар белән тәэмин итү, репертуар, артистларның тормыш хәлләрен яхшырту һәм башка бик күп җитди мәсьәләләр күздә тотылган була. М. Вахитов төзегән программа бу өлкәдә совет хөкүмәте билгеләгән чаралар белән бик тәңгәл килә, һәм Тинчурин аларны тормышка ашыру каһарман дустыбыз Мулланур Вахитовның теләкләрен, васыятьләрен дә үтәү булачак дип белдерә. Шул ук вакытта К. Тинчурин бу мәкаләсе белән революционер-ленинчы М. Вахитовның бу өлкәдә башлаган эшләрен, аның эстетик карашларын саклап калып, аны халыкка белдереп, тагы бер игелекле хезмәт күрсәтә.

Яңа, совет театры төзү ул — яңа, революцион эчтәлекле спектакльләр кую дигән сүз. Бу мәсьәләне тирән аңлап, беренче татар совет театры коллективы, аның җитәкчесе К. Тинчурин, моңарчы уйналып килгән демократик рухтагы әсәрләр һәм М. Горькийның «Мещаннар», «Тормыш төбендә», Г. Коләхметовның «Яшь гомер», «Ике фикер» драмалары белән беррәттән Шиллер, Гейненың революцион романтизм белән сугарылган «Юлбасарлар», «Мәкер һәм мәхәббәт», «Әлмансур» пьесаларын, Шекспирның «Отелло» һәм «Гамлет» трагедияләрен сәхнәләштерә. К. Тинчурин заман темаларын чагылдырган әсәрләр язуны оештыру максаты белән, шул чорда актив эшләгән язучылар белән бәйләнешне көчәйтә. Нәтиҗәдә Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек үзләре революцион хәрәкәттә актив катнашкан язучылар, Ф. Бурнаш кебек талантлы яшьләр тарафыннан берничә әһәмиятле әсәр иҗат ителә. К. Тинчурин үзе «Йосыф белән Зөләйха», «Тутый кош», «Сакла, шартламасын» исемле заман темасына язылган комедияләр бирә. Яңа репертуар булдыру өчен конкурслар үткәрелә, планлы рәвештә классиканы тәрҗемә итү эше башлана.

К. Тинчуринның оештыру сәләте бик күп башлангычларның уңышлы чыгуына тәэсир итә, шуңа күрә аңа бу өлкәдә яңадан-яңа эшләр йөкләнә. 1920 елның язында Идел буе хәрби оешмалары Кызыл Армиядә сәнгать эшләрен күтәрү максаты белән Татар студиясе оештыра, аңа җитәкче итеп К. Тинчурин чакырыла (баштарак артист З. Солтанов та катнаша). К. Тинчурин тапшырылган эшне намус белән башкарып чыга, алты ай эчендә профессиональ сәхнәдә уйнарлык бер төркем талантлы яшьләр тәрбияли, шулардан «Габдулла Кариевкә хатирә» (башта ул «Шәрык йолдызы» дип атала) труппасы төзеп, Оренбург шәһәрендә урнашып эшли башлый. 1922 елда Татарстан хөкүмәте тарафыннан Тинчуринга яңа җаваплы эш тапшырыла: ул ил буенча таралган күренекле татар артистларын җыеп, Дәүләт татар труппасы оештырырга тиеш була. Татар сәхнә көчләренең составын яхшы белгән Тинчурин бу эшне дә уңышлы башкарып чыга — 34 кешедән торган, теләсә нинди катлаулы әсәрне сәхнәгә куярлык труппа төзи. Ул үзе шушы театрның баш режиссеры итеп куела. Хәзерге Татар дәүләт академия театрына әнә шулай нигез салына.

Шул шартларда К. Тинчурин язучы буларак та иҗатын дәвам итә. Ул театр сәнгатен күтәрү, яңа репертуар булдыру эшенә башка язучыларны чакыру, алар белән эшләү белән генә чикләнми, үзе дә бу өлкәдә активлык үрнәкләре күрсәтә. Бу мөһим мәсьәләне хәл итүдә, аңа юнәлеш бирүдә җәмәгатьчелек, матбугат та катнаша, бүгенге вакыйгаларны чагылдырган әсәрләр таләп итә, яңача яза торган драматурглар тәрбияләү мәсьәләләрен күтәрә: «Пролетариат бездән үзенең сәхнәсендә инкыйлаби тәрбия алырга, капитализм тудырган трагедияләрне күреп, халыкның ничек җәберләнгәнен аңларга тели, кызыл сәхнәнең кызыл Давыдов, Варламовларын көтә. Безгә революционный пьесалар, кызыл Г. Камаллар кирәк» («Көч», 1921, 21 февраль,

Әстерхан). Оренбург шәһәреннән яшь режиссер С. Вәлиев-Сульва «кызыл Камаллар»-га геройларны кайдан алырга, ниндиләрен сайларга кирәклеген күрсәтеп яза: «Социальный элементларны, пролетариат Гамлетларын табарга вакыт. Ә алар, пролетариат Гамлетлары, бик күп һәм аларны табу да авыр түгел. Әллә Мулланур Вахитов, Камил Якубов кебек революционный геройлар азмы? Безнең көннәрнең хезмәт фронты геройлары да аз түгел» («Юл», 1924, 29 май).

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, К. Тинчурин революциядән соңгы вакыйгаларны үз әсәрләрендә чагылдырган беренче язучылардан була. «Йосыф белән Зөләйха», «Тутый кош» комедияләре 1918 елда языла. К. Тинчуринның драматургик таланты аеруча комедия, сатира өлкәсендә ачыла. Әлеге ике комедиядән башлап совет чорында ул тагы «Сакла, шартламасын», «Казан сөлгесе», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Хикмәтле доклад», «Нәни абый», «Алар өчәү иде» кебек күбесе һаман да сәхнәдән төшми уйналып килә торган әсәрләр яза. Комедиограф буларак аның төп игътибары яңа тормышка аяк баскан хезмәт ияләренең юлына аркылы төшкән, аңа комачаулый торган кара көчләрне, дошман элементларны төрле дәрәҗәдәге бюрократлар, икейөзле саламторханнарны фаш итү, дусны дошманнан аерырга ярдәм итүгә юнәлгән. Бу чорда, әлеге бәндәләрнең совет властена каршы ачык һәм яшерен эшләре көчәйгән вакытта, К. Тинчурин әдәбият-сәнгатьнең мөһим бурычы барыннан да бигрәк әнә шуларны фаш итүдә дип саный иде. Дөрес, ул, мәсәлән, «Американ» комедиясендә заман герое студент Искәндәр образын иҗат итеп, уңай герой драматургиясе үрнәген дә күрсәтә алды. Әмма анда да барыбер фаш итү пафосы гаҗәеп көчле иде.

Матбугат К. Тинчурин әсәрләренең оста язылган булуларына, аеруча «Сакла, шартламасын» комедиясенең матур эшләнешенә, Тинчурин каләменең көннән-көн үткенрәк була баруына игътибар итә. «Бу комедия,— дип яза «Татарстан» газетасы үзенең 1923 елгы 24 май санында,— безнең комедияләр арасында иң көлкесе, шул ук вакытта иң җитдие дияргә мөмкин... Комедиядә бөтен вакчыллыгы, риякярлыгы (икейөзлелеге), хыянәтчеллеге, бөтен куркынычлыгы белән гаҗәеп хакыйкый (дөрес итеп) тасвир ителгән Шакирҗан бай» образы күпкырлы характер буларак тирән эшләнгән. Ш. Усманов әсәрнең идея эчтәлеген һәм әдәби эшләнешен бергә бәйләп карап болай яза: «Мөндәриҗәсе (эчтәлеге), төзелеше, типларның ачык чыгуы, хәрәкәтнең бер-берсенә оста бәйләнгән булуы аркасында, бу пролетариат сәхнәсе өчен муафыйк (яраклы) бер әсәрдер («Татарстан», 1923, 27 май).

К. Тинчурин комедия өлкәсендә туктаусыз эшли һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары яулый. 1923 елда язылган «Американ» комедиясе моңа мисал булып тора. Әсәрдә буржуазия һәм аның идеологлары бөтен интереслары байлык җыю белән чикләнгән, ватанчылык хисе булмаган космополитлар, рухи тормыштан мәхрүм булган кызганыч бәндәләр итеп сурәтләнде. Алар совет илендә яшәсәләр дә, рухлары белән күптән «Америка»га күчеп киткән бушкуыклар булып чыгалар. Тарихи документларны алар кулыннан коткару өчен үзен Америкадан килгән Булат Сон исемле галим дип атап, болар арасына кергән совет студенты Искәндәр алдында алар әнә шундый сыйфатлары белән фаш булалар. Язылуына 50—60 еллар узганнан соң сәхнәгә куелгач та, бу әсәрдә әлеге теманың актуаль һәм көчле яңгыравы билгеләп үтелде, илдән-илгә, бер караштан икенче карашка җиңел генә күчеп йөрүчеләр психологиясен тирән ачкан әсәр дип кабул ителде. «Американ» 1970 елда Академия театрының Мәскәүдәге гастрольләре вакытында күрсәтелеп, үзәк матбугатның игътибарын җәлеп итте. Мәсәлән, «Правда» газетасы әсәр турында болай дип язды: «Сурәтләү чараларының төгәллеге ягыннан «Американ» спектакле аерылып тора. К. Тинчуринның сатирик комедиясендә вакыйгалар 20 елларда бара, әсәр мещанлык, милләтчелек, буржуаз көнбатыш алдында баш ию күренешләрен фаш итә... Анда милли сәнгать традицияләрен баету юллары ачык билгеләнгән. Пьеса бүгенге тамашачыга идеясенең ачыклыгы, заманча сурәтләү чараларына бай булуы белән якын» («Правда», 1970, 1 август). Танылган театр белгече профессор А. Анастасьев исә үзенең «На 45 языках» дигән китабында «Американ» пьесасы күпмилләтле барлык совет театрлары өчен дә кызыксынырлык әсәр» дип язды.

Язучының бу әсәрендә дә замандашлары реаль тормыш геройларын күрәләр иде. Мәсәлән, «Кызыл Татарстан» газетасында Тинчурин «әсәрләрендәге вакыйгаларның (интригаларның) төзелеше белән һәм сюжетның Казанда шаулаганрак хәлләрдән алынуы белән халыкның һушына китәләр» дип язылды («Кызыл Татарстан», 1926, 24 апрель). Бу фактны икенче автор да раслый. «Американ»да Муса Мәхмүди, Дилбәр, Габдуллаҗан шикелле исемнәр — болар нәкъ реальный типлар. Бездә язучылар гадәттә боларның индивидуумнарын (прототипларын дип аңлашыла.— Б. Г.) эзләүне ялгыш диләр. Ләкин «Американ»ны язучы шулардан бик нык файдаланган. Тик уйнаучылар гына моңар игътибар итеп бетерә алмаганнар — аерым типларны өйрәнүдә Кариевча тырыша алмаганнар» («Кызыл Татарстан», 1925, 5 январь).

Күп еллар буе күзәтеп, уйлап килнгән бу тема «Җилкәнсезләр» исемле социаль сатира жанрында да тирән чагылыш таба. Бу әсәрендә К. Тинчурин көлке типлар һәм конфликтлар төзү остасы буларак ачыла. Батырхан да, Мисбах та, Нуретдин һәм Дилбәр дә күпкырлы характер буларак сурәтләнә, шуның аркасында алар зур ышандыру көченә ия. Аларның һәркайсы бер үк вакытта икейөзле, дә, саран да, куркак та, әмма аларның һәрберсендә бу сыйфатлар үзенчә күренә.

Мәгълүм булганча, «Җилкәнсезләр» комедиясе финалы сугышлар бетеп, совет властеның ныгып, хуҗалыкның аякка басып килгән чорында тәмам була, төп геройлардан Батырхан, Мисбах, Давыт, Дилбәр яңа шартларга җайлашып, дошманлыгын дәвам итә, бер төркеме советка каршы яшерен көрәшкә хәзерләнә. Ләкин болар тормыш аренасыннан югалса да, аларның иң әшәке сыйфатларын үзләштереп алган, яңа сорыкортлар, паразитлар төркеме туып килә икән. Язучының «Хикмәтле доклад» комедиясендә әнә шул совет оешмаларына сырыша башлаган әрәмтамакларның чын йөзләре ачыла. Әсәрдә башкалар язып биргән докладын югалтып, мәсхәрәгә калган бюрократ Мортаза образы әле хәзер дә шундый алым белән түрә булып йөрүчеләрне хәтергә төшереп тора.

Татар совет драматургиясе, шул исәптән К. Тинчурин иҗаты да, ике тематик юнәлештә үсеп китә. Аның берсе заман темасына язылган әсәрләрдән гыйбарәт булса, икенчесе татар халкының үткән тормышын, революциягә килү юлларын сурәтләгән әсәрләрдән тора. Бу соңгысы үзенчәлекле бер жанр — тарихи-революцион драматургия булып формалаша.

К. Тинчурин, бу темага «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» «Зәңгәр шәл», «Ил» кебек күренекле әсәрләр яза һәм татар әдәбиятында, театрында зур урын алган әлеге жанрга нигез сала.

Тарихи-революцион драматургиянең үзенчәлекләреннән берсе киң күләмдә халык музыкасын, уенын, биюен, гореф-гадәтләрен сәхнәгә күтәрүдән гыйбарәт булды, ә бу исә әлеге әсәрләрнең төп геройлары халык вәкилләре булу белән бәйләнгән иде. Гади хезмәт кешеләрен спектакльләренең герое итеп алып, аларның дөньяга карашын, көрәшен, милли характерын ачып, татар совет театры үзенең мөһим идея-эстетик позицияләрен билгеләде, аңа халыкчан театр булып үсәргә, тамашачылар массасына якынаерга ярдәм итте.

К. Тинчуринның халык иҗатына мөнәсәбәте аның әсәрләрендә генә түгел, теоретик чыгышларында да киң чагыла. Мәсәлән, ул музыканы театрга очраклы гына килеп кергән бер нәрсә дип түгел, ә сәхнә героен сурәтләүдә әһәмиятле, көчле корал дип саный. «Соңгы елларда,— дип язды ул,— безнең театрда музыкалы әсәрләр күренә башлады. Моны санаигы нәфисә тарихыннан ерак торган кешеләр татар театрына бәла туды дип аңладылар. Ләкин без татар сәхнәсендә музыкалы әсәрләрнең күренүен татар театрының эзләнүдә алга баруы дип аңлыйбыз... Яңа театр баганаларының берсе музыка булуын кем инкяр итә алыр?» («Татарстан», 1924, 21 апрель). Театр җитәкчесе буларак, ул шушы юнәлешнең зур киләчәген сизенеп, аңа киң юл ачарга кирәк дип саный. Шул максат белән төрле оештыру чаралары үткәрә. Халык иҗатын профессиональ дәрәҗәдә файдалануны тәэмин итәр өчен, ул музыкаль җитәкче вазифасы булдыра һәм бу урынга Салих Сәйдәшевне чакыра. Шул эш өстендә бөек Сәйдәшнең чиксез зур таланты ачыла, ул спектакльләргә музыка яза башлый, ул музыка, театр залларыннан чыгып, бөтен илгә яңгырый.

К. Тинчуринның әлеге сериягә караган әсәрләре арасында үз вакытында ук зур дан казанганы «Зәңгәр шәл» була. Моның сәбәбен Г. Кутуй болай аңлата: «Зәңгәр шәл»нең 11 мәртәбә куелуын кайбер өстән караучы иптәшләр рекламадан күрәләр. Бу караш дөрес караш түгел. «Зәңгәр шәл»нең быелгы сезонда шундый триумф казануы биш көчнең бергә берләшүеннән, бер йөрәк булып тибүеннән килде. Бу көчләр: 1 — драматург, 2 — режиссер, 3 — композитор, 4 — уйнаучылар һәм рәссам, 5 — тамашачы үзе» («Тамашачы», 1929, 5 сан). Чыннан да бит: бүгенге көнгә кадәр бу әсәрнең шундый зур уңыш казануының сәбәпләрен, серләрен ачу омтылышы дәвам итә. Бәлки моңа Г. Кутуй күзәтүләре дә ярдәм итәр. Ничек кенә булмасын, аның сәбәбен, әлбәттә, пьесаның үзеннән эзләргә кирәк. Әсәрдә язмышлары, бәхетләре куркыныч астына куелган сөйкемле геройлар, аларның үзенчәлекле көрәшләре, кызыклы, мавыктыргыч сюжеты Ишан, Мәйсәрә, Булат кебек калку характерлар, романтик пафос белән сугарылган мәхәббәт күренешләре, шуларга бик табигый бәйләнгән музыка — болар барысы бербөтен булып тамашачы каршына чыга.

«Зәңгәр шәл»дән алда язылган «Казан сөлгесе» һәм «Сүнгән йолдызлар» әсәрләрендә әлеге алымнар, принциплар сынау рәвешендә кулланылып, аларның тормышчан икәнлеген, димәк, бу юнәлештә тагын да кыюрак эш итәргә мөмкин икәнлеген күрсәткәннәр иде. Әлеге әсәрләрнең бүген дә сәхнәдә булуы моңа өстәмә дәлил булып тора. Шул ук вакытта бу әсәрләрдә хезмәт кешеләренең изелеп яшәвенә басым ясалып та, алар арасында үсә барган каршылык күренешләре ул кадәр ачык чагылмый

иде. «Ил» драмасында язучы менә шул хәлләргә төп игътибарын юнәлтә. Драматургның башка әсәрләре кебек, «Ил» драмасы да тамашачы тарафыннан җылы каршылана. Бу спектакль уңае белән язган мәкаләсен Г. Кутуй болай тәмамлый: «К. Тинчуринга хәзерге, бүгенге авылны тасвир итүгә күчәргә кирәк. Безнең уебызча, ул монда да яңа «Зәңгәр шәл»ләр бирер» («Кызыл Татарстан», 1929, 2 ноябрь). Шулай итеп, театр сөючеләр, җәмәгатьчелек К. Тинчуринның яңадан-яңа әсәрләр язуын көтеп ала башлый.

Бөтен иҗаты, эшчәнлеге белән заман проблемалары белән нык бәйләнгән. Тинчурин тормыш таләбен үзе бик зирәк сизенә, үз алдына яңадан-яңа бурычлар куя. Аның күңеле совет авылында барган зур үзгәрешләргә тартыла. Коллективлашу хәрәкәтен, аның үзенчәлекләрен һәм нәтиҗәләрен тирәнтен өйрәнер өчен ул колхозларга чыга. Озак тикшерүләр, уйланулар нәтиҗәсендә, ниһаять, «Кандыр буе» драмасы барлыкка килә. Бу әсәр татар драматургиясендә колхозлашу хәрәкәтен тирән күрсәткән беренче сәхнә әсәре була. Драматургның икенче зур казанышы коммунист Акбирдин образын иҗат итүе белән бәйләнгән иде. Ул шул көннәрнең героен сәхнәгә күтәрә, бөтен көчен, акылын биреп яңаны төзи торган, халыкны чын-чыннан яктылыкка алып бара һәм яңача яшәргә өйрәтә торган чын җитәкче образын иҗат итә.

Бу елларда К. Тинчурин яңа кеше тәрбияләүдә хезмәтнең роле, яңа мөнәсәбәтләр тууы турында күп уйлана, шул темага әсәрләр яза. Драматург эшчеләр темасын сәхнәгә күтәрү өчен башкаларга ярдәмгә килә. Шулай итеп Р. Ишморат белән «Тургай», Ф. Сәйфи-Казанлы белән «Корыч орчык» драмалары языла. К. Нәҗмигә колхоз тормышыннан алынган «Булат бабай семьясы» пьесасын языша.

«Алар өчәү иде» исемле комедиядә К. Тинчурин яңа конфликтларга мөрәҗәгать итеп, кешеләр аңында калган мин-минлек, башкаларның уңышларыннан көнләшү кебек кимчелекләрдән көлә. Шул ук вакытта ул совет шартларында хезмәт ияләре арасыннан үсеп чыккан яңа халык интеллигенциясенең күркәм сыйфатларын, матур эшләрен чагылдыруны да бурыч итеп куя.

К. Тинчурин иҗаты татар совет театрының социалистик реализм принципларын үзләштерү юлындагы эзләнүләрен һәм табышларын чагылдырып, аның үсешенә, ныгуына тирән йогынты ясады. Бу мөһим эшкә К. Тинчурин үзенең күпсанлы теоретик чыгышлары белән катнашты (шушы мәсьәләгә багышланган җитмешкә якын мәкалә язып чыкты). Театр җитәкчесе сыйфатында аның хәзерге татар совет театрын юлга салучы буларак хезмәтләре чиксез зур.

**Риза Ишморат**

# ДУСТЫМ ҺӘМ ОСТАЗЫМНЫ САГЫНЫП...

Яхшы ук озынга сузылган гомерем юлында очрап бергә дустана яшәгән, эшләгән, күңелемдә якты эз калдырган һәм иҗат үсешемә ярдәм иткән дусларым, остазларым күп кенә булды. Алар — Ә. Фәйзи, Г. Кутуй, Х. Туфан, Һ. Такташ, М. Җәлил, остазларым Шәриф Сүнчәләй, Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан һәм күп кенә хөрмәтле кешеләр. Әмма үзенең гаҗәп бер мөлаем, ягымлы, ачык күңелле, намуслы, тырыш, эшчән, нинди генә кайгы-хәсрәтне, дәһшәтле хәлләрне дә батырларча каршы алган, халык бәхете, безнең уртак идеалларыбыз өчен көрәшкә багышлаган талантлы әдип, драматург, режиссер, артист һәм педагог буларак күңелемдә иң тирән эз калдырган кеше Кәрим Тинчурин булды.

Габдулла Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Галиәсгар Камаллар белән берлектә, ул татар театрына нигез салучы һәм аны алга таба үстерүчеләрнең берсе һәм иң күренеклесе булды.

Кәрим Тинчурин татар театры сәхнәсенә даими рәвештә заман рухы белән сугарылган әсәрләр язучы талантлы драматург иде. Игътибар итегез: аның менә бу түбәндә санала торган әсәрләрнең барысы да заман таләбе белән дөньяга килгән пьесалар: «Беренче чәчәкләр» (1913), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Американ» (1924), «Җилкәнсезләр» (1925), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930), «Алар өчәү иде» (1935). Алай гына да түгел. Татар дәүләт академия театры сәхнәсе ихтыяҗына нәкъ заманча җавап бирү өчен ул — атаклы драматургия остасы, башка авторларга ярдәмләшеп, аларның соавторы булып та, драма әсәрләре язды. Шулай итеп 1930 елда Фа-

тих Сэйфи-Казанлы белән бергә язган «Корыч орчык», 1931 елны Риза Ишморат белән бергә язган «Тургай», 1933 елны Кави Нәҗми белән бергә язган «Булат бабай семьясы» пьесалары һәм шулар нигезендә Татар дәүләт академия театры спектакльләре мәйданга килде.

Тарихчылар колагына шуны әйтеп үтәргә кирәк: «бүген мөстәкыйль театр буларак яшәп килә торган Татар дәүләт драма һәм комедия театры 1932—33 ел сезонында Татар дәүләт академия театрында колхозларга хезмәт күрсәтүче труппа буларак барлыкка килде һәм «Булат бабай семьясы» аның беренче репертуарларыннан берсе булды.

* * *

Күп кенә вакытларда мин үземнең драматургия һәм режиссерлык эшемдә (1930—1940 елларда җиде ел Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, өч ел режиссер һәм репертуар эшләре җитәкчесе) нык ярдәме тигән Кәрим Тинчуринны сагынып искә алам. Ул минем иң хөрмәт иткән якын дустым да, киңәшчем дә, остазым да иде.

1926 елны Театр техникумының режиссерлар бүлеген уңышлы тәмамлап Татар дәүләт академия театрына режиссер-лаборант сыйфатында хезмәткә кергәч, бер сезон эчендә режиссер буларак мөстәкыйль рәвештә дүрт спектакль сәхнәләштергән булсам, (аларның берсе Ф. Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясе, икенчесе Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе иде) болар өчен мин, бу җаваплы иҗатларны миңа — яшь режиссерга ышанып тапшырганы өчен, Кәрим абый Тинчуринга бурычлымын. Хәтта 1927—1930 елларда Ленинградка барып Сәнгать тарихы институты хозурындагы Дәүләт театры сәнгать курсларында (Высшие государственные курсы искусствоведения) өч ел укып кайтуга киңәш бирүчеләрнең дә берсе ул булды.

Татар дәүләт академия театрында эшләгән чорда К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» (1934), «Алар өчәү иде» драмаларын (1936) режиссер буларак сәхнәгә куйганда аның белән иҗади бәйләнештә үткән сәгатьләр һәм көннәрне иң күңелле һәм бәхетле көннәр итеп искә алам. Аеруча әсәрне икәүдән-икәү генә укып, аның әйтергә теләгән фикерен аңлау, төшенү һәм характерларның үзенчәлекле сыйфатларын җентекләү һ. б. Кайсы образны нинди артист башкаруы турында үзе артист та, режиссер да булган авторның киңәше — сәхнәгә куючы режиссер өчен иң кадерлесе, билгеле. Үз әсәре турында һәр авторның нигезле төп фикере бар. Әмма тирән акыллы Тинчурин һәрбер очракта үз фикерен генә нигез фикер итеп алып: «Мин шулай язганмын икән, нәкъ шулай булып калырга тиеш»,— дип тормый, режиссерны тыңлый һәм әсәрне төзәтә, ачыклый, тулыландыра, кирәксә, сызып ташлый да белә иде.

Миңа, режиссер буларак, Кәрим Тинчуринның ике әсәрен — «Беренче чәчәкләр» һәм 1935—36 елны «Алар өчәү иде» драмаларын — мөстәкыйль рәвештә сәхнәләштерергә һәм аның белән икәү бергә иҗат иткән «Тургай» дип исемләнгән пьесабызны икәүләшеп бергә үк режиссер буларак сәхнәләштерергә насыйп булды. Сталинград трактор заводын төзүче эшчеләр һәм инженер-техник хезмәткәрләре тормышыннан нәкъ үз вакытында (1931) әсәр язу һәм, спектакль иҗат итеп, аны тамашачыга җиткерү икебез өчен дә зур җаваплылык, шуның белән бергә зур бәхет иде.

Ике-өч айдан артык вакытка сузылган бу иҗади хезмәт безне якыннан дуслаштырды, бер-беребезне тирәнрәк аңларга ярдәм итте. Гомер юлларымны кичкәндә насыйп булган бу гүзәл көннәр һәм сәгатьләрне әле дә сагынып искә алам.

«Беренче чәчәкләр» пьесасы һәм спектакле турында берничә сүз. 1934—35 еллар сезонында «Беренче чәчәкләр» драмасын сәхнәләштерүне планга керттек. Минем тәкъдим белән кертелгән бу пьесаны, режиссер буларак, сәхнәләштерү үземә үк тапшырылды. Бу әсәрне мин 1917—1918 елларда Уфада «Нур» труппасы куелышында сәхнәдә күреп нык яраткан һәм дулкынланган идем. Ләкин күп еллар үтеп инде үзем сәхнәләштерү чарасын күрә башлагач, 1913 елны язылган драма бүгенге көн күзлегеннән караганда күп кенә яктан мине канәгатьләндермәде. Бу турыда Кәрим абый Тинчурин белән бик озак кына әсәрнең төп идеясе, художество эчтәлеге турында принципиаль һәм шул ук вакыт дустанә әңгәмә барды. Бу пьесада, зур осталык белән сурәтләнгән гаять үзенчәлекле типик характерлар арасында, шул еллардан алда ук инде, дөньяга чыгып, татар яшьләре, шәкертләре, гомумән киң катлам масса арасында яшерен рәвештә эш алып бара торган — Х. Ямашев, Г. Коләхметов, Г. Сәйфетдинов, Ш. Сүнчәләй, М. Вахитов кебек революцион позициядә торган бер генә образның да булмавы, алдынгырак фикерле образларның да артык дәрәҗәдә пессимизмга бирелгән булуы миңа ошап җитмәде. Бигрәк тә иң алдынгы фикер иясе итеп гәүдәләнгән герой иске мәдрәсәләрдәге пишкадәм шәкертләр арасында байлар тарелкасы ялап, үлем-китем исәбенә яшәгән кеше — Сукыр суфи булуы ошамады миңа. Дөрес, Кәрим абый минем белән барган әңгәмәдә Суфиның шулай уңай образ итеп бирелүенең төп сәбәбе,

халкыбызның киләчәге турында акыллырак фикерләрне сәхнәдән әйтүче кешенең сукыр суфи булуы патша цензурасын үтү өчен кирәк иде диде. Чөнки сукырга суд юк дигән мәкаль дә бар бит әле дип, төпле генә сүз әйтеп, мине бу турыда уйларга да мәҗбүр итте. Һәм мин, билгеле, Суфи образын күп кенә үзгәртсәм дә, шундый үткен һәм фәлсәфи сүзләренә режиссер буларак кагылмадым. Ниһаять, спектакль дөньяга чыкты һәм тамашачылар тарафыннан яхшы бәя алды. Минем өчен иң кадерлесе Кәрим Тинчуринның спектакльне хуплап, яратып кабул итүе булды. Ул бу вариантны хуплап 1935 елны матбугатка чыгарды. Үзе исән чакта Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган бу җыентыктагы җиде пьесаның берсе, иң беренчесе,— «Беренче чәчәкләр». Аннан — «Сакла, шартламасын», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе» пьесалары.

Кәрим абый Тинчурин белән бергә үткән көннәрнең иң истәлеклесе, иң кадерлесе айдан артык гомер алар квартирында икәүдән икәү генә калып (Заһидә ханымны «кунакка» җибәреп, билгеле), бергә-бергә сөйләшеп, киңәшеп, уйлашып, аерым бер план-сценарий схемасы төзегәч, икебез ике бүлмәдә утырып язу, аннан аны бергәләп тикшерү һәм төзәтмәләр кертү булды. Ай бу бик кызыклы да, җаваплы да, серле дә булган гаҗәеп бер сихри минутлар!.. Кайвакытларда онытылып, шашынып иҗат газабы яки ләззәте кичергән көннәр, сәгатьләр... Юк! Аларның нинди кадерле, серле минутлар икәнен язып кына аңлатып булмый. Мондый хәлләрне бары тик иҗат газабы һәм шатлыгы белән шашынган шагыйрьләр, композитор һәм артистлар гына аңласа аңлар, мөгаен.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:** К. Тинчурин иҗаты белән танышу, аның драмаларындагы рольләрне башкару Сезнең иҗат биографиягездә нинди урын алып тора?

**Вера Минкина,** РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы.

Театрда мин бик яшьли эшли башладым. Авылда укыганда ук сәхнәгә булган мәхәббәтем мине 1934 елны Казанга Театр училищесына алып килде. Аны 1938 елны уңышлы гына тәмамлагач, үндүрт ел Республика күчмә театрында (хәзерге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры) беренче пландагы рольләрне башкардым.

1952 елдан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшлим. Сәхнәдә уйнаган рольләрем арасында татар драматургларының да, рус һәм дөнья классикларының да әсәрләре бар.

Татар совет драматургиясе классигы Кәрим Тинчуринның әсәрләре Татар дәүләт академия театры репертуарыннан төшми әлегә кадәр уйналып килалар. Алар минем иҗатымда кызыклы гына урын алып тора. Кызыклы дигәнем шул: еллар үтә торды, еллар белән, табигый ки, мин иҗит иткән рольләр галереясе дә үсеш, үзгәреш кичерде. Әйтик, «Казан сөлгесе» пьесасының беренче куелышында мин мәзиннең олы кызы Сәҗидәне уйнаган булсам, бүгенге көннәрдә исә Шәмси әби ролен башкарам. «Зәңгәр шәл» драмасында элек малай ролен уйнасам, хәзер инде ишаннан печән өшкертергә килүче карчык ролен башкарам. Шуны да әйтеп үтәсем килә: «Зәңгәр шәл»дәге малай минем иҗат биографиямдә иң беренче башкарылган малай роле. Бик яратып уйнаганга күрәдер инде, мин ул рольне хәзер дә бик сагынып искә алам. «Назлы кияү» комедиясендә дә бик үзенчәлекле яраткан яучы карчыгым бар иде.

Менә күп еллар буе инде зур уңышлар белән сәхнәдән төшми уйналып килгән «Сүнгән йолдызлар»да да озак еллар, һич ялыкмый, Гөлнур исемле ятимә карчыкны уйнап килдем. ...Кәрим Тинчурин. Нинди хәтәр җилләрдә дә сүнмәс утлар кабыза алган бу сәхнә каһарманы, әлбәттә, минем иҗат биографиямне дә читләтеп үтмәде. Алай гына да түгел, иҗат юлымда Кәрим ага Тинчурин мәктәбе үзгә, аерым роль уйнап килгәнен әйтер идем.

Кәрим Тинчурин әсәрләрендәге образларны барлык артистларыбыз да яратып башкаралар. Режиссерлар да Кәрим аганың әсәрләрен кызыксынып, яратып сәхнәләштераләр. Бу барыбыз өчен дә зур шатлык.

Кәрим ага Тинчуринның әсәрләренда катнашуымны үзем өчен зур бәхет дип саныйм.

**Венера Ганиева**. Татар дәүләт опера һәм балет театры артисткасы.

Тормыш көтелмәгән борылышлар белән тулы. Әйтик, мине — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасын бер дә бер көнне, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына атаклы «Зәңгәр шәл»дә катнашырга чакырырлар дип кем уйлаган...




*«Зәңгәр шәл» спектакле афишасы (1930 ел.)*

Кәрим Тинчурин һәм Салих Сәйдәшевләрнең уртак иҗат җимеше буларак барлыкка килгән гүзәл Мәйсәрә образын башкару һәр артисткага да буй җитмәслек хыял булып тоелганын яхшы беләм идем мин. Өстәвенә, миңа бу катлаулы рольне 80 еллык бай традицияләре булган театрның тәҗрибәле артистлары белән берлектә тудыру сорала: шулай булгач, Мәйсәрәне уйнау турындагы уйның булуы да мөмкин түгел... Әмма чынбарлык хыялга караганда да кыюрак булып чыкты.

Мин үзем Казанда туып үскән кыз. Театр җанлы әти-әниләремә һәм дә мине укыткан Г. Ибраһимов исемендәге 89 нчы татар мәктәбе укытучыларына рәхмәт: алар мине кечкенәдән татар театры спектакльләренә йөрткәннәр. Туган телебезгә, туган халкыбызның саф һәм самими гореф-гадәтләренә, олы культурасына мин шул спектакльләр аша килеп кергәнмен. Шунда халкыбызның бөек тарихына мәхәббәт бөреләнгән. Без караган күптөрле спектакльләр арасында «Зәңгәр шәл» исемле мелодрама минем сабый йөрәгемә аеруча нык урнашып калган. Гаҗәп, әмма чын дөресе шулай. Театрда «Зәңгәр шәл»гә репетицияләр барган чакта, шул бала чакта каралган «Зәңгәр шәл» миңа үзенчә ярдәм итте. Хәтеремдә сакланган җанлы тамаша залы, сәхнәдәге зур артистларның уены гел күз алдымда булып, иҗат фантазиямне дулкынландырды. Әлбәттә, мин Мәйсәрә образы белән саташып йөргән көннәремдә әсәрне сәхнәгә куючы Марсель Сәлимҗанов ярдәмендә бу рольне беренче булып башкарган артисткалар Галия Кайбицкая һәм Оркыя Күшловскаялар тәҗрибәсен дә өйрәндем. Шулай итеп, Роза Хәйретдинова һәм Флера Хәмитоваларның мин күреп белгән, мине гашыйк иткән Мәйсәрәләре элегрәк табылган ачышлар белән дә тулыландырылды. Һәр яңа куелыш матур традицияләрне үзләштерү белән берлектә, шул традиция эченнән шытып чыккан яңа куелышның яңа бизәкләр белән бизәлгән булуын да таләп итә.

Кыскасы, мин — опера солисткасы драма театрында искиткеч мәктәп үттем. Бу минем иҗат тормышымда, әлбәттә, зур этәргеч булачак. Инде хәзердән үк драма театрында уйнап кайтып опера сәхнәсендә җырларга чыккач, драма сәхнәсендә файдаланган алымнарны да истә тотып эш итәм. Нәтиҗәдә мин башкарган партияләр үзенчәлекле төсмерләр белән тулылана бара-лар. Әйе, Кәрим Тинчуринның иҗат традицияләренә тугры артистлар белән очрашу, Мәйсәрәне уйнау минем тормышымда гаять зур вакыйгага әверелде. Инде язмыштан тагын ни теләр идең, дисәләр: кабат шундый очрашуны, дип җавап бирер идем. Җырдагыча, «авыр булса булсын, тик соңгысы гына булмасын».

**Равил Шәрәфиев**, РСФСРның атказанган, Татарстан АССРның халык артисты.

Кәрим Тинчуринның нинди генә әсәрен алсаң да, зур талант иясе икәнлеге ярылып ята. Аның геройлары чын мәгънәсендә образлар булуы белән аерылып тора. Һәрберсенең үз характеры, үзенең фикер йөреше, үз теле, хәтта үзенең хәрәкәте, пластикасы күз алдына килә. Мин бигрәк тә аның тел-сөйләм характерына басым ясап әйтергә телим. Хәзер дә оста гына язылган драма әсәрләре бар, характерлары да күренә сыман, ләкин персонажлар барысы да диярлек бер тел белән сөйләшәләр. (Мин, әлбәттә, тере классигыбыз Нәкый ага Исәнбәтне искә алмыйм.) Телебез бертөрле, шактый корыга әйләнгән. Өстәвенә телнең нечкәлекләрен бөтенләй диярлек белмәгән артистлар, бигрәк тә артисткалар күбәйгән чорда, драматургның тел характеристи-

касы бигрәк тә, заманча әйтсәк, дефицит булып бара.

Инде үземнең иҗатымда К. Тинчурин нинди роль тотуына килгәндә эш болай тора. Мин К. Тинчурин иҗаты белән беренче тапкыр Мәскәү театр училищесында укыган чорда, театрыбызның башкалабызда үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күрсәткән «Зәңгәр шәл» спектаклен карап таныштым. (Безгә анда массовкада да катнашырга туры килде). Шундый тантаналы көннәрдә күрсәтелгәнгәдер дә инде, спектакль никдидер зур бәйрәм булып кабул ителде. Икенче елны, ягъни 1958 елда, театрыбыз Мәскәүгә «Казан сөлгесе»н китерде. Ул спектакльдә дә катнашырга туры килде. Спектакль үзенең нинди самимилеге, сафлыгы белән хәтергә сеңеп калган.

Ниһаять аның, «Американ» дигән сатирик комедиясендә уйнау миңа бер яктан зур иҗат шатлыгы бирсә, икенче яктан артист өчен бик зарур булган беренче популярлык китерде дисәм дә, ялгыш булмас. Мине «Американ» дип йөри, хәтта эндәшә башладылар. Аннан соң мин аның «Назлы кияү»ендә, «Зәңгәр шәл»дә Шәйхи бабай белән Галәвиен, «Казан сөлгесе»ндә Хәзрәтен уйнадым.

Заманында К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» әсәре буенча режиссер Ширияздан ага Сарымсаков куйган спектакль дә хәтердә бик нык уелып калган. Анда уйнаган Х. Әбҗәлилов, Х. Сәлимҗанов, Г. Шамуков, А. Хәйруллина, Ф. Колбарисов, Ш. Әсфәндиярова, И. Гафуров һ. б. артистларның көчле ансамбле бик нык тәэсир иткән иде. Әгәр дә ул пьеса, яңадан сәхнәгә куелып, анда уйнарга насыйп булса, мин тагын да бәхетле булыр идем, чөнки Гражданнар сугышы, НЭП чорын чагылдырган зур полотнолы бик камил әсәр дип саныйм мин аны.

Тагын шул: әйтик, безгә автор яңа пьеса укып, аны тикшергәндә, әсәрнең кыйммәтен бәяләгәндә, минем бер критерием бар — (хәер, ул күп артистлар өчен шулайдыр) уйныйсым киләме, юкмы минем бу әсәрдә. Килсә — ул минем өчен әйбәт, килмәсә — начар пьеса.

Ә К. Тинчурин әсәрләрендә минем уйныйсым килә! Мәсәлән, шул ук «Американ» комедиясендә генә дә мин барлык ир рольләрен уйнап чыгар идем. Чөнки аларның һәркайсы бик тә үзенчәлекле, бик тә кызыклы, колоритлы типлар.

**Хәлим Җәлалов,** Татарстан АССРның атказанган артисты.

К. Тинчурин пьесалары буенча куелган спектакльләрдә катнашуны мин һәрвакыт үзем өчен бәхет дип саныйм. Әгәр аның берәр пьесасында роль бирелсә, мин К. Тинчуринның бөтен иҗатын яңабаштан карап чыгарга тырышам. Һәм укыган саен үзем өчен нindидер яңалык тапкан шикелле булам. Шул ук вакытта, аның әсәрләрендәге нинди генә образ өстендә эшләсәң дә, дулкынлану хисе кичерми мөмкин түгел. Һәм миңа шул роль сиңа тапшырылгач, әлбәттә, дулкынлану хисенә җаваплылык хисе дә өстәлә.


К. Тинчурин — гаҗәеп дәрәҗәдә популяр шәхес. Аның әсәрләрен тамашачы дистәләрчә еллар буе яратып карый. Һәм бу спектакльләрдә катнашу артист өчен актерлык осталыгын үстерүдә бер мәктәп булып тора. К. Тинчурин сәхнә теле, татар халкының гореф-гадәтләрен, уен-җырларын һәм аның үзенчәлекләрен ифрат нечкә тойган. Телнең нечкәлекләрен белмичә торып, тулы канлы образ тудыру мөмкин түгелдер дип уйлыйм. К. Тинчурин геройларының сөйләм теле шул кадәр халыкчан, гади — әйтерсең лә алар сәхнәдән торып түгел, нәкъ менә тормышта сөйләшкән кебек сөйләшәләр. «Белмисез ат урлауның тәмен!» кебек гыйбарәләр безнең телебезгә бик органик рәвештә кереп киткәннәр.

1970 елда безнең театр сәхнәсендә «Зәңгәр шәл» куелды. Бу спектакльдә миңа беренче пәрдәдә авыл егете Нурыйны, ә урман картинасында ялган акчалар ясаучы мошенник Тимушны уйнарга туры килде, ә 1971 елда «Сүнгән йолдызлар»да Ибраһим ролен тапшырдылар. Менә уналты ел инде спектакль сәхнәдә зур уңыш белән бара. Биш йөздән артык уйналды. Кайбер рольләрдә артистлар да алмашынды, ә спектакль бара... Ибраһим роле зур түгел, эпизодик роль генә... Ул каз өмәсе күренешендә генә катнаша... Бүгенгә кадәр шушы ролемне яратып уйныйм. Җырбиюгә, уен-көлкегә бай бу сәхнәдә авыл егетләренең җор телләре дә, чиста хисләре дә, ташып торган гайрәтләре дә ачык чагыла.

1975 елда «Назлы кияү» комедиясендә Төркстаннан өйләнергә кайткан байбәтчә Рәшит ролен уйнарга туры килде. Акыл ягыннан да ерак китмәгән, үзсүзле бу егетнең бай икәнен белгәч, шәһәрнең төрле «шома» кешеләре аны алдап-юмалап, кесә ягын шактый такырайтып, бер азгын кызны бөдәп озатып җибәрәләр.

1981 елда «Казан сөлгесе»ндә Салих шәкерт, быелгы сезонда «Зәңгәр шәл»дә чуваш Пәтрәйне уйнадым.

Кыскасы, киләчәктә дә театр сәхнәсендә К. Тинчурин әсәрләре еш-рак куелсын, һәм шул спектакльләрдә катнашу миңа да насыйп булсын иде, дип теләк телисем килә.



**Җәүдәт Фәйзи туган йорт**

Ивановлар тыкрыгы, 22 йорт.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме.*

# ОРЕНБУРГНЫҢ МОҢЛЫ ЕГЕТЕ

Һәр олы елга челтер-челтер аккан нәни генә кизләү-чишмәләрдән башлана. Җир-ана куеныннан тыйнак кына типкән йөзләгән-меңләгән чишмәләр бергә кушылып, Идел кебек мәһабәт елгага әвереләләр. Культурабыз тарихына күз ташласак та, шуңа охшаш хәл күрәбез: кечкенә генә елгачыклар, ерганаклар янына сыенган йөзәрләгән авылларда дөньяга килгән егет-кызлар әдәбият-сәнгатебезнең гүзәл сәхифәләрен язганнар. Бу яктан караганда Оренбург туфрагы аеруча бәрәкәтле булган. Халкыбызның рухи дөньясында тирән эз калдырган шәхесләр, вакыйгалар белән бәйле урамнарга, тыкрыкларга гаять бай бу шәһәр.

Менә Трофимов тыкрыгы. Бирелә мәшһүр Багъбостан мәктәбе эшләгән. Әнә Соленый тыкрыгы. Анда Хөсәен Ямашевлар татар телендә беренче большевистик «Урал»ны чыгарганнар. Ивановлар тыкрыгы исә культурабызның ике зур әһеле исеме белән бәйле. Монда күренекле язучы һәм публицистыбыз Шакир Мөхәммәдев яшәгән. Алардан берничә йорт аша гына торган Харис ага гаиләсендә 1910 елның 4 январенда дөньяга килгән балага Җәүдәт исеме куялар. Соңыннан музыка сәнгатебез күгендә якты йолдыз булып балкыячак Җәүдәт Фәйзи беренче булып әнә шул тыкрыкның бәбкә үләннәренә аяк баскан.

Язмыш бабай бәләкәй Җәүдәтнең композитор булачагын әйтерсең алдан ук белеп торган. Үз гомерендә беренче тапкыр фортепьяноны ул шул ук тыкрыкта — Ш. Мөхәммәдев өендә күрә, аның уллары — «гаилә ансамбле» башкаруында яңгыраган татар халык көйләрен күңеленә сеңдерә.

Язмыш юмартлыгы моның белән генә чикләнми. Бөек революция көннәре якынлашканда шәһәрдә «Музыка-драма» җәмгыяте оеша. «Акмый тынчып тора торган кечкенә күлне — шәрык музыкасын — олуг сәнаигы нәфисә диңгезенә тоташтыру өчен, Оренбург мөселман музыка вә драма җәмгыяте кечкенә бер канау казырга кереште: музыка мәктәбе ачты. Хезмәт зур. Көч аз, ләкин ул... кибеп бетәчәк түгел»,— дип музыка сәнгатебезнең якты киләчәгенә зур өмет баглап язган бу турыда күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими. Җәмгыятьнең идарәсендә шәһәрнең танылган кешеләре, язучылар, мәгърифәтчеләр: Шәриф Камал, Фатих Кәрими, Харис Фәйзи, Заһид Нуркиннар. Җәмгыять тырышлыгы белән 1918 елда тарихта беренче буларак «Шәрык музыка мәктәбе» ачыла.

Музыка сөюче татар яшьләрен үзенә тарткан сәнгать, мәгърифәт учагы балаларны да читкә какмый, әлбәттә. Туры килеп торуын гына кара. Нәкъ менә Җәүдәтнең күңеле хис-моң белән сугарылган вакытта Оренбургка яшь композитор Салих Сәйдәшев килә. «Бүгенге көн кебек хәтеремдә,— дип искә алган соңыннан Җ. Фәйзи.— 1920 нче елның көзендә булса кирәк, мин, иптәшләрем белән, кичләрен шунда (музыка мәктәбенә — Җ. М.) барып, зәңгәр күзле бер матур яшь егетнең трубада уйнап һәм шул ук вакытта дирижерлык итеп, тынлы оркестр белән «Хәйбулкин», «Тукай» маршларын яңгыратканын тыңларга ярата идем. Ул сөйкемле абый татар халкының булачак беренче профессиональ композиторы Салих Сәйдәшев иде. Мин 1921 нче елда шул мәктәпкә укырга кергәндә, ул аның директоры иде». Музыкаль белемне Җәүдәт беренче булып Хәлимә Ибраһим кызы Терегулованың (Булатова) фортепьяно классында ала. Халык җырларына, музыкага мәхәббәт тәрбияләүдә агасының, атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзинең дә өлеше зур булган, әлбәттә.

Дөрес, Оренбург музыка мәктәбен тәмамлауга ук Җәүдәт Фәйзи ныклап торып музыка белән шөгыльләнә башламый әле. Мөстәкыйль иҗатка омтылыш яшь Җәүдәтне иң элек әдәби әсәрләр язуга этәрә. Аның унбиш яшендә язган «Күз яшьләре» драмасы үз вакытында Оренбург татар драма театры сәхнәсендә куела. Музыканы гомерлек юлдашы итеп сайлау фикеренә ул соңрак, Казанга китеп университетның юридик факультетында укыган чорларда, мәшһүр Такташ сүзләренә язылып популярлык казанган «Урман кызы» кебек җырлары иҗат ителгәч киләчәк. Әмма аның күңелендә туган теленә, җырга-моңга мәхәббәт нәкъ менә Оренбургта — даладагы калада бөреләнә башлый.

## УФАДА ТАТАР КУЛЬТУРАСЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Соңгы елларда журналыбызда Казан, Уральск, Оренбург калаларындагы культурабыз ядкарьләренә багышланган рәсемнәр һәм мәкаләләр биреп барылуы укучыларда зур кызыксыну уятты.

Әлеге традицияне дәвам итеп һәм күпсанлы теләкләрне искә алып, киләсе ел дәвамында «Казан утлары»нда Уфадагы татар культурасы истәлекләре турында сөйләүче материаллар сериясе басылачак.

## Флера Ганиева

# ЙӨЗ ЯШЬЛЕКЛӘР БУЫНЫННАН МӘХМҮТ ГАЛӘҮ

Мәхмүт Галәүнең туган урыны — Казан арты, Тукайның балачагы үткән төбәк — Арча ягы, Ташкичү авылы. Туган елы 1887 ел дип билгеләнә иде. Соңгы вакытта метрика дәфтәрләреннән аның туган елы 1886 ел 8 ноябрь икәнлеге ачыкланды. (ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 4 ф., 204 эш, 27 б.) Әтисе, Шиһаб Мәрҗанинең туганнан туган кардәше Галәветдин хәлфә, аны укырга-язарга өйрәткән беренче укытучысы була. Унбер яшендә Мәхмүт Казанның кадими бер мәдрәсәсендә укырга керешә. Бу мәдрәсә аңа нинди белем биргән, ни дәрәҗәдә күзен ачкандыр — анысын әйтүе кыен, шулай да ул бит әле, ераграк булса да, Шиһаб Мәрҗани туганы, аның фамилиясен йөртә. Аның яшьтәше Фатих Әмирхан Ш. Мәрҗанине үзенең фикерен уяткан шәхесләрдән саный, гомумән, бу исем танылган, яшьләрне дулкынландырган шәхесләрдән берсе була.

Казанда төпләнергә мөмкинчелек булмау сәбәпле, 17—18 яшьлек Мәхмүт 1903 елда Әстерхан шәһәренә китә, татар бистәсендә балалар укыта башлый. Көч, энергия ташып торган, хыял-өметләрнең иң канатлы чагы һәм революция алды. Баку, Әстерхан шәһәрләре кайнап тора, РСДРПның Әстерхан комитеты актив эш алып бара. Комитет каршында күренекле революционер Зариф Садыйков җитәкчелегендә татар группасы оештырыла. Мәхмүт Галәү, аның члены буларак, листовкалар язу, бастырып тарату, митинглар оештыруда актив катнаша. Шәһәр читендәге татар бистәсе кайнап торган бер учак рәвешен ала. Алдынгы карашлар хакимлек иткән мәктәп, яшерен һәм легаль типографияләр шунда урнашкан.

Язучының үз язмаларыннан һәм Әстерхан дәүләт архивындагы документлардан күренгәнчә, Зариф Садыйков Мәхпүт Галәүгә политик аң, аның дөньяга карашларына юнәлеш биргән остаз була.

Мәхмүт Галәүнең каләме беренче чыныгуны «Туп» журналында ала. Шунысы игътибарга лаек — гаять дәрәҗәдә кыю, революцион эчтәлекле мәкаләләрдән торган журнал 1907 елның мартында чыга башлый. Беренче санына ук арест салына, һәм жандармерия белән губернатор арасында язышу башлана. Алар шулай бик «оператив» язышкан арада, «Туп»ның тагын ике саны чыгып өлгерә. Бу юлы инде журналны бөтенләйгә ябалар, редакторын төрмәгә утырталар. «Туп» кемгә атачагын ачыктан-ачык санап чыга — хөкүмәтнең егылырга торган иске крепостена, реакциягә, изүчеләргә. Мисал өчен берничә өзек китерү дә җитә: «Хөкүмәт халык белән идарә итә торган дилбегәне кулыннан ычкындырмаска тырышып, менә өч ел инде халык канын коя, аны бөлгенлектә тота. Байлар һәм помещиклар мәнфәгатен генә кайгыртып, крестьяннарның чөбен урынына кырылуына исе дә китми.» Яки Тукайның Дәүләт думасына мөнәсәбәте белән нәкъ аваздаш мәкалә: «Государственная думадагы татар фракциясенең дә өзгәләнә башлавында һич шөбһә юктыр. Чөнки эшче берлән бай, игенче берлән алпавыт һичбер вакытта да бер табактан аш ашый алмыйдыр».

Дин сабагы укыту урынына, атеистик пропаганда алып барганы өчен Галәүне укытудан чыгаралар. Реакция елларында революционерлар кулга алына, эзәрлекләнә. Беркадәр вакыт полиция күзәтүе астында яшәгәннән соң, М. Галәү Оренбургка күчеп китә.

Казан, Оренбург, Әстерхан, Уфа — мәгариф һәм культура учаклары. Һәрберсендә маяк булып янып торган әдипләр бар. Кызыклы картина: Беренче рус революциясе бу шәхесләрне бердәй күтәрә — Казанда Фатих Әмирхан, Уральскида Тукай, Уфада Ибраһимов. Алар бер юлдан йөриләр. Г. Ибраһимов 1906 елда Оренбургтан Уфага китә, соңрак Әстерханда нугай татарларының балаларын укыта. Вакытлар гына туры килми, әмма

бер юлдан йөриләр, бер-берсен беләләр, әсәрләре белән таныш булалар һәм матбугат аша мөнәсәбәт җепләре, бәйләнешләр сузыла.

Мәхмүт Галәү Оренбургка килгәч тә матбугат белән араны өзми, киресенчә, максатлы бер юнәлеш алып, иҗатын активлаштыра бара: Хөсәеновлар типографиясендә наборщик, корректор; китап кибетендә сатучы һәм революция алды елларында танылган журналист, публицист. Тукай һәм Әмирханнар үткән таныш юл, матбугатның иҗат һәм көрәш мәйданы икәнлегенә бердәй ышаныч, бер үк максат.

Карашлар уртаклыгы М. Галәү чыгарган «Кармак» журналында да (1915—17 еллар) ачык күренә. Беренчедән, «Кармак»ка кемнәр эләгә: фанатик руханилар, халык хезмәте белән кесә калынайтучылар, искелеккә ябышып яткан мөгаллимнәр, эшлексез «җәмгыять хадимнәре». Икенчедән, «Кармак»ның иң явыз дошманы — «Дин вә мәгыйшәт» журналы. Өченчедән, әдәбиятка күзәтү, тәнкыйть мәкаләләрендә зәвыклы, прогрессив карашлар. Журнал татар әдәбиятының иң зур фигуралары, чорның олы әдипләре итеп Ф. Әмирханны, Г. Ибраһимовны таный. «Ф. Әмирхан татар яшьләре өчен бер булган, һич тиңдәше булмаган бер кешедер» дип билгеләп үтелә журналда. Г. Ибраһимов турында да «һәм шагыйрь, һәм әдип, һәм социолог, һәм тәнкыйтьче — менә шул кадәр талант иясе» дип языла «Кармак» сәхифәләрендә. Тукай поэзиясе турындагы фикерләр көрәшенә дә М. Галәү икеләнүсез килеп кушыла: «Г. Тукайның космический таланты хакында әйтми калу, стилендәге музыканы яшерү, аның тәрҗемә гамәлләрен эзләмәү, аның матур хыялый ләүхәләрен күрмәү мөмкин түгел... Иң югары дәрәҗәдә куәтле хыялны, иң тирән кайнар хисне, иң матур табигать күренешләрен күрми калдырып та, ваклап та булмый». Журнал Тукай поэзиясенә, аның шәхесенә мөнәсәбәттә пакь күңелле булырга чакыра.

Күргәнебезчә, Мәхмүт Галәү әдәбиятка иҗтимагый-политик карашлары ачык формалашкан, әдәби хәрәкәтне объектив бәяли һәм үз фикерләрен кыю яклый алырлык шәхес булып килеп кушыла. Журналист буларак эшчәнлеге 1904 елдан «Шәркый рус» газетасында башлана. «Туп» һәм «Кармак» журналларын чыгара. Октябрь революциясеннән соң Халык мәгарифе (Уфа, Оренбург) өлкәсендә, нәшрият һәм әдәбиятны оештыру буенча җаваплы урыннарда (Оренбург, Мәскәү) эшли. Язучылык эше белән генә шөгыльләнгәндә дә ул актив җәмәгать эшлеклесе булып кала: язучыларның Мәскәү комитеты члены, ревизия комиссиясе әгъзасы, үзәк әдәби кабинетта консультант, «Коммунист» газетасы каршында әдәби тел түгәрәгенең җитәкчесе.

Мәхмүт Галәүнең иҗат активлыгы да зур ихтирам тудыра: утыздан артык әдәби әсәр, шуларның уналтысы революциядән соңгы чорда язылган. Дистәдән артык хикәясе «Качу» (1926), «Төеннәр» (1928) җыентыкларында һәм матбугат битләрендә басыла, берничә повесте дөнья күрә.

Китап итеп басылган «Салам торханнар» (1925) һәм «Пугач явы» (1926) тарихи пьесалары һәм шул чорда Казан, Мәскәү сәхнәләрендә куелган комедияләре («Курчак туе», «Иван баҗай» һ. б.) шулай ук аның күпкырлы художник булуы турында сөйли.

Рус әдәбияты белән бәйләнеш Мәхмүт Галәү иҗатында аеруча бер үзенчәлеккә ия. Беренчедән, революциягә кадәрге чорда ук ул актив рәвештә тәрҗемә эше белән шөгыльләнә — Пушкин, Лермонтов шигырьләрен тәрҗемә итеп «Ник язылганнар» исемле җыентыгына урнаштыра. Л. Толстойның «Хаҗи Морат» һәм «Крейцер сонатасы» әсәрләрен тәрҗемә итә. Художниклык таланты үсүдә бу төр хезмәтнең роле, һичшиксез, зур була. Икенчедән, Мәскәүдә яшәгән татар язучысына 30 елларда үз әсәрләрен татар телендә бастырып чыгару шактый катлаулы бер хәлгә әйләнә һәм аның зур күләмле әсәрләре — романнары — рус теленә тәрҗемә аша гына дөнья күрәләр. Ике телне дә яхшы белгән М. Галәү романнарын рус теленә үзе тәрҗемә итә. Мәхмүд Максуд, Гомәр Гали, Шамил Усманов, Муса Җәлилләр романнарның шул тәрҗемә вариантларына югары бәя бирәләр һәм «Федерация» нәшриятына язылган эчке рецензияләрдә оригинал нөсхә турында да сүз алып баралар.

Мәхмүт Галәүнең иҗат биеклеге, талант көче тулысынча «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнарында чагыла. Аның төрле өлкәләрдәге эшчәнлеге, хезмәтләре, туктаусыз эзләнүләре — романнарына алып килгән сукмаклар була.

Татар халкының тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешен бөтен нечкәлекләрендә чагылдыра алу, иҗтимагый катлауларны, кеше психологиясен анализлау көче аңа тормыш тәҗрибәсе аша һәм тормышны фән өйрәнгән кебек системалы, максатлы өйрәнү нәтиҗәсендә туплана. Шуңа күрә дә Мәхмүт Галәү татар халкының тормышы, дөньясы, тарихы дигән төшенчәләрне сәнгать образына әйләндерә алган, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салган. Әсәрләре аша ул киң колачлы фикер иясе, яза торган материалын энциклопедик дәрәҗәдә яхшы белгән, өйрәнгән әдип булып күз алдына баса. Моны аның романнары гына түгел, бөтен иҗаты раслап тора.

М. Галәүгә хас тагын бер сыйфат — аның иҗатындагы тарихилык. 1909 елда Оренбургта ул «Папалар вә муллалар, яхут Ян Гус» дигән публицистик хезмәт тәрҗемә итә.

Ян Гус — чех халкының патриоты, реформация җитәкчесе, милли азатлык хәрәкәтен оештыручы. Прогрессив карашлы галим (ул озак еллар Прага университетының ректоры булып эшли) крестьян һәм һөнәрчеләр интересын кайнар яклаучы халык көрәшчесе Ян Гус Урта гасырның иң зур еретикларыннан берсе буларак утта яндырыла. 1369—1415 елларда яшәгән бу тарихи шәхес көрәш рухы, гадәттән тыш язмышы белән М. Галәүне соклandырган дип уйлый алабыз.

Аның игътибарын җәлеп иткән икенче тарихи шәхес — Е. Пугачев. Шулай ук тарих, көрәш, зур шәхес һәм гадәттән тыш көчле драматик финал. «Пугач явы» пьесасында шул чор картиналары, вакыйгалары шактый тулы булып күзаллана.

М. Галәү романнарының нигезенә салынган вакыйгалар, фактик материал шулай ук татар халкы тормышының тарихи сәхифәләреннән гыйбарәт: 1887 елгы ачлык фаҗигасе һәм ул китереп чыгарган үзгәрешләр; 1897 елгы халык санын алу һәм шуңа бәйләнешле баш күтәрүләр; чарасызлыктан бәргәләнгән халыкның бер төркеме үткән фаҗигале юл — Төркиягә күчеп китү, андагы тормыш. Өченче һәм дүртенче кисәкләрдә автор 1905 һәм 1917 елгы революцияләрне тасвирларга теләгән, шуны планлаштырган була. Язылып бетмәгән әсәрләр, өзелгән гомерләр. Бу көннәрдә без шул турыда да уйланабыз. Булган байлыкны туплау, җыеп бастыру, югалганнарын эзләү эше дәвам итә.

Укучы кулында, китап киштәләрендә Мәхмүт Галәүнең рус һәм татар телләрендә бастырган «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» тарихи романнары.

Йөз еллыгы уңае белән Татарстан китап нәшрияты хикәяләр һәм пьесаларын туплап «Төеннәр» исемле җыентык бастырып чыгарды. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты әзерләп бастыра торган «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтнең дүртенче томына М. Галәүнең иҗаты турында бүлек кертелде. М. Галәү иҗаты мәктәпләрдә һәм вузларда өйрәнелә. Бу фактлар бай һәм үзенчәлекле мирасның әдәбият тарихында тәкъдир ителүе, рухи байлык булып яшәве турында сөйли. Әдипнең иҗат мирасын туплау һәм өйрәнү эше дәвам итә.


## ХӨРМӘТЛЕ АТА-АНАЛАР!

Улыгызга яки кызыгызга Туган илгә, туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, Ватанга бирелгәнлек хисләрен тагын да ныгытырга ярдәм итә торган китап бүләк итәсегез киләме сезнең? «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасының еллык төпләмәләрен нәкъ менә шундый китап белән чагыштырырга мөмкин. Бу китапларда — яшь ленинчыларның матур-матур эшләре, уйхыяллары, балачакның иң татлы мизгелләре. Монда язучыларыбызның һәм шагыйрьләребезнең балаларга кешелеклелек, игелеклелек дәресе бирә торган иң яхшы әсәрләре.

«Ялкын» журналына да, «Яшь ленинчы» газетасына да илебезнең теләсә кайсы төбәгендә язылырга мөмкин.

«Ялкын»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы —73582, бер елга язылу бәясе —2 сум 80 тиен.

«Яшь ленинчы»ның индексы —54124, бер елга язылу бәясе —1 сум 8 тиен.

# ГАШЫЙК БУЛУ БӘЛАСЕ

*Киләсе елда да журнал редакциясе укучыларны «Әдәби мирас» рубрикасында күпгасырлы әдәбиятыбызның күренекле ядкарьләре белән таныштырып баруны күздә тота. Шуларның берсе — XVIII гасыр татар прозасының гүзәл үрнәге булган хикәятләр җыентыгы — «Мәҗмугы-л-хикәят». Зур күләмле бу кульязма китапка сюжетлары бөтен Көнчыгышта һәм Европада популяр булган, берсеннән-берсе мавыктыргыч 33 хикәят теркәлгән. Җыентык 1775 елда Себердә, Тобол губернасы Тара өязендә, бараба татарлары арасында яшәгән Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани тарафыннан төзелгән һәм күчереп язылган. Мөхәммәдрәхим үзе Татарстанның хәзерге Арча районы Ташкичү авылы кешесе.*

*Гыйбрәтле язмышлы бу китап ерак юллар үтеп, Мөхәммәдрәхимнең туган ягына кайтып җиткән, яратып укылган, күчерелгән. Ташкичүнең күршесе генә булган Кысна авылыннан табылып, 1963 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивына тапшырылган.*

*Җыентыктагы хикәятләр эчтәлекләре һәм төзелешләре белән бөтен дөньяда мәшһүр «Мең дә бер кичә» хикәятләренә охшаган: шул ук төрле гаҗәеп маҗаралар, мәхәббәт вакыйгалары, яхшылык һәм яманлык көрәше... Әмма «Мең дә бер кичә»дән аермалы гына түгел, хәтта капма-каршы буларак, «Мәҗмугы-л-хикәят» тә хатынкызларның хыянәтләре түгел, ә төрле катлаулы, авыр хәлләрдә дә үз-үзләрен саклап, мәхәббәтләренә, сөйгән ярларына тугрылыклы булып калулары сурәтләнә.*

*Без «Шаһ кызының юлчыларга сөйләгән хикәяте»ннән өзек тәкъдим итәбез.*

Кыз егетләргә әйтте: «Әгәр мин башымнан кичкәннәрне ул бичара картның хакы өчен сөйләсәм, ярармы?»— диде. Егетләр: «Хөкем сезнеке»,— диделәр. Кыз сүз башлады: «Мин унөч яшемдә идем. Бер көн базар уртасыннан үтеп бара идем. Бер тегүченең улын күрдем, остаханәдә бер нәрсә тегеп утыра. Күрүем белән чын күңелемнән гашыйк булдым, шулкадәр: аякларым хәлсезләнде, остаханәдән аягымны алырга көчем калмады. Берничә кәнизәк һәм хадимнәр янымда иделәр. «Базарда рисвай булам» дип, йөз хәйлә белән үземне туктаттым.

Өйгә кайттым, әмма әүвәлге хәлем калмаган иде инде. Гыйшык уты көннән-көн газаплап, күңелемне учагыннан чыгарып, ялкыны күккә күтәрелде, минем намус һәм сабыр-түземлегемне көйдерде, ахры, алла белән ант итәм, сөягемә кадәр җитте. Тәкатьсез булып, серемне сөт анама әйттем. Ул әйтте: «Моңа чара булыр, син әле яшь, гыйшык тотуны әле белмисең»,— дип, мине күп үгетләде, шелтәләде. Сөт анамның сүзен колагыма элмәдем.

Кыскасы, бер хадимгә тегүче егетнең билгеләрен әйттем, алып килергә җибәрдем. Хадим барып, алып килде. Мин аның йөзен һәм гәүдәсен күргәч, һушымнан китә яздым, мең хәйлә белән үземне туктаттым. Төрле төстәге беркадәр парчаларны алдына куеп әйттем: «Берничә күлмәклек кис»,— дип. Үтенечем шул иде, «кеше начар уйламасын» дип, шул сылтауны таптым.

Ул — яхшы холыклы, әдәпле егет оялып һәм тарсынып кына ул парчаларны кисте, эшеннән бушагач, китәргә теләде.

Мин әйттем: «Безнең гадәт һәм йолабыз шундый: кем дә кем безнең сараебызга килсә, ризыктан авыз итми китмәс»,— дип, алдына ризык китереп куйдым. Ул, башын иеп, әдәп белән ашамлыктан авыз итә башлады. Мин итне үз кулым белән кисеп, алдына куяр идем. Ул егет бу тыйнаксыз хәрәкәтләрне күреп, башын күтәреп, «ләхәүлә» укыр иде.

Шул рәвешчә, өй аулак иде. Берничә кисәк авызына салдым, үземә таба тартып һәм кочаклап, шикәр иреннәреннән бер үптем. Ул диндар, тыйнак егет минем бу әдәпсез эшләремне күргәч, әйтте: «Әй, ай йөзле хур кызы! Ходайдан курыкмыйсыңмы, мондый яман хәрәкәтләр кыласың? Ул серләрне һәм бөтен яшерен нәрсәләрне белүче күреп тора бит». Минем ачуым килде, «куркытам» дип, пычак белән селтәндем. Казага каршы, ул мескенең бугазына тиде, шунда ук егылды, җан бирде.

Мин бу фаҗигале вакыйганы күрдем, эчемдә ут кабынды, төтене тамагымнан чыкты. Хәйран булып, борчылып, шунда ук сөт анамны чакырдым, вакыйганы белдердем...

# БЕЗНЕ КАЙДА КҮПМЕ УКЫЙЛАР

«Казан утлары» журналының быелгы 1 саны республикаларда һәм өлкәләрдә түбәндәгечә таралды:

БАРЫСЫ — 65000

РСФСР — 59275
Татарстан — 28561
Башкортстан — 17280
Үзбәкстан — 2278
Казахстан — 2293
Оренбург — 1845
Свердловск — 1581
Пермь — 1265
Төмән — 1195
Чиләбе — 977
Куйбышев — 738
Ульяновск — 712
Удмуртия — 571
Мәскәү — 457
Кемерово — 382
Киров — 365
Коми — 349
Кыргызстан — 346
Чувашстан — 312
Таҗикстан — 309
Украина — 304
Горький — 298
Мари — 288
Красноярск — 229
Төрекмәнстан — 191
Омск — 170
Курган — 141
Пенза — 136
Якутия — 136
Әстерхан — 117

Саратов — 100
Иркутск — 99
Томск — 90
Сахалин — 64
Новосибирск — 63
Магадан — 54
Чита — 52
Ленинград — 47
Хабаровск — 43
Мордовия — 41
Мурманск — 37
Ростов — 37
Приморье — 35
Камчатка — 33
Әзербайҗан — 32
Бурятия — 31
Башка төбәкләрдә — 366

**Татарстан районнарында**

Арча — 1579
Әлмәт — 1331
Азнакай — 1323
Саба — 1125
Кукмара — 1090
Сарман — 1047
Мөслим — 953
Актаныш — 945
Балтач — 929
Түбән Кама — 817
Апас — 791
Октябрь — 781
Мамадыш — 758
Буа — 589
Лениногорск — 575
Баулы — 571
Әгерҗе — 555
Чистай — 540
Тукай — 536
Зәй — 473
Зеленодольск — 469
Әлки — 457
Балык Бистәсе — 429
Минзәлә — 416
Питрәч — 413
Биектау — 391
Бөгелмә — 340
Кама Тамагы — 332
Чирмешән — 278
Чүпрәле — 261
Аксубай — 249
Яңа Чишмә — 206
Лаеш — 201
Алексеевский — 199
Куйбышев — 166
Тәтеш — 157
Алабуга — 139
Менделеев — 107
Югары Ослан — 42

Шәһәрләрдән:
Казан — 3732
Брежнев — 2279

Журналыбызны чит илләрдә (АКШ, ГФР, Финляндия, Англия, Болгария, Монголия, Австралия, Голландия, Көнбатыш Берлин, Төркия, Франция) 50 данә алалар.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1988 ЕЛДА

## ЯКУБ ЗӘНКИЕВ.

### «ИРТӘШ ТАҢНАРЫ».

*Роман.*

Тарихта мәгълүм булганча, Россиянең соңгы патшасы Николай II Вакытлы хөкүмәт тарафыннан Тоболга сөрелә. Әсәр аның губернатор йортында рәхәт чигеп яшәве, челтәрле балконга чыгып, халык каршында үз-үзен яхшатлы итеп күрсәтергә тырышу күренешләре белән башланып китә. Ләкин бу хәл озакка бармый, революцион кузгалыш, иске һәм яңа тормыш көчләренең бәрелеше халыкның да, патшаның да язмышын бөтенләй тамырдан үзгәртеп ташлый...

Романның баш герое — бала чагында ялчы булып эшләгән, үсмер чагында сәүдә мәктәбендә укыган, тора-бара большевиклар сафына баскан гайрәтле, кыю, саф күңелле ир-егет Мөхәммәт Уразаев. Себер ягында яшәгән һәм эшләгән кеше буларак, автор тормыш материалын әйбәт белә. Әсәрдә, сыйнфый бәрелешләр кискенләгеннән тыш, катлаулы мәхәббәт хәлләренә һәм Күчем ханның Себердә күмелгән алтын-көмешләрен эзләү мажараларына да киң урын бирелгән.

## МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИН.

### «ИЛЧЕГӘ ҮЛЕМ ЮК».

*Тарихи роман.*

Язучы М. Хәбибуллин әдәбият сөючеләргә «Кубрат хан» дигән тарихи роман бүләк иткән иде инде. Укучылар әлеге әсәрне яратып кабул итте.

Кубрат хан төзегән Бөек Болгар дәүләте таркала, сибелә, юкка чыга, әмма халык кала, төрлесе төрле җирдә булса да, тел вә гореф-гадәтен саклап яши бирә. Әйтик, VII гасырның икенче яртысында Кубрат хан улы Кодрак Идел буена алып килгән болгар-төрки халкы ыруы X гасырда мөстәкыйль Болгар дәүләте төзи. Тарихи чыганаклар раславынча, биредә халыкара сәүдә эшләре гөрли, культура зур үсеш ала, шәһәрләр төзелә. Болгарлар дөньяда беренче тапкыр буларак чуен коя башлыйлар.

Романдагы вакыйгалар XIII гасыр башына карый. Салим хан катына Үргәнечтән илче килеп төшә. Рәсми эшләреннән тыш, аның әле үзе генә белгән яшертен максаты да бар — ул чуен коюның серләрен алып китәргә тиеш. Болгар ханы, чуен коючылар яшәгән Шайтан каласына бару өчен, илчегә ярлык бирә... Татар халкында, илчегә үлем юк диләр диюен, ләкин бу һәр очракта да шулай микән?

## ВЕНЕРА КАСЫЙМОВА.

### «ӘЛЛӘ ЯЗМЫШЫМ, ӘЛЛӘ ЯЛГЫШЫМ».

*Повесть.*

«Мине карурманга кертеп адаштырдылар...»

Повесть әнә шундый сүзләр белән башланып китә. 17 яшьлек кызның — кибетче Динараның уй-кичерешләрен, борчуларын, тормышта үз-үзен табарга омтылышын автор шушы бер җөмләгә сыйдырган.

Яшьлек — канатлы, дәртле, мавыктыргыч дәвер, гомернең кабатланмас иң гүзәл өлеше. Яшьлек дөньяга сафлык, ышаныч һәм өмет тулы күзләр белән карый. Тормышта үз урыныңны, үз өлешеңә тигән беренче мәхәббәтеңне ничек табарга? Кешеләрнең яхшымы, начармы икәнлеген ничек, каян белергә? Ялгышларсыз яшәү мөмкинме...

Әле тормышка аяк басып кына килгән яшь кыз өчен яшәү, хезмәт, кешеләр — серле карурман кебек. Ул күе чытырманлыкларда адашып калмасмы, кыенлыклар каршында җебеп төшмәсме? Әсәр белән танышканда, укучы әлеге сорауларга җавап эзләячәк.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

17 июльдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышы булып узды. «КПСС Үзәк Комитетының июнь (1987 ел) Пленумы карарлары яктылыгында татар әдәбияты алдында торган бурычлар турында» доклад белән «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис чыкты.

Фикер алышуда язучылар Р. Хәмид, Д. Зөбәерова, Д. Вәлиев, Б. Камалов, Н. Дәүли, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мингалим һ. б. катнашты.

## СӘНГАТЬ БӘЙРӘМЕ

27 июньдә профсоюзларның Татарстан өлкә советы, ТАССР Культура министрлыгы, Язучылар, Композиторлар, Художниклар союзлары Казанда «Уйнагыз, гармуннар!» дип исемләнгән халык иҗаты бәйрәме үткәрде.

Бәйрәмне ачу тантанасы иртәнге сәгать унда Татарстан Художниклар союзы каршындагы мәйданда булды. Бирегә килгән кешеләр республиканың профессиональ һәм һәвәскәр рәссамнары белән очраштылар. Күргәзмә-ярминкәне карадылар. Шунда ук композиторлар, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, Казан курчак театры артистлары, музыка мәктәбе укытучылары, үзешчән сәнгать осталары чыгышы булды. Аннан соң бәйрәм Комлев урамындагы Язучылар союзы йорты янына күчте. Урамда ясалган сәхнәдә әдипләр Ә. Исхак, Р. Фәйзуллин, Ә. Гаффар, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов яңа әсәрләрен укыдылар. Кичке якта бәйрәмдә катнашучыларның театральләштерелгән тантаналы марш-парады, «Уйнагыз, гармуннар!» дигән тамаша башланды. Ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасы каршындагы мәйданда үтте.

Бу зур бәйрәмдә йөзләгән гармунчы, җырчы, биюче, фольклорчы, хор коллективлары, үзешчән сәнгать осталары һәм профессиональ артистлар катнашты.

Тамашачылар арасында Польша Халык Республикасының Ломжа воеводалыгыннан Татарстанга дуслык визиты белән килгән кунаклар да бар иде.

Ике мең ярым һәвәскәрне берләштергән олы тамаша халык бәйрәменә әйләнде.

## ПУШКИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

6 июньдә Казанда А. С. Пушкинның тууына 188 ел тулуга багышланган беренче шигырь бәйрәме үткәрелде.

Казанлылар, әдәбият сөючеләр иртәнге сәгать 10 да Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы янындагы Пушкин һәйкәле тирәсенә җыйналдылар. Бәйрәмне ТАССР культура министры М. М. Таишев ачты. Пушкин иҗатының рухи тормышыбызда урыны турында язучы Р. Мостафин сөйләде. Шигырь бәйрәмендә шагыйрьләр Зөлфәт, Р. Харис, Н. Беляев, Р. Кожевникова, М. Зарецкий һ. б. үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Пушкин әсәрләрен татар һәм рус телләрендә мәктәп укучылары, артистлар, шагыйрьләр Ә. Исхак, Р. Гатауллин укыдылар. Бу тантаналы митингта ТАССР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре Д. Х. Зарипова, О. В. Морозов, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова һәм башка иптәшләр катнашты.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУГАН АВЫЛЫНДА

6 июньдә БАССРның Авыргазы районы Солтанморат авылында Галимҗан Ибраһимовның әдәби йорт-музеен һәм һәйкәлен ачу тантанасы булды. Бу тантанага Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин, әдипләр Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Газиз Кашапов чакырылган иде. Уфадан БАССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Тимер Иосыпов, шагыйрьләр Рафаэль Сафин, Равил Бикбаев, Ирек Кинҗәбулатов, Фәрит Габдерәхимов, филология фәннәре докторы Үзбәк Гыймадиев, скульптор Зилфәт Басыйров, БАССРның Берләштерелгән дәүләт музее директоры Рим Ниязгулов катнашты.

Г. Ибраһимов исемендәге колхоз эшчәннәре кунакларны икмәк-тоз, якты йөз, чәчәкләр белән каршы алды. Колхозның культура үзәге мәйданында Галимҗан Ибраһимов һәйкәлен ачуга багышланган митинг булды.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРЕП

10—12 июньдә Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәрендә Хәсән Туфанга мемориаль такта ачуга багышланган татар әдәбияты көннәре булып узды. Анда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин, язучы Газиз Кашапов, башкорт шагыйре Рафаэль Ҫафин катнаштылар.

Хәсән Туфанның ун елга якын гомере Лысьва шәһәре белән бәйле. Ул атаклы Лысьва металлургия заводында токарь була, Лысьва шәһәрендә татар балалар мәк-

тәбен оештыра һәм анда укытучы булып эшли. Шул чорда алган тәэсирләрен ул «Башлана башлады», «Урал эскизлары» һәм «Бибиевләр» поэмаларын язган чакта файдалана. Хәсән Туфанның исталеген мәңгеләштерү өчен КПССның Лысьва шәһәр комитеты һәм халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты аның истәлегенә мемориаль такта кую турында карар кабул итте. Моннан тыш шәһәрнең бер урамы Хәсән Туфан исемен йөртәчәк.

## ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

23 июньда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, һәм тарих институтында тарихчы, галим һәм әдип Газиз Гобәйдуллинның тууына 100 ел тулуга багышланган киңәйтелгән Гыйльми совет утырышы булды. Утырышта Мәскәү шәһәреннән СССР Фәннәр академиясенең Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Ш. Ф. Мөхәммәдъяров «Г. Гобәйдуллинның татар этногенезы буенча карашлары», Г. Ибраһимов исемендәге Институтның өлкән фәнни хезмәткәрләреннән: тарих фәннәре кандидаты С. Х. Алишев «Г. Газиз тарихчы», филология фәннәре кандидаты М. И. Әхмәтҗанов «Ф. Әмирхан һәм Г. Гобәйдуллин» дигән темаларга докладлар белән чыктылар. Утырышта Г. Гобәйдуллинның улы, биология фәннәре кандидаты Сәлмән Гобәйдуллин әтисе турында истәлекләр сөйләде. Гыйльми совет Г. Гобәйдуллин мирасын өйрәнүне яхшырту һәм аның иҗатын пропагандалау буенча карар кабул итте.

Хәзерге вакытта Институт галимнәре Г. Гобәйдуллин әсәрләренең ике томлыгын хәзерләү өстендә эшлиләр.

## ФАЗЫЛ ТУЙКИН ИҖАТЫН БАРЛАП

18 июньдә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында күренекле фольклорчы, тарихчы һәм педагог Фазыл Туйкинның тууына 100 ел тулуга багышланган утырыш үткәрелде.

Утырышны кереш сүз белән филология фәннәре докторы Ф. Мусин ачты. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында филология фәннәре кандидаты М. Гайнетдинов сөйләде. «Фазыл Туйкин — фольклорчы» дигән темага филология фәннәре кандидаты Р. Ягъфәров чыгыш ясады.

## МОНГОЛИЯДӘ СОВЕТ КУЛЬТУРАСЫ КӨННӘРЕ

3 июньнән 17 июльгә кадәр Монголиядә барган Совет культурасы көннәрен халыкара күләмдә узган әдәбият-сәнгать сабан туе дип атарга мөмкин булды. СССР Культура министры В. Г. Захаров җитәкләгән делегациядә зур сәнгать коллективлары, күренекле җырчылар, рәссамнар, музыкантлар белән беррәттән Татарстаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин бар иде. Ул күпсанлы әдәби очрашуларда катнашып, татар әдәбияты турында сөйләде, үзенең әсәрләрен укыды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисткасы Әлфия Заһидуллинага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 9 июнь Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының балет солисты Наил Сәрвәрович Сәрвәровка, опера солисты Сәхәбиев Рафаэль Әхмәтовичка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 6 июль Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры хормейстеры Ирнис Әхмәдуллович Рәхимуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 6 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Эстрада музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистларына, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 22 июль Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде:

Ахманов Ринольд Павловичка — әдәби-музыкаль лекторий җырчысы.

Тимергалиева Хәмдүнә Сәетгалиевнага — эстрада бүлеге җырчысы.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Кутуев Рөстәм Гадельшевичка (Рөстәм Кутуйга), Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 22 июль Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

## ТӨЗЕЛЕШ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Кама Аланындагы хәбәрчебез Роберт Талипов белдерүенчә, «Аппаратстрой»ның махсус бригадасы беренче энергоблоктагы реактор бүлеге өчен нигез плитәсен бетонлауны алдан билгеләнгән графикта тәгәлләүгә иреште. Маҗитов, Бурмистров, Сәркиев җитәкчелегендәге монтажчылар реактор бүлегенең стенасына кирәкле җайланмаларны монтажлый башладылар.

Брежнев һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге йорт салу комбинатлары Кама Аланындагы эшләрне еллык планда каралгандагыдан алдарак төгәлләргә кирәк таптылар. Алар Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгын 36 мең квадрат метр торакны файдалануга тапшырып каршыларга теләк белдерделәр.

# ЧУЛПЫ ҖЫРЫ

Талир тәңкә авыр тарта —
Алты мыскылдан арта.

Чулпы, аларны икенче төрле тезмә яки чәч тәңкәсе дә диләр, татар хатын-кызларының милли киемендә аеруча тотрыклы урын били. Борынгы халык җырларында еш телгә алынуы да шул турыда сөйли. Бирегә тагын бер үзенчәлекне әйтми мөмкин түгел: татар бизәнү әйберләренә гомумән алганда да яңгырашлы стиль хас: яка чылбыры, хәситә, алка, шул исәптән, чулпыдагы тәңкәләр, бер-берсенә бәрелеп, үзенчәлекле көй — ягымлы көмеш чыңы тудыра торган булганнар.

Чулпыны, көндәлек бизәнү әйбере буларак, төрле яшьтәге кешеләр йөрткән. Кыз балалар өчен, мәсәлән, махсус кечкенә чулпылар ясалган, җиткән кызлар исә берничә тәңкәле һәм күпсанлы асылма бизәкләр куелганын йөрткәннәр. Өлкән яшьтәге һәм баерак катлаудан булган хатын-кызлар көянтәле чулпыны ярата төшкән.

Толымга төрле зиннәтләр үрү күп халыкларның милли киеменә хас. Әйтик, рус хатын-кызларында тәңкә тезелгән тасма, яисә ялтыравык тукыма белән тышланган өчпочмак рәвешендәге бизәк үрү гадәте яшәп килгән. Ә чулпыга охшаш бизәнү әйберләре исә татарлар белән мәдәни һәм экономик бәйләнештә яшәгән башкортларда, үзбәк һәм казахларда күзәтелә.

Ләкин тикшерүчеләр һәм белгечләр чулпының Идел болгарлары культурасы мирасы икәнен ассызыклап күрсәтәләр. Моны борынгы Биләр шәһәрендә алып барылган казу эшләре вакытында табылган асылма бизәкле, коелган челтәр тәңкәләр дә раслый.

Челтәр тәңкә — чулпыны оештыручы, туплаучы элемент буларак гасырлар буена үзгәрмичә диярлек килә. Бары тик аның формасы гына, ювелирның зәвыгына яки нинди стиль белән мавыгуына карап, вазага яки йолдызга охшаш, я булмаса, калаксыман рәвеш ала.

Металлны бөтереп эшләнгән челтәр тәңкәле чулпы аеруча киң таралган. Аның үзәгенә зур асылташ: алтынсыман кызылсу нур таратучы сердолик, сирәгрәк көмешсыман тау бәллүре яки шәмәхә балкышлы аметист куела. Мондый челтәр тәңкәләр яка чылбыры һәм хәситә кебек бизәнү әйберләрендә дә файдаланыла.

Чулпының төрләре күп: алар бер һәм үзара боҗралар ярдәмендә тоташтырылган ике яки өч челтәр тәңкәдән дә торырга мөмкин. Аларга исә асылма бизәк сыйфатында төрле зурлыктагы көмеш тәңкәләр беркетелә. Моннан тыш берьюлы ике толымга үреләторган көянтәле чулпы да бар.

Чулпы толымга чәчүргечләр ярдәмендә тоташтырыла һәм атлаган саен үзенә хас көй белән чыңлап тора. Борынгылар чулпы чыңы явыз рухларны куркыта дип ышанганнар. Ләкин гасырлар үтү белән аның ул вазифасы онытылган: матурлык, нәфислек, асылташлар уены, зәркән сәнгате осталыгы кебек сыйфатлары беренче урынга чыга барган. «Татар кызын башта ишетергә, аннан соң гына күрергә мөмкин» дигән тәгъбирдә чыңлаучы милли зиннәтләрнең асылы шигъри образ буларак тагын да киңрәк ачыла сыман.

**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.
**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда Л. Н. Толстой һәйкәле.

**Р. МАНСУРОВ** фотосы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезгә менә журналыбызның 9 нчы саны да килеп җитте.
Ә редакция хезмәткәрләре бу көннәрдә инде киләсе ел саннары турында уйланалар.
«Казан утлары» журналы 1988 елда да кызыклы булачакмы?
Нинди яңа әсәрләр белән очрашулар көтә?

# КАЗАН УТЛАРЫ - 88

Редакция хәзинәсендә халкыбызның үткәнен һәм бүгенге тормышын гәүдәләндергән, замандашларыбызның күңелен кузгатырлык шәхесләрне, вакыйгаларны сурәтләгән байтак кызыклы әсәрләр бар:

Хисам Камалов. **Үлгәннән соң яздым.** Роман.
Мөсәгыйт Хәбибуллин. **Илчегә үлем юк.** Тарихи роман.
Җәмит Рәхимов. **Кыядагы чәчәкләр.** Роман.
Якуб Зәнкиев. **Иртеш таңнары.** Роман.
Гомәр Бәширов. **Онытма.** Повесть.
Аяз Гыйләҗев. Яңа повесть.
Роберт Батулла. **Юл буенда зәңгәр чәчәк.** Повесть.
Нәбирә Гыйматдинова. **Ханым-солтаным.** Повесть.
Венера Касыймова. **Әллә язмышым, әллә ялгышым.** Повесть.
Рашат Низамиев. **Фәрит Яруллин.** Повесть.
Заһир Садыйков. **Ясалма чәчәкләр.** Повесть.

# КАЗАН УТЛАРЫ

Редакция өйрәнә башлаган һәм киләчәктә тәкъдим итәргә ниятләгән әсәрләрнең кайберләре:

Атилла Расих. **Елларны чигерсәм.** Истәлек-роман.
Мөхәммәт Мәһдиев. **Ватан турында җыр.** Роман.
Зөфәр Фәтхетдинов. **Үлем элмәге.** Роман.
Шамил Шәйдуллин. **Шөпшә оясында.** Повесть.

Танылган шагыйрьләребез, шулай ук яшь язучылар иҗатына да киң урын биреләчәк.

Тормыш һәм әдәбиятның бәхәсле мәсьәләләре хакында сөйләшү уздырылачак.

Үткән проблемалар күтәргән очеркларны да даими бирү күздә тотыла.

# КАЗАН УТЛАРЫ - 88

Күпләгән укучыларыбызның үтенечен искә алып, журналда татар язма әдәбиятына нигез салучы **Кол Галинең** гүзәл Зөләйха белән зирәк Иосыф арасындагы кайнар мәхәббәтне, катлаулы тормыш күренешләрен тасвирлаган атаклы **«Кыйссаи Иосыф»** дастаны басылып чыгачак.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)